КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Муса ҖӘЛИЛ. Бер үгет. *Шигырь*. 3
Марат КӘБИРОВ. Дәва. *Повесть*. 4
Ләбиб ЛЕРОН. Вакытны шул булмый туктатып... *Шигырьләр*. 40
Рабит БАТУЛЛА. Мур кырылышы. *Кинороман*. 45
МӨҖӘҺИТ. Кабатлансын догалар... *Шигырьләр*. 101
Равилә ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ. Карт шомырт хатирәсе. *Роман*. 104
Нурлан ГАНИЕВ. Зур суларда дулкын биек була. *Шигырьләр*. 150

«АҺ, ТУГАН КАУМЕМ ГАЗИЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА. Килен капкасы. *Хикәя*. 154

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Нәсим АКМАЛ. Бар җырымны илгә багышладым... *(Муса Җәлилнең тууына – 115 ел)*. 164
Нәсим АКМАЛ. Халкым дип янып яшәде *(Рәшит Ягъфәровның тууына – 75 ел)*. 165

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Сәгыйдулла ХАФИЗОВ. Бер бите – Шәрык, бер бите – Гареп... 166

СӘНГАТЬ

Бакырга уелган уйлар... *(Рәссам Александр ИВАНОВ белән Айсылу ИМАМИЕВА әңгәмәсе)*. 168

ҖАНИСӘП – 2021

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Россиядә халык санын алу тарихы. 170

УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

Рәис САФИН. Безнең рухта тау-кыялар биеклеге... *Шигырьләр*. 180

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ 135 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

Ландыш ӘБҮДӘРОВА, Луиза ЯНСУАР. Тукай шәхесенә шәрехләр. *Эссе*. 182

Шаян сәхифә: Илдар КЫЯМОВ. Уены-чыны бергә. 186

«Казан утлары» архивыннан. 162
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 190

КАЗАН УТЛАРЫ
№ 2 (1180) 2021

БАШ МӨХӘРРИР –
Рөстәм Госман улы
ГАЛИУЛЛИН

ИДАРӘ:
Ирада Әюпова
Разил Вәлиев
Рәдиф Гаташ
Искәндәр Гыйләҗев
Айрат Зарипов
Дания Заһидуллина
Илгиз Зәйниев
Илфак Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Газинур Морат
Рүзәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Айдар Сәлимгәрәев
Равил Фәйзуллин
Илсур Һадиуллин
Данис Шакиров
Ленар Шәех

Баш мөхәррир урынбасары: **Вакыйф Нуриев.**
Җаваплы сәркатип: **Ландыш Әбүдәрова.**
Бүлек мөхәррирләре: **Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**
Мөхәррирләр: **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Илгизә Сабирова.**
Сайт мөхәррире: **Ләйсән Зарипова.**
Исәп-хисап бүлеге: **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
Машина йөртүче: **Наил Кадыйров.**

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).
Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).
Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).
Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.01.2021, график буенча 29.01.2021, басылып чыгу вакыты 03.02.2021.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-250. Тираж 7865.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2021 ел

Муса
Җәлил

БЕР ҮГЕТ

(Кешелек турында)

Мин күп күрдем филдәй кешеләрне,
Киң күкрәкле, тимер бәдәнле.
Тик күрәсе иде эше белән
Кеше булган иң чын адәмне!

Кем сокланмас көчкә, тимер сынса
Һәм су чыкса баскан эзеңнән.
Тик ни файда, көчең филдәй булып,
Эшең булса чыпчык тезеннән.

Эзе калсын керсез намусыңның,
Ни үтсә дә синең кулыңнан.
Көчлелегең белән горурланма,
Кешелегең белән горурлан!

Һәр адымыңда синең туры акыл,
Көчле йөрәк эзен күрсеннәр;
Кылыч белән түгел, турылык һәм
Чынлык белән көчле кешеләр!

Син яшәмә җирдә файдасыз бер
Түмгәк булып тигез урында;
Янып калсын гомерең маяк булып,
Үзеңнән соң килгән буынга!

Утта булган балчык кире купмас,
Эштә булган тимер тутыкмас.
Эш күрсәткән ирне ил онытмас,
Каберенә эзне суытмас!

1943

Марат
Кәбиров

ДӘВА

ПОВЕСТЬ

1

Башта әнисенең тавышы ишетелде. Тавыш кайдандыр, караңгы билгесезлектән агып чыкты да тылсымлы бер нурга әйләнде, ул нур көчәя барып, бөтен өй эчен яктыртты. Фатирлары матур да, иркен дә, җайлы да иде. Бигрәк тә, качышлы уйнау өчен. Зифа да, Нәфисә дә бу уенны бик яраталар. Кайда качуың, күпме эзләвең артык мөһим дә түгел. Эзләп тапкач, бер-береңнең күзләренә карашып, рәхәтләнеп көлешү кызык. Табышу – шатлык. Иң якын кешеләрең сине эзләп тапса да, син аларны таба алсаң да, олы бәхет икән. Буынсыз булып, бер-берсенә карашып көлешәләр, кайчагында кочаклашып алалар, йә идәнгә тәгәрәп хихылдашалар... Качышлы уены – иң якты, иң ләззәтле уен.

– Кызлар! – диде әнисе, барысы да ишетерлек итеп. – Йокларга әзерләнә башлагыз.

– Ән-ни-и-и... – Нәфисәнең нәзек кенә тавыш белән шулай өздереп әйтүе Зифага кызык иде. – Бер генә тапкыр уйныйбыз да, яме...

– Бер генә тапкыр! – дип кабатлады әниләре. – Самат, табын әзер.

Әтиләре эштән кайткан гына иде әле, ул тагын каядыр җыена. Эше буенча шулай кирәк икән. Ашап ала да юлга кузгала. Әле аны озатканчы, тагын өч тапкыр качышлы уйнарга өлгерәләр. Нәфисә ишек яңагына капланып санарга тотынды:

– Бер, ике, өч...

Зифа алан-йолан каранып алды да шкаф эченә кереп качты. Җайлап урнашкач, ачкыч тишегеннән күзәтергә тотынды. Моннан бөтен нәрсә ачык күренә: фатирга керә торган ишек тә, ишек яңагына капланган Нәфисә дә...

Марат КӘБИРОВ (1970) – *шагыйрь, прозаик; «Онытма таңнарны», «Мәхәббәт яңгыры», «Китап» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Биш кенә яшьлек булса да, башы эшли кызның – апасының башын бутарга тырышып кычкыра:

– Апа, унга хәтле генә саныйм. Качып өлгердеңме?

«Әйе!» – дигәнне көтә. Берәр сүз әйттеңме – тавышка киләчәк. Зифа үзалдына елмаеп куйды. Нәфисәне ярата ул, сеңлесенең бөтен гамәле, үз-үзен тотышы кызык та, кадерле дә булып тоела. Аңа караган саен күңелне ниндидер наз, ягымлылык биләп ала. Рәхәт була.

Унга кадәр санап бетерде дә бик эшлекле кыяфәт белән:

– Алдап булмады моны, – дип куйды. – Ярый... Эзли башлыйм!

Нәфисә алан-йолан каранып алды да кухняга кереп китте. Апасының анда түгеллеген белә инде ул, тик әти-әнисе яныннан урап чыгу, аларның игътибарын татып калуны кызык күрә бугай, эзләүне ул гел шулар яныннан башлый. Зифа сеңлесенең кухняда нәрсә эшләгәнен дә күз алдына китерә ала хәтта. Башта әтисе тирәли әйләнеп чыга.

– Синең артыңа яшеренгәндер әле ул, – дип, мут елмайган була, әтисен кочаклап ала, әтисе аны күтәреп иркәли дә идәнгә куя, аннан соң Нәфисә әнисе янына китә... Шулай кухняны урап чыккач, үзләренең йокы бүлмәсенә кереп шкафларны актара, диван артларын карый... Кайчагында авыз эченнән генә нидер көйли-көйли, ашыкмыйча, хәтта вакытны юри сузып эзли. Жайсызрак урынга качсаң, аякларың оеп бетә. Ә ул суза, апасының түзәлмичә үзе килеп чыкканын көтә... Тик бу юлы Зифаның урыны уңайлы иде, өстәвенә сеңлесен күзәтеп тору мөмкинлеге дә бар.

Көтмәгәндә, ишектә кыңгырау шалтырады. Соң иде инде, мондый вакытта беркем дә килеп йөрми торган иде. Әтисе үзе генә тәүлекнең теләсә кайсы вакытында кайтып керергә яки чыгып китәргә мөмкин. Аның эше шундый. Ә башкалар бу вакытта... Кыңгырау тавышы тагы кабатланды.

– Кем йөри икән? – дигән тавыш ишетелде кухнядан. – Берәүне дә көтми идем.

– Күрше Зоя булырга тиеш, – диде әнисе. – Зифага күлмәкләр алып кайттым, кич кертермен дигән иде.

– Нинди күлмәкләр тагын? Аның киеме юкмы әллә?

– Төркиядән.

Әнисе кухнядан чыгып, йозакны бора башлады. Фатирдан чыккач, тагын бер тимер ишек бар иде әле. Ләкин әнисе фатир ишеген ачу белән аны кемдер өй эченә этәрде. Уртачадан калкурак буйлы, атлетларча таза гәүдәле бу егетне Зифаның беркайчан да күргәне юк иде. Ул бер кулы белән әнисенең авызын каплаган, икенче кулына озын көпшәле пистолет тоткан. Мондый пистолетны Зифа күрше малайларының кулында әллә ничә тапкыр күргән иде инде. «Кара әле, әллә өлкәннәр дә атышлы уйный микән?» – дигән уй ялтлап узды.

– Кем бар? – дигән тавыш ишетелде кухнядан һәм әтисе үзе дә күренде. – Ник дәшмисең?

Егет шундук каршы атлады һәм пистолетын әтисенең маңгаена төзәп атып җибәрде. Әтисенең маңгаенда кызыл нокта пәйда булды, ә аның артындагы стенага кан катыш сыекча чәчрәде. Әтисе акрын гына идәнгә сыгылып төште дә беркадәр тартышканнан соң тынып калды. Әнисе нәрсәдер кычкырырга теләп чәбәләнде. Егет аны ычкындырды һәм икенче

мизгелдә башына пистолет төбәде. Зифа күзләрен четердәтеп йомды. Берни күрмәде, бары тик кабартылган шар шартлагандагы кебек тавыш кына ишетелде. Зифа күзләрен ачты. Пистолет тоткан егет уйнап йөргән кеше кебек түгел иде. Ул кыска кара чәчле, кара кашлы, зәңгәр күзле. Һәм бик җитди. Тирә-якка каранып алды да йокы бүлмәсенә атлады.

– Син кем? – Нәфисәнең куркулы тавышы ишетелде. – Атышлы уйныйсызмыни?

Җавап бирүче булмады. Шартлау тавышы ишетелде. Бераздан йокы бүлмәсе ишегеннән куе кан агып чыкты. Пистолет тоткан егет ашыкмыйча гына бөтен бүлмәләргә күз салып, беркадәр тыңланып торды. Һәм Зифа яшеренгән шкафка карады. Кызның коты алынды, ул кычкырып җибәрмәс өчен иреннәрен тешләде, суламаска тырышты. Пистолетлы егет барысын да үтәдән-үтә күрәдер кебек тоелды, ул әле дә Зифага туп-туры карап торган шикелле иде. Тик ул кыз янына килмәде. Иелеп, идәндә ятканнарның беләкләрен капшап чыкты да канга басмаска тырышып, ишеккә атлады. Тышка чыккач, аны бикләде бугай, йозак борган тавыш ишетелде.

Зифа тиз генә шкафтан чыга алмады. Аның бар дөньясы курку белән тулган иде. Күз алдыннан пистолетлы егет китмәде. Ул чыкмагандыр, кайдадыр яшеренеп калгандыр сыман тоелды. Акрын гына шкаф ишеген ачып җибәргәч тә калтыранып утыруында булды – идән буйлап кызыл келәм сыман җәелгән кан тередер, кызны да үзенә суырып алырдыр төсле иде. Әти-әнисенең катып калган йөзләренә дә, стенага чәчрәгән канлы ит кисәкләренә дә карамаска тырышты. Бу өн түгелдер, өндә мондый нәрсә була алмый. Бу бары тик куркыныч төштер. Кычкырырга кирәк. Кычкырырга. Аның тавышын ишетеп, әнисе килеп җитәр дә уятыр, назлап юатыр, шушы коточкыч күренешләрдән азат итәр. Тик ул кычкыра алмады. Бөтен тәнен калтырау алды, тамагына төер тыгылды. Ул буыла башлады. Теге пистолетлы кеше беркая да китмәгәндер, хәзер ул Зифаның артыннан килеп, бугазыннан алгандыр сыман иде. Кызның бөтен тәне тартышты.

Кинәт кыңгырау шалтырады... Ишектә! Пистолетлы кеше кабат килдеме? Юк, бу ишек кыңгыравы түгел... Бу телефон иде... Өй телефоны шалтырый. Тукта! Шалтырама!.. Бераздан өй телефонына тагын ниндидер тавыш кушылды. Кесә телефоны!.. Өйне яңгыратып шалтыраган ике телефон Зифаны чынбарлыкка тартып чыгарды. Ул күзләрен ачты. Идәнгә күз салды. Бернинди кан диңгезе дә, мәңгелеккә тынып калган өч кеше гәүдәсе дә юк иде. Стеналар да чиста. Зифа инде башка дөньяда, башка чынбарлыкта. Ул җиде яшьлек кызчык түгел, ә утыздан узган ханым...

Зифа мендәргә капланып үксеп елап җибәрде. Әле генә күргәне төш иде. Ләкин бу гади төш түгел, ә кайчандыр булган чынбарлык иде, беркайчан да күз алдыннан китмичә, әледән-әле төш булып хәтерендә кабатланып торган чынбарлык. Җиде яшьлек кызны тома ятим калдырып, тәмуг газаплары аша узарга хөкем иткән ачы мизгел. Мондый бәхетсезлекне Ходай дошманыңа да күрсәтмәсен. Дошманыңа... Юк, күрсәтсен. Дошманыңа күрсәтсен. Аның дошманы – Пистолет Тоткан Егет иде. Кара чәчле, кара кашлы, зәңгәр күзле... Ул әле дә Зифаның күз алдында һәм

ул аны меңнәр арасыннан таный алырлык дәрәҗәдә иде. Тик ничек кенә эзләмәсен, таба алмады. Башкача очратмады. Очратса, таныячак һәм иң аяусыз үчкә дучар итәчәк иде.

Телефоннар һаман шалтырый. Ничек шундый үҗәт булып була икән?!. Алмыйлар икән, димәк, сөйләшергә теләмиләр. Димәк, кешедә сезнең кайгыгыз юк. Ник шуны да аңлый алмыйлар? Зифаның уйларын ишеткәндәй, телефоннар бер-бер артлы тынып калды. Һәм икенче мизгелдә шулай ук бер-бер артлы кабат шалтырарга керештеләр. Алмыйча чара юк иде.

– Алло!

– Зифа Саматовна! Иртә таңнан борчуым өчен гафу итегез... Тик сезгә ашыгыч рәвештә хастаханәдә булырга кирәк.

– Ашыгыч операция? Яхшы. Анализлар...

– Бар да әзер. Сез генә кирәк.

Зифа телефонын куйды да юыну бүлмәсенә ашыкты...

2

Юньле хатын-кыз яхшылап юынып, ашыкмый гына чәчләрен киптереп, бизәнеп-төзәнеп, ким дигәндә, үзенә берәр сәгать вакыт сарыф итеп кенә урамга чыга торгандыр. Тик Зифага андый бәхет сирәк эләгә, соңгы вакытта бигрәк тә: иртәләре ашыгыч чакырулардан тора, үзен затлы хатын-кыз итеп тоярга мөмкинлеге дә юк. Гомумән, хатын-кыз итеп тоярга... Ул – табиб, кичегүне кичерми торган нейрохирургия өлкәсендә эшләүче белгеч. Монда син үзеңне фәкать белгеч итеп кенә тоя аласың. Ашыгыч операцияләрдән башың чыкмый. Пациентның язмышы синең кулыңда була һәм эшең гел уңышлардан гына тормый. Хәтта әйбәт дигән операцияләр дә пациентны тулысынча аякка бастырмый, бары тик үлемнән генә аралап кала...

Юынып, чәчләрен тараган арада кофе кайнап чыкты. Зифа киенә-киенә, ашык-пошык бер чынаяк каһвә эчте дә эшенә кузгалды. Хәтта чынаягын чайкатып та тормады. Кемдер үлем белән тартышып ятканда, аның өендәге тәртип тә, ничек киенүе, нинди кыяфәттә булуы да мөһим түгел иде.

Подъезддан йөгереп чыгып, машинасына утырды да ашыкмаска тырышып кына, йортлар арасыннан үтте һәм зур урамдагы автомобильләр агымына кереп кушылды. Иртә иде әле, шуңа да юл беркадәр иркенрәк, берәр сәгатьтән «бөке»ләр хасил булачак. Иң аянычлысы – кемдер тегендә үлем белән алышканда, аңа ярдәм итә алырдай кешенең «бөке»дә утыруы. Андый хәлләргә дә калганы бар Зифаның, «Ник безнең машиналарга сирена куярга рөхсәт итмиләр икән?!» – дип тә уйлаганы бар. Ә әлегә юл иркен. Ул ашыкты. Кайларда камера торуын чамалый, берничә кат штрафка да эләккәндер инде. Әлегә анысы мөһим түгел иде.

Беркемгә дә үпкәләп булмый. Зифа бу һөнәрне үзе сайлады. Балалар йортыннан чыгып, үзаллы тормышка аяк басканда, аның алдында ике генә юл бар сыман тоелды. Яки тикшерүче булып, теге адәм актыгын – Пистолет Тоткан Егетне эзләп табарга, яки әти-әнисе кебек авыр хәлгә калучыларны үлем кочагыннан тартып алырга. Юрфакка керә алмады, ул чакта ук бик кәттә факультет иде. Ә медицина... Монда теш табибына гына кеше күп, ә нейрохирургиягә үз белемең белән дә керү мөмкин. Зифа шуны сайлады.

...Теге вакытта кыз калтыранып озак утырды. Күпме вакыт узганын хәтерләрлек хәлдә түгел иде. Бары тик әнисе сизелер-сизелмәс хәрәкәтләнгән кебек булгач кына, һушына килде. Әле генә күз алдында булган вакыйгалар төш тә, саташу да түгел, чынбарлык икән бит. Пистолет Тоткан Егет Зифаның бөтен гаиләсен атып чыгып киткән. Үтергән. Хәзер аның беркеме дә юк. Моны аңлаудан тормышның бөтен нуры сүнеп, дөнья салкын да, караңгы да, канлы да бер кыяфәткә керсә дә, ул ничектер хисләрен тыя алды. Һәм хәлсез адымнар белән ишеккә атлады. Тагын ничектер тартышып куйган әнисе аша атлап узганда сискәндеме, буыннары йомшардымы, ялгышрак басып таеп егылды. Бөтен киеме канга манчылды. Кыз курыкты да, кулларына сылашып шуып торган куе сыекчадан бераз чирканды да. Тиз генә торып басарлык та түгел иде – кан әле кибеп өлгермәгән, куллары да, аяклары да таеп китә. Ул дүртаяклап ишеккә таба китте. Тезләнеп, ишек тоткасына ябышып, аякларына басты...

Мәйданчыкка чыккач, Пистолет Тоткан Егет юкмы дип, бераз колак салып торды да тавыш-тын ишетелмәгәч, күршеләрнең ишеген дөбердәтергә тотынды... Үз-үзен белештермичә дөбердәтте, ачы итеп ярсып кычкырды да бугай... Елады да... Ишектә күрше Зоя апа күренгәнен бераз хәтерли әле... Аннан соң нәрсә булганын белми...

Соңыннан әйттеләр аны. Әнисе әле үлмәгән булган. Вакытында больницага илтеп, ашыгыч операция ясаганда, бәлки, коткарып булыр иде, диделәр. Тик Зифа «бәлки»не ишетмәде, ул әллә никадәр вакыт аңгыраеп утырганы өчен үзен гаепләде. Шкафтан чыгарга куркып, калтыранып тормаса, әнисе исән калыр иде кебек тоелды. Хәзер аңлый инде, әнисенең исән калуы бик тә икеле булган. Хәтта гомере бетмәгән очракта да ул бары тик «күзле бүкән» рәвешендә генә узар иде. Ә теге вакытта ул бик нык газапланды. Һәм нейрохирургияне сайлавына да, нигездә, шул сәбәпче булды.

Эшен һәрвакыт намус белән башкарырга тырышты ул, пациентны тулы канлы тормышка кайтару өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләде. Операция өстәлендә ятучыларның барысы да кемнеңдер әнисе, әтисе, сеңлесе, улы йә кызы иде бит. Алар Зифа өчен үзенең гаиләсе шикелле үк газиз булып тоелды.

Кыз туктаусыз рәвештә белемен камилләштерде, эшләде, өйрәнде һәм тиз арада коллегалары арасында да, пациентлар тарафыннан да хөрмәт һәм танылу яулады. Бүген ул – иң абруйлы белгечләрнең берсе. Иң катлаулы операцияләр ясарга сәләтле белгечләр исәбендә. Ә андыйлар санаулы гына була. Эше тынгысыз, әлбәттә, тик ул бик тә җаваплы һәм кирәкле. Дөрес, еш кына стресслар да, депрессияләр дә алып килә. Тик нишлисең... Аның каравы, мәңге җуелмас өчен хәтеренә сеңеп калган канлы хатирәләрне, ачы кайгыны оныттырып тора. Әлбәттә, сабый күңелендә тирән яра булып уелган мизгелләр бөтенләй үк онытылмый инде. Вакыт-вакыт бүгенге шикелле төш булып, күз алдында яңара, яраларны актара, тик анысына гына түзәсең. Түзәсең инде... Бүтән чараң юк...

– Шайтан алгыры! – Юл буенда кинәт пәйда булган юл хәвефсезлеге хезмәткәрен күреп сүгенеп куйды. – Туктатма, зинһар!..

Тик тәртип сакчысы аны ишетмәде. Туктарга кушып таягын болгады да, Зифа машинасын читкә алгач, ашыкмыйча гына килә башлады.

Юк, берәр тәртибе бардыр инде аның, тик Зифа юл хәвефсезлеге хезмәткәрләренең мәңге яшәргә килгән затлар шикелле атлавын беркайчан да аңлый алмады. Бу вакыт эчендә ул кеше тәнендәге әллә нинди катламнарга үтеп керә ала, ә болар... Хатын түзмәде, документларын тотып үзе аңа каршы атлады:

– Доктор, нейрохирург, – диде ул эчке ышаныч белән ныгытылган катгый тавыштан. – Операциягә ашыгам.

– Шуннан нәрсә? – Тәртип сакчысының анда гаме юк иде. – Юл кагыйдәләрен һәркем үтәргә тиеш.

– Аңлыйм, тик пациент – бик важный кеше. Соңласам, погоннарны гына түгел, ыштаннарны да салдырачаклар. Икебезнекен дә.

Тәртип сакчысы аңа шикле караш ташлап, документына күз салды да:

– Яхшы, – дип, китәргә ымлады.

– Рәхмәт!

Бу ихлас күңелдән иде. Кайчагында аңламый торганнары да очрый. Бөтен документларыңны, машинадагы әйберләреңне энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгалар. Ашыкканыңны белсәләр дә, юри вакытны сузалар. Ни өчен шулай кыланулары билгеле инде: ришвәт өмет итәләрдер. Тик доктор бик вакланып тормый, танышларының берәрсенә шалтырата. Кайчагында эскорт ясап илтеп куялар. Тоткарланган вакытны беркадәр шулай тутырасың.

Хастаханә алдында машиналар күп түгел иде. Зифа күтәрмәгә терәлеп диярлек туктады да машинасын юл уңаена бикләп йөгерә-атлый ишеккә юнәлде. Вахтёр аны күрүгә үк баш кагып исәнләште дә аратаны ачып куйды. Лифт төбендә травматология бүлегенең шәфкать туташы көтеп тора иде.

– Хәерле иртә, Зифа Саматовна! – ул кулындагы кәгазьләрне сузды. – Менә рентген нәтиҗәләре. Анализлар өстәлегездә. Пациентның шәхесе билгесез, йортлар арасында һушсыз яткан, «ашыгыч ярдәм» китерде. Киемнәренә караганда, бомж түгел, спиртлы эчемлек, наркотик кулланмаган. Физик яктан ныклы булган. Баш сөяге травмасы, миенә зыян килгән.

3

Бүлмә ишеге ачык иде. Зифа Саматовна кергән уңайга чишенеп, өске киемен урындыкка ташлады да үз урынына утырды. Компьютер кабызылган. Кирәкле программалар ачылган. Өстәлдә – тикшерү нәтиҗәләрен күрсәткән кәгазьләр өеме. Коллегаларына тел тидермәле түгел, кыска вакыт эчендә барысын да җиренә җиткереп куйганнар. Бик ашыгыч булса да, анализ һәм тикшерү нәтиҗәләрен җентекләбрәк өйрәнергә кирәк иде. Ә ашыкканда, игътибарлы булу җиңел түгел. Зифа Саматовна тирән сулыш алды, фикерләрен бер ноктага тупларга, уйларын чәчмәскә тырышты.

Мөмкин кадәр тизрәк, игътибарлырак булырга тырышып, кирәкле моментларны күңеленә беркетте. Үзе онытмас өченме, коллегаларының да хәтерендә калсын дипме, аларны кычкырып әйтеп барды:

– Йөрәк һәм сулыш алу эшчәнлеге тәртиптә түгел. Борыныннан туктаусыз рәвештә кан катыш сыекча килә. Ликворея. Баш миен тукландыруга һәм матдәләр алышынуына ярдәм итүче цереброспиналь сыекча бу. Сәламәт кешенеке баш мие сөяге белән ми тышчалары арасында була, ә сөяк сынган,

яки баш мие тышчалары зарарланган очракта борыннан, колактан яки җәрәхәт урыныннан тышка агып чыга.

Аяк-куллары хәрәкәтсез һәм бернәрсә дә сизми. Баш миендә гематомалар хасил булган. Әледән-әле җепселләр тартышуы күзәтелә. Организмның башка мөһим өлешләренә зарар килмәгән, невралгик тайпылышлар... Һм-м... Һушсыз һәм хәрәкәтсез ята, әмма тышкы ярсыткыч факторларны сизү сәләтен югалтмаган. Сопороз хәлендә, димәк. Озакка сузылса, комага китү куркынычы да бар. Ашыгырга кирәк.

Зифа Саматовна шул рәвешле кәгазьләрне аралап чыкканнан соң, компьютер экранына төбәлде.

– МРТ нәтиҗәләре... – дип, үзалдына сөйләнде ул, экрандагы сурәтне беркадәр зурайта төшеп. – Һм-м... Зарарлану урыны бик зур түгел... Әмма... Кан сауган... Кан сауган, шайтан алгыры... Рентгенографи-ия... Сынган... чатнаган... Эхоэнцефалография нәтиҗәләре начар түгел, баш миенең структурасы үзгәрмәгән... Көчле бәрелү нәтиҗәсендә барлыкка килгән баш мие имгәнүе. Катлаулы дәрәҗәдә.

Кинәт бүлмәне докторның боерыгы яңгыратты:

– Операциягә әзерләнегез.

Аңа шул мизгелдә үк җавап бирделәр:

– Әзер.

Ак халатлылар ашыгып чыгып китте. Зифа Саматовна алдындагы кәгазьләрне тагын бер кат барлап чыкты да урыныннан кузгалды.

Гади генә итеп «трепанация» дип йөртәләр аны. Мондый операцияне баш мие шешкәндә, медикаментлар белән туктата алмаслык булып кан сауганда яки сөякләр янчелеп, баш миен кысканда ясыйлар. Баш сөяге эчендәге басымны киметү ми куыкларын кан белән тәэмин итүне һәм күзәнәкләр эшчәнлеген яхшырта... Диагноз төгәл билгеле булмаса, чигә өлешеннән керәләр, уңагайларның – уң як чигәсеннән, сулагайларның – сул ягыннан. Бу юлы диагноз төгәл иде. Нәкъ менә имгәнгән урыннан кисәргә туры киләчәк.

Кичен йортлар арасында нишләп йөргән диген син аны?!. Яшь егет булса, кызлар янына килгәндер, дияр идең. Ә бу – иллегә җитеп барган ир. Хәер, нишләп йөрмәс кеше. Бәлки, ул шул тирәдә яшидер? Юк, алай булса, узгынчылар таныр иде. Сөяркәсе булдымы икән?.. Әллә дусты шул яктанмы?.. Эш белән килеп чыгарга да мөмкин инде... Сәбәпләр миллион. Явыз ниятлеләргә юлыгу мөмкинлеге – һәр адымда. Акча яки тәмәке сорап бәйләнмәгәннәр инде моңа. Каршылык күрсәтер иде... Карышмаган очракта да тәнендә вак-вак күгәргән урыннар булыр иде. Юк, моны бер сугудан аударганнар. Бәлки, алдан күзәтеп, сагалап килгәннәрдер дә аулаграк урында... Кесәсендә бернәрсә дә табылмаган... Акчасы да, документлары да. Өеңнән чыгарга да куркып утырырсың... Хәер, өеңә дә килеп...

Зифа бу уйларны куып җибәрергә ашыкты. Операция алдыннан андый нәрсәләрне хәтерләп, хискә бирелергә ярамый. Монда салкын акыл, төгәллек һәм җитезлек кирәк.

Гадәттә, операция бүлмәсенә керү белән ул үзен кеше итеп түгел, ә нәрсәнедер төзәтү өчен махсус тудырылган зат сыманрак тоя иде. Операция киемнәрен кия, алъяпкыч бәйли. Бармак очларыннан терсәкләренә кадәр

чистарткыч сыекча белән кулларын юа, медицина салфеткасы белән сөртеп, антисептик белән эшкәртә. Кулларын алга сузуга, шәфкать туташы махсус халат кидертә, докторның авыз-борынын каплап, борынчык бәйләтә, перчаткаларын кияргә җайлап куя. Бу стериль чисталык өчен эшләнсә дә, үзеңне башка үлчәмдәге кебек тоярга мәҗбүр итә. Үзенә күрә бер йола, ритуал сыман тоела. Һәм доктор авыру янына килә. Аны инде башын селкенмәслек аппаратка салып, кисү урынын чистартып, кырып, махсус сыекча белән эшкәртеп әзерләп куйган булалар. Кисәр алдыннан тагын бер кат эшкәртәләр. Һәм доктор скальпельгә үрелә...

Зифа пациентның йөзенә карамаска тырыша иде. Шулай итсәң, җайлырак. Синең алда үзең шикелле үк тере кеше түгел, ә төзәтергә кирәкле аппаратура тора сыман. Кисәсе җирен кисәсең, ялгыйсы урынын ялгыйсың, тегәсең... Барысы да механик гамәл кебек. Ә алдыңда ниндидер шәхес, адәм баласы дип уйлау – хискә бирелергә мәҗбүр итә, ә бу эш өчен хис түгел, салкын акыл мөһимрәк. Зифа шулай гадәтләнгән иде.

Тик бу юлы ни өчендер пациентка күз саласы итте. Ничектер үзеннән-үзе шулай килеп чыкты. Әлбәттә, Зифа Саматовна – тәҗрибәле доктор, пациентның йөзен күрү генә әллә ни зыян китерә алмас, ул үз-үзен кулга алуның җаен табар иде. Ләкин... Бу юлы... Пациентны күрү белән ул катып калды. Йөзе үзгәрде. Иреннәре күгәргәндәй булды. Операция өстәлендәге кеше аңа таныш иде. Мизгелнең бер өлешендә ул үзенең бала чагына... Балачак дип аталган тылсымлы дөньяның сүнгән мизгеленә кайтып килгәндәй булды. Һәм күз алдында Пистолет Тоткан Егет пәйда булды...

Онытмады аны Зифа. Оныта алмады. Беркадәр үсеп, аны-моны аңлар хәлгә килгәч, балалар йортындагы ахирәтеннән шул егетнең сурәтен ясатты. Фоторобот. Бераздан компьютерлар популярлашып китте. Анда фотосурәттәге кешеләрнең ничә елдан соң нинди кыяфәттә булачагын билгеләүче программалар барлыкка килде. Ахирәтләре бер-берсенең кырык, илле, җитмеш яшьлек чакларын күзаллап кызык табалар иде. Зифа Пистолет Тоткан Егетнең сурәтен дә шулай үзгәртте. Төп-төгәл түгелдер инде ул, бәлки, әмма кешенең егерме яшьтәге чалымнары илледә дә саклана кебек тоелды. Һәм ул сакланган да... Операция өстәлендәге кеше моннан егерме биш ел элек аның гаиләсен атып үтергән Пистолет Тоткан Егет иде.

– Юк... – дип пышылдады Зифа Саматовна. – Юк... Мин тотынмыйм... Мин операция ясый алмыйм...

Һәм ишеккә атлады. Бер мизгелгә тынып калган табиблар беравыздан аңа эндәште:

– Зифа Саматовна!

Шәфкать туташы шундук янына килеп, терсәгеннән алды.

– Зифа Саматовна, утырып торыгыз. Тынычланыгыз.

Ул утырды. Шундук су бирделәр. Эчте.

Ләкин күңелдәге яраларны бер стакан су белән генә юып бетерерлек түгел иде.

– Зифа Саматовна, сездән башка белгечләр юк, – диде кемдер. Һәм ул кайсы табибның ялга китүен, кайсының авырып ятуын санап чыкты.

Чынлап та Зифадан башка белгеч юк һәм операция өстәлендәге бәндәнең гомере аның ихтыярында иде.

«Ярдәм итмим, үлсен! – дип уйлады хатын. – Ятсын шулай тере мәет булып. Авыртуны баса торган дарулар да бирәсе калмаган аңа. Интексен, сызлансын, ник туганына үкенерлек булсын!»

– Зифа Саматовна! – монысы бүлек мөдиренең тавышы иде. – Үтенеп сорыйм... Зинһар өчен! Соңгы вакытта болай да бездә кешеләр күп үлә бит...

Кешеләр үлә... Бу статистика. Ә чынбарлык бүтән. Ә бу... Бу – кеше түгел. Бу бәндә үләргә тиеш. Зифа кайчандыр аны эзләп табып, җәзалап үтерергә ант иткән иде. Эзләде, таба алмады. Һәм менә ул бәндә операция өстәлендә ята.

– Зифа Саматовна... Зинһар өчен!... Үләчәк бит бу... Үләчәк бит...

Тагын бүлек мөдире... Кем?!. Йа Ходай!.. Әллә акылыннан шаша инде? Бүлек мөдире ул үзе ләбаса. Пистолет Тоткан Егет монда Зифаны акылдан яздырыр яки үтерер өчен килеп ятмагандыр бит... Ярдәм бир, Ходай! Дөрес юлны күрсәт...

4

«Үлсен... Аның яшәргә хакы юк!..» – Таулар арасында яңгырап, бер кыядан икенчесенә сугылган авазлар шикелле әлеге уй Зифаның бөтен булмышын актарды. Шушы дулкын тәненең бөтен күзәнәкләрен ватып, тышка атылса, бар дөньяның астын-өскә китерер шикелле иде. Тик бер мизгелгә барысы да катып калды... Ниндидер яңа көч, дәһшәтле яңа дулкын пәйда булды. Дулкын да түгел, ә тормышның бөтен агымнарын туктатып, аларны кире борырга сәләтле тылсым. Шушы тылсым бөтен уй-кичерешләрнең асылын үзгәртте, дөньяны башка кыяфәткә кертте... «Әгәр... – дип уйлады Зифа шул көч тәэсиренә бирелеп. – Әгәр бу кеше Пистолет Тоткан Егет булмаса? Әгәр мин хаталансам?»

Ул яңадан пациент ягына күз салды. Авыруны кысалардан азат итеп, кабат җайлап яткырганнар. Йөзе күренмәде. Әмма һәрбер секунд шешләрнең зураюына, чирнең тирәнәюенә алып бара, димәк, кеше гомерен куркыныч астына куя. Өстәлдә ятучының Пистолет Тоткан Егетме, түгелме икәнен ачыкларга вакыт булачак әле. Иң яхшы дигәндә дә, ул берничә айсыз аякка басмаячак. Ә әлегә – тоткарлануның һәр мизгеле үлемгә илтә иде.

– Башлыйбыз!

Көтмәгәндә, бүлмәне яңгыраткан тавыштан Зифа сискәнеп китте. Һәм аның үз тавышы икәнен аңлагач елмайгандай итте. Торып басты.

– Су!

Аңа бер стакан су тоттырдылар. Зифа аны йотлыгып эчте дә раковина янына килеп кулларын юарга кереште. Куллары җиңелчә калтырана иде. «Әгәр ул булмаса?.. – дигән уй бераздан бөтенләй башка кыяфәткә керде. – Барысы да соңыннан. Ә әлегә... Әлегә аның йөзе дә, кыяфәте дә, шәхесе дә юк. Ул – пациент. Кем булуына карамастан, ул ярдәмгә мохтаҗ һәм син аңа ярдәм итәчәксең. Син – табиб.»

Кулларын антисептик белән эшкәрткәндә, соңгы уе күңелендә ныгып өлгергән иде инде. Операция киемнәрен кигәндә, үзен дә үткәннәре һәм

киләчәге булган шәхес итеп түгел, ә бары тик әлеге мизгел өчен генә яратылган серле бер зат итеп тойды. Перчаткаларын киде, бармакларын аерып, кулларын алга сузып торды. Бармакларында бернинди калтырану, күңелендә бер авыр хис юк – ул эшкә әзер иде.

Зифа җыенган арада анестезиолог укол ясады, ярдәмчеләре пациентның башын калкытып, махсус җайланмага урнаштырдылар, пычак тиячәк урыннарны спирт белән эшкәрттеләр. Зифа Саматовна хезмәттәшләренә күз йөгертеп алды да: «Аллага тапшырдык!» – дип, сурәт төшерүче рәссам җитезлеге белән сызып җибәрде. Скальпель артыннан калган дуга рәвешендәге эзләрдән кан саркыды...

Катлаулылардан исәпләнсә дә, мондый операцияләрне инде күптән ясыйлар. Бер карасаң, әллә нәрсәсе юк та кебек. Баш тиресен дага рәвешендә кисеп, йомшак тукымаларны араларга да сөякләрне ачарга кирәк. Эчтәге шеш тәңгәлендәге сөякләрне зарарланган урынга тиеп тормаслык итеп тишәргә, зурайтырга. Шулай иткәч, минең зарарланган өлешенә басым азая, кан әйләнеше һәм баш миен кирәкле матдәләр белән тәэмин итү җиңеләя төшә. Операциянең төп мәгънәсе шул.

Әйтергә җиңел булса да, бу бик зур игътибар, төгәллек таләп итә. Чөнки кешенең баш миендә кан йөртүче җепселләр бик күп, аларны зарарламаска кирәк. Кайберләрен кисәргә туры килгән очракта, канны туктату өчен гадәти хирургия ысуллары файдасыз, алар өстәмә авыруларга китерергә мөмкин. Махсус кыскычлар куллану да һәрвакыт көтелгән нәтиҗәне бирми, аеруча, әлеге шикелле сөякләр чатнаган урыннар булганда. Күп вакытта ассистент һәм башка ярдәмчеләр киселеш урынындагы тән тиресен нык итеп учлары белән этеп торалар. Хирург кисеп җибәргәч, ассистент тирене аерып, канны һәм новокаин эретмәсе калдыкларын суыртып ала. Шуннан тирене кайтарып, аны 2-3 сантиметр калынлыгындагы марля белән беркетеп куялар. Бу кан агышын туктатып тора, тулысынча туктамаган очракта җәрәхәт читләрендәге кан тамырларын махсус кыскычлар, клипсалар белән эләктерәләр. Тире астындагы йомшак тукымаларны да шул рәвешлерәк читкә алгач, сөякләр күренә. Сөякне каплап торган мускулларны «элеватор» дигән җайланма белән күтәртеп, читкәрәк чыгаралар... Бөтен максаты баш эчендәге басымны азайту гына булса, сөякне тиешле зурлыкта тишеп кенә кую да ярдәм итә. Баш миенә кагылу кирәк булганда, сөякне кисеп, ми катламына үтәләр, сөяк чәрдәкләнгән очракта – бернинди вак-төякләре калмаслык итеп чистарталар да ялгану өчен җайлыйлар яки имплантант куялар.

Әлегә төп максат – пациентның баш миен кан белән тәэмин итүне яхшырту һәм мидәге шешләрнең зураюын киметү иде. Ул Зифа Саматовна дәрәҗәсендәге белгечләр өчен бик катлаулы саналмый һәм вакытында эшләнгән очракта уңай нәтиҗәләргә китерә. Әмма пациент йортлар арасында шактый яткан, монда килгәч тә, тикшерүләр үткәрү өчен беркадәр вакыт киткән, өстәвенә Зифа үзе дә хисләргә бирелеп, берничә минутны урлады. Шуңа күрә эш бераз катлауланган иде. Баш сөягендә басым көчле булгач, андагы шешләр зурая, кысыла һәм кан йөреше аз булу сәбәпле, ми күзәнәкләре эшчәнлеге тукталып тора. Бу исә организмның башка

әгъзаларына да көч китерә, аяк-кулларны хәрәкәтсез, тән тиресен сизү сәләтеннән мәхрүм итә. Бәхеткә каршы, пациентның организмы ярыйсы ук көчле, чыныккан, физик мөмкинлекләре югары дәрәҗәдә. Югыйсә инсульт, инфаркт, паралич сугу ихтималы да бар иде. Шулай да шактый гына маташырга туры килде. Мөмкин булганның барсын да эшләде Зифа Саматовна, зарарланган урыннарның, гематомаларның эресеннән вагына кадәр эшкәртте. Операция уңышлы үтте дип, тулы ышаныч белән әйтергә мөмкин иде.

Тик Зифа Саматовнаның беркайчан да болай дип әйткәне юк. Уйлаганы да. Уңышлы операция өчен сөенү сыманрак бер тойгы була, әлбәттә. Тик ул озакка бармый, шундук шик-шөбһәләр белән алышына. Бернәрсәне дә онытмадыммы? Авыруның гомум халәтен тулысынча күз алдына китерә алдыммы? Һәм үзенең эшен тагын бер кат энә күзеннән үткәреп чыгарга мәҗбүр була. Гомумән, бу бүлектәге авыруларның күбесе операциядән соң ук аякка басып, табибка куаныч өсти торган чирләр белән ятмый. Кайберләре хирург кулы тигәннән соң, ким дигәндә, берничә көн үткәч кенә, һушына килә, кайберләре айлар буена коматоз хәлендә ятарга мөмкин. Иң уңышлы дигәннәренең дә тормышка кайтуы, аякка басуы өчен айлар, хәтта еллар таләп ителә. Шулай булгач: «Мин бу кешегә гомер бүләк иттем!» – дип, күкрәк кага алмыйсың. Әлбәттә, үлемнән алып калуың дөрес, әгәр син ярдәм итмәсәң, бу кеше күптән инде гүр иясе булыр иде. Ә менә гомер бүләк итү икеле. Гомер бирдеңме син аңа, әллә үлемен кичектердеңме? Ә бит еллар буена урын өстендә ятканнан соң үлеп китүчеләр дә бар. Менә шуннан соң әйтеп кара: пациентларга файда китерүчеме син, әллә газапларын озайтучы гынамы?..

Мондый тойгылар һәр операциядән соң диярлек барлыкка килә. Бер карасаң, өйрәнергә, күнегергә дә вакыт кебек. Тик күнегеп булмый. Кайчагында үзеңне кешенең газапларын озайтучы садист кебек хис итәсең. Ә мондый мизгелләр күбәеп китсә, стресслар тирәнәя, күңел яралары актарыла... Мәгънәсез эш белән шөгыльләнүче кебек күренә башлыйсың. Кайчагында үкенеп тә куясың, ник бу һөнәрне сайладым икән, дисең. Ник бу һөнәрне сайладым икән?..

Зифа Саматовна үзенең ни өчен шушы һөнәрне сайлавын яхшы белә иде. Һәм бу хакта искә төшерү аны һәрвакыт сабый чагының бер мизгеленә алып китә. Өйдә, ишек төбендә кан диңгезендә яткан әти-әнисе... Пистолет Тоткан Егет...

Операция тәмамланып, пациентны реанимация бүлмәсенә алып китәр алдыннан Зифа Саматовна аның йөзенә тагын бер кат озак кына карап торды. Һәм иреннәрен кысып, баш кагып куйды. Шул.

– Танышыгызмы әллә? – дип сорады шәфкать туташы, аның киемнәрен салдырырга ярдәм итеп. – Аякка басачак, ныклы кешегә охшаган.

Зифа аңа нәфрәт тулы күзләрен төбәде. Тик берни дә дәшмәде. Хәле юк иде.

– Гафу итегез, – дип акланды шәфкать туташы.

Тик Зифа Саматовна аны ишетмәде. «Мин әле генә үземне ятим иткән кешене үлемнән алып калдым, – дип уйлады ул. – Үлемнән сакладым. Һәм мин аның калган гомерен тәмугка әйләндерә алам...»

5

Төшке аштан чыгу белән пациент янына керде. Йоклый әле, дөньялыкта эше юк. Аңына килгәнче, ике-өч тәүлек үтәр. Сулышы тигезләнгән, димәк, баш миенә кан килә башлаган. Мускулларының ирексездән тартышып-тартышып алуы да сизелми. Бер хәрәкәтсез ята.

Шәфкать туташының читкәрәк китүеннән файдаланып, Зифа кислород битлеген алып торды да аның йөзен фотога төшерде. Сулып, агарыныбрак калса да, пациентның йөзендә таныш чалымнар күзгә бәрелеп тора. Бу бәндәнең Пистолет Тоткан Егет икәненә тамчы да шикләнмәде. Шулай да ныклы дәлилләр табарга кирәк иде. Соңыннан, эш узгач, ялгышуыңны аңлап газапланырлык булмасын.

Бүлмәсенә атлаганда, таныш компьютерчының телефонын җыйды. Трубканы шундук алдылар.

– Альберт, сиңа йомыш бар, – диде ул саулык та сорашып тормастан. – Хәзер берничә фото җибәрәм. Шуларның бер үк кешеме, түгелме икәнен ачыкларга кирәк. Син бит ниндидер анализлар нәтиҗәсендә моны эшләп була дигән идең. Буламы? Яхшы. Җибәрәм, алайса.

Зифа елмайгандай итте. Уйлап карасаң, һөнәре ул кадәр үк начар түгел аның. Дөнья булгач, төрле кешеләр бәлагә юлыга бит инде. Чир-чордан беркем дә азат түгел. Зифа шуларга ярдәм күрсәтә, гариплектән, кайчагында үлемнән дә аралап кала. Һәм күпләре аның үзенең дә кадерен белә. Кайчан гына мөрәҗәгать итсә дә, ярдәмгә ашкынып торалар. Нинди генә өлкәдә йомышы төшсә дә, гозерен үтәрлек кешеләре бар.

Ишек төбендә полиция тикшерүчесе көтеп тора иде. Ул таң алдыннан килеп, медицина тикшерүләренең нәтиҗәсен алып киткән инде. Операциядән чыккач хәбәр иттеләр моны Зифага, төштән соң тагын киләчәген әйткән. Тик доктор моны шулай тиз булыр дип уйламаган иде.

– Зифа Саматовна, пациентыгыз белән сөйләшү мөмкинлеге юкмы әле? – диде ул исәнлек-саулык сорашкач һәм табибның баш чайкавын күреп, дәвам итте: – Янына килгән, хәлен белешкән кешеләр булмадымы?

– Юк, беркем дә.

– Бернинди яңалыгыгыз да юк, димәк? – Тикшерүче көрсенгәндәй итте.

– Яңалык? – Зифа Саматовна иңнәрен сикертеп куйды. – Сул яктан арттан киң һәм каты нәрсә белән сукканнар. Баш сөяге бер урыннан сынган, берничә җирдән чатнаган. Миенең кан сауган өлешләре күп. Боларны сез иртәнге тикшерү нәтиҗәләре буенча беләсездер инде. Ә яңалык булырлыгы... – Юк, моны әлегә әйтергә ярамый иде бугай. Беркадәр икеләнеп торды да дәвам итте: – Мин әлегә операция нәтиҗәләренең ничек булып бетәчәген дә төгәл генә әйтә алмыйм. Ул аякка басарга да, «күзле бүкән» булып калырга да мөмкин. Ә сез яңалык сорыйсыз...

– Яхшы, Зифа Саматовна, мин соңрак тагын кагылырмын әле сезгә.

Бүлмәсенә кереп, Альбертка фотолар җибәрде. Күрер күзгә Пистолет Тоткан Егетнең егерме биш елдан соң ничек булырга тиешлеген чагылдырган рәсем белән пациентның фотосы арасында аерма юк иде. Уртак чалымнар, иреннәр, кашлар, борын, хәтта колакларының рәвеше дә бертөрле. Ике рәсемдә дә бер үк кеше икәнен һич шикләнмичә әйтеп була.

Фотоларны чагыштырып утырганда, Зифаның башына кинәт кызык фикер килде. Гади генә ул. Ник бу хакта элек уйламавына ул аптырап та куйды хәтта. Һәрнәрсәнең үз вакыты, диюләре шулдыр инде. Югыйсә бик баш ватып этләнерлек тә нәрсә түгел. Зифа Саматовнаның танышлары күп, хәтта дәүләт иминлеге хезмәтендә дә бар. Менә шуларның берсенә мөрәҗәгать итәргә кирәк булган. Аларда һәртөрле базалар бар, теләсә кайсы кеше турында мәгълүмат таба алалар, диләр бит. Ник әле Пистолет Тоткан Егетне шулар аша эзләтеп карамаска?

Һәм ул телефон номерын җыйды.

– Һо, Зифа Саматовна, сезне дә ишетер көннәр бар икән. Хәлләрегез ничек?

– Яхшы, Артур Илдарович. Тавышыгызга караганда, үзегез дә сөбханалла.

– Сезнең тавышны ишеткәч, шулай булды, Зифа Саматовна. Ни рәхәтлекләрдә яшәп ятасыз?..

Артур Илдаровичның ФСБ офицеры икәнен ишеткәч, Зифа беркадәр аптыраган да иде. Шундый ачык йөзле, һәрвакыт күтәренке кәефле, шаян кеше ничек инде шундый урында эшләсен? Алар ничектер җитди, аз сүзле, кырыс булырга тиештер кебек тоела. Ә бу... Тик соңыннан аның робот кебек чакларын да күрергә туры килгәләде. Кеше бер генә кыяфәттә булмый шул. Ә бүген кәефе шәп иде.

– Артур Илдарович, сезгә йомышым бар...

Зифа гозерен сөйләп бирде. Артур Илдарович бүлдермичә тыңлады, аннан соң да беркадәр сүзсез торды. Һәм көтелмәгән җитдилек белән әйтеп куйды:

– Яхшы, Зифа Саматовна. Кулдан килгәнне эшләрбез. Фоторәсемнәрне ватсаптан шушы номерга җибәрегез.

– Рәхмәт, Артур Илдарович.

Трубканы куйгач, фотоларны җибәрде дә кәгазь эшләренә чумды. Хисләр ничек кенә котырмасын, эшләрне карарга кирәк иде. Ә алар күп. Иң үзәккә үткәне – кәгазьләр белән мәш килү. Хәзерге таләпләр буенча табиб, кайсы өлкәдә генә эшләмәсен, үзенең һәр адымын теркәп барырга, исәп-хисап бирергә тиеш. Бу, бәлки, кемгәдер ни өчендер кирәктер дә инде, юкка гына уйлап чыгармаганнардыр. Ләкин ул бик күп вакытны ала һәм табибның игътибарын төп эшеннән читкә юнәлтә. Менә Зифа Саматовна да бүлек мөдире буларак, кул астындагы хезмәткәрләрнең эшчәнлеге теркәлгән язмаларны өйрәнергә, шулар нигезендә үзе дә хисап бирергә мәҗбүр.

Әле бүлектәге корылмаларны тикшерү, ватыкларын төзәтү яки яңага алыштыру, дәвалау әсбаплары, дарулар белән тәэмин итү, бүлмәләрне төзекләндерү кебек санап бетергесез эшләре дә бар. Моның өстенә сәгать саен диярлек килеп торучы авырулар. Аларның күбесе авыр хәлдә булып, ашыгыч операция таләп итә. Ә кадрлар җитми, медицина уку йортлары елына меңәрләгән белгеч әзерләсә дә, чын мәгънәсендә табиб булырдайлары бармак белән генә санарлык. Табиб булу өчен дә талант кирәк. Диплом гына җитми, белем, эшләү һәм камилләшү теләге, үз-үзеңне аямау кирәк.

Ә бүгенге заман кешеләрне һавадан акча ясарга өйрәтә, чынлап та кирәкле, файдалы һөнәрләрнең бәясе түбән. Шул вазгыятьтә формалашкан

буын табиб булырга бик атлыгып тормый, җиңел акча китерердәй һөнәр эзли. Хәтта бик сәләтле, киләчәктә медицина йолдызы булыр дип өметләндергән яшь хирургларның да берничәсе медицинаны ташлап, базарга эшкә урнашты. Берсе бөтенләй ит чабучы булды. Бер сүз дә әйтә алмыйсың, анатомияне яхшы белә, кулы туры. Андый югары белемле ит чабучыларның бәясе югарыдыр инде.

Кәгазь эшләрен бетергәч, кирәкле корылмалар исемлеген тотып, баш табибка керде.

– Сез генә түгел бит, Зифа Саматовна, – диде тегесе. – Бу исемлектәге бөтен әйберне дә берьюлы ала алмабыз. Иң кичектергесезләрен билгеләгез, ә калганнары соңрак...

Зифа Саматовна озын исемлекнең өчтән беренә плюс куеп чыкты. Моны күргәч, баш табибның йөзе яктырып китте:

– Яхшы, кайтартырбыз.

– Рәхмәт!

Зифа Саматовна инде беренче ел гына эшләми, баш табиб белән сөйләшү серләрен яхшы белә. Шуңа ул исемлеккә бүгеннән үк кирәк булмаган корылмаларны да күп итеп өстәгән иде. Сөйләшүләр нәтиҗәсендә, аларын сызып ташладылар, ә иң кирәклеләре калды. Менә шулай! Әгәр кирәклеләрен генә язып кертсә, аларның да бер өлешен сызарга туры килер иде.

Авырулар килеп торды. Операцияләр дәвам итте. Бик катлаулы авырулар юк, гади эшләрне башкарырдай хирурглар җитәрлек иде, Зифа Саматовнага мохтаҗлык булмады. Көндәлек вак-төякләрен беркадәр ерып чыккач, реанимациядәгеләрне тагын бер кат урап чыгарга уйлады. Бу мотлак таләп ителә торган гамәл түгел, теге пациентны тагын күрү теләгеннән туган нәрсә булды бугай. Тик Альберттан электрон хат килү белән, бу ниятеннән кире кайтты.

Ә хат кыска гына иде: «Зифа Саматовна, тикшердем. Бер үк кеше булу ихтималы – 97,85 процент».

Барысы да аңлашылган кебек инде. Шул ук вакытта әлеге саннар үзең нәтиҗә чыгаруны сорый, ә аның әзер һәм катгый җавап ишетәсе килде. Башкалар фикерен. Әгәр шулай әйтергә яраса, белгеч фикерен. Ул телефонга үрелде. Озак көттермәделәр. Доктор шундук һөҗүмгә күчте:

– Альберт, нәрсәне аңлата бу процентлар?

– Бер үк кеше булу мөмкинлеген.

– Бер үк, димәк.

– Әйе, ике кеше арасында бу дәрәҗәдәге охшашлык булмый. Хәтта махсус сайланган һәм әзерләнгән «двойник»ларның охшаш ягы да 80-85 проценттан узмый. Шуңа күрә бу фотоларда бер үк кеше диярга нигез бар.

– Син шулай дип раслыйсыңмы?

– Мин түгел, компьютер шулай раслый. Ә ул күзгә эленми торган иң вак детальләргә дә игътибар итә, әллә ничә параметр буенча исәпләп, нәтиҗә чыгара.

– Рәхмәт, Альберт.

Димәк, реанимациядә ятучының Пистолет Тоткан Егет икәнлеге расланды. Кылган гөнаһлары өчен хак җәза адәм баласын егерме биш елдан

соң да эзләп таба. Хак җәза Зифа үзе иде. Бу бәндәнең җавапсыз калырга хакы юк. Ә үтерү ысуллары хастаханәдә дәвалау чараларына караганда да күбрәк...

6

Пистолет Тоткан Егет яткан бүлмәнең ишеге ябылып бетмәгән, аннан шәфкать туташының нәрсәдер сөйләгәне ишетелә. Реанимация бүлеге өчен табигый хәл инде бу, хезмәткәрләр комадагы кеше белән сөйләшә, аның аңын тупларга тырыша. Зифа Саматовна ишек төбендә тукталып, бераз колак салып торды.

– Бер карасаң, бәхетле кеше инде син, – дигән тавышы ишетелде шәфкать туташының. – Вакытында табып алганнар, «ашыгыч ярдәм» чакырганнар. Хастаханәдә дә иң яхшы доктор кулына эләктең. Безнең Зифа Саматовна бөтенләй өметсезләрне дә аякка бастыра ул. Менә сине дә үлемнән тартып алды. Хәзер сәгать саен сихәтләнә барасың. Болай булса, тиздән аякка басачаксың син...

Зифа Саматовна ишек шакыды. Аны күрүгә шәфкать туташы уңайсызланып китте, кызарды.

– Хәлләр ничек? – Доктор кергән уңайга ук авыруның пульсын капшап карады.

– Яхшы.

– Тән температурасы да артык югары түгел...

Зифа Саматовна өстәл янына килде дә шәфкать туташы алып барган күзәтү язмаларын тикшерергә кереште. Шәфкать туташы елмайды:

– Терминатор кебек бу, Зифа Саматовна, үзеннән-үзе җыела.

Доктор дәшмәде.

Пациентның хәле чынлап та яхшы иде. Сулыш алу эшчәнлеге әкрен генә әйбәтләнеп килә, әлбәттә, респираторны салдырырлык ук дәрәҗәдә түгел әлегә, тик барыбер күрсәткечләр яхшы. Һәрхәлдә, ИВЛ аппараты ярдәмендә үпкәне ясалма җилләтү ысулларын кулланырга туры килмәс. Кан басымы да шөкер итәрлек. Гадәттә, мондый операцияләрдән соң кан басымы уйный торган була, йә түбән тәгәри, йә күтәрелә. Ә моныкы... Гомумән, бу бәндәнең сәламәтлеге дә, физик мөмкинлекләре дә ис-акылың китәрлек дәрәҗәдә югары иде. Операциядән соң өч көн үтүгә үк сизелерлек алга китеш күзәтелә, бу темп белән барса, чагыштырмача бик кыска вакыт эчендә аягына басачак. Бөтен организмның да яшәүгә омтылышы шушы дәрәҗәдә булса, табибларның берсе дә стресс кичермәс иде.

– Бөтен авырулар да шулай булса икән... – диде шәфкать туташы аның уйларын сизенгәндәй.

Доктор сискәнеп китте. Күз алдында бер мизгелгә пистолет тоткан егетләр төркеме пәйда булды. Тик бу уйларын куып җибәрергә тырышты. Шәфкать туташына карап, баш кагып куйды, елмайгандай итте.

Пациент буларак, ул Зифага бик якын, хәтта кадерле дә иде. Үзең операция ясаган кеше хастаханәдә ятканда, гомумән, якын була. Хезмәтеңнең бер җимеше бит инде ул, син үлемнән тартып алган җан иясе. Эшеңнең күрсәткече дә. Әгәр күзгә күренеп савыга икән, димәк, барысын да дөрес эшләгәнсең. Хәле начарая икән... Монда, әлбәттә, төрле сәбәпләр

килеп кушылырга мөмкин – организмның гомум халәте, пациентның яше, ярдәмнең үз вакытында күрсәтелмәве... Күп алар... Ләкин сәбәпләре нинди генә булса да, әгәр авыруның хәле начарая икән, табиб мотлак рәвештә үзен гаепле итеп сизә. Ул моны кычкырып әйтми, беркемгә дә сиздерми, күңеленнән генә газаплана. Хәтта алга китеш бик акрын барган очракларда да борчыла ул – нәрсәнедер эшләп җиткермәгән шикелле тоела.

Ә мондый тизлек белән савыгучы кеше һәр доктор өчен шатлык чыганагы була алыр иде. Шуңадырмы, Пистолет Тоткан Егет турында уйлауга шайтаны котырып, зыян салу теләге көчәйсә дә, реанимациягә кереп, пациентны күрү белән ниятеннән кире кайта, аның савыгуын тизләтү өчен чаралар күрергә тотына, өстәмә дәвалау ысуллары куллана. Моны ул үзе дә сизми кала һәм ни өчен шулай эшләгәнен дә аңлый алмый. Ә җәзалау теләге көчле. Үтерү ысуллары да күп, алар һәр адымда – ниндидер препаратның дозасын үзгәртү, ниндидер чараны тизләтү, йә кичектерү... Барысы да гади генә. Монда хәтта битарафлык та, ашыгу яки соңлау да үлем коралы була ала. Һәм аларны кулланган өчен беркем дә гаепли алмаячак. Бу пациентны үтерергә теләге һәм мөмкинлекләре булып та, Зифа аны дәвалый бирә.

– Сөйләндерергә тырыш, – диде ул шәфкать туташына. – Сораулар бир. Һич югында китап булса да укы.

– Мин шулай итәм. Анекдотлар да сөйлим әле. Көлми генә... – дип елмайды шәфкать туташы.

Ләкин Зифа аны күрмәде. Ул кабат үз уйларына кайткан иде.

Аның болай кылануы табиб фидакарьлеге дә, сантыйлык та түгел бугай. Менә шулай бер хәрәкәтсез яткан дошманның гомерен алу аңа бернинди дә канәгатьлек бирмәс иде кебек. Үлде инде, моргка озаттылар, ди... Шуннан? Нинди нәтиҗә бирә бу? Дөньяны бер явыздан коткарам, дияр идең... Менә ята ул, бернинди начарлык та эшли алмый хәзер. Үчен кайтардым, дияр идең... Синең кемлегеңне дә, үзенең ни өчен шундый язмышка дучар булуын да аңламыйча китеп барачак... Ә аңлавы кирәк. Кирәк! Үзенең егерме биш ел элек кылган гөнаһын исенә төшереп, хәзер инде бернәрсәне дә төзәтү мөмкин түгелен аңлап, үкенеп, әрнеп, газапланып китәргә тиеш ул. Менә шул очракта гына үч кайтару була. Менә шунда гына явыз җинаятьче үз җәзасын алды дип тынычланырга, күпмедер дәрәҗәдә канәгатьлек кичерергә мөмкин.

«Терминатор кебек...» – дип кабатлады күңеленнән Зифа. Бу тизлектә савыкса, тиздән һушына килер, сөйләшә башлар. Ә аннан соң реабилитация бүлегенә күчерерләр. Ул вакытта инде әлеге шикелле тулысынча Зифаның карамагында булмаячак. Әлбәттә, кереп хәл белүгә каршы килмәсләр, әмма мөмкинлекләр бераз чикләнәчәк. Ул тулысынча үз ихтыярында чакта нәрсәдер эшләп калырга кирәк. Бәлки, аның савыгу барышын азрак тоткарлап торыргадыр? Һушына килгәч, әлбәттә. Сызлансын, интексен беркадәр. Ул чагында реанимациядә дә озаграк яткырып булыр...

– Ярый, күз күрер әле...

Бу уйларын кычкырып әйтүен сизеп, Зифа уңайсызланып китте. Ярый әле шәфкать туташы ихлас күңелле кыз иде, югыйсә үз-үзе белән сөйләшеп йөри дип көләргә дә күп сорамаслар.

– Ни дидегез, Зифа Саматовна?

Доктор елмайды:

– Әлегә берни дә өстәми торыйк. Калганын соңрак күз күрер, дим.

– Ә-ә-ә... Яхшы...

Реанимация бүлегендә Зифа Саматовнаның тагын берничә пациенты ята иде. Шулар яныннан урап әйләнүгә шәфкать туташы коридорга атылып чыкты. Һәм аның янына ашыкты:

– Зифа Саматовна! Ул уянды! – дип ярсып пышылдады кыз. – Уянды!

Йөгерә-атлый бүлмәгә керделәр. Тик пациент һаман элекке хәлендә һәм бернинди дә үзгәреш юк иде. Табиб шәфкать туташына текәлде. Тегесе акланырга ашыкты:

– Валлаһи-билләһи менә, Зифа Саматовна. Ул күзләрен ачты. Тирә-якка каранып алды. Мин башта сискәндем, аңламыйчарак тордым, ә соңыннан сезнең янга...

– Ышанам, – дип елмайды доктор. – Башта шулай кыска вакытка гына уяналар алар. Тиздән һушына килер. Яныннан китмә.

Пациентны беркадәр күзәтеп торды да ишеккә юнәлде. Тик коридорга чыгу белән шәфкать туташының пышылдавы ишетелде:

– Зифа Саматовна!

Кабат кергәндә, чынлап та авыруның күзләре ачык иде. Битләрендәге мускуллар сизелер-сизелмәс кенә тартыша, иреннәрен хәрәкәткә китерергә тырыша. Зифа елмайды:

– Тереләр арасына рәхим итегез!

Пациентның йөзендәге тартышулар тагы кабатланды.

– Әлегә сез сөйләшә дә, хәрәкәтләнә дә алмыйсыз. Анысы соңрак булыр. Ә әлегә... Сез реанимация бүлегендә. Башыгызга операция ясадык. Уңышлы үтте. Тиздән сез сөйләшә башлаячаксыз. Сез мине аңлыйсызмы? Керфекләрегезне ачып йомыгыз.

Пациент керфекләрен ачып йомды. Күзләрендә гаҗәпләнү дә, бетмәс-төкәнмәс сораулар да, тагын әллә нәрсәләр бар иде. Тик озаклап өйрәнеп торырлык форсат булмады, ул күзләрен йомды.

7

Комада яткан пациентлар күзләрен ачу белән тормышка аяк басмый. Уянулар башта бик кыска вакытлы була, соңрак озыная, акрынлап кына сөйләшү сәләте, хәрәкәтләнү мөмкинлеге кире кайта. Үзләренең нинди халәттә икәнен тулысынча аңлау, хәлләренә яраклашу өчен дә беркадәр вакыт кирәк.

Зифа Саматовна барысын да аңлап тора. Ләкин бу бәндә белән тизрәк сөйләшү, аңа үзендәге фотоны күрсәтү, әти-әнисен үтереп чыккан мизгелне исенә төшерү теләге тынгы бирмәде. Күңелендәге яраларын актара-актара, барысын да күз алдына китереп, авыр язмышка дучар булуы өчен үч аласы иде.

– Менә монсы – әтинең гомерен өзүең өчен! – дип, үлмәслек тә, чыдап та булмаслык авыртуга дучар итәсе. Аннан соң әнисе, сеңлесе өчен җәзалыйсы. Газапларның хәтәрләре үтте дип тынычлана башлауга, үзенең үтерелгән балачагы, шул мизгелдән бирле кичергән барлык

михнәтләре өчен җавап аласы. Калган бөтен гомерен тоташ газапка әйләндерәсе...

Нәфрәте дә, үч алу теләге дә көчле иде Зифаның. Кайчагында ул әле дә булса хәрәкәтләнергә, тормышка кайтырга, яшәргә тырышып яткан шушы бәндәнең бугазына барып ябышудан үзен көчкә тыеп калды. Дәвалаучы түгел, ә савыгуны тоткарлаучы, сызлануны арттыручы препаратлар бирү теләге дә әледән-әле калкып чыкты. Сулыш алу аппаратын йолкып ыргытасы, тукландыручы матдәләр урынына кислота саласы, күзләре акаеп шартлаганчы кан басымын күтәрәсе килде. Кайчагында аның яшәвенең бөтен мәгънәсе шушы кешене интектерүдер, Ходай аның гомерен фәкать шул максат белән генә саклап калгандыр шикелле тоелды. Җәзалауларның һәр мизгеленнән үзе дә тәм табар, ләззәт алыр сыман булды.

Ләкин үзе дә аңламаган сәбәпләр Зифаны бу гамәлләргә тотынудан кичектереп килде. Агу бирергә теләсә дә, үтерүченең шул агу тәэсирендә көчле авыртудан йомарланып, җан бирүен күз алдына китерә-китерә дару бирде. Хәле аз гына начарланып китсә дә, шундук ярдәмгә килде. Үзенең бөтен пациентларын бер дәрәҗәдә караса да, бу бәндә турында күбрәк уйлады. Һәм Зифа моның сәбәбе бары тик аны тизрәк терелтеп, аңлашырга ашкыну гына түгеллеген аңлаган да кебек иде. Шул гына булса, фотоны хәзер үк кулына тоттырырга мөмкин. Кемнең сурәте икәнен аңларлык кына һушы бар инде пациентның. «Менә синең эшең!» – дип, алгы як идәнендә яткан мәетләрне дә күрсәтергә була. Үзенең кемлеген әйтергә дә. Хәтта шушылар үзләре генә дә авыруның тынычлыгын алачак, аны үткәннәрен хәтерләргә, газапланырга мәҗбүр итәчәк. Күңеле таш булып каткан очракта да ул үзенең кем кулында икәнен аңлап борчылачак, борчылган саен хәле начараячак, газапланачак. Гомер һәркемгә кадерле, үтерүчеләр аны яхшы белә.

Табиб анты гына сәбәпче түгел бит инде монда. Хәтта анда да «Әткәм-әнкәмне, туганымны үтерүчене дәваларга» дигән төшенчә юк. Бәлки, үтерү сәләте бөтен кешегә дә бирелмәгәндер? Үз куллары белән җәзалап, шуннан ләззәт алу мөмкинлеге дә? Моның өчен аерым бер сыйфат кирәктер?

Бу сорауларга җавап булып, Артур Илдарович килеп керде. Ул һәрвакыт диярлек шулай алдан хәбәр итмичә генә килергә ярата. Бу юлы да хәл-әхвәл сорашу белән, ашыгыч эшләре юкмы, дип кызыксынды да якындагы кафега чакырды. Җыйнак һәм пөхтә булгангамы, кафеда кеше күп иде. Хәвефсезлек хезмәте офицеры бер дә юктан гына килмәгәнен белеп, Зифа сорау бирергә ашыкмады. Артур Илдарович бүген гадәттәгедән җитдирәк иде, уен-көлкегә бирелмичә генә сүз башлады:

– Сез җибәргән рәсемдә – туксанынчы елларда бик актив эшләгән киллер, – диде ул бернинди кереш сүзсез генә. – Рэкетирлар заказын үтәп, башбирмәс бизнесменнарны үтерүче. Элекке КГБ офицеры. Аның артыннан куркынычсызлык хезмәте дә, милиция тикшерүчеләре дә күп чапты...

Моны Зифа үзе дә чамалый иде. Бүлдермичә түзә алмады:

– Ә икенче фото? Өлкән яшьтәгесе?

– Өлкән яшьтәгесе дә – шул ук кеше. Безнең белгечләр әллә ничә ысул белән тикшереп карады. Шул ук кеше, дигән фикергә килделәр. Сурәт буенча.

– Кем соң ул? Исем-аты бардыр бит?

Артур Илдарович анның күзләренә текәлеп торды:

– Гафу итегез, Зифа Саматовна, анысын әлегә әйтә алмыйм.

– Ник?

– Әйтә алмыйм. Ә бу фотолар сезгә ничек килеп эләкте?

Хатын бер мәл икеләнеп торды:

– Гафу итегез, Артур Илдарович... Мин дә әйтә алмыйм.

Хәвефсезлек хезмәткәре кычкырып көлеп җибәрде:

– Ну, сез, Зифа Саматовна! – Һәм җитдиләнеп дәвам итте: – Ул кешене туксанынчы елларда ук үтергәннәр. Эз яздыру өчен үз заказчиклары юк иткән. Моны дәлилләүче документлар бар.

– Ә теге фоторәсем?

– Ул дәлил була алмый. Фотоларның берсе компьютерда эшләнгән, ә икенчесе... Аның да шулай булу ихтималы бар. Мин әлегә бу хакта берни дә әйтә алмыйм. Ә сез ник кызыксынасыз?

Зифа Саматовна бераз дәшми торды. Каршыда утыручы ир аның яхшы танышы, дусты дип әйтерлек кеше булса да, куркынычсызлык хезмәте офицеры иде. Ә бу үзе генә дә сак булуны таләп итә. Ниһаять, ул телгә килде:

– Фотоларның ничек миңа эләгүен әлегә әйтә алмыйм, Артур Илдарович, бәлки, ул мөһим дә түгелдер. Тик безнең гаиләне үтереп чыккан кеше шул булырга тиеш, дип уйлыйм.

Артур Илдарович моңсу елмайды:

– Шулайдыр дигән идем. Ә сез дөрес уйлыйсыз. Бу – нәкъ шул киллер.

Зифа өчен яңалык түгел иде. Тик ул тагын бер сорау бирмичә кала алмады:

– Ә заказчик кем?

– Меркуно, – диде Артур Илдарович, тик докторның берни аңламавын тоеп дәвам итте: – Шундый кушаматлы рэкетир бар иде. Рейдер. Завод-фабрикаларны кулга төшерү белән шөгыльләнде...

– Ә хәзер кайда?

– Җир астында... Ул елларда җинаятьчеләр дә күп кырылды бит. Үтерешләр дулкын-дулкын булып калкып, кабатланып торды.

Бер мәлгә сүзсез утырдылар. Ул арада официант аш китерде. Артур Илдарович кинәт кенә сорап куйды:

– Ә ул киллерны очратсагыз, нишләр идегез?

– Үтерер идем, – диде Зифа, ике дә уйламыйча.

Куркынычсызлык хезмәткәре аңа гаҗәпләнеп карады да көлемсерәде:

– Сезме?!. – Һәм җитди дәвам итте: – Кеше үтерү җиңел түгел. Йөзгә йөз сугышканда, хәтта солдатларның да күбесе... үтерә алмый... кайберләренең кулын, бармагын көзән җыера башлый, кайберләре һавага ата. Яу озакка китсә, акылын җуючылар да бар. Әзерлек үткән солдатлар болар! Үз тиңнәрен үтерүгә кешенең биологик механизмнары каршы төшә, моны хәтта акыл да контрольдә тота алмый.

– Тик сугышта кешеләр барыбер үлә. Кем үтерә соң алайса?

– Кеше үтерергә сәләтлеләр солдатлар арасында 2-3 процент кына. Һәм корбаннарның 100 проценты шушылар өлешенә төшә. Галимнәр боларны

нормаль кешеләр түгел, ә психопатлар дип аңлата. Алар сугышта – герой, ә тыныч тормышта – җинаятьче була...

Көтмәгәндә, Артур Илдаровичның телефоны шалтырады. Ул кем шалтыратуына күз салды да хушлашырга ашыкты:

– Зифа Саматовна, зинһар, гафу итегез, миңа китәргә кирәк.

– Рәхмәт сезгә, Артур Илдарович!

– Ерунда. Йомышыгыз булса, һәрчак эндәшегез.

Инде куркынычсызлык хезмәткәре ишеккә юнәлгән иде, тик табиб сорамый кала алмады:

– Артур Илдарович!

Офицер шундук борылып, аңа атлады. Докторның елмаюын күреп, үзе дә елмайды.

– Ә куркынычсызлык хезмәте хаталанырга мөмкинме?

– Ничек кенә әле! – диде ул һәм җитди кыяфәткә керде. – Бик нык хаталанырга мөмкин. Ләкин бик сирәк.

Кафедан чыккач, Зифа Саматовна әлеге сөйләшүне тагын бер кат күз алдыннан үткәрде. Гаиләсен үтерүчеләрнең барысы да кабердә, димәк. Тәмугта. Алар хәләл җәзасын алган булып чыга. Ә реанимациядәге бәндә кем соң алайса?

Куркынычсызлык хезмәте офицеры нәрсәнедер әйтеп бетермәде бугай. Аның каравы, ул Зифаның башка соравына җавап бирде. Үтерү җиңел түгел, аңа кешенең биологик механизмнары каршы төшә. Үтерүче – психопат. Мондый мәгълүматларга Зифаның беркайчан да очраганы булмады. Бәлки, куркынычсызлык хезмәткәре үтереш өлкәсендә күбрәк беләдер, ә бәлки, нәрсәдер сизенеп, Зифаны ялгыш адымнан саклау өчен шундый ярымялган факт сыман фикерләр китерәдер. Алай да булырга мөмкин. Тик аның бер сүзе хакыйкать иде: җиңел түгел, нормаль кешенең табигате моңа каршы килә.

Ләкин икенче нәрсә бар: максатыңа ирешергә телисең икән, авырлыкларны да, каршылыкларны да, хәтта кеше табигатенең үзен дә җиңәргә кирәк. Ә куркынычсызлык хезмәте бик сирәк, әмма бик нык хаталана ала. Бу нәкъ шул очрак иде бугай.

8

Артур Илдарович белән сөйләшкәннән соң да шактый вакыт узды. Зифа һаман икеләнеп йөрде, нәфрәте дә сүрелмәде, ният иткәненә тәвәккәлли дә алмады. Ә һәрвакыт уйланып йөрү, әллә нинди фикерләргә килеп, әлләниләр эшләрдәй булу һәм берни дә майтара алмау – үзе үк газап иде. Сөйләшерлек, серләшерлек кешесе дә юк бит ичмасам. Мондый нәрсәне кешегә сөйләп тә булмыйдыр, хәтта иң якын ахирәтеңә дә. Ә Зифаның андый ахирәте юк та иде бугай. Эшендә зур оста булса да, хезмәттәшләре белән җиңел аралашса да, бүтәннәр белән бик якыная алмады ул, күңеленә беркемне дә кертергә ашыкмады. Кечкенә вакытындагы алданулар эзсез үтмәгәндер. Үтерүчене җәзаларга теләве үзен газаплауга әверелде. Мондый халәт озакка китсә, акылдан шашуың да бар. Нәрсәдер эшләргә кирәк.

Ә үтерүче савыга. Һәрхәлдә аның күрсәткечләре инде әйбәт, гомеренә куркыныч янамый. Алай гына да түгел әле... Анализлары яхшы, төрле белгечләр – психолог та, невролог та, физиотерапевт та, нейрологопед

та туктаусыз эш алып бара һәм нәтиҗәсе күз алдында. Авыруның сулыш алуы яхшырды, инде трахеостома да кирәкми, бернинди аппаратка да мохтаҗлыгы юк. Гастростома дип аталган тукландыру җайланмасын кулланмый башладылар, хәзер аның йоту функцияләре әйбәт эшли – махсус әзерләнгән ризыкны үзе ашый ала. Тышка чыгуны үзаллы башкара, сидек катетеры кирәк түгел. Аяк-куллары хәрәкәтләнә, ул хәтта үзе торып утыра да ала. Инвалид коляскасында утырганда, кан басымы да күтәрелми хәтта. Бу инде алга китеш. Сокланырлык дәрәҗәдә.

Бер карасаң, ул инде кул-аякларын хәрәкәтләндерергә генә түгел, ә үзаллы атлап йөрергә дә тиеш кебек. Авыруның савыгу тизлеге, организмының гомум картинасы шуны күрсәтә. Физиотерапевт язмаларында да аның күнекмәләр вакытында аягында нык басып торуы, адымнарын ышанычлы атлавы билгеләнә. Ләкин көндәлек тормышында пациент урынында борылып ятудан узмый, кайчагында торып та утыра, әмма аягына басып та карамый. Монысы беркадәр сәеррәк иде. Баш мие функцияләренең тулысынча көйләнеп бетмәве белән бәйледер инде бу. Хәтер эшчәнлеге дә яхшы түгел аның. Әлегә үзенең кем икәнен дә, ничек мондый хәлгә юлыгуын да әйтә алмады. Сөйләшүенең дә рәте юк – аерым сүзләрне дөрес әйтә, ә җөмләләр төзи алмый. Сорауларга да «әйе-юк» дип кенә җавап бирә, күп очракта ишарәләр белән генә аңлата. Монысына психолог белән нейрологопедның исе китә инде:

– Ул бит барысын да аңлый, башы эшли аның, ә җавап бирми, сөйләшми. Ничек алай булырга мөмкин? – диләр.

Алар хаклы да кебек. Әгәр әйткәнне аңлый ала икән, фикерләү сәләте бар, дигән сүз. Аваз чыгару системасы да дөрес эшли. Димәк, фикерен сүз рәвешенә китерү, ягъни сөйләшү өчен бернинди каршылык та булырга тиеш түгел. Күрәсең, ниндидер психологик тайпылышлар бар, мөмкинлекләрен тулысынча файдалана алмый.

– Көтик әле, – ди Зифа Саматовна. – Бераз вакыт кирәктер, бәлки...

– Соң, Зифа Саматовна... – дип каршы төшә коллегалары. – Айдан артык көтәбез бит инде...

– Нәрсә тәкъдим итәсез соң?

Коллегалар бер-берсенә карашып кына куя, җавап бирмиләр.

Җәзаны кичектерүнең сәбәбе дә, бәлки, шул булгандыр әле. Сөйләшергә кирәк иде башта, кеше үтерүнең никадәр зур фаҗига икәнен төшендерергә һәм бары тик шуннан соң гына җәзаларга. Бу газапларның ни өчен икәнен белеп, бер гөнаһтан да качып котылып булмавын аңлап тилмерсен. Еласын хәтта, аяу сорап ялварсын. Шулай иткәндә, яхшы буласы иде. Әмма бу мизгелне көтү артык озакка сузылды һәм Зифаның үзе белән идарә итә, үзен газаплый башлады.

Алай гына да түгел, пациентның хәле яхшырган саен, җәзага тарттыру кыенлаша, ул Зифа Саматовна кулыннан ераклаша бара. Элек аны җәзалау өчен сулыш алу системасын туктату кебек гади бер хәрәкәт тә җитә иде. Хәзер эш бераз катлаулана, андый гамәлләр белән генә булмый. Барысын да алдан уйлап, үзеңә күләгә төшмәслек итеп эш йөртү таләп ителә. Һәм вакыт та хәзер пациент файдасына эшли. Үтерүче файдасына. Кичекмәстән тәвәккәлләргә кирәк.

Озакламый җае да чыкты. Кизү торырга тиешле табибның баласы авырып киткән дә, ул кем беләндер алыштыруны сорап, Зифа Саматовнага керде. Бүлек мөдире табиблар исемлегенә күз салды да керүчене шелтәләп алды:

– Соңгы көнне көтеп йөрмәсәң...

Коллегасының, әлбәттә, бер гаебе дә юк. Иртән иртүк кергән, әле вакыт бар.

– Кинәт авырып китте бит, Зифа Саматовна, – дип акланды табиб. – Ярамаган нәрсә ашаганмы шунда. Инфекционистка алып барырга иде.

– Беркем дә юк бит әле. – Доктор табиблар исемлеген тагы бер кат күздән кичерде. – Таш яуса да, булмый.

– Зинһар өчен, Зифа Саматовна.

– Берәү дә бушамый...

Тик кинәт Зифага бу гади генә күренеш түгел, ә күкләрдән килгән билге кебек тоелды. Үтерүче белән бергә-бер калырга мөмкинлек туа түгелме соң?! Әлбәттә, арыган инде ул, тәүлек әйләнәсенә эшләү кыен булачак. Тик нишлисең... Ә чынлап уйласаң, соңгы араларда арымаган көне булмый да иде бугай.

– Ярый, үзем торырмын, – дип елмайды ул.

Кизү калырга тиешле табиб рәхмәт укып чыгып киткәч: «Ниһаять, сәгате сукты!» – дип, җиңел сулап куйды. Тик шундук икенче сорау баш калкытты: ә ничек җәзаларга соң? Үч алу, газаплау теләге көчле булса да, хыялында әллә нинди коточкыч ысулларны күз алдына китерсә дә, Зифа моның чынбарлыкта кулланырлык чараларын уйламаган икән бит. Пациентны вакытлыча хәрәкәтсез калдыручы укол кадарга да мөмкин. Дозасын аз гына арттырырга. Тик бу очракта бернинди җәзалау турында да сүз була алмый, ул нибары үләчәк кенә. Бернинди авыртуны да тоймаячак, бер хис тә кичермәячәк... Ә үзеңә кулга төшермичә тиз генә эшләнә торган башка юл юк иде. Антибиотиклар бирүне туктатырга була, башка препаратларны... Бу очракта төрле инфекцияләр үрчеп, аны сызланырга мәҗбүр итәчәк, хәлен авырлаштырачак, хәтта үлемгә җиткерәчәк. Тик бу бүген-иртәгә генә эшли торган гамәл түгел, ким дигәндә, атна-ун көн буена дәвам иттерергә кирәк. Шул вакыт эчендә: «Пациентымны аңлы рәвештә үлемгә дучар итәм бит», – дигән уйлар эчендә яшәргә, үзең дә газапланырга мәҗбүр булачаксың. Аның хәле начараюын күреп, коллегаларының кайсыдыр каршы да төшәргә мөмкин әле.

Күпме генә баш ватса да, Зифа бүген үк кулланырдай җайлы ысул таба алмады. Пациентның хәлен, мөмкинлекләрен тагын бер кат күз алдыннан үткәрде дә компьютерындагы фотоларны принтер аша кәгазьгә чыгарып, өстәл тартмасына салды. Бераздан үтерүче янындагы шәфкать туташын чакыртып алды:

– Хәле ничек?

– Шул килеш. Үзгәреш юк.

Кинәт психолог белән нейрохирург әйткән сүзләр исенә төште. «Айдан артык котәбез бит инде...» Һәм коллегаларының серле итеп бер-берсенә карашып куюы... Ачыктан-ачык әйтмәсәләр дә, алар Зифаны ниндидер нәтиҗәгә этәрәләр иде түгелме соң? Әлбәттә, шулай. Савыгу күрсәткечләре

соклангыч тизлек белән үсеп, кинәт айдан артык вакытка бер үзгәрешсез кала икән, моның бик җитди сәбәбе булырга тиеш. Һәм ул сәбәпне Зифа Саматовна дәрәҗәсендәге доктор һичшиксез табарга тиеш иде. Психолог белән нейрологопед та тәҗрибәле белгечләр, борчылулары юктан гына түгелдер. Нindидер сәбәп булырга тиеш. Тик ничек кенә тикшерсәләр дә, сәбәп табылмады. Табылмады һәм вәссәлам. Ә моннан бер генә нәтиҗә чыгарырга мөмкин: пациент хәйләләшә.

– Холтер аппараты куеп карагыз әле.

– Яхшы, Зифа Саматовна.

Гади генә процедура инде бу. Пациентны бил тиңентен чишендерәләр дә тән тиресен спирт белән эшкәртеп, датчиклар беркетәләр. Аппарат тәүлек буена авыруның йөрәк тибешен яздыра. Ә махсус көндәлектә аның ризык кабул итү вакыты, физик нагрузкалары, дару эчүе – барысы да теркәлеп бара. Шуннан доктор йөрәк эшчәнлегенә нәрсәләр нык тәэсир итүен билгели. Тик бу юлы Зифа Саматовнаның максаты бүтән иде.

Пациент янына ул төшке аш узып, беркадәр вакыт үткәч, «йокы сәгате»ндә керде. Шәфкать туташы нәрсәдер язып утыра иде, табиб аңа кул хәрәкәте белән генә эшен дәвам итәргә кушып, карават янына узды. Ята... Бер хәрәкәт тә ясамый, әмма күзләре йомык түгел. Зифа гадәттәгечә тыныч тавыш белән хәлен сорагач, сизелер-сизелмәс кенә башын кагып куйды.

– Хәзер ми күзәнәкләре өчен бераз күнекмәләр ясап алырбыз. – Зифа читтәрәк торган утыргычның берсен караваттянына шудырды да кулындагы катыргы карточкаларны шунда куйды. – Мин сезгә рәсемнәр күрсәтәм, ә сез анда нәрсә төшерелгәнен әйтерсез. Аңлашыламы?

Пациент беркадәр аның күзенә төбәлеп торды да баш каккандай итте. Табиб аңа шелтәле караш ташлады:

– Ым-ишарә кирәкми, барсын да сүз белән әйтәбез. Аңлашыламы?

– Әй-йе... – дип сыгып чыгарды авыру. Читтән караганда, бу гамәлнең аңа авырлык белән бирелүе күренеп тора иде.

– Яхшы. – Зифа Саматовна иң өстә яткан катыргыны алды: – Бу нәрсә?

Пациент бер мәлгә сурәткә карап тынып торды, аннан соң бөтен бит мускулларын киеренкеләндереп, авызын очлатты:

– Ү-ү-ге-ез...

«Нейрологопедны да чакырырга кирәк булган, – дип уйлады Зифа. – Аның янында сүзләрне бик җиңел әйтә иде». Һәм икенче сурәтне күрсәтеп, сораулы караш ташлады.

– Каз, – дип җавап бирде авыру.

– Маладис, ә монысы?

– Ку-у-ян.

Беркадәр авырлык белән әйтелсә дә, монысы да матур гына килеп чыкты. Шул рәвешле тагын берничә сурәтне күрсәткәч, доктор принтердан чыгарылган кәгазьне кулына алды:

– Ә монысы кем?

Пациент рәсемгә карап катып калды. Тик йөзендә бер мускул да селкенмәде, күзләрендә бернинди үзгәреш тә сизелмәде. Ул бу сурәтне күрә, тик нәрсә дип атарга гына белми сыман. Шулай да Зифа аның сулышы

беркадәр ешаеп китүен тоймый калмады. Бәлки, киеренкелек белән җавап эзләүдән генәдер?

– Е-е-г-ге-ет...

Тавышы беркадәр карлыккан шикелле тоелды. Бу пациентның дулкынлануыннан да, башка сәбәптән дә булырга мөмкин иде. «Шайтан алгыры! – дип уйлады Зифа. – Ул берни дә сиздермәде. Яки бу кеше аңа чынлап та таныш түгел, яки баш мие эшчәнлеге зәгыйфь...»

– Пистолет тоткан егет, – Зифаның тавышы хөкем карары сыман яңгырады, тик пациентның моңа исе китмәде.

Ул тагын берничә сурәт күрсәтте. Пациент аларга үз җаенча җавап бирде.

– Арыдыңмы? – Пациент бу юлы баш кына какты. Зифа сәгатенә карап алды да карточкаларны җыеп, ишеккә юнәлде. – Ял ит. Әйбәтләнәсең син. Маладис.

Бүлектә кемнеңдер хәле начараеп китәргә, яки «ашыгыч ярдәм» белән килгән авыруларга кичектергесез операция кирәк булырга мөмкин. Кизү торган табиб әнә шундый мизгелләрдә алыштыргысыз була. Ул яки тиешле белгечне өеннән чакыртып китертә, яки үзе операциягә алына. Ә калган вакытларда, хәлләр чагыштырмача тыныч булганда, ял итә. Авырулар кизү торган шәфкать туташлары карамагында кала.

Зифа Саматовна да көн ахырына арыганлык тойды, бераз ял итеп, ә иң яхшысы – йоклап алырга кирәк иде. Тик ул башта Холтер аппаратын китерттерде. Һәм компьютерга тоташтырып, аның нәтиҗәләрен тикшерде.

Пациентның йөрәге әйбәт иде. Соклангыч дәрәҗәдә. Ләкин Пистолет Тоткан Егетнең фотосын күргәннән соң, аның йөрәге бик ашыгып, ярсып тибә башлаган һәм бары тик кичке процедуралар вакытында тынычландыргыч укол биргәч кенә, нормага кайткан. Хәтта анда да әле элекке хәленә үк төшеп җитә алмаган, чагыштырмача югары килеш калган. Бу инде мәсьәлә иде. Беренчедән, пациентның чынлап та киллер икәненә тамчы да шик калмады – тыштан берни сиздермәсә дә, үз фотосын күргәч, тынычлыгы югалды... Икенчедән, аның табиблар белән уйнавы, симулянт икәне хак булып чыкты. Үз халәтен шул дәрәҗәдә контрольдә тота алу иң сәламәт кешеләрнең дә кулыннан килмәскә мөмкин. Ә бу хисләрен дә, тән күзәнәкләрен дә йөгәнли белә. Бу кеше инде кызганыч түгел, ә куркыныч иде.

Уйлар тынгысыз, ә тойгылар ничек кенә үткен булмасын, беркадәр ял итәргә кирәк иде. Зифа Саматовна өстәл тартмасындагы даруларны актарып бер таблетка алып эчте дә урын җәйде. Табиблар китеп өлгергәнче, беркадәр черем итеп алырга кирәк. Калганын күз күрер...

9

Төнге больница коридоры караңгы, палаталарның ябылып бетмәгән ишегеннән кемнеңдер гырылдавы, сызгыртып тын алуы, кемнәрнеңдер ара-тирә җиңелчә ыңгырашып куюлары да шушы караңгылыкка кушылып, тирә-якка шом өсти. Зифа үзе дә шушы тынчу-шомлы караңгылыкта эрегән, аның коточкыч бер өлешенә әверелгән һәм бернәрсәдән дә курыкмый, нәфрәттән башка бернинди хис тә кичерми иде. Көндезләрен атлап барганда, дөп-дөп итеп туфли тавышлары ишетелсә, әле ул бер тавыш та

чыгармый, хәтта аяклары да җиргә тими, ә йөзеп баргандай тоела. Бәлки, ул чынлап та йөзәдер... Әллә ничә еллар буена күңелендә кайнаган үч алу теләге, нәфрәт хисләре, югалту һәм ятимлек ачылары куерып, матди халәткә кергәндер дә хәзер Зифаны күтәреп алып барадыр сыман иде.

Ул кулындагы балтаны ныграк кысып тотты. Ит чабучыларныкы шикелле яссы итеп эшләнгән озын саплы үткен балта иде бу. Йөзенә чиртеп карады – «чең»ләгән тавышы бөтен коридорга таралып озак кына яңгырап торды. Үзе сатып алмады аны, бүлмәсендә кем калдырып киткәндер – монысы да, бәлки, югарыдан җибәрелгән бер билгедер. Җәзалау ысулы ничек булырга тиешлеге турындагы кисәтүдер.

Коридорда ят тавышлар ишетелмәде. Шәфкать туташларының бер ише йоклый, йокламаганнары башын өстәлгә кадап, аңгы-миңге утырадыр. Утырсыннар, авырулар тынычсызлана башласа, шундук сикереп торып эшкә тотына алар. Зифаның да күңеле тыныч иде. Анда бер тамчы курку да, кылачак эшенең барлык кануннарны җимерерлек икәнен уйлап чиркану да, бернәрсә дә юк. Шатлык бар. Гомер буе көткән бәхетенә ирешкән, гомер буе атлаган максатына җиткән кеше куанычы. Канәгатьләнү хисе, ләззәт тойгысы бар. Шуңа, ахры, ул үзен атлап түгел, ә йөзеп баргандай сизә.

Мең тапкырлар ачып кергән ишек ул килеп җитүгә бер тавыш-тын чыгармыйча үзеннән-үзе ачылды. Монысы да күкләр әмере белән эшләнде бугай. Шәфкать туташы монда юк иде, йомыш белән кайдадыр чыкканмы, башка палатага кереп киткәнме шунда. Ярый, бик яхшы. Зифа ишекне эчтән бикләп куйды да караватянына килде.

Үтерүче одеялга төренеп, йомарланып яткан. Сулышы тигез, димәк, йоклый. Йоклый... «Мин күпме төннәремне әткәм-әнкәм, сеңлем өчен кайгырып, керфек тә какмый үткәрдем, – дип уйлады ул. – Ә бу йоклый... Бер гөнаһ кылмаган изгеләр шикелле татлы мышнап, изрәп йоклый...» Һәм балта түтәсе белән аркасына төртте:

– Уян, кабахәт! Ни җаның белән йоклап ятасың?..

Үтерүче селкенеп тә карамады. Бу Зифаның ачуын гына чыгарды.

– Син үләргә тиешле кеше идең, – диде ул хөкем карары укыган тавыш белән. – Мин сине үлемнән алып калдым. Тормышка кайтардым. Мин! Сине! Әткәм-әнкәмне, бердәнбер сеңлемне тартып алып, мине гомерлеккә япа-ялгыз һәм бәхетсез итеп калдырган бәндәне...

Үтерүче бер хәрәкәт тә ясамады, бер тавыш та чыгармады. Ләкин Зифа аның уянганын белә иде. Хәлсез авыруга салышып ятса да, бу бәндә барысын да аңлый, ишетә, хәрәкәтләнә. Һәм ул зур ихтыяр көченә ия, сәгатьләр буена хәрәкәтсез торырга да сәләтле. Ләкин ул ишетә, аңлый һәм борчыла ала... Холтер аппараты шуны раслады.

– Нәфрәтем чиксез булса да, мин сиңа авыр хәлгә юлыгып, хастаханәгә кергән гадәти авыру, бәхетсезлеккә тарыган кеше итеп карарга тырыштым. Сине дәвалаган һәр мизгелем үз-үзем белән көрәшүдән, нәфрәтемне җиңәргә тырышудан торды. Һәм мин җиңдем. Ә син...

Сөйләгән саен Зифа ярсый барды, күңеле тулды, күзләренә яшь бөртекләре бәреп чыкты. Тик ул дәвам итте:

– Ә син үзеңнең кемлегеңне сиздермәс өчен башы эшләми, сөйләшә белми торган авыруга салышып яттың. Үзеңә гомер биргән, аякка бастырган

кешеләрне алдарга тырыштың... – Зифа балтасын күтәрде дә көч белән үтерүченең чәкәненә чапты. – Аяклар кирәкми сиңа...

Үтерүче ябынып яткан простыняның аскы өлеше канга батты. Ләкин саңгырау гына ыңгырашудан гайре бер тавыш та ишетелмәде. Бу Зифаның канын гына кыздырды, димәк, үтерүченең газаплануы тиешле дәрәҗәдә түгел. Ул баягы урынга тагын чапты, юрган ертылды, тирә-якка кан сиптерде. Өзелгән аякның берсе дөпелдәп, идәнгә төшеп китте. Әмма үтерүче элеккечә ыңгырашудан узмады. Бер мәлгә Зифа гаҗәпләнүдән катып калды. Юк... Акырырга, авыртудан тартышырга, акылын җуеп тыпырчынырга тиеш иде бит. Авыртудан туган шок шулай тәэсир итәме әллә кешегә?.. Тик икенче мизгелгә ул ерткычка әйләнде һәм үз-үзен белештермичә чапкаларга тотынды. Инде күзенә ак-кара күренмәде, кайсы җир эләгә – шунда бәрде. Күзләреннән яшь акты, ак халаты тулысынча диярлек канга манчылып бетте, тик хатын моңа игътибар итмәде, балта белән тураклавын белде. Бераздан тукталып калды:

– Үзең дә яшәү белән үлем арасында калып, шулкадәр авырлыклар кичергәч, мин синең азрак булса да, чистарынуыңны, кешелек сыйфаты алуыңны көткән идем. Тик син үзгәрмәдең, фәкать үзе турында гына уйлый ала торган кабахәт килеш калдың. Син – үтерүче һәм үлемең дә үтерүченеке кебек булырга тиеш.

Зифа аның башын каплап торган юрганны ачып җибәрде һәм катып калды. Бу аның пациенты түгел иде. Үтерүченең караватында бөтенләй бүтән кеше ята. Хатын-кыз... Зифа аны танымады һәм абайлабрак карар өчен күзен томалаган яшьләрне сөртеп алды. Ә кем икәнен аңлагач, башына суккандай катып калды. Бераздан коты алынып кычкырып җибәрде:

– Ә-ән-ни-и! Әнием!..

Канга баткан караватта аның әнисе ята иде. Зифа калтыранып кычкырды. Әлеге мизгел аның өчен аңлаешсыз да, куркыныч та, үкенечле дә... Шушы дәрәҗәдәге хисләрне аның гомер эченә бер тапкыр да кичергәне юк һәм Зифа бу басымга чыдый алмас, менә-менә шартлар кебек иде.

– Кызым... – Әнисе торып басты. Аның бер җәрәхәте дә юк, өстендәге туй күлмәгенә охшабрак торган киемнән нур бөркелә иде. – Кызым минем...

– Әни... – Әнисе торып баскач, Зифа беркадәр тынычланып калды. – Әни, синме бу? Үзеңме бу?

Хатын колачларын җәеп, әнисенә ташланды, әмма кочаклый алмады, куллары бушлыкны гына телеп үтте. Гаҗәпләнеп, артына борылып караганда, әнисе инде аз гына читтәрәк басып тора иде.

– Тынычлан, балам, – диде ул җанны эретерлек тавыш белән. – Күңелеңдә рәнҗеш уты йөртмә, ул ут синең үзеңне генә яндырачак. Рәнҗеш-нәфрәтләреңне оныт, үч алу теләгән җуй – күңелеңне чистарт. Шул чагында үзең дә газаплардан арынырсың, җаның якты тормышны кабул итәргә әзер булыр.

– Тик ул бит сезне...

– Кызым, без монда өчебез дә бик бәхетле... Үч алма безнең өчен, үзең өчен яшә.

– Тик мин бәхетле түгел...

Әнисе сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды:

– Син мине ишетәсеңме, балам? Күңелеңне чистарт... – Ул Зифаның чәчләреннән сыйпады. – Менә шулай... Хәзер бар да үтәр... Син олы йөрәкле бала. Горурланам, кызым, синең белән. Моннан соң да...

Әнисе нурга әверелеп, бүлмәне бер очып әйләнеп чыкты да тәрәзә төбендә туктап катып калды. Зифа күзләрен ачты. Тәрәзә төбендәге нур шул килеш иде. Ул әлеге хәлләрнең өнме, төшме, тормышмы, могҗизамы икәнен аңлап бетмәстән сак кына эндәште:

– Әни?

Тәрәзә төбендәге нур бер хәрәкәтсез калды. Зифа торып, шул якка атлады һәм моның тыштан төшкән кояш нуры икәнен аңлады. Өстәлдәге графиннан су салып эчте. Әле күргәннәре төш булды бит. Йа Ходай! Зифаның тамагына төер тыгылды. Һәм ул хәлсезләнеп, караватына ауды да үксеп еларга тотынды.

10

Әлеге күренешләрнең нибары төш кенә икәнен аңлау да тынычландыра алмады. Шулкадәр аермачык булып кергәнгәме, ул өн шикелле тоелды, кылган гамәлләрең өчен үкенергә, ялгышыңны аңлап әрнергә мәҗбүр итте. Мондый хәлләрнең хәтта төшеңә керүе үзе үк гарьлек булып тоелды. Балта белән бит... Бер хәрәкәтсез яткан кешене... Кем икәнен дә белешеп тормастан... Ләкин ачы тойгылар давылы узгач, күңеле беркадәр тынычланып калды. Хәтта нindидер шатлык хисе биләп алды. «Ярый, дәваладым әле, – дип сөенде ул. – Ярый әле кичерешләремә бирелеп, ялгышлык эшләп ташламадым. Ә бит җәзалау һәм үтерү теләге көчле иде. Хәтта укол да әзерләп куйган идем бит...»

Зифа төнен авыру янына барырга туры килсә дип әзерләп куйган уколын халат кесәсеннән алды да чүп савыты янына килде, ыргытырга уйлагач тыелып калды. Монда ташларга ярамый инде. Урамга чыккач, чүп савытына бәреп китәр әле. Уколны ул хатын-кыз сумкасының тышкы кесәсенә салды. Тагын су салып эчте. Менә сиңа кизү табиб!

Беркем дә кереп уятмаган, бүгенге төн шулкадәр тыныч узды микәнни? Бәлки, шулайдыр да. Була андый вакытлар. Әлегә бәйрәмнәр дә, шау-шулы вакыйгалар да юк. Ышанмаслык түгел. Гадәттә, бәйрәмнәр, спорт ярышлары вакытында халык күп травма ала, кайчагында чәй эчәрлек тә вакыт калмый, кеше өстенә кеше өелә. Ә бүген...

Кизүгә калуы да, төш күрүе дә яхшы булды бугай. Югыйсә һаман газапланып, ниятен чынга ашыру турында уйланып йөрер иде әле. Ә бүгенге төше... Әнисен күрде ул... Әнисе аның күңелендәге кабахәт уйларны алып ташлады. «Күңелеңне чистарт. Шул чагында үзең дә якты тормыш белән яши башларсың... Горурланам, кызым, синең белән...» – диде. Әниләрнең тавышын төштә ишетү дә бәхет бит ул. Ә көн саен өндә ишетүчеләр моны аңлый микән? Кадерли микән? Шушы тавыш Зифаны үзгәртте бугай... Чынлап та үзгәртте... Ничек икәнен төгәл генә әйтә алмаса да, ул үзенең үзгәрүен, аз гына башка кешегә әйләнүен үзе дә тоя. Һич югында, аның инде теге бәндәне үтерәсе дә, җәзалыйсы да килми. Яши бирсен, әйдә. Ходай бар ул, үзе хәл итәр. Хәшәрәтләрне җәзага тарттырырга теләп, Ходайга комачаулап йөрергә кирәкми. Үзенең бу уйларыннан Зифа елмаеп куйды.

Кинәт ишек шакыдылар да шәфкать туташы керде:

– Хәерле иртә, Зифа Саматовна! – диде ул күтәренке кәеф белән. – Бүген төн тыныч узды әле. Әллә сез кизү булганга...

– Үзем дә шуны гына уйлап тора идем, – дип елмайды доктор. – Кофе эчеп алабызмы?

– Әйдәгез, мин кайнатып куйдым инде, чакырырга дип кергән идем.

– Рәхмәт, хәзер киләм.

– Яхшы, әзерли торам. – Шәфкать туташы ишеккә җиткәч, кире борылды. – Зифа Саматовна, карагыз әле, ә теге билгесез пациентны кая күчердегез сез?

Доктор халатының бер җиңен кигән көйгә катып калды:

– Нинди билгесез пациентны?

– Соң...

Сүзнең кем турында барганын табиб үзе дә чамалаган иде инде. Ул халатын кия-кия ишеккә атлады:

– Беркая да күчермәдем...

– Урынында юк бит...

– Ничек юк? Сез нәрсә сөйлисез!

Үтерүче... Юк ла, пациент караватында да, бүлмәдә дә, якын-тирәдә дә юк иде.

– Сез берәр җиргә күчергәнсездер дигән идем, – дип акланды шәфкать туташы. – Сезнең пациент бит...

– Ник хәбәр итмәдегез?

– Уятасым килмәде.

Бүлек мөдире аңа бик яман итеп, нидер әйтергә теләде дә дәшми калды. Ни дип әйтәсең инде? Үзең йоклап яткан көйгә, кешене тиргәп буламыни? Тиз арада бөтен бүлекне аякка бастырдылар. Хастаханәдә дежур торучыларны, вахтёрларны җыйдылар. Әмма беркем берни күрмәгән булып чыкты. Пациент эзсез югалды.

Бүлек, хастаханә генә түгел, гомумән, шәһәр тарихында мондый хәлнең беркайчан да булганы юк. Баш сөягенә операция ясаганнан соң түшәк режимында яткан пациентның юкка чыгуы гадәттән тыш хәл, моңа берничек тә ышанырлык түгел иде. Әлбәттә, «түшәк режимы» дип әйтүнең беркадәр дәрәҗәдә шартлы икәнен Зифа аңлый инде. Мөмкинлекләренең ни дәрәҗәдә икәнен төгәл билгеләү авыр булса да, пациентның озак вакыт буена симулянт булып, авыр чирлегә салышып ятуына хәзер шик калмады. Әмма шулай кинәт юкка чыгуы беркадәр сәер иде. Ә бу юкка чыгуның нәкъ менә Зифа Саматовна кизү торганда булуы гарьләнергә дә мәҗбүр итте.

Гайре табигый хәлләргә бик шикләнеп караса да, доктор хәтта мистикага да бирелеп алды. «Төш дип уйлаганнарым чынбарлык түгелме? Мин аны чынлап та үтереп, мәетен берәр җиргә яшереп куймадыммы?» – дигән сорауга да җавап эзләргә мәҗбүр булды. Беркемгә дә сиздермәскә тырышып, үзенең киемнәрен барлап чыкты – кан тамчысы яки башка төрле җинаять эзе юкмы дип тикшерде. Үз бүлмәсеннән дә, пациент яткан палатадан да шуңа дәлил булырлык детальләр эзләде. Швабраларны, чиләкләрне, химик препаратларны

карап чыкты. Бернинди шикле нәрсә юк. Ахыр чиктә тынычланып калгандай булды. Төш кенә... Әгәр шулкадәр кабахәтлек өндә булса, кешеләр игътибарыннан читтә калмас иде. Идәнгә агып төшкән канны юар өчен генә күпме тырышырга кирәк...

Кичкә кадәр эзләсәләр дә, пациент табылмады. Тик вахтада торучы ирләрнең берсе үзенең киемнәре югалуны хәбәр итте. Монысы була торган хәл, тиешле-тиешсезрәк җирдә торса, бутап алып китүләре дә бар. Шулай да бу вахтёрның гәүдәсе пациентныкы шикеллерәк булуын күргәч, Зифа Саматовна киемне кем алганын аңлагандай булды.

Бер карасаң, артык гаҗәпләнерлеге дә юк бит инде. Үзенең шәхесен ачыклауларын теләмәгән пациент хәле яхшыргач та, ай буена көч җыеп, киләчәккә план корып ята, ял итә. Һәм көннәрнең берендә... Дәвалаучы табиб күрсәткән фоторәсем буенча, ул үзенең эзенә төшүләрен чамалый һәм монда калуның куркыныч икәнен аңлап, тиз арада качып китәргә мәҗбүр була. Ә медицина хезмәткәрләренең берсе дә аны йөри ала дип уйламый, шуңа күңелләре тыныч, караватында чәбәләнеп ятмый икән, борылып та карамыйлар. Бу аның бер өстенлеге. Икенчесе – мондагы авырулар, нигездә, түшәктә генә ятучылар. Аягында булмагач, беркем беркемгә игътибар итми. Ә коридор тыныч һәм ярымкараңгы. Кыскасы, бу бүлектән качарга ниятләгән кеше теләгән вакытында урыныннан торып чыгып китә ала. Бер катлаулыгы да юк. Ә заманында КГБ мәктәбен үтеп, гомер буе җинаятьчелек сукмагында йөргән бәндә өчен – бигрәк тә.

Хастаханә җитәкчелеге бик безләсә дә, бүгенгә беркайда да хәбәр итми торырга булды. Әгәр иртәгә дә табылмый икән – монсы инде башка мәсьәлә.

Шул рәвешле анда-монда сугылып, көнозын чабып йөреп, кич җитүгә үз бүлмәсенә кереп кенә утырган иде, ишек шакыдылар.

– Зифа Саматовна кирәк иде, – диде ишектән узган әзмәвер. Иңенә япкан ак халат әбиләрнең ак шәле кебек кенә күренә, ә аягындагы бахилла менә-менә ертылып китәр шикелле. Кыяфәте көлкеле булса да, йөзе кырыс, үзе җитди иде. – Мин бик четерекле бер эш буенча. Тик вакытыгызны күп алмам.

Тавышы да әллә кайдан – үпкә төбеннән чыга торган калын тавыш. Шкаф хәтле гәүдәсенә килешеп тора. Йөзендә хис эсәре чалынмый, күзләрендә нур да чамалы. Мондый кешеләрне дә күргәне бар Зифаның. Ул хәтта аның нindirәк даирә кешесе булып, нинди йомыш белән килүен дә сизенде. Шулай да ачылырга ашыкмады:

– Әйтеп карагыз.

– Бер яхшы кешегә медицина ярдәме кирәк. Түләү яхшы.

– Алып килдегезме?

– Монда күренергә ярамый аңа.

– Гафу итегез, мин криминал белән шөгыльләнмим.

– Сез мине аңламадыгыз, – дип, аның каршысына килеп басты әзмәвер. – Мин сезгә яхшы түләнә торган эш тәкъдим итәм. Кыска вакытлы эш. Ризалашсагыз, әлбәттә.

– Мин ризалашмыйм.

– Ул чакта без башкача эшләргә мәҗбүр булачакбыз.

Әзмәвернең бу сүзе янау иде. Тик Зифа Саматовна дулкынлануын сиздермәскә тырышты:

– Куркытырга маташучылар җитәрлек монда, – дип елмайды ул. – Яки пациентны монда китерәсез, яки...

– Докторны аның янына илтәбез, – дип бүлдерде әзмәвер. – Без әле бүген тагын очрашырбыз. Хәзергә сау булыгыз.

Ишек төбенә җиткәч, кире борылды:

– Бәлки, барсын да үзара килешеп, тыныч хәл итәрбез?

Зифа дәшмәгәч, чыгып китте.

Фу-у-у... Җинаятьчеләр белән генә маташу җитми иде бүген... Зифа Саматовна инде күпне күргән табиб, мондый тәкъдимнәргә ризалашмауның куркыныч икәнен яхшы аңлый. Ләкин ризалашу тагы да начаррак булырга мөмкин. Бер тапкыр бәйләнденңме, ничек кереп батканыңны да сизми калырсың, ул сазлык шикелле... Һәм мондый сазлыкта юкка чыккан табиблар аның танышлары арасында да бар иде. Тагы шул Артур Илдаровичка барып егылырга туры килә инде...

Кизү торган табиб буларак, иртән үк кайтып китәргә тиеш иде ул. Пациентының югалуы эшне бозды. Хәзер үзен тыны чыгып беткән туп шикелле тойды һәм тизрәк өенә ашыкты. Кайтырга да ятарга... Юк, башта яхшы гына итеп юынып алырга... Ашарга да кирәк инде... Һәм йокларга... Тыныч, тирән, сәламәт йокы кирәк. Шунсыз булмый.

Өстен алыштырып, сумкасын кулына тотуга теге шприц турында исенә төшерде. «Эчендәге препаратны агызып, шприцны чүпкә генә ыргытасы инде. Нәрсәгә дип, сумкада тотарга, урам буйлап чүп савыты эзләп йөрисеңмени?!» – Шул уйлар белән раковина ягына атлаганда, ишек тукылдатып та тормастан полиция тикшерүчесе килеп керде. Зифа кулындагы шприцын пинжәк кесәсенә яшерде.

– Саумысыз, Зифа Саматовна, – диде тикшерүче аны гаепләргә җыенган кыяфәт белән. – Пациентыгыз аякка баскан дип ишеттем. Ә сез аны сөйләшми дигән идегез.

– Сөйләшми иде... Йөрмәде дә.

– Аңлашыла. – Тикшерүче астыртын елмайды. – Очып киткән. Канатланган.

– Айга якын хәйләләшеп яткан ул...

– Симулянт, димәк... – Тикшерүче өстәл артына барып утырды. – Ә бит мәсьәләгә болай да карарга мөмкин. Сез аның чын хәлен яшергәнсез һәм качып китәргә булышкансыз...

– Нәр-сә?!. – Бу кешене пыр туздырып ташлау теләге көчле булса да, тыелып калды. – Кирәк булгач, саклап торырга иде. Ике тапкыр килдегез дә башкача күренмәдегез бит. Ә мин...

– Ни өчен нәкъ менә сез кизү торган чакта юкка чыккан ул? – дип бүлдерде тикшерүче. – Очраклы хәл алай булмый.

– Белмим, анысы сезнең эшегез. Минем эш – дәвалау. Мин аны аякка бастырдым. Ә шәхесен ачыклау, кайда икәнлеген табу – сезнеке. Гафу итегез, мин арыдым, өйгә ашыгам. Ә сез, кем генә булсагыз да, медицина бүлегенә халат һәм бахилла киеп керергә тиеш идегез.

Бүлек мөдире өс киемен эләктерде дә ишеккә юнәлде:

– Сез чыгарга уйлыйсызмы, өстегездән бикләп китимме? – диде ул кузгалырга уйламыйча утырган тикшерүчегә. Теге торып басты да гафу үтенергә ашыкты:

– Гафу итегез, Зифа Саматовна, – диде ул күңел болгатырлык ясалмалылык белән һәм кочаклап алды. – Ләкин...

Табиб аны этеп җибәрде

– Хушыгыз! – дип кистерде ул. – Күземә күренмәгез.

Һәм ишекне бикләгәч, тек-тек басып атлап китте. Ишек төбендә басып калган тикшерүченең телефоннан сөйләшкәне ишетелде: «Пациент табылмады, ә док өенә кайта...» Зифа бер мәлгә тукталып калды. Тикшерүченең янына барып, тиргәп ташлау теләге ялтлап китте. «Нәрсә дип минем хакта исәп-хисап бирә ул?! Ни хакы бар?!» Тик кире борылу хәлен алыр сыман тоелды һәм юлын дәвам итте.

11

– Шайтан алгыры! – дип сүгенеп куйды доктор үзенең машинасы янына килеп җитүгә. – Нинди каһәрле көн булды бу?!.

Башта бер генә тәгәрмәченә күзе төшкән иде, ныклабрак карагач, икенчесен дә күрде һәм машинасын әйләнеп чыгарга мәҗбүр булды. Кайсыдыр имансызы аның дүрт тәгәрмәченең дә тынын чыгарып киткән. Теге әзмәвернең үч алуы шул булдымы икән? Үзенчә кисәтү инде бу. Моның белән генә бетүе дә икеле. Кайту белән шалтыратырга кирәк.

– Шайтан алгыры!..

Автосервис юллап йөрсәң, тагын ярты төн җитте дигән сүз. Ул тирә-ягына каранып алды. Якында гына бер такси машинасы кузгалып китәргә тора иде. Зифа кул болгады. Китте... Шайтан алгыры! Юк, туктады. Хатын шул якка ашыкты. Караңгы төшкән иде инде, каршы килгән машиналарның фарасыннан күз чагыла дип, алга утырмады. Адресын әйтте дә, арткы ишекне ачты. Йомшак, җылы урынга кереп утыргач бөтен тәне йомшарып, изрәп киткәндәй тоелды. Һәм ул ләззәтләнеп күзләрен йомды. Их, беркая да бармыйча шушында гына йоклап китәсе иде.

– Гафу итегез, – диде ул күзләрен ачмыйча гына. – Мин бик арыдым, чүт кенә йоклап алам. Ә сез адресны беләсез...

– Әйе, – диде таксист. – Әйттегез.

Тавыш таныш кебек тоелды. Тик талчыгу үзенекен итте. Билгесезлек, анда-монда сугылу, гарьләнү һәм тагын әллә күпме кичерешләр... Өстәвенә теге бандит... Һәм мент... Кочакларга маташа бит әле... Әллә бөтен дөнья сантыйланган инде?.. Болар иң катлаулы операциядән дә ныграк арыта шул... Берничә минут үтүгә үк Зифа инде йокыга талган иде.

Зифаның күз алдында бер көчәеп, бер сүрелеп ут яктысы уйнаклады. Каршыга килүче машиналарның фара яктысы булды бугай. Ул башын түбәнгәрәк иярргә тырышты, әмма утлар югалмады. Борылып утырыргамы соң? Әмма үзендә хәрәкәтләнерлек көч тапмады. Йокы аралаш булгач, мускуллары буйсынмый, ихтыяры йомшарган. Әмма көтмәгәндә, ут шарларының берсе аның янындагы утыргычка күчте дә адәм рәвешенә керде. Бу хатын-кыз иде. Яшь, чибәр... Йа, Ходай! Әнисе ләбаса! Зифа авыз ачып өлгергәнче, әнисе аның чәчләреннән сыйпады:

– Тор, кызым!.. Уян... Соңга каласың бит!..

– Әни!

Тик яктылык кинәт югалды. Зифаның колагында «Соңга каласың

бит!» – дигән сүзләр генә яңгырады. Ул мизгелләрне әле дә хәтерли Зифа. Әнисе бакчага барганда да, мәктәпкә йөри башлагач та шулай уята иде. «Тор, кызым... Уян...» Тавышы да ягымлы иде ул чакларда. Ә әле... Әле аның тавышы ничектер сәер тоелды. Борчылган, кабаланган кебек. Нигә борчыла, кайда ашыга икән?

Аз гына, тагын биш кенә... юк, җиде генә минут... Кинәт аны әнисе... юк, әтисе бугай... әйе, әтисе күтәреп алды да каядыр атлады. Ваннага булырга тиеш. Хәзер ишек төбендә төшерә дә әйтә инде: «Юынырга кирәк. Матур кызлар һәрчак чиста булырга тиеш.» Ә Зифа кабат үз бүлмәсенә йөгерә. Йокысы ачылган инде, тик урында яту рәхәт. Әллә ничек рәхәт инде менә, әйтеп аңлатып булырлык кына түгел... Тик әнисенең тавышы... Ул бүген әллә нинди...

Шулай иркәләнеп, назланып тагын аз гына яту теләге көчле булса да Зифа әнисенең тавышына сәерсенеп күзләрен ачты. Тирә-ягына каранып алды, әнисен эзләде... Тик караңгылыктан башка нәрсә юк иде. Ходайның рәхмәте! Төш кенә булды, ләбаса! Тик әниеңне төштә генә, кыска вакытка гына күреп калу да бәхет иде. Әниләрен көн саен өенндә күрүчеләр моны аңлый микән? Кадерли микән?

Ләззәтле уйлардан арынасы килмәсә дә, чынбарлыкка кайту мәҗбүри иде. Зифа үзенең кайда икәнлеген исенә төшерергә тырышты. Таксида ул... Өенә кайтып бара... Ләкин урамда утлар күренми... Тик алар булырга тиеш бит, Зифаның өенә кайткан юлда, шәһәр урамында... Юл да, тәрәзә дә, такси да юк иде...

Караңгылыкка күзе ияләнә төшкәч, ул үзенең ниндидер бүлмә уртасында, йомшак кәнәфидә утыруын аңлады. Тәрәзә кебек нәрсә дә юк. Утырган урынын капшап карады, чынлап та кәнәфи бу. Йомшак. Үзе хастаханәдән ничек чыкса, шул килеш. Чишенмәгән дә. Бәлки, таксист аны күтәреп фатирына кертеп куйгандыр? Кайдан белә инде ул фатирыңны? Бәлки, йокылы-уяулы килеш үзе кергәндер дә, черем итеп алгач, хәтереннән чыккандыр. Һич югы таксистка акча түләгәнен хәтерләргә тиеш бит инде...

Зифа торып басты. Бер адым атлады... Кыска гына адым... Үзе теләгәнчә атларлык мөмкинлеге юк, аяклары тышаулы. Тагы ярты адым... атламакчы иде... тигезлеген югалтып кабат креслога ауды. Күңелен курку яулап алды, куркуы ярсуга әйләнде һәм ул дәһшәт белән кычкырды:

– Бармы монда берәрсе! Кайда мин?

Тик эндәшүче булмады. Хатын тагын бер тапкыр кычкырып карады да моның файдасыз икәнен аңлап тынып калды. Иелеп, аякларын капшады. Бау гына да, чылбыр да түгел. Ниндидер тимер җайланма белән эләктерелгән һәм берничек тә ычкынырлык түгел. Иелгән уңайга идәнне капшады – таш. Шунда кулы ниндидер йомшак нәрсәгә тиеп китте. Сумкасы. Аны күтәрде дә ашыгып актарырга кереште. Документлары урынында. Акчасы да. Хәтта телефонына да тимәгәннәр. Шалтыратырга кирәк! Ул каударланып, телефонын актара башлады. Артур Илдаровичка хәбәр итәргә. Аның номерын табу белән чакыру төймәсенә басты, әмма берни дә үзгәрмәде – чакыру юк иде.

– Шайтан алгыры! – дип сүгенде хатын, телефонына карап – Тотмый... Бер шкаласы да юк... Кайда соң мин?!.

Һәм ул башка төймәләргә басты. Башка вакытта мондый чакларда экранда әйләнгеч түгәрәк хасил була да, беркадәр вакыттан соң нинди дә булса челтәрне табып ала. Рәхәтләнеп сөйләшеп булмый инде, шулай да ярдәм чакырырга була. Тик бу юлы экранда хәтта түгәрәк тә барлыкка килмәде. Бу урында телефонның бер файдасы да юк иде. Хәер, бар!

Зифа телефонның фонарен кабызды. Ул бүлмә уртасында түгел, ә стена буенда икән. Стеналар как кирпечтән генә тора, идәнгә җәелгән плитәнең төсе уңа башлаган кебек. Ул иске кәнәфидә утыра. Каршыдагы стенада плафонга тартым әйбер тора, аның астында – артсыз урындык. Иске. Түшәмдә дә плафон бар икән. Тәрәзәгә охшаган нәрсә юк. Берни дә юк. Фатир түгел, фатир болай булмый. Телефон тотмавын исәпкә алганда, шәһәр читендәге яки берәр авылдагы яхшы гына йортның подвалы булырга мөмкин...

Ничек монда килеп эләкте соң? Әзмәвер... Тикшерүче... Тәгәрмәчләре тишелгән машина... Такси... Очраклы рәвештә эләктеме ул бу таксистка? Әллә тәгәрмәчләрен тишеп куеп, күз төшәрдәй уңай урында көтеп тора идеме? Димәк, ул Зифаны таный. Машинасын белә. Тик ни өчен? Димәк, әзмәвер... Шул дәрәҗәдә тиз һәм оешкан рәвештә эш итәләр. Ә полиция беркайчан да болай тиз була алмый. Бу илдә җинаятьчелек мәңге бетмәячәк.

– Мин риза түгел! Барыбер мәҗбүр итә алмаячаксыз!

Кинәт аяк тавышы ишетелде. Зифа ашыгып, телефонын сумкасына тыкты. Ишектә ачкыч әйләнгән тавыш ишетелде, һәм бераздан ул ачылып китте. Каршы яктагы плафон... юк, ул прожектор икән... кабынды һәм аның бөтен нуры Зифаның күзен томалады. Бүлмәгә яктылык таралса да, керүченең кем икәне күренми.

– Сез кем? Мин кайда?

Керүче дәшмәде, янына килеп сумкасын алды да каршыдагы стена буендагы урындыкка барып утырды. Зифа аның ир-ат икәнлеген абайлады, әмма йөзен күрә алмады. Ир ашыкмый гына сумканы актара бугай, Зифа моны күрмәде, әмма тавыш буенча шулай аңлашыла иде.

– Сез кем? – дип кычкырды ул, аяклары белән идәнне төеп. – Нигә мине монда китердегез?

Каршы яктан кычкырып көлгән тавыш ишетелде. Ихлас көлү түгел. Истерикларча да түгел. Әллә нинди салкын һәм тигез тавышлар тезмәсе иде бу. Тыныч, тигез, хиссез... Шуңа да ул ялангач таш бүлмә эчендә бик куркыныч булып ишетелде.

– Мин сездә озак сыйландым, доктор, – диде бераздан керүче. – Хәзер миндә кунак булырга вакыт.

Зифаның тәне эсселе-суыклы булып китте. Таныды. Тавышы теге чакта юкка гына таныш сыман тоелмаган. Бу – аның югалган пациенты иде. Киллер. Пистолет Тоткан Егет.

12

– Үлемнән йолып калган кешене яхшырак җиргә чакырсагыз да булыр иде, – диде Зифа, тынычрак булырга тырышып. Ә тынычлык аңа кирәк хәзер. Каршысында торган бәндәнең кем икәнен ул яхшы аңлый, аны җиңү, һич югы дәрәҗәңне төшермичә үлү өчен салкын канлылык кирәк. Ә бу

авыр, хәтта мөмкин түгел кебек. Бөтен күзәнәкләренең ничек дерелдәп, тибрәнеп торуын ул үзе дә тоя шикелле. Әмма тавышы тигез чыккандай булды. Аз гына юаныч инде.

– Гафу итегез, – диде киллер җитди генә. – Башка мөмкинлек булмады. Ә мин сезне чынлап та бүтән урынга чакырып, рәхмәт әйтергә теләгән идем.

– Әгәр теге фотоны күрсәтмәгән булсаммы? – Зифа елмайды һәм үзенең елмая алуына үзе дә аптырап куйды. – Аңлыйм.

– Сез берни дә аңламыйсыз. – Үтерүче бер мәлгә тын калды. – Нәкъ менә сез кичергәнне мин дә кичердем. Үзләренә хезмәт иттерергә теләп, әти-әниемне, хатынымны һәм улымны атып үтерделәр. Бу гамәле өчен теләсә кемне җир астыннан табып, юк итәргә әзер идем. Үзем ачыктан-ачык тикшерү алып бара алмыйм, бу минем һөнәр кешесенә куркыныч иде. Һәм гаиләмне заказ биреп үтертүчене таптылар. Меркуно кушаматлы рэкетир тапты. Бандит. Заказчы – бер завод директоры урынбасары, имеш. Гаиләсе, ике кызы бар. Ышанмадым. Дәлилләр китерделәр, кире каккысыз – бөтен мәгълүматлар шуңа илтә. Һәм мин бер кичне кереп, барысын да атып чыктым... Ул сезнең гаилә иде.

– Юк, – дип ярсыды Зифа. – Дөрес түгел. Сез алдыйсыз...

Ул ярсуына тончыгып тынып калды, киллер дәвам итте:

– Алдамыйм. Тик мин ялгышкан булып чыктым. Меркуно үзенә буйсынмаган кешене юк итү өчен мине ялган юлдан җибәргән. Дәлилләре дә, барысы да – «юкә чөй». Минем гаиләмне юк итүче дә Меркуно үзе булган. Моны мин соңыннан гына белдем. Ә белгәнемне аңлагач, үземә ау башланды. Һәм мин үз үлемемне оештырдым. Шау-шу басылып, барысы да урынына утыргач, Меркуноның үзен юк иттем. Бөтен бандасы белән...

Зифа ярсырга, котырырга, өзгәләнергә тиеш кебек. Әмма ул ничектер тыныч калды. Бүгенге төшендә әнисенең әйткән сүзләре чынга аштымы соң әллә?!. Күңеле чынлап та чистарынып калдымы? Ничек кенә булмасын, ул киллерның хәбәрен салкын кан белән кабул итә иде.

– Мин сиңа рәхмәтле булырга тиешме? – диде ул тимерне чатнатырлык салкынлык белән. – Ә сеңлемне нигә? Биш яшьлек сабыйны!..

– Шаһитлар калмаска тиеш, – диде киллер тыныч кына. – Мин сезне дә үтерергә тиеш. Тик ул чакта шаһитлар турында уйламадым. Мин үч алдым...

Аның тынычлыгы Зифаның сабырлыгын өзде һәм ул утырган җиреннән алга омтылып куйды, тик кабат кәнәфигә ауды. Шулчак кулы кесә тирәсенә туры килде дә ниндидер каты нәрсәгә эләкте. Бу шприц иде... «Тыныч булырга кирәк, – дип кабатлады доктор күңеленнән. – Тынычлык һәм салкын акыл».

– Сез минем йөземә яктыртасыз... – диде ул канәгатьсезлек белән. – Бер-беребезне күреп сөйләшергә кирәк. Болай дөрес түгел.

Киллер урыныннан кузгалды. Каршыдагы прожекторны сүндерде дә түшәмдәге плафонны кабызды. Ул арада Зифа кесәсендәге шприцның энәсен ачып, җиң эченә яшерде. Якын гына килсен, ә ул уколны ничек кадарга кирәген бик яхшы белә. Бары тик тыныч булырга кирәк. Һәм аны чыгырыннан чыгарырга...

– Шулай яхшымы? – Киллер кабат урынына барып утырды, Зифа сискәнеп китте, аның кулында пистолет иде. – Яктыда сөйләшик.

– Күзгә күз карап! – Зифаның тавышы таләпчән яңгырады. – Бәлки, сез алдашасыздыр. Якынрак килегез.

Киллер кабат урыныннан торып, аның янына килде. Докторның күзләренә карады. Чүгәләде. Бу иң уңайлы мизгел иде. Зифа тирән итеп сулыш алды. Тыныч булырга кирәк. Һәм игътибарын читкә юнәлтергә.

– Ник минем аякларым богаулы?

– Кулларыгызга кагылырга кыймадым, – диде киллер җитди итеп. – Алар...

Кинәт Зифа шприц тоткан уң кулын яшен тизлеге белән киллерның ботына юнәлтте. Ир ниндидер хәрәкәт ясады. Зифа башта берни аңламады, шприцны аның кулында күргәч кенә күзләре шар ачылды. Ничек? Ничек алай булырга мөмкин? Шундый кыска, җитез хәрәкәтне ничек шулай...

– Сез яхшы табиб, ләкин начар киллер, – дип, ул шприцны читкә атып бәрде. – Ә мин киресенчә...

Зифа дәшмәде. Ул һаман һушына килә алмыйча учларына карап тора иде. Киллер урынына барып утырды да пистолетын кулына алды. Глушителен бора башлады:

– Сезнең мине юк итәргә әллә күпме мөмкинлегегез бар иде. Тик сез аның берсен дә файдаланмадыгыз. Хәзер менә минем сезне юк итү мөмкинлегем бар. Һәм аны файдаланырга тиешмен. Чөнки сез исән булсагыз, мин тынычлыкта кала алмаячакмын.

Ул хаклы. Зифаның әллә күпме мөмкинлеге булды. Бернәрсә дә эшләмичә, чын мәгънәсендә, берни дә кылмыйча гына торса да, бу бәндә үлемгә дучар иде. Ә ул эшләде... Ул аны аякка бастырды. Һәм менә... Кешене коткарырдан алда аның яшәве нинди нәтиҗәләргә китерәчәген уйларга кирәк икән. Ә Зифа менә уйламады... Ул үзен үтерәчәк кешене үлемнән алып калган икән... Үзенең әҗәлен коткарган.

– Үкенмәгез. – Үтерүченең тавышы тыныч һәм ягымлы иде. – Сез мине үлемгә бирмичә дөрес эшләдегез. Табибларның шулкадәр тырышуын күреп, мин үземә меңәр тапкыр бер сорауны кабатладым: «Болар минем кемлегемне беләләр микән?» Ә дөрес җавап һәрвакыт бер генә булды: «Юк, әлбәттә! Юк!!!» Сезнең тырышлыкны, борчылуларны күреп, үземне алдакчы итеп тойдым. «Шулкадәр өзгәләнмәгез, юньлерәк кешеләргә ярдәм итегез», – дип әйтергә теләдем. Тик йөрәк җитмәде...

Зифа аны ишетте, әлбәттә. Ләкин аның уйлары бөтенләй башка юнәлештә йөрде. Ничек котылырга? Холкының нинди төймәләренә басып, күңелен йомшартырга? Ничек котылырга? Ләкин берниндн җавап та табылмады. Әллә аның башы начар эшли, әллә чынлап та котылу юлы юк.

– Иң якыннарымны югалтып, ялгызым калганнан соң, берни сорамыйча, берни таләп итмичә ихлас ярдәм күрсәтүче беренче кешеләр сез идегез. Бары тик сезгә эләккәч кенә, мин үземне кеше итеп тойдым. Исемсез, көчсез, зәгыйфь килеш тә мин кемгәдер кирәк идем. Мин гомерем буе үземне үтерергә теләгән кешеләр арасында яшәдем, үзем дә үтердем. Ә монда... Мондагылар мине яшәтергә тырышалар иде. Сез... Сез аеруча, Зифа Саматовна.

Зифа дәшмәде. Ни генә әйтсә дә, бүлмәдәге халәтне бозар төсле тоелды. Ә бер карасаң, бу кешенең сүзләрендә дә дөреслек бар бит.

– Тик һәрвакыт: «Кемлегемне белсәләр, шундук сөреп чыгарачаклар», – дип курыктым. Шуңа күрә... Ә сез... Ә сез барысын да белгән булгансыз... Сез кемлегемне белгән килеш... Гаиләгезне юк иткән кеше мин икәнен аңлаган килеш... Бу дәрәҗәдәге изгелек хәтта мине дә тетрәндерде... Рәхмәт сезгә!

Киллерның тавышында беренче тапкыр калтыранып алу ишетелде. Ул урыныннан кузгалып, бүлмәне әйләнде дә ишеккә капланып тынып торды. Аннан соң ачкычны борды.

– Басыгыз, Зифа Саматовна.

Докторны күтәреп, стенага каратып бастырып куйды. Хатын баштарак тыныч булырга тырышса да, хәзер бар дөньясын калтырау ялмады. Шулай да ул:

– Үтерәсезме? – дип сорый алды.

– Үтерәм. – Ир тыныч иде, ул хатынның аякларын богаудан арындырды. – Сезнең пинжәгегезгә маяк беркетелгән иде. Мин аны урамдагы агачка кадап киттем. Сезне монда калдырмаячаклар, килеп алырлар.

Ниндидер билгесез подвалда сасып, череп ятмавың да юаныч инде, бер карасаң. Яхшы килеп чыкмады шулай да. Әллә күпме кешеләргә гомер бүләк итте, ә үзе бер бала да үстермәде. Уйлап та карамады. Нәсел җебе өзелә инде хәзер. Әти-әниеңнәрнең дәвамы калмый, бар да синең белән китә. Нишлисең инде...

– Зифа Саматовна, соңгы сүзегез бармы?

Аркаңа пистолет төбәлеп торганда, ни әйтәсең инде? Сүзең булса да, сөйләрлек түгел...

– Юк...

– Ә минем сезгә бар...

Тавышы шундый тыныч, ягымлы... Кеше үтерергә түгел, ә дога укырга җыена, диярсең...

– Тормыш мине ерткыч иткән иде, сез кешегә әйләндердегез... Кызганыч, соңга калынды...

Бер мизгелгә тынлык урнашты. Зифа күзләрен йомды. Кабарткыч шартлаган кебек кенә булып пистолет тавышы ишетелде. Зифа гаҗәпләнү катыш күзләрен шар ачып тынып калды һәм буыннары йомшарып, акрын гына стена буйлап шуып төште…

Бераздан дөпелдәгән тавышлар ишетеп, ишек ягына борылды һәм идән уртасында кан эчендә яткан киллерга күзе төште. «Әтинеке кебек...– дип уйлады Зифа аның маңгаендагы пуля эзенә карап. – Димәк, ул үзен-үзе...»

Икенче мизгелдә ишек ачылып китте, һәм бүлмәгә кораллы кешеләр кереп тулды. Ыгы-зыгы башланды. Тик Зифа аларны ишетмәде. Колагында һаман да киллерның соңгы сүзләре яңгырый иде.

Ләбиб
Лерон

ВАКЫТНЫ ШУЛ БУЛМЫЙ ТУКТАТЫП...

Вакыт җитми, дибез...

Ашыгабыз һаман...
Хафаланып,
Өтәләнеп, дөнья көтәбез.
– Вакыт юк бит! Вакыт җитми! – дибез,
Эш күплекне сылтау итәбез.

Вакыт, вакыт...
Барысын да уптым
Без бәйлибез мескен вакытка.
Вакыт юк бит, дибез... Ник булмасын!
Без үзебез – вакыт... Факытта!

Әйтерсең лә, вакыт – дөньялыкта
Сирәк очрый торган бер нәрсә.
Кирәк булса, теләк булса әгәр,
Вакыт табабыз бит югыйсә!

Ничек итсәк итик, әмма табыйк,
Зарланмыйча табыйк вакытлар!
Вакытларың булыр бервакытны...
...Югалтканны булмас табыплар.

Бүген гүя үлеп терелдем мин...

Бүген гүя үлеп терелдем мин:
Гасырга тиң озын төн аша,
Саташулы төшләр эргәсеннән
Төсе качкан өнгә тоташам.

Ләбиб ЛЕРОН (1961) – *шагыйрь, прозаик, драматург; М.Җәлил исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Сине генә сөям», «Сөяксез тел», «Бәхеткә биш минут кала» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Күз алдымнан үтә мең күренеш,
Мең яңалык йота карашым.
Илдән – илгә, телдән телгә күчеп,
Өйдән өйгә йөри кара шом.

Дөнья күген караңгылык баскан,
Тыпырчына зәгыйфь яктылык.
Көзге көннең нурсыз йөзләрендә
Кайчан кояш калкыр – яктырып?

...Саташулы төшләр эргәсеннән
Өнгә кайтып кердем төн аша:
Кичәгемне бүгенемә ялгап,
Мин иртәгәм белән тоташам.

Мона Лиза кебек серле ханым

Мона Лиза кебек серле ханым
Кергәнгәме әллә төшемә,
Бүген кинәт кенә,
Париж, Париж,
Син килдең дә... төштең исемә.

Әле кайчан гына – май аенда,
Җилләр белән бергә лыбырдап,
Йөргән идем синең урамыңда...
Йөргән идем синең Луврда!

Буйдак чаклар күптән артта калды...
Кырык елга бераз соңарып,
Мона Лиза кебек серле ханым,
Ник төшемә кердең соң әле?

Париж, Париж!
Сине инде бүтән
Мин сагынмам, дигән идем дә...
Бүген менә Эйфель, Монмартрның
Чагылышын күрдем Иделдә.

...Мона Лиза кебек серле ханым
Төшләремдә йөрде тулганып...
И сөеклем! Иркәм! Газиз ярым! –
Син булгансың икән ул ханым.

Мин бүгеннән ашыкмаска булдым...

Көне-төне... Ары-бире... Мәхшәр!
Тын алырга кайчак юк вакыт.
Чабуыннан тартып торыр идем –
Вакытны шул булмый туктатып.

Мин бүгеннән ашыкмаска булдым...
Тын алырга булдым тагы бер.
Күпме генә чапма, бу дөньяны
Куып җитеп булмый барыбер.

Бүгеннән мин ашыкмаска булдым...
Сабыр булуларга ни җитә.
Сабыр иткән – морадына җиткән,
Ашыкмаска кирәк ничек тә!

Ашыкмаска булдым бүгеннән мин...
Бисмилладан башлыйм иртәмне.
Акча – бүген бар ул, иртәгә – юк,
Булганына шөкер итәмен.

Ашыкмаска булдым мин бүгеннән...
Син дә тын ал, әйдә, тагын бер.
Күпме генә чапма, бу дөньяны
Куып тотып булмый барыбер.

Төшенкелек биләп ала кайчак...

Төшенкелек биләп ала кайчак –
Бигрәк кыен булган мәлләр бар.
Аңлый алмый торган әйберләр күп,
Аңлап булмый торган хәлләр бар.

Чорлар арты чорлар алышына,
Гел үзгәреп тора замана...
Аңлый алмыйм: иксез-чиксез илдә
Кешегә җир җитми һаман да!

Бу дөньяда, әгәр уйлап баксаң,
Җиргә бәйле кебек һәр нәрсә...
Ике арадагы ызан өчен
Күрше белән күрше әрләшә!

Чир китә ул, гадәт китми, диләр.
Миңа калса, килгән чир китми.
Берсен-берсе бугазларга әзер –
Бәндәләргә һаман җир җитми!

Ирләр генә түгел, җир дәгъвалап,
Илләр белән илләр сугыша.
Киеренке халәт: кайсы җиңәр? –
Кысылыплар куя сулышлар.

Илдә-көндә бетмәс көрәш бара –
Җирләр яна, таулар ишелә...
...Югыйсә бит, ахыр чиктә, бары
Өч аршын җир җитә кешегә.

Акыл сатучылар – адым саен...

Акыл сатучылар – адым саен,
Өйрәтүче – дөнья тутырук.
Вәгазь сөйләүчеләр хәттин ашкан,
Киңәш бирүченең чуты юк!

– Алай итмә, болай ит син! – диеп,
И, өйрәтә сине барсы да.
Нервың какшый шулчак: эшең бармый,
Эчтә ачу кайный ярсудан!

Үз-үзеңне көчкә тыеп кына
Елмайган һәм көлгән буласың...
Киңәшләрдән тәмам туйсаң да, син:
– Рәхмәт, рәхмәт! – дигән буласың.

Сабырлыгың сына ахыр чиктә,
Түземлегең бетә берочтан...
Шул чагында әйтәселәр килә
Каты итеп – тозлап-борычлап!

Юк, ярамый!
Начар сүз әйтүдән
Син каласың янә тыелып.
Ачуыңны тыеп кала алу –
Бу тормышта – иң-иң кыены!

Өйрәтәләр сине төрле яктан –
Киңәш бирә олы-кечесе...

Барлык киңәш-фәләннәрен тотсаң,
Алар өчен әйбәт кеше син!

Мин дә, ахры, шулар кавеменнән,
Алар белән бергә – бер рәттә.
Әле менә, киңәш бирмәгез, дип,
Өйрәтмәгез, диеп... өйрәтәм.

Дөнья шулай яратылган...

Дөнья шулай яратылган:
Кояшы бар, ае бар.
Юмарты бар, сараны бар,
Ярлысы бар, бае бар!

Дөнья шулай яратылган –
Яңгыры бар, кары бар.
Чокыры бар, таулары бар,
Елгасы бар, яры бар.

Дөнья шулай яратылган:
Карасы бар, агы бар.
Баллысы бар, ачысы бар,
Эресе бар, вагы бар.

Дөнья шулай яратылган:
Җиңеле бар, кыены.
Олысы бар, кечесе бар,
Турысы бар, кыегы.

Даруы бар, агуы бар –
Сырхавы бар, дәвасы.
Эчим, дисәң – чишмәсе бар,
Сулыйм, дисәң – һавасы.

Дөнья шулай яратылган –
Гүя һәркем бертигез:
Кемдер – арыш, кемдер – арпа,
Кемдер – бодай бөртеге...

Дөнья шулай яратылган:
Иртәсе бар, киче бар.
Холыклысы, холыксызы –
Һәркемнең үз ише бар!

Матуры бар, ямьсезе бар,
Озыны бар, кыскасы.
Тегесе дә, бусы да бар –
Озын сүзнең кыскасы!

Дөнья шулай яратылган:
Искәрмә юк вәләкин:

Син дә әүлия түгелсең,
Мин дә түгел әлләкем.

Дөнья шулай яратылган –
Кайгысы бар, шатлыгы.
Яхшысы бар, начары бар,
Яшьлеге бар, картлыгы.

Дөнья шулай яратылган –
Иге-чиге юк аның...
Тәмугы да, оҗмахы да
Бар бу фани дөньяның!

Дөнья шулай яратылган –
Рәхәте бар, газабы...
...Тормыш – кино. Матур булып
Бетсә иде азагы.

Карап торам тәрәзәдән...

Тәрәзәдән карап торам:
Киенеп кара төстән,
Вакыт белән култыклашып,
Төн узып бара өстән.

Еракларда тонык айның
Шәйләнә силуэты.
Ашыкмый барган берәүне
Каядыр сөйри эте.

Үтә таныш күренеш бу:
Таш йортлар, урам, кибет.
Карлы ялгыз эскәмия.
Лампалар тора көлеп.

Көне-төне тыз-быз йөреп
Өшәнгән машиналар,
Берсен-берсе уза-уза,
Һаман да ашыгалар.

Менә хәзер тротуардан
Парлылар узар кебек.
Мәңге таныш манзараны
Бер сәрхуш бозар кебек.

Карлар төшә, уйнаклый җил –
Ак тузан тузып ала.
Карап торам тәрәзәдән...
...Гомерләр узып бара.

Мин күп нәрсәләр беләм

Мин күп нәрсәләр беләм,
Күп нәрсәләрне белмим...
Үземнән үзем көләм,
Үземнән үзем көнлим.

Мин күп нәрсәләр белмим,
Күп нәрсәләрне беләм...
Таш бәреп чыккан гөл мин,
Саргаймый торган үлән!

Рабит Батулла

МУР КЫРЫЛЫШЫ

КИНОРОМАН

Нахак яла

Сәмәрканд сараенда булды бу хәл.

Аксак Тимер Әлмансурдан җиңелүен кичерә алмый иде. Ул кәефсез халәттә арлы-бирле йөренде. Әмирнең хатыннары Мәликә, Түкәл, Сарана бикәләр җыелды.

– Галиҗәнабем, – диде Мәликә бикә. – Син яуда йөргән чакта сараеңда яңалыклар булып алды бит әле.

– Нинди яңалык ул, бикә? – дип сорады әмир.

Мәликә әмирнең колагына әйтте:

– Синең сөекле яшь хатының Гайшә бикә...

– Кизәнгәнсең икән, сук, суккансың икән – үтер! – диде баһадир әмир. – Башлагансың икән, азагына чаклы әйтеп бетер.

– Ни инде...

Түкәл сүз алды:

– Әйтмә син аны, ханым бикә, – диде.

– Мин әйтмәс идем, – диде Сарана бикә.

– Ни булды, әйт! Нигә сез өчәү генә йөрисез? Кайда Гайшә бикә?

– Гайшә бикә, синә тугры хатын булып чыкмады, әмирем, – диде дә Мәликә бикә читкәрәк китте.

Тимер ярсуын тыеп:

– Мәликә хатын! – дип кычкырды. – Нинди сүз әйткәнеңне аңлыйсыңмы? Кайда дәлилең?

– Синең сөекле Гайшәң ханәкәсендә төннәрен яраннарыңның берсен кабул итә.

– Исбат! Дәлил! Юкса, үзеңнең башың тәгәрәп төшәчәк! – дип акырды әмир Тимер.

– Гайшәнең кул сандыгында бер һәдия белән хат ятыр.

– Хакмы шул? Хатынны хыянәттә гаепләр өчен дүрт шаһит кирәк, хатын! Кайда синең ике шаһитың?

Ахыры. Башы узган санда.

– Әмирем, без икәү, шулар өстенә кулсандыктагы ике дәлил. Менә була дүртәү.

Әмир Тимер әйтте:

– Түкәл бикә, син дә шаһидәме?

– Ни инде... – дип, ык-мык итте Түкәл бикә. – Әйтмик, дидем мин сиңа...

– Кертегез Гайшә бикәне! – дип боерды әмир Тимер.

Гайшә бикә керде.

– Әмиремә иминлекләр юлдаш булсын! – диде Гайшә бикә.

– Бикәләр әйтә, имеш, син ханәкәңә яраннарымның берсен аласың икән! Дөресме шул?

– Әмирем, мин ялгыш ишеттемме? – диде аптыраган Гайшә бикә.

– Син дөресен әйт, хатын. Кем ялган сөйли, кем исбат китерә алмый, шуның башы чабылачак.

Мәликә бикә башлады сүзне:

– Синең уңышсыз яуларың турында ишеткәч, өч хатын бергә төннәр уздырдык, шул төннәрнең берсендә, аннан тагын берничә төн Гайшә бикәнең ханәкәсенә гел бер шәүлә узып китте. Таң алдыннан гына шул ук шәүлә яшертен генә сарайдан чыкты.

– Бер хатыным яраным белән хыянәт итте. Аның ахыры ни булып бетте? – диде усал әмир.

Мәликә әйтте:

– Яраның качып котылды, хатыныңның башын чабып өздең, тәкъсир.

– Гайшә бикә турында дөрес сөйлиме Мәликә хатын? Түкәл бикә, әйт! – диде хаким..

– Ни инде... күрдек... – диде Түкәл бикә.

– Мин берни дә әйтмим, – диде Сарана бикә.

– Кемне күрдегез? Кем иде ул кеше?

– Танымадык.

Сарана:

– Мин берни дә күрмәдем, – диде.

Тимернең җен ачуы чыкты, ул яраннарына бакырды:

– Барыгыз, Гайшә бикә ханәкәсеннән сандыгын алып килегез!

Яраннары берсен-берсе этә-төртә чыгып йөгерде.

Гайшә бикә аптыраган-йөдәгән, ул ярсып кычкырды:

– Әмирем, бу – бөһтан, бу – яла, ялган! Хыянәттәме соң минем уем? Үзең беләсең бит минем хәсрәтемне!

– Ике шаһит җитә гаебеңне раслар өчен! – диде әмир Тимер.

Шулчак Мәликә бикә әйтте:

– Мин беләм кем икәнен! – диде.

– Кем? – дип кычкырды әмир Тимер.

Мәликә бикә әйтте:

– Шәех Исрафил хәзрәтләренең колы Мостафа!

– Мостафа? – дип, күзен акайтты хөкемдар.

– Рас! Мостафа! – дип раслады Мәликә бикә.

Ул арада яраннар кечкенә сандыкны күтәреп килде.

– Ачыгыз сандыкны! – дип боерды әмир Тимер. – Мостафаны китерегез!

Тагын бер яран чыгып йөгерде. Мәликә бикә әйтте:

– Ачкычы Гайшә бикәдә! – диде.

Әмир Тимер бичара Гайшә бикәгә кычкырды:

– Ач!

– Әмирем, бу нинди афәт? Минем гаебем юк! – диде каушаган бикә.

– Ачкыч! – дип ярсыды әмир.

Гайшә җиң очыннан ачкыч алып, хуҗасына сонды:

– Әмирем!

Мәликә бикә, каерып диярлек, яшь бикәч кулыннан ачкычны тартып алды.

– Китер әле! – Сандык ачылды. Аннан хат белән алмаз кашлы йөзек килеп чыкты. – Менә, әмир җаным! – дип, Мәликә бикә аларны бөек җиһангирга сонды.

– Бу йөзек синекеме? – дип сорады әмир Тимер.

– Юк, минем йөзек түгел бу, – диде каушаган бичара хатын.

– Алайса, кемнеке? – дип сорады дәһшәтле әмир. – Каян килеп эләккән ул синең кулсандыкка?

– Белмим! – диде Гайшә бикә.

Кулындагы кәгазьне әмир Мәликә бикәгә сузды.

– Укы! – дип боерды әмир.

Мәликә укый башлады:

«Күктәге Чулпан йолдызым син, Гайшә бикә. Күктәге Зөһрә йолдызым син, Гайшә бикә. Күктәге тулган аем син, Гайшә бикә. Сине күрми торсам, янамын, көямен, кибәмен... Ләззәтле кочагыңда үлсәм, мин үземне бәхетле санар идем. Сине өзелеп сагынучы, сөюче Мостафаң».

Гайшә бикә үзен белештермәс дәрәҗәгә килеп җиткән иде инде.

– Йа Аллам, бу нинди афәт, бу нindидер куркыныч төш, мин беркемне дә белмим, минем бу хатны күргәнем дә юк...

Әмир Тимер Мәликә бикә кулыннан хатны тартып алды да яшь бикә чыраена сонды.

– Ничек килеп эләккән соң ул синең сандыкка? Ачкыч синдә генә бит.

– Белмим, белмим. Минем гөнаһым юк. Бу – яла! – диде дә Гайшә бикә җиңенә капланып үкси башлады. Мостафаны алып керделәр.

Әмир Тимер хатны Мостафага сузды:

– Бу синең язумы? – диде.

Мостафа кәгазьне кулына алып бакты да әйтте:

– Юк, тәкъсир, мин яза белмим.

– Димәк, син минем хәләл хатыным янына төннәрен кереп йөрүче, димәк, син мәхәббәт хатын кемгәдер әйтеп яздыручы, – диде хуҗа.

– Әмирем, бу ялган! Мин яза белмим! Кешегә дә әйтеп яздырмадым. Гайшә бикә ханәкәсе ишегенең кайсы якка ачылганын да белмим. Зинһар, ялгышмагыз, әмирем, хатыныгызның да, минем дә гаебем юк. Хата кылмагыз, зинһар, бу кем тарафыннандыр кылынган явыз гамәл.

– Күгелташ!

– Әмерең, әмирем!

– Икесен дә кылычтан узгарырга!

Күгелташ кылычын суырып чыгарды:

– Әйдәгез!

Бикәне – ике яран, Мостафаны икесе кулга алды.

Гайшә бикә әйтте:

– Әмир! Минем гаебем юк! Ләкин мин бу бөһтаннарны, бу кайгыларны күтәрмәс өчен үләргә дә риза! Котылырмын, иншаллаһ.

Мостафа да сабыр иде, ул:

– Гаебем юк, тәкъсир. Бу – яла! – диде.

Тимер ачуына буылып кычкырды:

– Зиначылар! Сезгә үлем! Алыгыз хыянәтчеләрне!

Икесен дә алып киттеләр.

Шулчак Исрафил хәзрәт (Карадәрвиш) килеп керде.

– Тәкъсирем, монда ни булды? – диде каударлы хәзрәт.

– Зиначылар тотылды! – диде әмир.

– Зиначылар? – диде Исрафил хәзрәт, гаҗәпсенеп. – Кемнәр алар, кабахәтләр?

– Аларның берсе – синең колың Мостафа.

– Мостафа? Булмас!

– Икенчесе – минем сөекле хатыным Гайшә бикә.

– Шаһитлар бармы?

– Ике хатыным, сөяркәсенең хаты һәм Мостафа аңа бүләк иткән алмаз кашлы йөзек. Аларның башлары чабылачак.

Яраннар хатны Исрафил хәзрәткә бирде, Карадәрвиш хатны игътибар белән кат-кат укып чыкты.

– Әмирем Тимер! Сабыр булыш кирәк. Монда нидер аңлашылмый. Тукта, тукта, ашыкмыйк, кире кайтарып алып булмаслык хата булачак, тәкъсир.

– Дәлилләр җитәрлек, хәзрәт!

– Тәкъсирем, мин Мостафа белән бер йортта торамын. Мостафаның төнлә чыгып йөргәне юк. Күкрәгемә кулымны куеп, Алла исеме белән ант итеп әйтәмен ки: Мостафа бу эшне кылмас!

Әмир Тимер сөмсере коелып, кашларын җыерып, иреннәрен кысып уйга калды. Ул киңәшчесе Исрафил хәзрәтләренә бик нык ышана иде, шулай байтак кына уйланып утыргач, бөек әмир Тимер калын, авыр тавышы белән әйтте:

– Шаһитлык шиккә алына!

– Икенчедән, тәкъсир, минем колым яза белми. Өченчедән, бу хатны ир кулы язмаган. Өченчедән, бу зәгъфран[1] буяудан ясалган кара белән язылган. Тикшерт, әмирем, зәгъфран кара кайсы җарияңдә яки кайсы хатыныңда бар?

Әмир Тимернең өмете актыра бара иде һәм ул:

– Шаһитлыкка шик артты, – диде.

Түкәл бикә кинәт калтырый, елый башлады.

– Йа Аллам, Ходаем, үзең сакла! – дип сулкылдады.

Карадәрвиш тагын әйтте:

– Бу алмаз йөзекне мин Чаршау базарында сату итүче Сархан сәүдәгәрнең ләүкәсендә күргән идем. Аның бәһасе илле алтын дирхәм иде. Барып сорагыз Сархан сәүдәгәрдән, бу алмазны аннан кем сатып алды икән?

Әмир Тимер эчтән куана иде:

[1] Зәгъфран – сары төстәге буяу.

– Ялган шаһитлык ачыла бара! – диде ул.

Түкәл сулкылдаудан ярсу халәткә күчте:

– Әйттем, әйттем мин, алай итмик, дидем.

– Син нигә үкерәсең, Түкәл бикә? – диде әмир Тимер.

Мәликә бикә эчтән бик борчулы иде, ләкин ул батып баручы кеше саламга ябышкандай, котылу әмәлен эзләде.

– Үкерми! Үкерер шул, – диде Мәликә бикә. – Зәгъфран кара Түкәл бикәдә генә. Алмазны ул сатып алып кайтты да сандыкка ачкыч яратып, хатны, йөзекне Гайшә бикә сандыгына салды.

– Дөресме шул? – диде әмир Тимер.

Түкәл бикә карышудан ваз кичте:

– Мин сатып алып кайттым алмазны, мин яздым хатны Мостафа исеменнән, мин салдым сандыкка боларның барысын да. Мәликә бикә акчасына йөзекне мин барып алдым. Гайшә бикә үз эчкәрисендә йоклап ятканда, шыпырт кына узып, ачкычын алдым. Әйберләрне салгач, ачкычны кире кертеп куйдым. Ачкыч аның котыйчынында иде. Гөнаһлы булдым.

Мәликә бикә җыландай ысылдап, Түкәл бикә тарафына атлады:

– Ялганлый ул, тоз күз. Минем ни катнашым бар? Үзең кылгансың, үзең җавап тот. Мине катыштырма!

Түкәл бикә әйтте:

– Әмиребез Болгардан Гайшә бикәне алып кайтканнан бирле бер җанына урын табалмый ул. Төннәрен пошкырып чыга. Гайшә бикәне ике тапкыр агуларга маташты. Агу ясап, миңа бирде, Гайшәнең ашына сал, диде. Мин ул эшкә бармадым. Инде менә монысында ялгыштым. Кичерә күр мине, әмирем.

Карадәрвиш бу җинаятьне тикшерү эшен үз өстенә алды һәм ул Түкәл бикәгә әйтте:

– Ант итә аласыңмы? – диде.

Түкәл бикә күз яшьләрен җиңе белән сөртте, бераз тынычланды һәм әйтте:

– Валлаһи газыйм, эш мин сөйләгәнчә булды, Мәликә бикә мине котыртты, куркытты.

Исрафил хәзрәт әмир Тимергә әйтте:

– Эш узганчы, әмереңне кире ал, тәкъсир! – диде.

Тимер боерды:

– Алып керегез икесен дә! – диде.

Ишек сакчысы кычкырды:

– Тоткыннарны алып керегез!

Күгелташ, Мостафа, Гайшә бикә кереп, әмир Тимер хозурына килеп басты.

Гайшә бикә кырә-керешли үк катгыян сөйли башлады:

– Коръән тотып ант итәм, Аллаһ исеме белән ант итәмен, минем гөнаһым юк. Үлемнән курыкмыйм, ләкин зиначы исеме белән дөньядан китәсем килми. Хатыннарың ялган сөйли!

Мостафа да ант итте:

– Валлаһи, гаебем юк Аллаһ каршында да, синең каршыңда да. Бу бала да гөнаһсыз.

– Йа Ходам! – дип үкерде әмир Тимер. – Сараемда ниләр кылына?! Әмерем шул! Мәликә бикә, сиңа сиксән таяк, Түкәл бикә, сиңа кырык таяк! Алыгыз!

Түкәл бикә һаман такмаклый иде:

– Әйттем, алай кылу гөнаһ, дидем.

Хатыннарны яраннар алып чыгып китте. Артта чырыйлап кычкырган авазлар ишетелә башлады, бикәләр җәза ала иде.

Әмир Тимер кырыслыгын югалткан, ул йомшак тавышлы кешегә әверелгән иде.

– Газизем Гайшә бикәм, кичер мин карт тилене, кеше сүзе кеше үтертер, ди. Ярый әле шәех Исрафил хәзрәтләре килеп керде. Юкса, икегезнең дә башыгыз оча иде. Киңәшчемә чиксез рәхмәт. – Тимер Гайшә бикәне эчкәрегә чаклы озатты да кире борылды. – Йа Алла, дошманым шаһ Мансурдан җиңелгәндә, сараемда ниләр кылынган!

– Аллага шөкер! – диде Исрафил хәзрәт. – Фаҗига булмый калды.

Мәкерле хәйлә

Әмир Тимернең тәхетханәсе.

Сәмәрканд каласында пошаманлык хөкем сөрә иде. Әмир Тимер яраннары арасында балтасы суга төшкән оста кебек чарасыз хәлдә утыра.

Күгелташ:

– Әмирем, анда Шираз шаһиншаһы Әлмансурдан тагын илчеләр килгән, – диде.

– Ни булыр бу? Ни өчен Әлмансур мин яудан чыгуга артымнан ук илче юллаган? Киңәшегез, яраннарым? – диде әмир Тимер.

– Илчеләр бик күп бүләкләр алып килгән! – диде Күгелташ.

Карадәрвиш салмак кына әйтте:

– Бүләкләрне кабул итәргә кирәк! – диде дә әмир Тимерне яраннарыннан аерып, бер читкә алып чыгып, яшертен сүз әйтте. – Тәкъсирем, бу – шаһиншаһның бер хәйләседер, мөгаен. Үзең җиңгән патшалыклардан да син шаһиншаһ Әлмансурдан алган байлык кебек ганимәт алганың булмады. Ул сине җиңеп, биргән байлыгын кире кайтарырмын, дип уйлый, күрәмсең. Хәйләгә каршы хәйлә кирәк, әмирем. Шаһиншаһ Әлмансур бүләк-санак белән алдап-йолдап, арка ягыңа төшәргә маташмыймы?

– Ул нинди хәйлә, пирем?

– Син хәзер үк куй бәрәнен бугазлат та, бер чүмеч җылы бәрән канын эчеп бетер. Илчеләр кергәндә, ятып тор. Без сине сырхау, дип игълан итәрбез. Бәрән канын эчкәч, синең йөзең ап-ак булыр. Хәлең китәр, эчең борып авырта башлар. Күрсеннәр илчеләр: шул канны кос. Син тагын да агарырсың. Алар әмир Тимер үпкәләрен косып бетерде, ул инде бу дөнья кешесе түгел, дип уйлап, сөенеп кайтып китәр һәм шаһларына синең үлем ястыгында ятканыңны җиткерер. Шаһиншаһ гаскәрен таратып, тыныч кына яшәп ятканда, син зур гаскәр белән яуга чыгарсың, шаһ Әлмансур Ширазга гаскәр туплап өлгергәнче, каланы басып алырсың.

Әмир Тимернең күңеле кытыклана башлады, ул бу хәйләнең уңышлы чыгасына инде хәзер үк ышанган иде.

Әмир Тимернең куанычы йөзеннән күренде.

– Йа хуп! Яраннарым!

– Өмереңне көтәм, әмирем, – диде Күгелташ.

– Тиз булыгыз, куй бәрәне суеп, бер чүмеч канын миңа китерегез.

– Баш өсте, йөзем түбән, тәкъсир! – дип, Күгелташ йөгереп чыгып китте.

Әмир әйтте:

– Чыгып әйтегез, илчеләр бераз көтсеннәр. Әмир Тимер каты хаста, бераз хәл алсын, аннан соң чакырырбыз, диегез. Озак тормас, күреп калыгыз, диегез.

Карадәрвиш эшне тиз тотты:

– Җиз тас, комган, тастымал, су алып килегез! – дип боерды.

Хезмәтчеләр чыгып йөгерде, озакламый кушкан нәрсәләрне алып керделәр. Эчкә уздылар. Алар Карадәрвиш кушканны үти иде. Әмир Тимер чаршау артыннан чыкты. Ул агарынган иде. Эчен тотып, тәхетенә кырын ятты.

– Илчеләрне чакырыгыз!

Күгелташ ишек тарафына кычкырды.

– Шираз шаһиншаһы Әлмансурның илчеләрен кертегез!

Мостафа илчеләрне алып керде. Алар йола буенча авыру әмир каршында баш иде. Тимер чынлап ыңгыраша иде. Карадәрвиш Тимернең баш очында ясин укый башлады.

– Бисмиллаһ ир-рахман ир-рахим. Йәә сиин...

Баш илче кыюсыз гына хаста янына килде.

– Бөек зафәр иясе әмир Тимер. Хастаң узар булсын! – диде баш илче.

– Амин! – диде кунаклар.

Баш илче әйтте.

– Әмир Тимер җәнаплары! Шираз шаһиншаһы Әлмансур хәзрәтләре солыхның дәвамлы булуын теләп, сиңа вә синең хатыннарыңа ошбу һәдияләрне юллады. Зинһар, ихластан биргән бүләкләрне кабул итсәң иде.

– Әмир Тимернең хәле начар, – диде Карадәрвиш.

Тимер укшый башлады. Тас алып килделәр, комган белән су тотып тордылар. Әмир Тимер чаршау артына кереп, мул итеп таска кан косарга тотынды. Чаршау артыннан хәлсез Тимерне алып чыктылар, кырын яткырдылар. Хезмәтчеләр, илчеләр күрерлек итеп, тасны алып чыгып киттеләр. Анда кып-кызыл кан чайпала иде.

Баш илче куркынган кыяфәттә:

– Лә хәүлә вә лә куәтә! – диде.

– Бүләкләрегез өчен әмиребез Тимер чиксез рәхмәтләр әйтә, ләкин аның бүләкләрдә галәкәсе[2] юк инде, – диде Күгелташ.

– Васыятен әйтеп өлгерсә, ярар, – диде Карадәрвиш.

– Кичерегез могтәбәр илчеләр, – диде Күгелташ.

Баш илче аягүрә басты.

– Әйдәгез, кайтып, шаһиншаһка бу хәбәрне ирештерик, – диде илче.

Әмир Тимер телгә килде:

– Үләм! Бәхил калыгыз... яраннарым...

[2] Галәкә – бәйләнеш, игътибар, кызыксыну.

Күгелташ, Мостафа илчеләрне озата чыгып китте. Хаста янына, илаулап, хатыннары, җарияләр керде. Алар артыннан Күгелташ күренде.

– Әмирем, җаным бәгърем, ни булды сиңа? – диде Мәликә.

– Сау-таза йөргән кеше шулай кинәт егыламы? – дип сорады Түкәл.

– Мин берни дә белми калдым... – диде Сарана.

– Ханым бикәләр, әмиребезнең хәле авыр. Зинһар, аны борчымагыз, – дип дәвам итте Күгелташ һәм сүзен йомгаклап әйтеп куйды: – Бикәләр! Сез чыгып торсагыз, яхшырак булыр.

Хатыннар, җарияләр чыгып китте.

Алар чыгып китүгә әмир Тимер саф су белән авызын чайкый башлады, салкын су эчте. Аңа хәл керә башлады.

– Фу-у, чыннан да, үлә яздым! – диде әмир.

– Елга бер тапкыр җылы кан белән ашказанын пакьләндерү озын гомергә сәбәпче була, тәкъсирем, – диде Карадәрвиш.

– Хәзер үлеп ашыйсым килә! – диде әмир Тимер.

Күгелташ:

– Кыздырылган бәрән ите белән кымыз-буза сезне көтә, тәкъсир, – диде.

Тимер үләргә яткан кеше булып шундый ышандырырлык итеп кыланды ки, илчеләр генә түгел, үзенең якыннары да моңа инанган иде. Хәер, Тимернең күз буулары бәрән каны белән генә бетмәде. Ул берничә тапкыр үзенең үлүе турында халык арасында, сарайдагылар арасында ялган хәбәр тараттырды. Аның үлгәнен ишеткәч, кем сөенә, кем көенә, кем битараф кала – әмир шуларны хисапка ала, һәм бу мәгълүмат алга таба эш йөрткәндә, тегеләрнең язмышларына сизелерлек тәэсир итә килде.

Оттыру

Баги-Чинардагы дәстәрхан бакчасында булды бу хәл.

Падишаһның ашханәсендә учакта куй кыза. Мул табын янында ашау-эчү, шау-шу. Сакыйлар шәраб, кымыз, буза тарата.

Әмир Тимер аштан соң бакчада йөрергә чыкты.

– Адәм көлкесе! – диде ул, барысына да ишетелерлек итеп. – Шул фәхеш Әлмансурдан ничә тапкыр җиңел, имеш! Ул мине мыскыл итте. Гаскәре минекеннән күбрәк булса да, көчле булса да, миңа олы һәдияләр биреп, солых төзеде. Оят, валлаһи!

– Бәлки, чыннан да солыхта яшәү кирәктер, тәкъсир, – диде Күгелташ. – Юкса, без яу саен халыкны кырдырабыз түгелме?

– Ә дин бозучы монафикълар иркендә яшәсенме? Мәсехлек вазифам бар, ул – динне сафландыру. Мин дөньяга килгән сәгатьтә атам Тарагай изгеләрдән Коръән ачтырган. Тимер сүрәсе ачылган, анда язылган: Күкләрдә вә Җирдә булган барчасы Аллаһка тәсбих әйтә. Аллаһ – җиңелү белмәс кодрәт һәм хикмәт иясе. Күкләрдәге, Җирдәге бөтен байлык Аныкы. Без тимерне дә иңдердек, чөнки тимердә сугышлар өчен хәтәр куәт бар һәм тынычлыкта ул инсаннарга файдалы... Шуңа күрә, атам миңа Тимер исеме куштырган. Мин Коръәннән алынган исемемне аклаячакмын! Киңәшең, Исрафил хәзрәтләре?

Карадәрвиш әйтте:

– Тәкъсирем! Бу уңышсыз сәфәрләрең синең бөек уңышыңа күпер булып ятсын! – диде.

– Амин, хәзрәт! – диде әмир Тимер.

Тәхетханәгә Тимер, Исрафил хәзрәт, Мостафа, Гайшә бикә, Мәликә бикә, Түкәл бикә, Сарана бикә һәм җарияләр җыелды.

Исрафил хәзрәт әмир Тимер каршында тез йөгенеп әйтте:

– Тәкъсирем, килешенгән вакыт инде күптән чыкты, өч айга урнашып, мин синең янда ике елга якын хезмәт иттем. Мине азат ит бу вазифамнан. Ватаныма – Гранадага кайтып китим.

– Сарай казнасындагы хәзинәдән син ни телисең, хәзрәт? – диде әмир Тимер.

– Дәрвиш кешегә ни кирәк? Азатлык белән саф һава!

– Мәйлең, хәзрәт... Гранададан Кастилия еракмы?

– Ерак түгел, бер атналык юл. Кастилиянең башкаласы Толедо якын гына.

– Шәех Исрафил хәзрәтләре, мин сиңа яңа вазифа йөклим. Гранаданың хәлифә Мөхәммәд Бишенчегә һәм дә Кастилия короле...

– Кастилия короленең исеме Һенрих Өченче, тәкъсир!

– Кастилия короле Һенрих Өченчегә син миннән илче булып барырсыңмы?

– Ышанычыңа күрә рәхмәтләрем.

– Күгелташ, илчеләремне юлга әзерлә. Аларга егерме хезмәтче күндер.

– Дикъкатеңә чиксез рәхмәтләрем, тәкъсир, – диде Исрафил хәзрәт.

– Аерылышыр алдыннан колың Мостафа белән шахмат уйнарга телим.

– Мәйлең, тәкъсирем.

– Шартлары ничек соң? – диде Мостафа.

Тимер әйтте:

– Минем шартым шул: әгәр дә мин отсам, сез монда минем хозурымда каласыз. Сезне җибәрәсем килми. Миңа синдәй киңәшче кирәк, Исрафил хәзрәт.

– Мин отсам? – диде Мостафа.

– Шартыңны әйт! – диде җиһангир.

– Болгар явына атланып барган Акбәкәл кушаматлы атыгызны куймаячаксыз!

– Куймаячакмын! – диде Тимер.

– Яу бәрәбанын куймаячаксыз!

– Юк! Ул комарга куелмас! Башка нәрсә сора!

– Кичерә күр, тәкъсир, кичерә күр. Алайса, хатының Гайшә бикәне куй! – диде Мостафа.

Әмир Тимер сикереп торды да билхәнҗәрен чыгарды.

– Ахмак! Ни сөйләгәнеңне колагың ишетәме? Димәк, чыннан да сезнең арада кышы-мышы булган?

– Юк, тәкъсир, гөнаһ юк. Ләкин мин аны үзем өчен сорамыйм. Илче булып кайткач, без Гранада халифе Мөхәммәд Бишенчегә, Кастилия короле Һенрих Өченчегә нинди бүләк алып кайтырбыз? Аларның алмазлары баз тулы. Комачлары киштәләп. Аларга иң яхшы бүләк – ул

синең җарияләреңнең берсе. Анысы Мөхәммәд халифкә. Хатының Гайшә – корольгә.

– Булмас эшне сөйләмә, кол Мостафа! Әмир Тимернең хәләл хатынын даулыйсың! Әмир Тимер хатынын җирәбәгә салмас!

Исрафил хәзрәт әйтте:

– Тәкъсир, шахматта кем ота, кем оттыра бит әле! Уеннарның отышы күбесе синең кулда була килде. Отыш Мостафа ягында булырмы, юкмы, нә мәгълүмдер. Падишаһ отса, безне ота. Маллар тигез түгелме, тәкъсир?

– Анысы шулай! – диде әмир Тимер. – Мине откан кеше сирәк!

– Без ике гүзәл хатынны диңгез кырындагы ике падишаһка алып китеп, арагызда бик файдалы килешү корсак, арагызда сәүдә кәрваннары, мал төягән көймәләр йөри башласа! Колым Мостафа белән монда калып, синең янда Коръән укып утырсак, ничек? Фикерем шул: син оттырсаң да, оттырмаячаксың, икесе дә синең өчен файда гына!

Әмир Тимер әйтте:

– Һым, анысы дөрес! Ярый! Тезегез шакмакларны! – Күгелташ чыгып китте.

Карадәрвиш әйтте:

– Шартнамә язуы лязем, тәкъсир, – диде.

– Языгыз! Хаттатлар шартнамә язарга әзер иде. Мостафа отса, бер җариям, Гайшә бикә исемле хатыным миннән талак алып, чит патшага һәдия булыр. Мин отсам, шәех Исрафил белән аның колы Мостафа белән гомерлеккә сараемда киңәшче сыйфатында кала! Ике яклы килешү. Имзам. Мөһерем. Алыгыз!

Шартнамәнең бер данәсен хаттат алды, икенче данәсен Мостафа үз кесәсенә тыгып куйды. Күгелташ керде.

– Шахматлар әзер, тәкъсир, – диде Күгелташ. – Шаһитлар ян-якка бастылар.

– Аллага тапшырдык! – дип, әмир Тимер тәхетханәдән чыкты.

Шахмат ханәкәсендә барысы да ярышка әзер иде.

Барысы да шахмат өстәле янына килде.

Гайшә бикә, шобага салынган җария белән Исрафил хәзрәт бакчага чыгып китте.

Гайшә бикә әйтте:

– Рәхмәт, изге ата. Син мине хурлыклы үлемнән коткардың. Инде нишлим? Әгәр дә Мостафа отса, әгәр дә әмир отса?

– Гүзәлләрнең язмышы шул, кызым. Алар кулдан кулга, илдән илгә күчеп йөри. Кыз кеше ватанында үлә алмый. Ул ире кулында. Әгәр дә Мостафа отса, син Испаниягә китеп, анда королева булачаксың. Әгәр дә әмир отса, аның сөекле хатыны булып калачаксың, ничек булса да, син патшабикә булудан туктамаячаксың.

– Изге ата, мине нинди язмыш көтә? – диде шобагага куелган җария.

Исрафил хәзрәт әйтте:

– Сиңа да шул ук язмыш әзерләнгән, кызым. Син Гранада халифе Мөхәммәд Бишенченең сараена төшәчәксең! Фикерем шул: Мостафа отса, сөенегез, сөенечегезне әмиргә күрсәтмәгез. Монда сезнең язмыш тиз үзгәрүчән. Бүген бар ул патшалык, иртәгә юк. Бүген сез әмирнең хатыны,

иртәгә бер юлбасар кулында. Ни булса да, кайгырмагыз! Язмышыгыз шобага куелган.

Җария әйтте:

– Кайгырмыйм. Кем куенында ятсак та, бер түгелме? Җир куенында ятканчы, ир куенында ят!

Җария кулына дутар алып уйный башлады, Гайшә бикә көйгә кушылды. Аны моң баскан иде.

Сызла, бәгърем, сызла, җаным,
Сызылып бет, йөрәк маем.
Сызлап, сызылып бахыркаем
Егълап туймый Гайшәкәең.

Ел кебек тоелыр анда айлары.
Сызар ла йөрәкнең майлары.

Шахмат уены ягыннан шау-шу ишетелә башлады. Шаулаша-шаулаша уенчылар чыкты.

– Ничек шулай булды соң?

– Уенда харам юк, тәкъсир.

– Харам юк, әмма ничек кол мине отты? Ни гомер аны мин ота килдем. Хәйран, вәйран!

– Тәкъсир, сез филегезне сакламадыгыз. Шулай итеп, ат белән ике яклы чатал-сәнәккә килеп эләктегез.

– Ярый, шигем дә бар минем ул хатынга. Талак! Талак! Талак! Алыгыз сез Гайшә бикә белән бу җариямне! Гранада хәлифе Мөхәммәдкә җариям, Гайшә бикәне Кастилия короле Һенрихка тапшырыгыз! Хәерле юл! Исрафил хәзрәт, Гранададан илче булып янә миңа килерсезме?

– Иншалла!

– Озатыгыз! Хуш, Гайшә бикә! Синең минем яннан китеп торуың мәгъкуль. Син янымда чакта күңелем тыныч булмас. Ә минем эшлисе эшләрем бихисап! Минем әле ләшкәрем илә диңгез кырыендагы Гранада, Кастилия җирләренә атым Акбәкәлемнең тоякларын бастырасым бар.

– Хушча калыгыз барчагыз да, – диде Карадәрвиш.

Тимер хезмәтчеләренә эндәште:

– Хәлиф белән корольгә һәдияләрне кызганмагыз!

Күгелташ, Карадәрвиш, Мостафа, Гайшә бикә, җария һәм тагын берничә хатын-кыз сәфәр чыкты. Тимер моңсуланып калды, аның күңеле тулган иде. Ул ачынып, хәнҗәрен суырып чыгарды да, кемгә кадарга белмәстән, мендәргә кадады. Мендәр йоны белән бүлмә тулды.

Тимер шашкан кыяфәттә йөренә:

– Хуш, Гайшә бикәм!.. Үз кулларым белән ятларга тапшырдым. Кичер мине, Гайшә бикәм! Отылдың, Аксак Тимер, оттырдың, Аксак Тимер!

Оттыруданмы, Гайшә бикәсен югалтуданмы, әмир Тимер җанын-тәнен кая куярга белми. Аның бу тетрәнүен сугыш кына бәреп чыгарасын ул яхшы тоя. Алда шаһиншаһ Әлмансур белән орыш тора.

Җиһангир бу орышка тәфсилләп әзерләнде.

Ул күрше урман илләреннән такталар, корыклар, сүс, мунчала, каеш

катыштырып ишелгән арканнар, баулар кайтарткан иде. Аның бу эшенең серенә беркем дә төшенә алмады, хәтта башкарачы Күгелташ та ни өчен урман ташытканын аңламады. Исрафил хәзрәт аңа яшерен киңәш биргән иде: Ширазга дала юллары буйлап хәрәкәт итмәскә, моңарчы бер генә гаскәр дә кичә алмаган Тәңре таулары аша яугирләрне, атларны, дөяләрне ян корсакларына такталар куеп, нык баулар белән кыядан бау белән төшерергә, тауларны ашкач, җәйләүдә җыелып, гаскәргә ял бирергә һәм көтелмәгән яктан Ширазга һөҗүм итәргә!

– Күгелта-аш! – дип кычкырды әмир Тимер.

Күгелташ атылып керде:

– Әмирем!

– Гаскәрне тупла! Фарсы иленә, шаһиншаһ Әлмансур өстенә яу чыгабыз!

– Гаскәр тупланган! Әмерең, әмирем! Бәрәбаннар! Карнайлар! – диде Күгелташ.

Бәрәбан, карнай тавышлары дөньяны яңгыратты.

Әл Мансур белән сугыш

Шәһри Ширазга һөҗүм.

Аксак Тимер гаскәрләре кызган чүл буйлап бара. Чүл комы йомырка пешерерлек кайнар. Яугирләр генә түгел, атлар, дөяләр, качырлар сусаган.

Кайнар чүлне узып, Аксак Тимер гаскәре тауларга якынлаша иде. Бичара хайваннар тауларны күреп, адымнарын тизләтте.

Гаскәрләр таулар арасыннан китте. Текә кыялар, төпсез упкыннар сугышчыларны сагалап тора. Кайберләрен таудан тәгәрәгән ташлар баса, кайберләре упкынга оча.

Бара торган бердәнбер юлны таудан ишелеп төшкән кыя каплап торганы аңлашылды. Кешеләр атларны, дөяләрне ян-якларына такталар бәйләп, арканнар белән кыялардан аска төшерә башлады. Бөтен гаскәрне, атларны, дөяләрне, атларга ашатырга дигән солыны капчык-капчык итеп, арканнар белән аска төшереп бетерделәр.

Ниһаять, алар киң далага килеп чыкты. Атларны утлауга җибәреп, яугирләр чатыр кора башлады.

Шираз каласының манзарасы. Мәһабәт манаралар, кәрвансарайлар.

Шаһ сарае. Бакчада балалар уйный. Шаһзадә Сөрәя сеңелләренә карап куана. Шаһбикә таганда йокымсырый. Агач күләгәсендә шаһ Мансур китап укып утыра иде.

Шулчак каравыл манарасындагы күзәтче бактанның[3] шөбһәле авазы яңгырады.

– Карагыз, анда офык ягында болытмы ул, әллә томанмы? Йа Аллаһым! Бу дошман явы булса кирәк! Югыйсә тау-кыялар ягыннан гаскәр уза торган түгел! – диде бактан.

– Гауга быргысын кычкырт! Гауга бәрәбанын как! – дип оран салды икенче бактан.

Шаһ бакчасына атылып, хәбәрче-чапкын килеп керде.

– Ни булды? – диде Әлмансур.

[3] Бактан – күзәтүче, сакта торучы, багып торучы.

– Харап булдык, шаһым, дошман явы капка төбендә!

– Дүрт якка дүрт чапкын юллагыз! Барысы да коралланып, монда килсен! Каладагы барча яугирләрне дә чакырыгыз! Кылыч тота алган һәммә кеше ватанын сакларга атылсын!

Урамнар буйлап чапкыннар чабыша иде.

– Сугыш! Коралланыгыз, дошман явы капка төбендә!

Шираз каласының җәйләвендә Аксак Тимернең яу ыстаны.

Яугирләр арасында сугыш алдында була торган киеренкелек.

Әмир Тимер әйтте:

– Беркая да китә алмас ул шаһиншаһ Әлмансур! Каршылык күрсәтмичә капкаларны ачар, калага кертер һәм казнасындагы бөтен хәзинәсен үзе чыгарып, безнең алга салыр, иншалла!

Бәрәбаннар дөпелди, карнай, сорнайлар каты тавыш белән уйный башлады.

Каравыл манарасыннан Әлмансур Тимер гаскәрләренең хәрәкәтен күзәтә иде.

Шәһәрне дошман гаскәре уратып алган. Башка өлкәләрдәге гаскәрләр Ширазга ярдәмгә килә алмаячак. Эш мөшкел, хәл бик хәтәр иде.

Берничә ярдәмчесе белән Күгелташ шәһәр диварларына якын килде.

Күгелташ диварларга карап, оран салды:

– Һә-й, шаһиншаһ җәнаплары! Әмир Тимер килде! Ач капкаларың, күтәр пәрдәләрең! Җиңелмәс баһадир әмир Тимер килде. Без дүрт йөз мең гаскәр белән яуга чыктык.

Әлмансур җавап бирде:

– Һә-й, Күгелташ! Әмиреңә әйт, бездә дә бар ул дүрт йөз мең гаскәр. Ләкин шулар өстенә бездә кырык сугыш филе бар. Һәр фил өстендә ун кеше сыярлык мөнбәр бар. Анда утырган укчыларымның уклары сезнең күкрәкләргә батар, филләрем барыгызны таптап сытар. Соңгы тамчы каныбызга кадәр орышачакбыз.

Күгелташ тагын кычкырды:

– Карарбыз, кем-кемне сытар!

Атын борып, Күгелташ чатырлар ягына чаптырып китте. Манарадагылар аның артыннан сызгырып, үртәү сүзләре кычкырып калды.

Әмир Тимер ыстаны.

Тимер илчеләрнең кайтканын көтә иде.

Күгелташ үзенең егетләре белән Тимер каршысында туктады.

Күгелташ:

– Тәкъсирем, алар орышачаклар! – диде.

Әмир Тимер кычкырды:

– Бәрәбаннар!

Һәр дөянең ике ягына да олы сугыш бәрәбаннары асканнар. Бәрәбан аскан дөяләрнең саны унау. Бәрәбанчылар үҗәт рәвештә тукмаклары белән бәрәбаннарга оралар.

Ат өстендә ун карнайчы карнайга өрә. Ун ат өстендәге карнайлар юан тавыш белән, сорнайлар әче тавыш белән яу маршын уйный.

Тимернең атлы гаскәре һөҗүмгә китте. Тояк тавышлары, ат кешнәгән авазлар, дөбердәү, шартлау – әйтерсең лә, дөнья бетә, әйтерсең лә, җир җимерелә иде.

Эчендә шом юшкыны булса да, шаһ Әлмансур тыныч күренә.

Тимер гаскәрләре якынаеп килә. Әлмансур өч тапкыр кул изәде.

Капкалар ачылды, ачык капкалардан сугыш филләре борыннары белән быргы авазлары чыгарып, атылып чыкты, филләрнең аркаларында такталардан корылган саклагыч манаралар, алар эчендә укчылар урнашкан.

Дошманның атлы гаскәре белән фил гаскәре йөзгә йөз каршы килде. Фил өстендәге укчылар дошман атлылары өстенә ук яудыра, күп кенә атлылар, атлар күкрәкләренә ук алып егылалар. Алар ат, фил аяклары астында калып һәлак була. Филләрдән куркып, атлар шашардай булып чиный-чиный кешни. Филләр азау тешләрен ат корсагына батыра, кешеләрне чөеп-чөеп ыргыта. Йөрәкләренә курку төшкән атлар, җайдаклар кире борылып чаба, ләкин алар һөҗүм итүче башка атлыларга бәреләә, арттан филләр таптап килә. Дошман гаскәре күп мәетләр, яралыларын калдырып, ыстанына кире кайтып китте. Филләр дә кире борылды.

Диварлар, манаралардан карап торучы Шираз кешеләре бәйрәм итә, кычкыра, бииләр, җырлыйлар иде.

Тимер ыстаны.

Хәрби киңәшмә. Киңәшмәдә әмир Тимер, башкарачы Күгелташ, меңбашлары Миран белән Сөләйман һәм башка хәрбиләр катнаша.

Әмир Тимер сүз башлады:

– Нишләргә? Атлар филләргә каршы барырга курка. Сүзегезне көтәм, яугирләрем!

Күгелташ әйтте:

– Төнлә филләр киләсе юлларга очлы ягын өскә каратып, казыклар куярга.

– Шымчылар сизәр, – диде әмир.

Түмәнбаш Миран әйтте:

– Сумала яки җир мае агызып, филләр якынаюга ут төртергә.

– Үзебезнең атлар уттан куркыр! – диде әмир.

Унмеңбаш Сөләйман әйтте:

– Иң җегәрле йөз дөя сайлап алырга кирәк! – диде.

Аксак Тимер ыстанында халык мәш килә. Балта осталары озын корыкларны очлый. Ул корыкларны һәр дөянең ян-ягына нығыталар. Баш-башларына коры чыбык, салам бәйлиләр. Коры чыбык белән салам өстенә тиз яна торган сыекча сибәләр.

Әмир Тимер ыстанында сугышка әзер дөяләрне сафка тезделәр.

Әлмансур ыстаны.

Тимернең чираттагы һөҗүмен кайтарырга әзерлек бара. Филләрнең өзелгән каешларын, кыйшайган манараларын рәтлиләр.

Тимер ыстанында сугышка әзер дөяләрне тезделәр.

Әлмансур елмая:

– Нәрсә эшли ала ул Аксак Тимер минем филләремә каршы дөя көтүе чыгарып? – диде.

Капка алдында сугыш филләре яуга әзер тора.

Күгелташ яман аваз чыгарып, бәрәбанчыларга кычкыра. Бәрәбаннар дөпелди. Дөяләр ташкыны Шираз тарафына чабып китте.

Әлмансур филләре дөяләргә каршы чаба башлады.

Филләр дошман явын сытып китте дигәндә генә, дөячеләр саламга ут төртте. Берьюлы йөз ялкын гөлтләп кабынды. Барган шәпкә дөяләр утлы корыкларын филләр корсагына батыра. Ялкын филләрне куркытты. Корсакларына утлы корык кергән филләр аркаларындагы кешеләрне сытып, җиргә ава. Калган филләр нишләргә белмичә артка борылып чаба, алар үз артларыннан килгән башка филләрне бәреп, үз кешеләрен таптап, шәһәр тарафына ыргылалар иде.

Күгелташның кул ишарәсеннән соң, ярсыган атларга юл ачыла. Тимернең атлы гаскәре кыргый авазлар чыгарып, җан-фәрманга шәһәр ягына томырыла. Атлылар юлында фил гәүдәләре, дөя үләксәләре, кеше мәетләре аунап кала. Тимер яугирләре качып баручыларны рәхимсез рәвештә кыра, чаба, турый иде. Бичаралар шәһәр капкасына кереп качмак була, ләкин алар дошман кылычыннан, ат тояклары, дөя аяклары астында изелеп калалар.

Әлмансур йөзендә курку шәүләсе уйный иде:

– Капкаларны ябарга-а! Капкала-ар! – дип кычкыра шаһиншаһ.

Капкаларны ябарга өлгермәделәр, качучылар артыннан атлылар да капкага ыргылды, тимернекеләр шәһәргә бәреп керде. Урам сугышлары башланды.

Шаһ Әлмансур ике кылыч белән үзен үзе белештерми орыша иде.

Шираз капкасы төбендә каты сугыш бара.

Шәһәр эчендә үтереш, талаш, кырыш дәвам итә.

Яу кыры.

Анда мәет җыючылар тын гына эшли. Тимернең бик күп яугирләре дошман мәетләренең башларын кисеп җыялар да арбаларга салып, каядыр алып китәләр.

Дәһшәтле, кодрәтле Аксак Тимернең дүрт йөз мең кешелек гаскәре Шираз каласына ябырылды. Бу – җиде икълимнең бишенчесен яулау иде. Бу Тамерланның иң олы җиңүләренең берсе булды. Шаһ Әлмансур ирексездән шәһәр язмышын рәхимсез дошман кулына тапшырды. Җиңүчеләр капчыклап-капчыклап, саф Һиндстан алтынын, хисапсыз күп алмазлар, әйдәүчеләре белән меңләп, сугыш филе һәм бихисап гүзәлләрне ганимәт вә үлҗә хисабыннан үзләре белән алып, ватаннарына кайтып китте. Иң кыйммәтлесе, иң кадерлесе – әсирләр арасында шаһиншаһның сөекле кызы, гүзәл Сөрәя шаһзадә иде.

Байлык төягән дөяләр, атлар, арбалар Сәмәркандка таба йөри. Күгелташ артка, Шираз тарафына борылып карады. Гүзәл шәһәрдән хәрабәләр генә калган иде. Шул хәрабәләр янында җитмеш мең кешенең баш сөягеннән корылган манара ап-ак булып җемелдәп, кояшта чагыла. Бу имәнгеч күренештән күпме дәһшәт күргән Күгелташның тәне чымырдап китте.

Чатыр корулы фил өстендә кайгылы әсир шаһзадә Сөрәя тирбәлә иде.

Шаһзадә бикәч Сөрәянең хәле

Яу сәфәреннән кайтыш.

Бөек җиңүче әмир Тимер бөек тантана белән башкалага якыная бара. Барча халык җиңүчеләрне каршы алырга чыккан. Бәйрәм. Җырлыйлар,

бииләр. Урамның бер ягыннан икенчесенә тарттырылган арканнарда җанбазлар осталыкларын күрсәтә.

Адым саен куй кыздырыла, адым саен казаннарда пылау әзерләнә.

Атка атланган әмир Тимер шәһәр капкасына якынлашканда, аваз яңгырады.

– Машалла, Тимер бәк! Машалла, яугирләр!

Бәйрәм ыгы-зыгысыннан соң, үлҗә, ганимәт малын яугирләр арасында бүлешкәннән соң, тыныч тормыш башланды. Әсирә Сөрәя бикәч тә игътибарсыз калмады. Яугир Тамерлан өчен иң олы җиңү – шаһиншаһның кызы Сөрәяне җиңү иде.

Ханәкәдә кайгыга баткан шаһиншаһ Әлмансурның сөекле кызы шаһзадә бикәч Сөрәя утыра. Аның янында ахирәтләре бөтерелә.

Беренче ахирәт әйтте:

– Сөрәя тутай бикәч! Ник син шулай һаман кайгылы, һаман моңлы? – диде.

Икенче ахирәт тә сүзгә катнашып китте.

– Ник син шулай озак хәсрәт йотасың? – диде.

– Тирә-якта нинди гүзәллек! – диде беренче ахирәте.

– Әйләнәндә матур гөлләр, күбәләкләр.

– Өстең тулы затлы кием, алтын укадан, бизәнгәнең алмазташлар, энҗе-мәрҗәннәр белән.

Бичара Сөрәя:

– Күрмим мин ул матурлыкны, күрми күзем хозурлыкны. Тамагымнан үтми тәгам-ризыклар. Нигә миңа затлы кием, нигә миңа алмазташлар? Читлектәге кош кебек мин. Сайрар кошны затлы читлеккә ябып, аны бәхетле иткән кеше бармы? Мин сагынам ватанымны, Ширазымны... Юксынам атам-анамны, кызганамын бичара бабамны, – диде.

Аның тавышы калтырады, ул йөзен ике учына яшерде.

– Бәгыре өзгәләнә бичараның... Фарсы хакиме шаһиншаһның иң сөекле кызы булып дөньяга кил дә, колиһә булып ят җирләрдә каңгыр, имеш, – диде беренче ахирәте.

– Хатын-кызның тәкъдиредер. Бәргәләнмә, Сөрәя. Өлешеңә тигән көмешең. Язмышыңа буйсын!

– Дикъкать итмә, бәгим, аларның сафсатасына! – диде иң якын ахирәте.

Бичара Сөрәя әйтте:

– Минем атам Шираз шаһиншаһы Шаһ-Мансур, анам исә Баһдад шаһзадәсе Җәмилә иде, минем никахланмыш җегетем атаклы шагыйрь Шәмсетдин Хафизның туруны Шәһрияр иде. Аксак Тимер Ширазыбызны ничә тапкыр килеп җимерде. Соңгысында ул атам-анамны, бөтен сарай әһелләрен кылычтан узгарды. Шәһриярым яу кырында яраланган, диделәр. Ә мине Аксак Тимер кол итеп, Сәмәркандка алып кайтты.

– Сөрәя бәгим, әмиребез турында алай хөрмәтсез сөйләмә, – диде ахирәтләре.

– Нәселемне кырган, башкаламны җимереп талаган, ярты халкымны кылычтан узгарган бәдбәхетне мин ничек дип атарга тиеш? – диде Сөрәя.

Бер-бер артлы бикәләр күренде. Иң алда әмир Тимернең беренче хатыны

Мәликә бикә, аннан икенче хатыны Түкәл бикә, Сарана бикә һәм аларның җарияләре пәйда булды.

Мәликә бикә керә-керешли әйтте:

– Кем ул бәдбәхет, кызым? – Ханәкәдә шомлы тынлык урнашты. – Кем ул? Әмиребез Тарагай углы Тимер турында түгелдер бит?

Түкәл бикә әсирә бикәчкә төрттерде:

– Дәшмәү – ризалык галәмәте.

– Мин дәшмим, – диде Сарана бикә.

– Дәшмәү – артык горурлык галәмәте! – диде Мәликә бикә.

– Олуг әмир бикәбез ! – диде ахирәт кыз. – Сөрәя бикәч менә бу тамырга абынып китте дә егыла язды. Ул тамырга «кабахәт» диде.

– Тамырның ни гөнаһасы? Аяк астына карап йөреш кирәк! – диде Мәликә бикә.

Түкәл бикә тагын төрттерде:

– Тамырга абындым дип, кан тамырын кисмәссең бит?

– Мин тамырга абынмадым вә дәхи кан тамырымны кисәргә җыенмыйм да, – диде горур бикә Сөрәя катгыян тавыш белән.

– Син нинди аваз гәп орасың, кызый? – диде кырыс бикә Мәликә.– Синең каршыңда...

Түкәл бикә һаман җәнҗал тели иде:

– Сиңа монда Шираз җире түгел! Бу – Сәмәрканд! – диде ул мыскыллабрак.

Мәликә бикә дәвам итте:

– Хорасанны, Гүргәнечне җир белән тигезләп, ясмык чәчтергән бөек яугир...

– Алтын Урданы, Ак Урданы, Күк Урданы тетрәтеп торучы түрә... – диде Түкәл бикә.

– Шулай шул, – диде Сарана бикә.

– Каф таулары артындагы илләрне буйсындырган...

– Иранны аяк астына салган Тарагай углы әмир Тимернең кече хатыны, Чыңгыз канлы Тарма Ширин ханның сөекле кызы Түкәл бикә...

– Чыңгыз канлы Казган ханның сөекле кызы, Тарагай углы әмир Тимернең олы хатыны Мәликә бикә басып торганын онытма.

Сарана да әйтте:.

– Мукшы бәгенең кызы – Сарана бикә.

Сөрәя аларга охшатып әйтте:

– Алдыгызда Фарсының Шираз каласындагы шаһиншаһ Мансурның сөекле кызы, Хорасанны, Гүргәнечне, Урдаларны аяк астына салган Тарагай углы әмир Тимернең иң яшь, иң гүзәл, иң кече хатыны Сөрәя бикәч басып торганын онытмавыгызны үтенәм!

– Сөбханалла! – дип кычкырды Мәликә бикә. – Киленнең теле ачылды!

Яраннары белән Аксак Тимер керде. Ике кәнизәк Сөрәяне әмир каршысында тезләндерде. Сөрәя теләр-теләмәс кенә баш иде. Хатын-кызлар бер якка, ирләр икенче якка китеп югалды.

– Мәрхәбә, хуш килдең, шаһ кызы Сөрәя туташ, – диде әмир Тимер.

– Мин туташ түгел! – диде тоткын бикә.

– Ха! Үзенең кыз булмавы белән мактанганнарны беренче тапкыр күрәм, – диде әмир.

– Мин кызчык түгел! Мин башканың никахындагы хатын! – диде тоткын бикә.

– Нинди никах? Нинди башка? Әйе, ишеткән идем, син шагыйрьләр шагыйре Хафиз Ширазиның торыны белән ярәшелгән, дигәннәр иде.

– Никахлашкан!

– Ярый, синеңчә булсын! Син аның никахындагы хатын, ди. Ләкин сугыш-яу шартларында җиңелгән, һәлак булган патшаларның, яугирләрнең хатыны үзеннән-үзе талаклы санала. Ягъни, ганимәт хокукында, үлҗә хокукындагы хатынга, җиңгән яугирның хатынына әверелә. Аннан соң синең никахлы ирең яуда һәлак булган, диләр.

– Ялган! Ул хәбәрсез югалды.

– Ярый, хуш! Хәбәрсез югалган икән, без аннан хәбәр алырбыз. Хәбәр дә, талак та алырбыз.

– Шәһриярым исән! Күңелем сизә, ул исән.

– Шуннан ни үзгәрә, бикәч?

– Шуннан шул, син миңа өйләнә алмыйсың. Чөнки Шәһрияр беркайчан да миңа талак әйтмәячәк!

– Кызым! Мин инде яшь кызлар белән сүз куертып утырудан узган. Синең хакимең, булачак ирең белән шушылай дорфа сөйләшкәнеңне уен буларак кына кабул итәм. Нәфис сының, гүзәл чыраең, укымышлы булуың, шулар белән бергә нык холыклы, батыр булуыңа сокланам. Шуңа күрә, сүзләреңә ачуланмыйм. Тора-бара бөтенесе дә тәкъдиренә буйсына. Һәм мине хәтта ярата-сөя башлыйлар.

– Ә мин уйнамыйм! – диде тоткын бикә. – Мин уйнамыйм, Тарагай углы әмир шаһ Тимер! Ихластан сөйлим. Мин дорфа түгел, күңелемдәгене шулай җиткерергә тырышам. Хакимем, булачак ирем, Тарагай углы шаһ Тимер, күпме шаһлыкларны, күпме ханлыкларны алган, күпме кызларны үзеңә хатын иткән әмир. Син аңларга тиеш минем хәлемне. Минем сөекле атам, сөекле анам, туганнарымның барысы да һәлак булды. Шаһиншаһның казнасы таланган, халкы кырылган, нинди бай-гүзәл Шираз каласын син җир белән тигезләдең, шаһның бердәнбер кызы исән калган. Аның никахлы ире бар. Әгәр дә Шәһриярымның исән икәнен сизенмәсәм, ике дә уйлап тормастан бәгыремә хәнҗәр батырыр идем. Мин сине түгел, Шәһриярымны көтәм. Син мине талап ала аласың. Ләкин үз ихтыярым белән бирелмәячәкмен, сине инкарь иткән, сине җене белән сөймәгән, чиксез нәфрәтле булган шушы зәгыйфь бикәчне көч белән, ризасызлык белән алырга вөҗданың җитмәс.

– Бәгыреңә хәнҗәр батыру «катиле нәфес» дип атала, кызчыгым. Коръән Аллаһу Тәгалә биргән җанны үз кулың белән чыгаруга каршы. Андыйларны хәтта зиратка да җирләмиләр, читкә, кяферләр кебек, каракларны каргаган кебек догасыз күмәләр.

Сөрәя әче итеп көлде.

– Коръән турында сөйләп торган көне! Тәһарәтсез авызың белән Аллаһның китабы Коръән турында фәлсәфә куертырга хакың юк, җәллад. Кяферләр белән сугышыр өчен Ислам байрагын тотып чыккан булсаң, мин сине аңлар идем, син Коръән исеме белән мөселманнарны кырып, җәннәткә кермәк телимсең? Ха-ха-ха... – Хатын көлүеннән туктады, кинәт, җитди

рәвештә әйтте. – Суфыйларның сафсатасы белән чагыштырганда, синең көфер сүзең чүп кенә, Тамерлан! Син тел тегермәне корырга яратасың, Тамерлан! Кичер мине, зинһар, бәдәни кимчелегеңә кагылырга тиеш түгел идем... Ярсыйм, үкерәм, мин акылдан язамдыр... кичер... мин сине аксак килеш тә сөяр идем, мин сине чулак килеш тә яратыр идем, әгәр дә син шулай кансыз булмасаң. Синең бит җаның аксак, синең рухың чулак, әмирбай! – Тимернең сабыр халәте үзгәрде. Ул шушы киребеткән кызның мантыйгына сокланган да, аңа җавап табуның ничек кыен икәнен дә төшенә бара сыман. Ул нидер эзләгәндәй, як-ягына каранып алды. Ни әйтергә сүз табалмагач, кызны туктатырга теләп бары тик: «Сөрәя, Сөрәя», дип кабатлый иде.

– Син бит килешү антын бозып, атамны алдап, хыянәтчел рәвештә бәреп кереп кенә, аның гаскәрен җиңә алдың. Башка калаларны, башка илләрне чәнчә бармагыңны селкетеп кенә алырга күнеккән кешене, Шираз шаһиншаһы Әлмансур еллар буе кыерлады, еллар буе син безнең илдән шәҗәрәңне кушучлап тотып кайтып киттең. Без бит сиңа бәреп кермәдек, син безнең капка төбенә килеп, сөяк көткән алама эттәй ялманып каңгырып йөрдең. Мәрхүм атам шаһиншаһ Әлмансур шушы җиңүләренә күрә «Әлмансур Зафәри» кушаматын яулаган баһадир.

Сөрәя шундый гайрәт белән сөйли, көчләүдән дә, үтерүдән дә, җәзалардан да курыкмас дәрәҗәдә шашкан ки, бу мохиттә ул – хуҗабикә, җиңүче кыяфәтендә иде. Дәһшәтле әмир Аксак Тимер каушап калганмы, әллә ул, бу бәхетсез бала үлеме алдыннан соңгы сүзен әйтеп бетерсен дипме, гамәлсез, хәрәкәтсез тора. Бу кечкенә кызчыкның нинди куәткә ия икәненә шаккаткандыр... Әллә бу кызны нинди җәзага тартырга кирәклеге турында баш ватамы? Сөрәя инде үзен үзе белештермәс дәрәҗәгә җиткән.

– Соңгысында да син атамны җиңә алмый идең, җиңә алмый идең. Чөнки атам ике арадагы солых булганына күрә, ваемсыз кала бирде, атам сиңа дөнья бәһасе торган маллар, затлы киемнәр, хәзинә бүләк итте. Синең белән орышмас өчен ул казнасындагы бөтен малын бирердәй иде, син антны боздың, бүләкләрне алдың, хаиннарча посып кына, игълансыз гына, куркак шакал кебек килеп бастың да, атам шаһиншаһ гаскәрен җыеп өлгерә алмый калды. Шулай да тиз генә Ширазны ала алмадың. Ярты гаскәрең кырылып бетә язды. Каушап калдың. Атам арткы капкадан чыгып, нибары ике йөз кешесе белән ике йөз меңлек гаскәреңнең артына төште, рәхәтләнеп турадылар безнекеләр синең нәҗесләреңне, артыңа борылганда, янында биш йөз генә яраның калган, калганнары шәһәр капкасына ябырыла иде. Шунда атам, куркусыз атам, каһарман атам үзенең кешеләре белән яныңа бәреп керде, атам өч тапкыр кылыч белән чапты, ләкин ике яраның гәүдәләре белән сине каплап өлгерде. Атам янә һөҗүм итте, син агарган, каушаган идең, сине курку белмәс, үлемнән курыкмас җан дип данлыйлар, ә бит атамнан курка идең, атам сине аркылы чаба иде, насыйп булмады. Күреп тордың, мәркәзеңә бәреп керә алган баһадир Әлмансур һаман орышты, һаман орышты, аның күкрәгенә ике ук кадалды, ботына сөңге батты, ләкин ул якын килгәннәрнең җанын кыя торды. Ул тагын синең янга бәреп керде, ләкин аты сөрлегеп, ияреннән егылды, синекеләр саранчадай аны урап

алды. Атам җан ачуы белән кычкырды: «мин Әлмансур шаһиншаһ, мине әмир Тимер җәнаплары янына алып барыгыз», – дисә дә, син чабарга куштың. Кабих җаннарың аның шәрә калган башына ун тапкыр кылыч чаптылар. Аны үтерергә куштың. Чөнки атамның исән калуыннан курка идең. Шатлан, кабихҗан, син безне җиңдең. Ләкин мөслимнәр канын агызганың өчен сиңа кыяматтә җавап бирергә туры килер. Ике сүзнең берендә: мин Коръән кушканча гамәл кылам, мин Пәйгамбәр юлыннан барам, дисең. Атлаган саен Коръән ачтырып, үз явызлыкларыңа аклану эзлисең. Ачтыр Коръәнеңне, әмир Тимер. Син надан, укый да, яза да белмисең, синең укырга, язарга өйрәнергә вакытың булмады, чөнки гомерең буе җан кыйдың, таладың, бастың, кырдың, адәм башларыннан, мөселманнарның баш сөякләреннән манаралар кордырдың. Синең тарихта калдырган һәйкәлләрең шулар булыр. Бисмиллаһ-ир-рахман-ир-рахим! – Ул ян кырда махсус җайланмада торган Коръәне алып, Тимергә сузды. – Теләсә кайсы сәхифәсен ачыгыз, тәкъсир. Коръән ни ди икән сезнең җәнапларыгыз хакында? Ачыгыз! – Тимер Коръәнне ала, ача, ачкан килеш Сөрәягә суза. Сөрәя башта укый, аннан китапны ябып, яттан сөйли: «Коръәни Кәримнең тугызынчы, ягъни Тәүбә сүрәсенең дүртенче аяте: «Килешүне азагынача бозмагыз! Аллаһ гаделсезлек эшләүдән сакланганнарны сөя!» – Тагын бер бит ача. – Коръәни Кәримнең уналтынчы сүрәсе, туксан икенче аяте: «Күзәнәкләрен тыгыз итеп бәйләгән бәйләвен сүтеп ташлаган хатын хәлендә калмагыз. Бер халык икенчесеннән өстен булырга мөмкин. Ләкин ул өстен халык өстен булмаганын ялган ант биреп кыерсытмасын. Аллаһ сезне шулай сынап бага!» Син сыналдың инде, әмир Тимер, синең урының тәмугта!

Тимер кинәт кызып-ярсып, кылычын суырып чыгарды, Сөрәягә кизәнде.

– Токымыңны ор-раем! – дип кычкырды әмир.

Сөрәя урыныннан һич кузгалмыйча, кычкырып көлеп, Тимернең кыланмышларына бага иде.

Сөрәя әйтте:

– Син мине урталай чапсаң, миңа яхшылык кына кылган булырсың. Минем һәлак буласым килә. Изге орышта шәһит китәсем килә минем! Чап син мине, Тимер! Чап! Урталай яр! Минем йөрәгем, үпкәләрем, бавырым урталайга аерылсын, аннан кайнар кара кан аксын.

Тимер чарасызлыктан кылычын аска төшерде, ул яшь хатын каршысында ихтыярсыз иде.

– Дөреслекне күтәрә алмыйсың, Тамерлан. Мин бит сиңа чүп кенә. Мин яклаучысыз бичара бикәч. Минем беркемем юк, минем бернием юк. Ярлы янудан курыкмас, ди аталарыбыз. Бәс, тугрысын чыраеңа чәпәп әйтәмен. Кулың белән изә-изә миннән камыр ясый торган зат түгелмен. Үзем тимерне кулым белән изеп, камыр ясый торган заттан! – Ул тынып калды, аның хәле китте, Тимер дә каушаган иде, ул кылычын кынына тыгып куйды, сабырланды. Тынлык урнашты.

Тимер әйтте:

– Сөрәя бикәч, син мине кире чыкмас тарлавыкка ябып куйдың. Мин хәзер шул тарлавыктан чыгу җаен табарга тиеш. Сине көч белән алырга яки ирекկә җибәрергә, яки урталай чабарга. Мин сине иреккә

җибәрер өчен Шираз тикле Шираздан монда алып кайтмадым. Ирекка аткару ул Аксак Тимернең йолаларына туры килми. Чөнки монда кергән хатын-кыз кире чыга алмый, аларның барысы да минем хатыным яки харам хатыным булачак. Мин сине урталай чаба алам, ләкин бүген түгел. Шулай булгач, бер генә юл кала, син минем хатыным яки җариям булырга тиеш. Ләкин иң кулай юлны күрсәтәм: син минем иң сөекле никахлы хатыным булырсың!

Сөрәя бикәч тә сабыр иде, ул тыныч кына әйтте:

– Атамны чабып, анамны бугазлаган кешенең юрганы астында ничек ятармын икән соң, бөек әмир Тимер? Син бит хатыннарыңның юрган астында кайнар булуын телисеңдер. Мин бит синнән җирәнәм! Курыкмыйм, җирәнәм синнән, җирән сакаллы әмир. Мәетне кочачаксың бит юрган астында. Син мәетләрне сөясеңмени, шаһ Тимер?

Әмир Тимер җәрәхәтләнгән юлбарыс кебек үкерде.

– Канымны кыздырма, бикәч! Үзем Тимер булсам да, сеңерләрем тимер түгел, алар бер шартлар. Кинәт кылычын чишеп ташлады, җөббәсен салды. Янаулы атлап, Сөрәягә таба килә башлады, бикәч икенче якка күчте. Син, кызый, артыгын кыланасың. Мин сине ирексезләмәскә уйлаган идем. Хәзер барысы да үз урынына утырыр.

Сөрәя кинәт куеныннан хәнҗәр чыгарды:

– Тагын бер атла, бәгыремдә шушы фарсы пычагы булыр. Син фарсы пычагының ни икәнен яхшы беләсең. Ике ягы да үткен хәнҗәр «Әҗем пычагы» дип атала. Мин шушы әҗем хәнҗәрен йөрәгемә батырам!

Әмир Тимер чыгырыннан чыкты һәм ул:

– Бөһтан! – дип кычкырды. – Яла! Нахак сүз сөйләп, гөнаһасын кая куярсың?

Сөрәя хакимнең бу кыланышыннан кычкырып көлде:

– Ә син кая куярсың гөнаһларыңны?

Бу әсир бикә каршысында Тимер чарасыз иде:

– Куй пычагыңны! Яхшылап сөйләшик.

Сөрәя әйтте:

– Без сөйләштек бит инде, әмир Тимер хәзрәтләре, барысы да аңлашылды.

– Теләгеңне әйт! – диде кырыс әмир.

– Мине ватаныма кайтарып куй! – диде әсир бикә.

Тимер ишек тарафына карап кычкырды:

– Һәй, кем бар анда! – Ханбикәләр керде. – Сезләр! Сөрәя бикәчкә иң олы хөрмәт, иң олы хезмәт булсын! Башыннан бер бөртек чәче төшсә дә, башыгыз белән җавап тотарсыз. Сөрәя бүген минем эчкәриемдә[4] булсын. Аны әзерләгез! – Әмир тыйтаклап чыгып китте.

Мәликә бикә артык ягымлы иде:

– Хуш килдең, шаһиншаһзадә Сөрәя бикәч!

– Мәрхәбә, гүзәлбикә, – диде Түкәл бикә. – Әмиребез ни сәбәпле сине аерым хөрмәткә куйды, бикәч?

– Гүзәл булгангадыр, – диде Мәликә бикә.

– Сез дә гүзәл, – диде Сөрәя.

– Акыллы булгангадыр, – диде Мәликә бикә.

[4] Эчкәри – ят кешегә керергә ярамый торган эчке бүлмә.

– Сез дә ахмак түгел, – диде әсир.

– Алайса, ни өчен? – диде бикәләр.

– Чөнки мин аның турында ни уйласам, шуны әйттем, – диде Сөрәя.

– Ни дидең? – дип сорады Түкәл бикә.

– Мин аңа «аксак, чулак, денсез, кяфер, җан кыючы, тәмуг кисәве», дидем..

– Ул сине кылыч белән чапмадымы?

– Күреп торасыз сана! Минем никахлы ирем бар. Әле аннан талак алганым юк. Мин эчкәригә кермәмен!

– Каян килгән Алланың кашка тәкәсе! Керерсең! Син түгел, башкалар да керде, – диде Мәликә бикә.

Ашыгып, чапкын керде.

Мәликә сорады:

– Ни бар, кем син, каян син чапкын?

Сөрәя бикә чапкынга таба атлады:

– Ихласҗан! Хәбәр бармы Шәхриярымнан?

Чапкын тынына капланып әйтте:

– Шаһзадә Сөрәя бикә, синең никахлы ирең таулар арасында, алган җәрәхәтләреннән вафат. Аны мин үз кулларым белән җирләдем. Урыны җәннәттә булсын! Чапкын Сөрәя бикәчкә яулык бирде.

– Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун, – дип, дога кылдылар.

Сөрәя бикә яулыкны алып сөйләнә башлады:

– Шәһриярым! Җаным, муенында минем яулыкны ахырынача саклап йөрткән. Хуш, бәхил бул, ярым, Шәһриярым.

Чапкын әйтте.

– Авыр туфрагы җиңел булсын!

– Менә мин хәзер тол хатын! – диде Сөрәя бикәч. – Хуш, бәхил бул, Ихласҗан! – Һәм яулыкны йөзенә каплап үкси башлады. Аны кәнизәкләр алып чыгып китте.

Ашыгып-кабаланып, Күгелташ керде.

– Ханым бикәләр, кичерегез, мин кисәтмичә генә. Әмир сарайда күренмәдеме?

– Сарайда аңа ни калган, – диде Мәликә бикә. – Ул зөфаф кичәсе уздыра яңа кәләш куенында.

– Йа Ходам! Кайда әмир?

– Эчкәридә.

– Ни булды, Күгелташ? Яу бармы?

– Яу булса, куаныр идең, Мәликә бикә. Мур килә!

– Мур килә? Әстәгъфирулла!

– Мур кыра елкыларны, куйларны, дөяләрне. Кешеләрне мур кыра.

– Качарга кирәк!

– Мурдан качып котылып буламыни, Мәликә бикә?

Эчкәридә әмир Тимернең:

– Сөрәя, ни кыласың? – дигән тавышы ишетелде. Барысы да куркып-тынып калды. Бераздан Сөрәянең гәүдәсен күтәреп, әмир Тимер чыкты, Хатынның күкрәгендә хәнҗәр иде. Әмир Тимер гәүдәне уңайлы урынга яткырды, үзе үксеп елый башлады.

Түкәл бикә шелтә белән әйтте:

– Син аны үтердеңме?.. Ул бит сиңа хыянәт итмәде, аның җанын кыярга тиеш түгел идең.

– Мин берни дә күрмәдем, – диде Сарана.

Әмир Тимер сулкылдап әйтте:

– Ул үз хәнҗәрен бәгыренә батырды! Мин аны коткарып калалмадым.

Чапкын әйтте:

– Әйе, бу шаһзадә Сөрәянең хәнҗәре. Сөйгәне Шәһриярның туй бүләге.

– Әмирем, мур килә! – диде Күгелташ.

Чапкын әйтте:

– Бу – кылган гөнаһларыбызга күрә җибәрелгән җәза!

Бикәләр, җарияләр:

– Мур килә! Качыгыз, мур килә! – дип кабатлады.

Чапкын аларның тавышын уздырып кычкырды.

– Аксак Тимер муры килә икълимгә! Аксак Тимер муры!

Буйсындырылмаган әсир бикәч Сөрәяне җирләгәннән соң, әмир Тимер тагын яуга әзерләнә башлады.

Тимер явының хәрәкәте. Бер офыктан икенчесенәчә хәтле атлы гаскәр, җәяүлеләр, дөя җайдаклары сузылган иде.

Король Һенрих Өченче

Толедо шәһәре.

Чыннан да, Койрыклы йолдыз узып киткән елда Кастилия короле сараенда бер зәгыйфь бала дөньяга килгән иде. Әтисе – король Хуан да, әнисе – королева да шул төнне вафат булды. «Чирләшкә Король» кушаматы алган Һенрих сабый чактан ук сырхау булса да, зиһенле, үҗәт иде. Чире аркасында аның дуслары да күп түгел. Сеньорлар үз балаларын Һенрих белән уйнатмаска тырыштылар. Бичара сабый янында иң якын дусларын санарга бер кул бармаклары да артып калыр иде. Чиркәү каршындагы мәктәптә укып, аннан пажлар мәктәбенә бирелгән берничә ятим баладан башка аның янында дуслары күренми. Ләкин үҗәт Һенрих үзенең король углы – инфант[5], ягъни принц икәнен бер генә мизгелгә дә онытмады. Пажлар мәктәбендә укыганда да, университетта да тарихны, фәлсәфәне, патшалар турындагы китапларны ул су кебек эчә иде. Аның тырышлыклары бушка китмәде, ниһаять, тәхеткә утыра алырлык шәхес икәнен исбат итте һәм король булды.

Кастилиянең башкаласы Толедо шәһәре гаять матур иде. Король сарае башкаланың горурлыгы, мактанычы. Корольнең тәхетханәсе гүзәл, ялтыравыклы. Корольнең тәхете аннан да затлырак.

Тәхетханәдә король Һенрих белән канцлер Салазар – икәү дәүләт белән хөкүмәтнең авыр чишелә торган мәсьәләләре турында гәп кора иде. Шулай тыныч кына сөйләшеп утырганда король Һенрих ютәлли башлады, аның ютәле көчәя барып, тын ала алмыйча буылуга җитте. Корольнең күзләре акайды, тыны капланды. Бетте король, тынды, үлде дигәндә генә, канцлер Салазар аңа дару каптырды, кадехкә[6] салынган суны эчерде. Король Һенрих калтырый-калтырый су эчте. Аннан тирән сулыш алды.

[5] Инфант – балигъ булмаган сабый варис; принц.

[6] Кадәх – бокал, сыеклык салынган савыт, бокал, рюмка.

Король Һенрих озак кына тын утырды, башындагы таҗын, карышкысын ачу белән идәнгә атып бәрде.

– Король имеш! – диде ул ачыну, кемгәдер рәнҗеш, үпкә белән. – Инаугурация[7] уздырдылар, янәсе, Хуан углы Һенрих Өченчене кануни король итеп, тәхеткә күтәрделәр... Мин нинди король, дустым Салазар, нинди король инде, йә? Минем турыда халык арасында, бигрәк тә сеньорлар, монахлар арасында ни сөйлиләр? Салазар таҗны алып, тузаннарын өрештергәләп, тәхет янындагы калкулыкка куйды, еракка тәгәрәгән карышкыны сак кына алып, корольнең уң тарафына сөяде. «Чирләшкә король» минем исемем! Чирләшкә король озак тормас, аның урынына башка инфантны, ягъни варисны әзерләргә кирәк. Чирләшкә өйләнергә охшамаган, анда хатын-кызлар кайгысы юк, ул маврлар, басклар, яһүдләр белән күбрәк аралаша, дип сөйли, ди халык... Беләсеңме, Салазар? Мөселманнар, яһүдләр белән аралашканга, мине «еретик» дип атыйлар кайбер монахлар. Мин еретик түгел, мин чын христиан, ләкин башка диндәгеләр белән кешеләрчә мөнәсәбәттә булырга кирәк, дип уйлыйм. Арагон, Португалия, Кастилия, Леон, Валенсия, Кордова, хәтта Гранада – бөтенесе бер булып, бөек Испанияне тәшкил итәргә тиеш. Безнең корольләр үзара сугышып, бер-берсен талап ята... Мөселман маврлар җиде йөз ел безнең өстә тора. Ә инквизиция христианнарны кыра, яһүдләрне талый, маврларны үтерә. Яһүдләрне, маврларны, баскларны күпләп кырып, католик динен ныгытып булмый, дустым Салазар. Халыкта нәфрәт уятып кына була. Маврлар, яһүдләр тагын да ныграк үрчи, тагын азау яра. Испания булсын, дисәк, сеньорларның казнасы түгел, король казнасы бай булырга тиеш. Ә минем казнам буш. Сеньорлар бай, алар – король, мин король түгел. Узган атнаны кыяфәтемне үзгәртеп, шәһәрдә йөрдем. Һәр магнатның сараенда сыяфат мәҗлесе. Кардинал Бардини сараендагысы иң бае, корольләр көнләшерлек мул табын. Мәҗлесләрдә шау-шу, акырыш-әчеш, кочыш, шулар арасында бер генә сүз сөйләшүгә сәбәп: король чирләшкә, король малай гына әле, башка король кирәк! Корольнең казнасы буш дип, яшермичә кычкыралар. Нишлим, Салазар? Алар мине мыскыл итә!

Салазар әйтте:

– Атагыз король Хуан епископларга, инквизиторларга азынырга юл куймады, ул яһүдләрне талауга, аларны күпләп үтерүгә дә каршы чыкты, әмма ул мәрхүм булгач, магнатлар да, епископлар да ныграк азды.

– Иң яманы шул, Салазар, аларның барысы да католик дине исеменнән гамәл кыла. Католиклар исеменнән католик динен җимерергә алынган җинаятьчеләр алар, дустым. Бөек инквизитор Бонифаций IX шул җинаятьләрне хуплый кебек. Аның урынында ниндидер тиле, комсыз, рәхимсез кеше утыра. Аңа маврның мөселман булуы нәфрәт чыганагы түгел, бай маврның малы кирәк. Яһүдләрнең башка дин тотуы фәлән дә тормый, аңа яһүдләрнең байлыгы кирәк.

Салазар як-ягына каранып алды да әйтте:

– Имештер, бу Бөек инквизитор чын түгел, элеккегесенең игезәге икән. Чын түрәне үтергәннәрме, каядыр ябып куйганнармы, дип сөйли халык, – диде.

[7] Инаугурация – патшаны тәхеткә күтәрү тантанасы.

– Имешләр күп, дустым Салазар. Атам Хуанны да мин туган көнне агулаганнар, дип сөйли халык. Мин Койрыклы йолдыз узып киткәндә туганмын. Шул төнне үк анам да кинәт өзлегеп үлә. Яхшылап карамаганнар: сабый чагымнан ук мин үпкә чирле булганмын. Сәер хәлләр сарайда, Салазар. Имешләрнең кайсысы дөрес, кайсысы уйдырма – шуны гына белеп булмый.

– Сеньорлар арасында һәр көн сугыш-суеш, – диде Салазар.

– Шулай, – диде король. – Христиан христианны суя.

– Граф Ниебла белән сеньор Понсе арасындагы сугышта өч йөз илле кеше һәлак булды. Граф Кабра белән граф Альфонсо үзара сугышканда, өч мең кеше үтерелгән. Толедода яһүдләр мәхәлләсендә яһүдләрне талап, өч меңен кылычтан уздырганнар. Ересьта гаепләп, ике мең дүрт йөз кеше яндырылган.

– Иисусе Христосе! Кырылып бетә бит халык. Бу нинди афәт? Бу нинди гаделсезлек!

– Инквизиция тагын мең ярым кешегә аутодафе әзерли.

– Кая бара дөнья?

– Шулар өстенә, королем, Франция ягыннан басып кергән юлбасарлар илне талый. Гасконлылар, германнар, инглизләрдән торган этрәк-әләм, өер булып оешалар да, урман юлларында, тау тарлавыкларында гына түгел, хәтта шәһәрләрне, кальгаларны да талый, яндыра, кешеләрне кыра башлады. Аларның башында француз рыцаре Бертран Дюгеклен, инглиз башкисәре Ричард Ланкастерский тора. Йөз мең флорин бәясенә француз короле Тилемсә Карл Кастилиягә өстергән.

– Йа Аллам, йа Иисусе Христосе, ни өчен барысы да Кастилиягә ябырыла? Ни өчен мин король булып утыргач кына, бу афәтләр килә. Ул йөз мең флоринны алып калыр өчен юлбасарлар бездән миллион алтын флорин таларга тиеш булып чыга бит! Йа-а, дөнья-а, үләм мин бу тәхеттә.

Җенләнә, тәхеттән төшеп, тәхетне типкәли, өс киемнәрен салып ыргыта.

– Нигә мин инфат булып тудым икән, нигә миңа атам мирас итеп, шушы тәхетне калдырды икән! Суялар, кыралар, кая качыйм? Кемнән ярдәм сорыйм? Бүген, менә хәзер сеньорларның арманданосы[8] булырга тора. Мин бу җыелышка әзер түгел, мин ни әйтим аларга? Аларның тәкъдимнәренә ничек каршы чыгыйм? Алар минем тарафыма борылып та карамаячак. Әйтерсең лә, тәхеттә король түгел, бер уенчык малай утыра.

Салазар чыгу юлына юнәлде.

– Король хәзрәтләре!

– Кем бар анда, магнатлар җыелышы башланырга тора, соңыннан сөйләшербез.

– Король хәзрәтләре, ерак-ерактан илчеләр килгән. Алар Бөек Тартария иленең падишасы әмир Тамерланнан! Илчеләрне король гадәттә өч көннән соң кабул итә торган иде.

– Нигә кирәк ул купшы церемонияләр, дустым? Вакыт уза. Хәзер үк керсеннәр.

Салазар корольгә киенергә, өстен-башын рәтләргә булыша башлады. Король тәвәккәлләп таҗны башына киде, кулына карышкысын тотты. Бөек

[8] Армандано – җыелыш.

Татар иленең падишасы әмир Тамерланнан илчеләр, дидеме? Кайда соң ул Бөек Татар иле?

– Маҗарстаннан ары, славяннардан да ары, кар илләреннән ары, Чипанго диңгезе буендагы ил, королем. Чыңгыз, Батый илләре ул, королем. Дөньяның аргы читендәге ил ул Татар иле.

– Бөек Тартария хакиме Тамерланның миндә ни йомышы булыр икән? Алар нинди телдә аңлаша соң? Чакырыгыз телләр белүчене!

– Королем, алар гарәпчә, татарча, фарсыча аңлаша. Бөек Мәвәрәэннәһер, Сәмәрканд, Хорезм һәм Татар илләренең хакиме әмир Тамерланның бөек илчесе Исрафил хәзрәтләре!

Тантаналы рәвештә илчеләр керә. Мөселман илчеләре киемендә Карадәрвиш, Олонсо, бер-ике хезмәтче күренә.

– Илчеләр, сез Кастилия короле Һенрих Өченче хозурында! – диде Салазар.

Король Һенрих әйтте:

– Хуш килдегез, илчеләр! – диде. – Бу кыргый татарлар испанча аңламый булса кирәк! Шулай да «кыргый татарлар», «вәхши татарлар» дип мәгълүм бу халыкны кысык күзле, сирәк сакаллы, кәкре аяклы, дип әйтәләр иде. Болар кешегә охшаган лабаса.

Карадәрвиш король алдында тез йөгенде дә әйтте:

– Татарлар арасында сез әйткән кебекләр дә бар, җәнабегали, гомумән алганда, татарлар бик мәһабәт халык. Испаннардан ким түгел.

– Иисусе Христосе, сез безнең телне каян шулай яхшы өйрәндегез? – диде Салазар.

– Минем уң кулым – Мостафа Гранадада туган, ул испанчаны, французчаны, итальянчаны, гарәпчәне, татарчаны, фарсычаны бик яхшы белә, королем. Җиде икълимнең бишесен яулаган бөек җиңүче әмир Тимер хәзрәтләре сезгә минә шушы хатны, килешү язуын һәм һәдияләрен озатып калды.

Хезмәтчеләр берничә сандыкны тәхет янына куеп, артка чикте. Әмир Тимер җәнаплары Кастилия белән сәүдә итмәк тели, сездән нинди маллар безгә, бездән нинди маллар сезгә китерергә мөмкинлеге турында кызыксына?

– Бу гаҗәеп бер матур гамәл, бөек илче Исрафил хәзрәтләре. Сөйләгез, илчеләр, кем ул әмир Тимер, аның гаскәре күпме, теләге нинди? Ихтимал, сәүдә, алыш-биреш теләгеннән тыш, безгә карата башка бер ихтыяры бардыр.

– Бөек король! – диде Карадәрвиш. – Бөек әмир Тимер сезләргә тагын бер һәдия юллады. Ул өйләнмәгән яшь король икәнегезне ишетеп, сезгә үзенең иң гүзәл җарияләренең берсен күндерде.

Гайшә бикәне алып керделәр. Бикә шәрыкча бай киенгән. Ул тез йөгенгән килеш кала бирде.

– Кабул кылып алыгыз, король җәнаплары! – диде Карадәрвиш.

Король Һенрих әйтте:

– Иисусе Христосе! – Ул ютәлли башлады, ютәле тынычлангач, Гайшәне әйләнеп чыкты. Глориан дей![9] Талифа куми![10]

[9] Глориан дэй – искиткеч гүзәл чәчәк (исп.).
[10] Талифа куми – кызыкай, аягыңа бас (исп.).

Тәрҗемәче аңлатты:

– Король җәнаплары: гаҗәеп гүзәл чәчәк! Гүзәлкәй, аягүрә басыгыз! – диде.

Король Һенрих соклануын яшерми иде инде.

– Калык! Аягыңа бас, ди, кызым... – диде Карадәрвиш.

– Талифа куми! – Гайшә бикә аягүрә басты.

– Бөек король! – диде Карадәрвиш. – Хозурыгызда Алтын Урданың бер олуг вилаятендәге Габдулла ханның кызы Гайшә бикә бу. Затлы нәсел, затлы кан. Атасы, кардәшләре яуда һәлак булгач, аны әмир Тимер үз хозурына алдырган иде. Бөек әмиребезнең изге теләге: сезнең илә дустанә мөнәсәбәтләрдә яшәү, бәс, шуңа күрә атаклы яугир Тамерлан үзенең иң кыйммәтле «асылташ»ын сезгә юллады.

– Искиткеч асылташ, Салазар. Бөек илче Исрафил җәнаплары, шундый гүзәллекне исән-сау алып килеп җиткергәнегез өчен сезгә чиксез рәхмәтләрем. Ләкин безнең католик дине йолалары аны миңа хатын итеп алырга рөхсәт итми.

Карадәрвиш әйтте:

– Җариягез, хезмәтчегез, ястыкчыгыз итеп алыгыз, королем.

– Хуш! – диде король. – Без бу турыда уйлашырбыз әле. Кунакбикәне урнаштырыгыз! – Сарай хатын-кызлары Гайшәне алып китте. Инде тел төбеңдә, астарлы сүзеңнең астында ни ятканын безгә бәян ит, илчем!

– Мин ялгышмаганмын, Аллага шөкер! – диде Карадәрвиш. – Мин ялгышмаганмын. Кастилия короле зиһенле зат икән!

– Мин дә ялгышмадым шикелле. Синең сүзең әле төкәнмәгән...

– Дөрес, король, минем сүзем әле төкәнмәде. Бүгенге көнең синең тууыңа караганда да хәтәррәк. Чөнки Кастилия короленең казнасы буш. Казна хәзинәсен юлбасарлар гына талап бетерә алмый, епископлар, хәерче монахлар, Бөек инквизитор гына ашап бетерә алмый. Казнаны үзеңнекеләр талый. Алар талаган хәзинә һәр илнең короле, падишасы, әмиренең байлыгыннан да артык.

Король бу сүзләрдән өнсез калды:

– Иисусе Христосе! Син боларны каян беләсең, Тамерлан әмирнең илчесе? Син күрәзәчеме? Әллә сихерчеме?

– Мин сихерче түгел, король Һенрих. Синең бу канцлерың ышанычлы кешеме?

– Корольлегемдә шул минем бердәнбер таянычым – Салазар!

– Салазар? – дип гаҗәпсенде Карадәрвиш.

– Әйе, шулай! Дустым Салазар! Без аның белән пажлар мәктәбендә бергә укыдык.

Дәрвиш Салазарга сокланып карап торды да:

– Салазар! – диде. – Сөбханалла! Салазар, синең сул беләгеңдә көрән миңең бар! Дөресме?

Салазар аптырады, ул җиңен сызганды. Җиң астыннан кызгылт көрән миң күренде.

– Дөрес!.. Ә сез аны каян белдегез?

Олонсо сүзгә катнашты:

– Тамерланның илчесе күрәзәче бит! – диде юлчы.

Дәрвиш әйтте:

– Король җәнаплары, синең яхшы дустың бар, шөкер! – Илче як-ягына каранып алды. – Безне тыңлап тормыйлармы? – Салазар белән Олонсо ишекләрне тикшереп килде. – Сарайда диварларның да колаклары бар, королем. – Корольне бер кырга алып, яшертен, ярымпышылдап әйтте. – Бөек инквизитор Бонифаций урынында юлбасар Педро Бургос утыра! – диде.

– Иисусе Христосе! – диде король.

– Тсс! Чын Бонифацийны яшертен генә куып, аңа тач охшаш каракны, башкисәрне утырттылар.

– Баш китәрлек сүзләр сөйлисең син, илче. Әгәр боларны башкаларга сөйләсәң, инквизиторлар яндырып үтерәчәк. Син боларны каян беләсең?

– Чөнки мин үзем чын Бонифаций!

Һенрих тагын ютәлли башлады, Дәрвиш аңа дару каптырды, король тиз тынычланды.

– Бу нинди дару? – диде король.

– Тибет тауларыннан җыелган үлән – җәншән тамырының тузаны. Мә, ютәл кытыклый башлагач, шушыны иснә. – Илче корольгә дару бирде.

Һенрих әйтте:

– Акыл җитмәслек сүз сөйлисең син, илче! Мин синнән курка башладым. Син гади кеше генә түгел, син сихерче яки тылсымчы.

– Теләсәң ничек уйла, ләкин сине коткарырга кирәк, сине генә түгел, корольлекне коткарырга кирәк, корольлекне генә түгел, католик динен, Кастилияне коткарырга кирәк. Кастилияне маврларга, яһүдләргә, гарәпләргә, төрекләргә хач сәфәрләре оештырып кына коткарып булмый, яу артыннан яу чаптылар христианнар Ислам илләренә. Мөселманнар, яһүдләр үрчи барды, байый барды, куәтләнә барды. Яңа ысуллар кирәк, король.

– Кем син?

– Мин хаиннар тарафыннан сарайдан куылган чын Бөек инквизитор Бонифаций. Мин сине коткарырга килдем. Мин ватанны коткарырга килдем. Ал мине үз яныңа.

– Син мөселман илчесе, син Ислам динендәге кеше, мин сине сараема алсам, кардинал Бардини икебезне дә учакка ташлатачак.

Илче шәрык киемнәрен салып, испанча кием белән калды. Мостафа да шулай ук кием алмаштырды. Алар икесе дә почмакка карап чукына башлады.

– Без икебез дә чын христиан. Минем исемем Бонифаций, сарайда мине Пилигрим дип атарсыз, Мостафаның христиан исеме дон Олонсо Поэс булыр.

– Могҗиза бу, Салазар! – диде король.

Салазар куанычын яшерә алмыйча әйтте:

– Бу могҗиза безнең файдага, королем, – диде.

Король җәнаплары әйтте:

– Салазар, син сул ягымда, Пилигрим, син минем уң кулымда торырсың. Патшалыгымда эт – баш, сыер – аяк, тәртип юк.

Карадәрвиш әйтте:

– Королем, зинһар, сак бул! Магнатлар синнән куәтле. Аларда гаскәр һәм

байлык. Иң башта казнадан талап алынган байлыкны кайтарырга кирәк. Ышанычлы сакчыларыңны һәм җәлладларыңны чакыр, аларны пәрдә артына постырып куй. Аннан соң магнатларны, кардиналны чакырырсың. Үгезне мөгезеннән алыр вакыттыр! Кинәт һөҗүм ит! Каушап калсыннар!

– Бар, дустым Салазар, – диде король. – Минекеләрне һәм җәлладларны чакыр, иң башта епископ-инквизитор Бардинины, аннан соң магнатлар керсен. Кардиналларның җыенын башлыйбыз!

Салазар чыгып китте.

Казнасы буш фәкыйрь Кастилиянең Чирләшкә короле Һенрих IIIнең югалтыр нәрсәсе юк. Аның ата-анасы вафат, сәламәтлеге юк, ул озын гомерле булмас, хатыны, балалары юк, король мотлак ирекле, мотлак азат. – Ул ютәлләп алды. Дару капты, бераз тынычланды. – Тәвәккәл таш ярган, ди. Мин дә тәвәккәлләдем! Иисусе Христосе, ярдәмеңнән ташлама! Амин!

Тәхетханәгә Кардинал Бардини, аның артыннан магнатлар керде. Болар үзләрен корольдән өстен тота иде, һәрберсенең берничә кальгасы, гаскәре бар. Чынлыкта алар корольгә буйсынмый. Кардинал Бардини тәкәллефсез генә узып, король янына килеп утырды. Магнатлар да корольдән арттырыбрак киенгән. Үзләре теләгән урыннарга урнаштылар. Бардини король янында басып торучы Карадәрвиш белән Олонсоны күреп алды һәм әйтте.

– Иисусе! Король җәнаплары! Сараеңда яңа магнатлар барлыкка килдеме?

Король әйтте:

– Минем икенче канцлерым Пилигрим һәм аның хезмәтчесе Олонсо... Бу – кардинал-инквизитор Бардини хәзрәтләре. Ул минем мәгънәви атам, гөнаһлыларның гөнаһларын ярлыкаучы. Гөнаһлар ул ярлыкап кына бетәрлек булмаса, аларны учакта яндыру – аның изге вазифасы.

Бардини әйтте:

– Бу йөзләр бер дә таныш түгел кебек, – диде.

– Алар бик ерактан, кардиналым, Константинополь шәһәреннән. Хәзерендә Пилигрим вакытлыча минем киңәшчем, ягъни икенче канцлерым вазифаларын үтәячәк!

– Бөек Кардиналның рөхсәте, һич югында кардиналыңның фатихасы кирәк булмадымыни, король җәнаплары?

– Сеньор кардинал, бюрократия уйнамыйк инде! – диде король.

– Ичмасам киңәшкән булырга кирәк иде.

– Киңәшкән булам бит инде. Менә бу минем икенче киңәшчем Пилигрим, аны сараема хезмәткә алырга сез каршы түгелдер бит? Сеньорлар-магнатлар, сараема яңа хезмәткәр алуыма сез дә ризадыр бит? Дәшмәү – ул ризалык галәмәте! Языгыз! Бу кәгазьгә корольнең мөһере, имзасы сугылып, яңа канцлер Пилигрим вазифаларын башкарырга тотынсын!..

Дәрвиш корольгә якын тора һәм ара-тирә иелеп, киңәшләр бирә иде.

– Хәзер король сараендагы киңәш җыелышын башларга тиеш идек. Ләкин җыелыш башлана алмый! Халык шаулашырга тотынды. «Ни өчен, ничек?» кебек сүзләр ишетелеп куйды.

– Барыгыз да тәхетханәдән чыгыгыз! Сарайдагы олы җыелышка, элеккеге корольләр янына, тәхет залына, король Педро IV, король Энрико

II, король Хуан янына ничек керә идегез? Минем яныма да, ягъни королегез янына да шулай керегез! Йола шулай куша!

Салазар боерды:

– Басыгыз! Барыгыз да!

Иң беренче магнат Рамиро ризасызлык белдерде:

– Бу нәрсә була инде? – дип, иңен җыерды.

Икенче магнат Кассио да Рамирога кушылды:

– Бала-чага уены уйныйбызмы?

Өченче магнат кызып китте:

– Чишеләсе бер кочак мәсьәлә бар, без монда уен уйнап маташабыз.

Салазар аның сүзен кисте:

– Корольгә ике тапкыр кабатлатмагыз, зинһар! Тиз булыгыз, тәхетханәне бушатыгыз!

Магнатлар теләр-теләмәс кенә чыга башлады. Кардинал утырып калды.

Король Һенрих әйтте:

– Кардинал-инквизитор Бардини җәнаплары, бу боерык сезгә дә кагыла, – диде.

– Кардинал, рәхим итегез! – диде канцлер Салазар.

Бардини нидер әйтмәкче булып, корольгә эндәште:

– Һенрико!

– Король ике тапкыр кабатламый! Чыгыгыз! – дип, катгыян боерды Салазар.

Бардини чыгып китте. Карадәрвиш, Олонсо, Салазар шатланып, бер-берсенә баш бармакларын күрсәттеләр. Һенрих аягүрә басты. Музыка уйный башлады.

Салазар ишек тарафына карап:

– Кардинал Бардини җәнаплары, сеньорлар! Король сезне кабул итәргә әзер! – дип кычкырды.

Бардини, магнатлар төзәтенә-төзәтенә керә башлады. Барысы да аягүрә басып тора. Һенрих утырган. Шуннан соң гына Бардини һәм башкалар утыра башлады.

Король Һенрих сүз алды:

– Кардиналлар җыены башланганчы, мин Бардини җәнапларына бер сорау бирермен... Әйтегез әле, хөрмәтле кардинал, Кастилиядә ничә король бар?

Бардини әйтте:

– Кастилиядә бер король!

– Кем инде ул король?

– Сез, Һенрико III җәнаплары!

– Ялган! Дөрес түгел җәнаби-кардинал! – диде Бардини.

– Мин башка корольне белмим. Ә-ә, сез ничә кеше тарихта Кастилия короле булып торды, дип сорыйсызмы? Фернан Гонсалес, Гарсия Фернандес, Санчо Фернандо...

– Юк! Мин бүгенгесен сорыйм. Бүген Кастилиядә ничә король бар? Сеньор Альфонсо Фредрико, сез җавап бирегез.

Альфонсо да бер генә король барын раслады.

– Сеньор Луис, сез ни әйтерсез?

Луис ни әйтергә белмичә, ык-мык итте, җавап бирергә базмады:

– Мин... ни... король... – диде дә туктады.

Һенрико:

– Мин киемемне алыштырып, шәһәр буйлап йөрдем, сезнең кальгаларыгызны барлап чыктым. Халык арасында йөрдем. Сеньорларның бәйрәмнәрендә катнаштым. Хезмәтче кыяфәтендә кардинал-инквизитор Бардини сараена да үтеп кердем. Гәрчә, ул туйларга чакырылмаган идем. Чирләшкә корольне кем туйга чакырсын, авыру корольне кем кальгага, сараена кунакка алдырсын! Бай яшисез, сеньорлар, бай яшисез. Минем сеньорларым муллыкта көн итә, дип куандым. Ә шәһәрләр арасында йөргәндә, соңгы яңгырлыгымны сатып, тамак ялгадым. Кем король бу илдә? Ялган сөйлисез, галиҗәнаплар, Кастилиядә король берәү генә түгел, Кастилиядә кимендә утыз король бар. Мине санасаң, утыз бер король, ләкин мине корольгә санаучы юк. Сеньорлар арасында исемем чирләшкә Һенрих, монахлар арасында үземне күптәннән табутта күрәләр. Алар мине тере мәет Һенрих дип атый. Сарайлары берничә булган сеньорлар кызларын чирләшкә корольгә түгел, бай юлбасарларга димли. Кастилия короле Хуан углы Һенрих юлбасар дәрәҗәсендә дә түгелмени? Мине кардинал әллә кайчан инде чиркәүгә алып кереп, дога укып, яхшылап җирләде. Җирләмәгән булса, тере король алдында сез шундый әдәпсезлекләр кылмаган булыр идегез. Корольнең хәзинә казнасы буш, минем майордомым, ягъни акча эшләрем өчен җавап бирүче хисапчым эшсез утыра. Санарга акча юк казнада. Пешәргә ит юк казанда! Королегезнең теш казнасына кыстырырга ипие, эчәргә шәрабы юк. Чөнки Кастилиядә утыз король тыгына, ашый, чөмерә, кикерә. Алар яһүдләрне талый, маврларны сыга, еретиклардан акча каера. Бүгеннән Кастилиядә бер генә король – Һенрих III кенә булачак. Ризасызлык, шау-шу купты.

– Салазар! – дип кычкырды король.

Салазар үз чиратында:

– Каравыл! – дип боерды.

Як-яклардан, уртадан баштан-аяк коралланган сакчылар кереп, шпагаларын ялангач тотып, магнатларны урап алды. Уртада кып-кызыл киемле өч палач калкып чыкты.

Король әйтте:

– Менә исемлек. Һәр сеньор казнадан алган акчаны кайтарырга, һәр сеньор үз биләмәләреннән король карамагына ун-унбиш мең атлы, кораллы сугышчы бирергә тиеш. Сеньорлар арасында шау-шу башланды. Урыныннан кузгалган һәр каракны шпага тишеп узачак. Бу – бер. Сабый чагымда, мин авырып ятканда, казнадан урлаган акчаларны кем кайтармый, аның урыны җәһәннәмдә булачак! Аңлашылдымы? Имза куймаганнарның һәрберсен аерым бүлмәгә, каты сак астына, зинданга урнаштырыгыз. Магнатның ышанычлы кешесе сарай казнасына тиешле акча китереп биргәч яки имза салгач кына, сеньорны азат итегез! Миңа үпкә сакларга уйламагыз. Үч алу юлына да басмагыз! Югалтасы нәрсәм юк. Әмма мин әҗәлемә чаклы илдә тәртип урнаштырырга тиешмен! Тиешмен! Бетте! Салазар, укы!

Салазар исемлекне укый башлады.

– Мин – Севилья кальгасының сеньоры Ордонио Рамиро король казнасыннан бурычка алып торган илле мең алтын мараведины шартнамәгә кул куйган көннән алып, бер атна эчендә кайтарып бирергә ышандырып, имзамны куям... Имза, елы, ае, көне... Рамиро кәгазьгә имза салды да кире үз урынына утырды. Салазар дәвам итте:

– Мин – Леон замогының сеньоры Гарсия Бермудо...

Гарсия да кул куйды. Имза салу сөреше арткы рәткә күчте. Король Һенрих белән Бардини алга чыкты.

Бардини ризасыз иде, ул әйтте:

– Сез, король җәнаплары, кардиналга да имза салдырмыйсыздыр бит?

– Мин сездән икеләтә алган булыр идем, кардинал җәнаплары, сез – хәйләкәр инквизитор, сез шартнамә язмыйча гына казнаны талагансыз.

– Инквизиторлар белән бил алышырга азапланганнарның үз билләре сынды, король! – диде Бардини.

– Бу корольгә янаумы, кардинал-инквизитор?

– Ничек аңларга телисез, шулай аңлагыз.

– Король Хуанны да без агуладык, дип әйтергә теләмисездер бит, кардинал?

Бардини шартлый язды:

– Король җәнаплары, сез артыгын кылана башладыгыз түгелме?

– Бусын да янау дип аңларга кирәкме, кардинал?

– Инквизиция барысын да күрә, барысын да белә, король җәнаплары.

– Инквизиция барысын да белә, барысын да күрә. Илне юлбасарлар талый, кая карый инквизиция? Җавап бирегез, кардинал-инквизитор! Чит ил башкисәрләренең ватаныбызда кылган кабахәтлекләре турында инквизиция белмимени? Әллә күрмәмешкә салышамы?.. – Тынлык хөкем сөрде. – Сез, кардинал-инквизитор, атам үләсе көнне аның сараенда булгансыз, шулаймы?

Бардини сагаеп калды:

– Моның белән ни әйтмәкче буласыз?

– Сез, кардинал-инквизитор, король Хуан үләсе көнне аның сараенда булдыгызмы?

– Булдым! Мин аутодафе эшләре белән килгән идем. Шуннан ни?

– Болай гына! Шунда булганыгызны гына беләсем килгән иде.

Салазар әйтте:

– Король җәнаплары! Барысы да имза салды. Ике сеньор гына риза булмады.

– Кемнәр? – диде король.

– Сеньор Опелио белән сеньор Диего Лопес.

– Зинданга! – дип боерды король.– Инквизициянең еретикларны җәзалый торган бүлмәсе аша алып барыгыз да аерым камераларга ябыгыз.

Опелио әйтте:

– Минем казнага бурычым юк!

Диего сүз алды:

– Король җәнаплары, минем йортым, авылым янды, хәзер генә кайтарып бирерлек малым да юк.

Король әйтте:

– Гранадага якын җәйләүләрдән маврларның елкы, куй көтүләрен ничә тапкыр куып алып кайттың? Син инде янган йортыңны тагын да яхшырак итеп төзеп кердең. Алыгыз!

Опелио белән Диегоны алып чыгып киттеләр. Магнатлар үз урыннарына утырды. Кардинал белән король дә урыннарына кайтты. Тәхетханәдә авыр тынлык урнашты.

– Алга таба көн тәртибе нинди? – дип сорады король.

Салазар әйтте:

– Король Һенрих III сараендагы тәхетханәдәге утырышның көн тәртибе, кардинал-инквизитор һәм магнат-сеньорларның теләге: Франциядән бәреп кергән юлбасарлар илебезне, замокларны, калаларны, көтүлекләрне, кешеләрне талый, хатыннарны көчлиләр, кызларны урлап алып китеп, таулар арасына качалар. Бу афәттән котылу чаралары, тәкъдимнәр!

– Нишлибез, сеньорлар? Илебезне талап-корытып торучыларга каршы көрәшәбезме, әллә үзара сугышып ятабызмы? – диде король.

Рыцарь Айяла сүз алды:

– Король җәнаплары, ул башкисәрләрне Франция короле Тиле Карл белән Бонифаций яллап, безнең илгә керткән, дигән хәбәр бар.

Король әйтте:

– Йөз мең алтын флорин бәрабәренә аларны чыннан да Тиле Карл белән Бонифаций җибәргәне ачык, сеньорлар.

Рыцарь Айяла дәвам итте:

– Хөрмәтле сеньорлар, чыннан да, илдә тәртип урнаштырырга вакыттыр. Чит илләрдән кереп талаганнары җитмәгән, бер-беребезне талыйбыз. Каты кул кирәк! Педро IV, Энрико II, Хуан кебек батыр король кирәк. Король җәнаплары Һенриконы мин хуплыйм! Аның фәрманнарын тулысы белән кабул итәм. Иң беренче мин король карамагына ун мең кораллнган атлы сугышчы бирәм. Һәм иң башта әтрәк-әләм башкисәрләргә каршы көрәшкә үзем алынам.

– Рәхмәт, Педро де Айяло, – диде король. – Син, сеньор Айяло бабам король Энрикога да, атам король Хуанга да күп еллар тугры хезмәт иткән батыр рыцарь. Хөрмәтле кардинал-инквизитор, сеньорлар, Педро де Айялоны ватаныбыз алдында күрсәткән батырлыклары өчен, башкалабыз Толедоның баш алькальды, ягъни баш хөкемдары итеп билгелим! Сугыш вакытында яки юлбасарларны эзәрлекләү заманасында Педро де Айялоны баш командор итеп куям. Ул вазифалы чакта аның әмере – минем әмерем кебек, һич карусыз башкарылырга тиеш. Сеньор Айяло, вакыт кыса, юлбасарлар тагын да катырак кыса, шушы эш буенча кыскача фикерегез ничек?

Айяла әйтте:

– Король җәнаплары, һәр сеньорлыктан һич югында бишәр мең генә сугышчы җыелган очракта да тау араларына, тарлавыкларга, качкыннарның оясына, тау куышларына һөҗүм оештырып була. Як-якка шымчылар җибәреп, юлбасарларның кай тирәдә икәнен чамаларга, аңарчы гаскәрне туплап өлгерергә бер атна вакыт кирәк.

– Магнатлар ни ди? – диде король.

Айяла әйтте.

– Монда ризалык сорап торыш артыктыр, җәнабым. Кем күпме сугышчы бирә ала, мәгълүм бит.

– Мин алты мең атлы бирәм, – диде Рамиро.

Гарсиа әйтте:

– Мин өч мең атлы бирәм.

– Бер атнадан тауларга һөҗүм башкарырлык гамәлме? – дип сорады король.

Айяла әйтте:

– Башкарырлык гамәл, королем, – диде.

Салазар әйтте:

– Сеньорлар, кальга хуҗалары арасындагы талаш, кырылышны туктату ысуллары нинди булыр?

– Артык сүз – ертык сүз! – диде король. – Ике күрше сеньор арасында канкоеш булса, гаепле кешене җәзага тартырга. Үлем җәзасына! Ун мең кеше үлгәнче, бер сеньор үлсен! Фәрманым бөтен вилаятьләргә дә иртәгә үк чапкыннар аша җиткерелсен. Тәмам! Өченче көн тәртибе!

Салазар әйтте:

– Өченче көн тәртибе... Кара халык өстенә сеньорлар салган салым, сеньорлар өстенә епископлар тарафыннан салынган салым, епископлардан кардиналлар җыйган салым акчаларын чиркәүгә, Бөек инквизиторга ничек тапшырылуы турында.

– Салымнар үтәп булмас дәрәҗәдә авыр, – диде король. – Халык риза түгел, алар комсыз монахлардан зарлана, инквизиторларның рәхимсезлегеннән иза чигә. Ишетеп торасыз, күреп торасыз: халык баш калкытачак. Кара халык түзем, ул түзеп-түзеп тора да бер кузгала. Кузгалса, аны тыюы шактый озакка сузылачак. Ни кылабыз?

Айяло игълан итте:

– Шушы салымнар, җир салымы, уңыш салымы, чиркәү салымы – барысы да кара халык сыртында. Шулар өстенә монахлар, епископлар «гөнаһларны ярлыкау» дигән кыйммәтле салым уйлап таптылар.

Бардини урыныннан кычкырды:

– Сеньорлар, Felix sulpa! дигән нәрсә бар. Гөнаһның бәһасе, кыйммәте, дигән сүз ул «феликс сульпа». Языкның кирәклеге.

Һенрих көлә башлады:

– Сезгә – инквизиторларга гөнаһлылар бик кирәк, әгәр дә кеше гөнаһ кылмаса, кемнең гөнаһларын ярлыкар идегез, кемнән акча җыяр идегез? Феликс сульпа! Кешеләр һәрдаим гөнаһ кылырга тиеш, алар гөнаһ кылмаса, чиркәү нишләр иде? Кешеләр гөнаһлы булганда гына, инквизиция, католиклык яшәячәк. Кешеләр гөнаһ кылмыйлар икән, аларны гөнаһ кылырга мәҗбүр итәргә яки гөнаһ кылган итеп күрсәтә белергә кирәк. Инквизициянең төп максатларыннан берсе – булмаган гөнаһ өчен җәзалау. Халыкны куркытып тоту өчен кирәк ул суд процесслары. Чиркәүгә, монахларга гөнаһ кылмый торган саф кешеләрнең кирәге юк! Менә бөек парадокс кайдан килә! Бәс, чиркәү салымнарын, гөнаһларны ярлыкау салымнарын кыскартырга яки бөтенләй бетерергә кирәк!

Күбесе:

– Дөрес! Халык җиңел суласын! – дип кычкырды.

Бардини кызганнан-кыза барды:

– Сез ни кыласыз, сеньорлар? Моңарчы халыкны чиркәү, инквизиция тотып килде.

– Тотып килде, ләкин гөнаһ кылучылар азаймады, – диде король.

Бардини кычкырды:

– Бөек инквизитор салымнарны кыскартырга рөхсәт бирмәячәк! Бу гамәл ереська тиң.

Король да кычкырды:

– Моннан соң чиркәүгә дигән салымны беркая да җибәрмәскә! Мин чыгарган фәрман түгел, атам-бабам фәрманы. Король контадорлары турындагы фәрманны архивтан табып алыгыз! Анда король контадорлары, ягъни салым-ясак җыючылардан хисап алу вазифалары гамәлгә кертелгән. Салым җыю каты контрольдә тотылсын! Үтәгез! – диде дә король тәхетенә утырды.

Салазар тәхетханә утырышын япты.

Катнашучылар тарала башлады, тәхетханәдә король, Салазар, Карадәрвиш, Олонсо гына калды.

– Дүртенче көн тәртибен карамадык, король җәнапләре! – диде Салазар.

– Дүртенче көн тәртибен менә хәзер карыйбыз, – диде Һенрих.

– Дүртенче көн тәртибе шул иде. Күршеләрдәге, ерак күршеләрдәге, бөтен дөньядагы сәяси, икътисади мохит. Бөек җыелыш алдында король җәнапларының яңа канцлеры сеньор Пилигрим нотык сөйләячәк.

Король әйтте:

– Җиде йөз илле алтынчы елда Астурия короле Фруэла илчесе Бермудо кайтып, маврлар турында хәбәр итә. Бермудо маврларны куркыныч, җиңелмәс батырлар итеп, аларның гаскәрен иксез-чиксез дип, испаннарның йөрәгенә курку сала. Король Фруэла җиңелә. Бераз хәл алгач, Фруэла илчесе Бермудоның башын чаптыра. Икенче илчесе Овиедо Кордовадан кайтып, маврларны зәгыйфь итеп сурәтли. Фруэла тынычлана, маврлар ул гаскәр җыеп өлгергәнче Фруэланың җирен баса. Король Фруэла тагын җиңелә. Бераз хәл алгач, король Овиедоның да башын чаптыра. Татарлар турында арттырып сөйләсәң, без куркырбыз, каушарбыз, бу безгә зыян булыр. Синең башың чабылыр. Татарлар турында аларның куәтен киметеп сөйләсәң, без тынычланырбыз, алар куәтләнер, бу да безгә зыян. Бу очракта да башың чабылыр. Син, Пилигрим, коры дөреслекне сөйлә. Без шуннан ни кылырга кирәклекне аңларбыз.

Карадәрвиш аягына басты.

– Хөрмәтле король Һенрих җәнаплары! Биредә дүрт мөһим мәсьәлә бар. Аларның һәммәсе дә бик әһәмиятле. Үзара талаш та, юлбасарларның азуы да, салымнарның тәртипкә салынмавы да, фәкыйрьлекне мактаучы бай монахларның әхлаксызлыгы да – барысы да җанны тырный торган, бүген хәл ителәсе мәсьәләләр, ләкин мин әйтәсе көн тәртибе каршысында алар бик кечкенә күренер. Королем, Испания сеньорлары динебез өчен бер-берсенең канын коймый, алар байлык өчен, шәхси үч өчен сугыша. Бу көчне динне яклау тарафына, ватанны саклау тарафына юнәлтергә, кардиналларның, монахларның җинаятьләрен фаш итәргә кирәк. Ләкин иң олы афәт, иң олы кырылыш... Мур кырылышыннан да куркыныч афәт

якынлашканын берсе дә сизенми, аңламый, күрми. Янәшәдә генә мөселман дәүләтләре: Кордова, Гранада, Балеар утраулары. Ярты Пиреней мөселман маврлар кулында... Янәшәдәге христиан дәүләтләре: Византия, Болгария, Юнанстан төрек солтаны Баязид Елдырым кулында. Баязид Елдырымның бер миллион кылыч туплартлык куәте бар. Ул Бурса каласын яулап ала. Яулап ала, ләкин җимерми, халкын таламый. Ул Бурсаны гөл-чәчәккә күмә, ерак таудан Бурсага су китертә, мәчетләр, мәдрәсәләр төзетә, хастаханәләр салдырта. Юксылларга, мохтаҗларга бушка ашау ханәләре төзетә. Шуңа күрә башка калалар да аңа капкаларын ачып торалар. Акшәһәр, Бәйшәһәр, Конья шәһәрләре. Халык аңа күп итеп сугышчы бирә. Шуннан Баязид Византия, Косоволарны яулады. Озакламый ул бөтен Ауропаны басып алачак. Баязид Елдырым – гайрәтле, акыллы солтан. Әгәр аңа комачау итүче булмаса, биш-алты елдан ул Пиреней ярымутравын да, Англияне дә килеп басачак. Чөнки аңа каршы торырлык көч юк. Аның иле чәчәк ата, шул ватанда үскән сугышчы Баязид Елдырым өчен утка да керә, суга да чума. Сугышта җиңелгән дошманнан алган ганимәт маллары төрекләр арасында тигез бүленә. Сугышта һәлак булган яугирнең малы гаиләсенә кайтарыла. Сугышчы ни өчен үлемгә барганын аңлап бара. Баязид Елдырым – безнең иң куркыныч дошманыбыз.

– Баязид Елдырымны җиңәр көч бармы? – диде король.

– Королем, сабыр итсәгез, ул мәсьәләгә дә килеп җитәрбез, иншалла...

– Мин сабыр, мин түзем. Сөйлә!

– Ислам-төрек дәүләте Баязид Елдырым исән булганда, иң бай мәмләкәткә әвереләчәк. Баязид Елдырым белән тигез, шулай ук дәһшәтле татар ханы Туктамыш бар. Ул Алтын Урдага баш. Бай ил, алты йөз меңлек кылыч туплый ала торган бөек Туктамыш ханның иле Идел, Чулман, Ак Урда, Нугай Урда, Кырым Урда, Азәрбайҗан иле, Кавказ илләре, Бөек Болгар дәүләтен, урыс-славян, чирмеш-чуаш-башкорт илләрен үз эченә ала. Коточкыч куәт, бетмәс гайрәт бар Алтын Урдада. Алтын Урда – ислам-татар дәүләте.

– Кая качыйк? Кемнән ярдәм сорыйк? Татар муры килә! – диде король.

– Өченче куәт бар Бөек Тартариядә. Анысы сезгә мәгълүм әмир Аксак Тимер – Тамерлан. Бөек Тамерланның империясе Мәвәрәэннәһер, Хәрәзем, Иран, Күк Урда, далалар, тауларны үз эченә ала. Тамерлан сигез йөз мең кылыч туплый ала. Тамерлан җиңелү белмәс баһадир. Тамерлан иле – ислам-түрк дәүләте.

Король Һенрих әйтте:

– Әгәр бу сүзләрең хак булса, ахырзаман киләдер, – диде.

– Дөрес, ахырзаманга ерак түгел.

Король сорады:

– Татарлары кем дә, түркләре кем? Алар маврмы соң?

– Түрк тә, татар да – барысы да бер нәсел, барысы да мөселман. Маврлар мөселман-гарәпләр. Әгәр дә диннәре уртак, телләре бер халыклар шушы өч мөселман баһадир байрагы янында берләшә калса, аларга Гранада, Кордова, Мавритания, Мисыр мөселманнары килеп кушылса – без мәңгегә юкка чыгачакбыз, королем. Ауропаның йоны күккә очачак. Католиклар да, православныйлар да татарларның ат

тояклары астында туфрак булачак. Һуннар патшасы Атилланы гына искә төшерегез, тәкъсир. Алар бер нәсел.

– Димәк, бу өч баһадирның берләшүенә киртә куярга кирәк.

– Мин ялгышмаганмын! Сез зиһенле рыцарь... Бөтен Ауропаның, Кастилия, Франция, Англия, Германия, Италия, Балкан илләренең, маҗарларның, урысларның бер генә максаты булырга тиеш шушы җиңелмәс өч баһадирны үзара дошманлаштыру, аларны зәгыйфьләндерү, ул арада көч туплап, Ауропаны, динне саклап калу, һәм, ниһаять, коллыктан котылу!

– Кем алына аларның арасын бозарга?

– Кемнәр алына, дип сорагыз...

– Кемнәр алына бу эшкә? Өч кеше җитә, дип уйлыйм мин. Шушы өч җиңелмәс баһадирны җиңәргә нибары өч кеше җитә. Без – фәкыйрегез Туктамыш белән Аксак Тимерне сугыштырдык, Туктамыш татарларының йөз илле мең Кондырча болынында ятып калды. Без – фәкыйрегез Аксак Тимер белән Бөек Болгар падишаһы Габдулла ханны чәкәштердек. Идел ярында болгарларның йөз мең сугышчысы һәлак булды. Алтын Урда зәгыйфьләнде. Ләкин аждаһаның койрыгы гына киселде, белгәнегезчә, экияттә аждаһаларның өзелгән койрыгы урынына яңасы үсеп чыга. Тутамыш хан һәлак булмады, ул яраланды гына, аның куәте җитәрлек. Хәзер ул котчыккыч куәт туплап ята. Аксак Тимер – гайрәтле баһадир, акыллы әмир. Ләкин Аксак Тимердә зиһният юк.

– Акыл белән зиһен икесе бер түгелмени, Пилигрим?

– Юк, королем, акыл башка, зиһен башка. Акыл өстенә зиһенле дә булса, кешене җиңеп булмый. Аксак Тимер акыл иясе, ул акыллы яугир, акыллы гаскәр башлыгы, шахматта аны җиңгәннәр сирәк. Ләкин Аллаһы Тәгалә аны зиһенле итмәгән. Аксак Тимер никадәр генә кырыс булса да, беркатлы бәндә. Ул шикчел булса да, бик тиз ышанучан. Мин аларның дин тотудагы кечкенә генә аермаларын зур гаугага әверелдердем. Аксак Тимер – бик диндар кеше. Коръән ачтырмыйча, ул сәфәр чыкмас. Ләкин Коръәнне өстән-өстән генә белә. Күп вакыт үзе Коръәнгә каршы килә торган гамәлләр кыла. Туктамыш белән Тамерлан һичшиксез тагын сугышачак. Чөнки алар арасыннан кара мәче узып китте инде. Туктамыш җиңелүенең үчен кайтарыр өчен, Аксакка каршы гаскәр туплап ята. Алар сугышканнан соң, кайсы гына җиңсә дә – Туктамыш Аксакнымы, Аксак Туктамышнымы, – җиңгән якны Баязид Елдырым белән сугыштырырга кирәк.

– Монысында нинди хәйлә?

– Хәйлә бар, королем. Аксак Тимер Туктамышны тагын җиңәр, дип уйлыйм. Баязид Елдырымга яу белән йөрер өчен Тамерланга сылтау кирәк. Ул шул сылтауны эзли булса кирәк. Икесе дә мөселман, икесе төрк-татар. Коръән буенча мөселман мөселманга кылыч күтәрергә тиеш түгел. Сәбәп яки сылтау булса, мөселман мөселманның бугазын чәйнәячәк. Төркиядә Кара Йосыф исемле бер юлбасар бар. Ул таулар арасыннан уза торган бай кәрваннарны талый, Тәбризне, Кавказ, Кырымны тетрәтеп тора. Аксак Тимергә әнә шул турыда сөйләргә кирәк. Таланган кәрваннарның хуҗалары ярдәм сорап, Аксак Тимергә килергә тиеш. Аксак Тимер ярдәм сораган һәр илгә ярдәм итәргә атлыгып тора. Дошманы ярдәм сорап килсә дә, Тимер аңа рәхәтләнеп ярдәм итәчәк. Гаскәрен шул илгә кертәчәк. Аның халыклар арасында ярдәмчел

мөселман дәрәҗәсен яулыйсы килә. Чыннан да ул бик күпләргә ярдәм иткән зат. Тимер эзәрлекләгәнне сизенгәч, юлбасар Кара Йосыф Баязид Елдырымга барып сыеначак. Аксак Тимер халыкларны талаучыны яклыйсың дип, Баязидка яу чабачак. Византия, Болгария, Юнанстан Аксак Тимергә илчеләр җибәрсен. Ул илчеләр Аксак Тимердән ярдәм сорасын, имеш, Баязид Елдырым аларны талый, кыерсыта, имеш, алар Аксак Тимер химаясенә кереп, аңа баш орырга тели. Аксак Тимернең көймәләре юк, ул дала кешесе. Тегеләр аңа Баязидка каршы сугышканда, диңгез ягыннан көймәләр белән килеп, ярдәм итәрбез, дип вәгъдә бирсеннәр. Баязид белән Аксак Тимер сугыша башлагач, көймәләрен кирегә борсыннар. Шулай итеп, арыслан белән юлбарыс икесе генә сугышып калыр. Кем җиңсә дә, безгә файда.

– Мин синең чын Бонифаций икәнеңә ышана башладым бит, Пилигрим! – диде король.

– Моны хәзергә калдырып торыйк, юлбасар Педро Бургосны фаш итәргә озак калмады. Татарларны хәлсезләндергәч, иркенләп, каракны фаш итәргә алынырбыз.

– Мин сине нинди дәрәҗәгә күтәрим дә, сиңа нинди бүләк бирим икән?

– Татарларны җиңү, Педро Бургосны фаш итү минем өчен иң зур бүләк булыр, королем.

– Каян табыйм мин үзләрен корбан итәрлек фидаиләрне?

– Аның беренчесе синең яныңда тора.

– Салазармы?

– Әлбәттә.

– Ничек?

– Салазар – минем углым.

– Ничек? – дип сорады Салазар.

– Синең анаң Беатриса белән без яшьли таныш идек. Синең анаңны сөйгән кебек мин бер генә хатынны да сөя алмадым. Ул сине пажлар мәктәбенә тапшырып, үзе вафат булды.

– Атам!

– Улым, Салазарым! – Ата белән бала кочаклашты. – Елашырга вакыт тар. Ватан бездән ярдәм көтә. Озакламый Баязид Елдырым Маҗарстанга яу чыгачак. Бу яуга каршы Изге Рим империясенең короле Сигизмунд җитәкчелегендә Франция, Англия, Ләһестан, Швеция, Германия, Болгария гаскәрләре хач сәфәре әзерли. Бу яуга Бонифаций фатиха биргән. Сез дә, королем, бу яудан читтә калмассыз.

– Мин анда батыр рыцарь Педро Айяло командалыгында гаскәр юллармын.

– Ярамый!

– Ни өчен?

– Айяло – иң кирәкле кешең. Шундый тугры терәгеңне сугышка, үлемгә юллыйлармыни? Ул сиңа монда кирәк. Кардиналлар, комсыз монахлар, гаделсез сеньорлар белән көрәштә Айяло – синең уң кулың. Син күз буяр өчен генә бераз гаскәр бир. Шул гаскәр эчендә синең якын дустың, минем бердәнбер улым Салазар булыр. Баязид Елдырым бу хач гаскәрен җиңәчәк. Ә Салазар аңа әсир төшәчәк, яшь солтан аны үз янына алдырыр. Салазар Исламны кабул итәр.

– Теләсә нинди эшкә риза, ләкин мине динемнән яздырмагыз, – диде Салазар.

– Христос синең юри генә мөселман булганыңны күреп тора.

– Син Ватан өчен, динебезне саклар өчен мөселман булып, Коръән укып, намаз кылып йөрергә тиешсең. Бу саваплы эш, сөекле улым. Бәс, минем дустым Олонсо сине гарәпчә Коръән укырга, төрекчә сөйләшергә өйрәтә башлар. Сине солтан тәрҗемәче буларак бәяләр. Телләр белгән кеше югалмый ул. Татарга тылмач кирәкми. Ә христианнарга тылмач кирәк. Чөнки христианнар үз телләреннән башка телләрне белми. Белергә дә теләми.

– Ризамы? – диде король.

– Риза, королем! Риза, атам. Ярый, мин сугышта катнашырмын, исән калып, әсир төшәрмен, калган вазифам нинди булыр?

– Баязидны Аксак Тимер белән сугышырга котырту. Сиздермичә генә аларның йомшак якларын өйрән. Әйтик, Баязид Юнан җирләренә басып керсә, Юнан короле Аксак Тимердән ярдәм сорый. Аксак Тимер Баязид белән сугышырга мәҗбүр булачак. Ул барып чыкмаса, юлбасар Кара Йосыфны мактап, солтан белән дуслаштырып, Тамерланның ачуын кабарт.

– Икенче зат кем ул? – дип сорады король.

– Анысы мин фәкыйрегез! Руи Гонсалес Клоавихо! – диде Дәрвиш.

– Руи? – диде Һенрих.

– Руи-Бонифаций! – диде Дәрвиш.

– Өченчесе?

– Минем тугры сакчым Олонсо. Ул Кастилия короленнән солых, килешү хаты белән олы бүләкләр алып, мин дәрвиш Исрафил, Олонсо Мостафа кыяфәтендә Аксак Тимергә барып җитәргә тиешбез. Аксак Тимер чит илчеләрне бик яхшы кунак итә. Туктамышны җиңгәч, Тамерлан Баязид өстенә барачак. Баязидны җиңгәч, ул, һичшиксез, Кытайга яу чабачак. Кытайның да, Тамерланның да көче зәгыйфьләнәчәк. Ауропа олы афәттән котылачак, – диде Дәрвиш.

– Католикларны коткаручы дүртенче баһадир кем ул?

– Дүртенче баһадир ул барысына караганда да баһадир. Аксак Тимернең иң сөкле хатыны Гайшә бикә ул баһадир.

– Ничек?

– Гайшәнең Тамерланга үче бар. Ул Гайшәнең атасын, туганнарын яндырып үтерде. Без Гайшәне алып, кире Сәмәркандка кайтып китәрбез, – диде Дәрвиш.

– Әгәр Тамерлан ышанмаса?

– Инанамын ки, Тамерлан ышаначак. Һәм ул аны тагын да ныграк сөячәк. Никах яңарткан бер төндә Гайшә бикә аның шәрабына агу салачак. Шулай итеп, без Кытайны тар-мар килүдән коткарачакбыз, үзебез дә татарлар, мөселманнар, төрекләр золымыннан котылачакбыз.

Һенрих көлә башлады.

– Каян килеп чыктың син, Пилигрим Бонифаций? Син мине үлемнән алып калдың бит, рәхмәт. Менә хәзер шатланырга да була. Биергә дә була. Һәй, шәраб китерегез!

Лакей ливреелары кигән хезмәтчеләр, тантаналы музыка яңгырап торганда, алтын төпсәләргә куелган шәраб кадехләрен алып чыктылар. Кадехләр бер-берсенә бәрелешеп серле музыка кебек зыңгылдады.

Корольнең кәләш сайлавы

Король Һенрих III тәхетханәсе.

Корольнең сарайда ышанычлы өч дусты бар иде. Аның берсе сеньор Айяло, икенчесе – канцлер Салазар, өченчесе – донья Леонора. Атасы маврлар белән сугышта һәлак булган каһарман Карлос Вианның ятимә кызы Леонораны сарай тәрбиясенә алганнар иде.

Толедо сарае. Король Һенрих белән донья Леонора әңгәмәсе:

– Һенри, мин синең өчен бик куркам, җаным. Син коточкыч дәһшәткә каршы куйдың үзеңне. Сак бул! – диде сеньора.

– Леонора, минем өчен кайгырма, – диде король. – Мин барысын да алдан уйладым. Рәхмәт сиңа! Һәрвакыт мине сакладың, мине дәваладың. Синнән якын кешем юк. Син мине аякка бастырдың.

– Һенри! Минем дә синнән башка якын кешем юк. Атам-анам вафатыннан соң, сарайда дөньялар мәктәбенә тапшырылган ятимә. Син пажлар мәктәбендә укыганда, бик еш авырый идең.

– Мин бакчада башка инфантлардан артка калып, озак кына ютәлләдем. Буылып ютәлләвемә игътибар итмичә, пажлар уза торалар. Аларга үпкәләмим, чирләшкә инфантның кемгә кирәге бар. Мине пажлар сафының иң артына бастыралар, аерым савыт, аерым кашык тоталар. Аерым бүлмәдә йоклыйм. Мин гел ялгыз. Син шунда башка сеньориталардан аерылып, яныма килдең.

– Принц, сине ташлап киттеләрмени, Ходаем? Принц, мин сиңа ничек ярдәм итим. Әйдә, пажлар ятакханәсенә алып кайтып куям.

– Син ютәл йоктыру турында да уйламыйча, миңа якын килдең. Кочаклап, аягыма бастырдың... Миннән җирәнмәгән кеше дә булыр икән, дип уйладым.

– Синнән башка яшәвемне күз алдыма да китерә алмыйм. Мин сине өзелеп сөям, Һенри.

– Мин дә сине үлеп яратам, Леонора.

– Ләкин минем күңелем сизенә, эчтән нидер тоям мин, Һенри, без аерылышырбыз, гомергә бергә була алмабыз кебек.

– Мин дә синнән башка тора алмам сыман. Ләкин, чыннан да, без алга таба бергә була алмыйбыз.

– Ни өчен, Һенри?

– Чөнки минем төзәлмәс авыруым бар.

– Мин авыру йогуыннан һич курыкмыйм.

– Юк, җаным, авыру йокмаса да, безгә аерылырга кирәк.

– Күз алмам, Һенри, син ни сөйлисең? Сиңа ни булды? Берәрсе гайбәт җиткердеме?

– Юк, синең турыда гайбәт була алмый. Син изге зат, син миһербанлы җан, син наз иясе. Син минем бәгырем түрендә урын алган илаһи зат.

– Җаным, рухымның иясе... Безгә ни комачаулый соң?

– Минем гомерем санаулы гына.

– Ташла бу сүзләреңне, Һенри! Үпкә авыруы белән җитмешкә җиткәннәр бар.

– Мин башка, җаным. Мин үлемгә дучар.

– Авызыңнан җил алсын, король!

– Мин сиңа өйләнә алмыйм, Леонора!

– Чөнки син король, мин сарайда тәрбия алган бер ятимә кыз. Кардинал, канцлерлар, сеньорлар җыены никахка фатиха бирмәячәк, шулаймы?

– Анысы да бар. Ләкин аларны җиңә алыр идем...

– Шулай булгач, ни комачаулый? Әгәр алар никахны хупламаса, без никахсыз гына очрашырбыз.

– Сарайның диварлары колаклы, түшәмнәре күзле... Леонора, минем дөньяга авыру туган баланың атасы буласым килми. Мин өйләнмәячәкмен.

– Йа Иисусе Христосе! Өйләнмә! Тик мине генә яныңнан кума!

– Леонора! Мин авыру, ләкин Алла тарафыннан бирелгән кыска гомеремне корольлекләрне берләштереп, Бөек Испания дәүләте кормак булам. Бу изге максатым. Иң беренче безне урап алган Кордова, Гранада илләрен маврлардан арындыру кирәк. Мин Бөек Инквизиторның комсызлыгына чик куярга тиешмен. Булачак Кастилияне татар-төрек варварларыннан коткарып калырга. Минем шәхси тормышым юк, була да алмый. Өйләнеп, бала-чага үрчетеп, көнкүреш мәшәкатьләренә батсам, шушы дүрт бөек максатымнан читләшермен, дип куркам. Мин мотлак азат булырга тиеш! Әйе, дошманнарым аз түгел. Бабам Энрико, атам Хуан шул юлда һәлак булган. Гаиләмне, хатынымны, балаларымны шушы фетнәләргә кушып, җанымны, канымны тинтерәтмәсеннәр өчен мин өйләнмәячәкмен. Бу юлдан мине хәтта олы мәхәббәтем дә тайчандыра алмас.

– Аңладым, Һенрико. Син мәхәббәтеңне корбан итәсең.

– Мин олы мәхәббәтемне ике тапкыр корбан итәм.

– Ничек, ни өчен ике тапкыр?

– Гранаданың хәлифе Мөхәммәд куәтле ир. Аның илендә байлык, корал, гаскәр. Ул Кастилиянең борын төбендәге иң хәтәр куркыныч. Маврлар, мөселманнар халкыбызны җиде йөз ел буе коллыкта тота, бу коллык богауларын ватып ташларга вакыт җитеп килә, Леонора. Әгәр дә без Гранаданы хәлсезләндерсәк, Кордованы тиз алырбыз.

– Син сәясәткә алып кереп киттең мине.

– Гранада хәлифе Мөхәммәдне син, солых төзегәндә, сараебызда күрдең. Ул да сине күреп алган.

– Шуннан ни?

– Ул миннән сине сорый.

– Ничек сорый?

– Ул сине хатынлыкка алмак була.

– Син ни сөйлисең, Һенри, мине маврга сатып җибәрмәкче буласыңмы? Оятсыз!

– Тынычлан, Леонора. Тыңлап бак. Мөхәммәд хәлиф сиңа үлеп гашыйк булган. Әгәр дә аңа кияүгә чыксаң...

– Аңладым, король, син мине сатасың, мәхәббәтеңне кыргый мөселманга, маврга сатасың.

– Мин Испаниянең киләчәге өчен, католиклык куәтләнсен өчен синнән – сөеклемнән ваз кичәм. Олы мәхәббәтемне корбан итәм. Әгәр мине сөйсәң, син дә үзеңне корбан ит. Мине, ватаныбызны, динебезне ихластан сөйгәнеңне исбат ит. Син хәлиф Мөхәммәдкә кияүгә чык!

– Котчыккыч сафсата!

– Фидаилек, бөек максат өчен бөек корбан!

– Аңладым, король! Менә хәзер ни теләсәң, шуны боер.

– Кичер, җаным. Гаепләмә! Каргама да! Син Мөхәммәд хәлифкә чыгып...

– Хәлиф христианга өйләнә алмый, король!

– Син Ислам динен кабул итәрсең!

– Изге Мария! Иисусе Христосе! Денемнән язарга кушасың? Католик динен сафландырырга алынган король Христостан ваз кичеп, Исламны кабул итәргә боерамы? Мин үземә үзем кул салачакмын!

– Алайса, син Мөхәммәд хәлифнең харамына төшәсең! Ләкин синең максатың: мәхәббәттән тилергән маврның башын әйләндерү, аны дәүләт эшләреннән биздерү, кирәге чыкса, ашына агу салу.

– Мин барысын да риза, король!

– Ләкин син хәлифкә назлы булырга тиеш. Аны гүзәллегең, акылың белән хәйран-вәйран калдырырга.

– Мин риза, король!

– Сине Мөхәммәд хәлиф илчелеге көтә, Леонора.

Тәхетханәгә Олонсо белән Гайшә килеп керде.

– Король җәнаплары, – диде Олонсо керә-керешли. – Гайшә бикә хозурыгызга килде.

– Хуш килдең, Габдулла хан кызы Гайшә бикә! – диде король Һенрих.

– Сәламәтлек телим сезгә, король! – диде Гайшәбикә.

Тәрҗемәче Олонсо аша Һенрих әйтте:

– Рәхмәт! Сәламәтлек миңа бик кирәк. Гайшә бикә, ватаныңны Тамерланны искә аласыңмы?

– Ватанымны бик сагынам, Болгарым төшләремә керә. Чыдап булмас җирсү били җанымны, хөрмәтле король, әмма Аксак Тимерне мин юксынмыйм. Тик үч алу хыялы яши.

– Алайса, минем бер гозерем бар.

– Җәнаби король, сезнең хозурыгыздамын.

– Сине миңа ерак илләр аша атаклы түрә шаһ Тимер һәдия итеп юллаган икән. Мин һәдия буларак кабул иттем.

– Мин сезнең идарәгездә, король.

– Сине кая куярга, дип баш ватам.

– Ихтыярың, король, мин синең колың, хезмәтчең, хатының була алам. Мин бит җиңелгән ханның бичара кызы. Сез – җәнабе король – хәл итегез.

– Син мөселманлыкны ташлап, христианлыкка күчәргә ризамы?

– Минем ихтыярга куелса, денемнән ваз кичмәс идем, әлхәмдүлиллаһ, мөэмин мөселманмын.

– Әгәр дә син миңа кияүгә никахлашып чыгарга ризалык бирсәң, сине, һичшиксез, чукындырырга кирәк.

– Әстәгъфирулла.

– Юкса, чиркәү еретик белән мине кушмаячак.

– Мин харам җарияңез генә булып калырмын.

– Ихтыярың! Ләкин харам җариясе булудан да син азат.

– Ничек? Мин ирeклeме?

– Әлбәттә.

Гайшә бикә король алдына тезләнде:

– Чиксез рәхмәтләрем сезгә, король җәнаплары. Димәк, мин илемә кайтып китә алам?

– Әлбәттә, ләкин бер шартым бар.

– Нинди шарт ул, король?

– Син минем илчем белән Сәмәркандка шаһ Тимер янына кайтып, аның яхшы мөнәсәбәтен яулыйсың. Аның белән яуга бергә йөрисең: мин синнән аерым тора алмыйм, синнән калмыйм дип, ант итәсең һәм җае чыкканнан соң ашына, шәрабына менә шушы агуны саласың. Шулай итеп, син янып һәлак булган атаң, анаң, башка туганнарың, Бөек Болгарның үчен алачаксың.

– Мин ике куллап риза.

– Олонсо! Калганын син аңлатып бирерсең!

Олонсо белән Гайшә бикә чыгып китте.

Алардан соң тәхетханәгә Карадәрвиш килеп керде.

– Арагонда эшең уңдымы, Пилигрим?

– Арагон короле Мартин мине бик яхшы кабул итте. Синең тәкъдимеңне ул биш куллап каршы алды. Король Мартин ике илне берләштерергә риза.

– Кит аннан! Чынлапмы?

– Иисус Христос шаһит! Король Мартин Арагонны тулысы белән Кастилиягә кушарга риза.

Һенрих Карадәрвишне кочаклап әйләндерә башлады.

– Йөз яшә, Пилигрим!

– Ләкин аның шарты бар, сир.

– Нинди шарт? Үтәлерлекме, үтәлмәслекме?

– Король Мартин Арагон патшалыгы белән Кастилия патшалыгын бергә кушарга ризалык бирәчәк, әгәр дә Кастилия короле Һенрих Өченче аның кызы Изидага никахлап өйләнсә!

Һенрих артына утырды.

– Иисусе Христосе! Ава Мария! Нинди коточкыч шарт!

– Шулай, королем, шарты бик җиңел түгел...

– Син аның кызын күрдеңме соң?

– Күрдем. Сөйләшеп тә утырдык, – диде Карадәрвиш.

– Ул бит дөнья ямьсезе! Убырлы карчык бит, канцлерым, – диде король, ачынып.

– Арттырмагыз, король, ул кадәр ямьсез түгел Изида. Матур түгел, әмма убырлы карчык та түгел бит инде. Аңа егерме биш кенә яшь. Изидага өйләнүең – ул синең батырлыгың, Испаниянең киләчәге өчен бәһаләп бетергесез батырлык. Эшлә син ул батырлыкны! Арагон белән Кастилия кушылып, Испания хасил итү хөрмәтенә Изидага гына түгел, аждаһаның үзенә өйләнергә дә була! Ә принцесса Изида гүзәл булмаса да, бик акыллы, королем!

– Ярый! Күндердең! Хәл иттек! Арагон короле Мартинга кызы Изиданы Кастилия короле Һенрих III гә кияүгә сорап илче-яучылар җибәрегез!

Бирнәгә алтын таулары вәгъдә ителгән булса да, бер генә король дә, бер генә сеньор да, бер генә кабальеро да, хәтта тол калган ирләр дә король Мартинның кызы Изиданы ярәшмәде. Кастилиянең яшь короле утырып калган карт кыз Изидага өйләнүе христиан дөньясын шаккатырды.

Баязид Елдырымның Аксак Тимергә әсир төшүе

Госманлы мәмләкәтендә булды бу хәл.

Анкара янында әмир Тимер ыстаны корылган. Сугыш яңа гына Аксак Тимер файдасына тәмамланган. Аксак Тимер күчмә тәхетендә утыра. Янында берничә хаттат тезләренә рәмел тактасы куеп, канат-каләм белән язалар. Муеннарына кара савыты асылган. Хаттатларның арка ягыннан, алар язганны карап, хаталарын төзәтеп, Ибраһим-бахшы йөри.

Әмир Тимер Һиндстан сәфәреннән алып кайткан ганимәткә корган Җәмигъ мәсҗеденең гүзәллеген сүз белән сөйләп, каләм белән язып бетергесез. Мәсҗеднең арка капкасы белән гөмбәзен күк гөмбәзе һәм Киек Каз юлы белән генә чагыштырып булыр иде.

Әмир Тимер әйтте:

– Яу артыннан яуга мин үзем өчен йөрмим. Бөтен кешелекнең сәгадәте өчен кешеләрнең канын коям. Бу гүзәл мәсҗеднең нурында бер мин генә коенмыймын, барысы да коена, бу мәһабәт Аллаһ йортында мин ялгызым гына намаз укымыйм, һәр теләгән кеше керә ала. Һиндстанга, монафикълар, фетнәчеләр иленә, таш сыннарга табынучылар ыстанына барып, алар кулыннан алган байлыкны мин үземә тотмадым. Әйтте миңа сәед углы сәед Исрафил хәзрәтләре, Һиндстанны алсаң, андагы алтын таулары сине җиде икълимнең дүртесенә падишаһ итәчәк, дип. Яу алдыннан Коръән ачтырдым.

Мин Аллаһ юлында Җиһад иттем, Эрзерум янында гаскәремне туктаттым, гаскәрем бөтен тау итәген, даланы кара күч кебек сарган иде. Шәһәр шул кара күч уртасындагы утрау кебек кенә булып калганын күрдем. Тау түбәсеннән гаскәремә бактым. Һәм уйладым: менә мин берүзем, япа-ялгызым, әллә нинди куәтле көчем дә юк кебек, ләкин шушы чиксез гаскәрнең һәр яугире, аерым алганда, бөтен гаскәр, һичшиксез миңа буйсына. Бер-бер әмер бирә калсам, ул әмерем төп-төгәл җиренә җиткереп башкарылачак. Шул турыда уйлап, безне барлыкка китерүче Аллаһка чиксез рәхмәтләр укыдым. Ул мине шушы колларга башлык итеп куйды. Бу турыда голәмәдән сорадым. Ни өчен шушы хисапсыз халык миңа буйсына, дидем. Алар әйтте: сиңа Аллаһның нуры төшкән, Аллаһ сине олы иткән, шуңа күрә, син Аллаһтан алган көч белән куәтле. Әгәр дә кылмышларында хаким гадел булса, буйсынарлары аңа һич икеләнмичә хезмәт итәчәк, дошманнары аннан кан калтырап торачак, диделәр. Идел-Урал, Тәбриз-Кавказ, Мисыр-Фарсы, Төрек-Көрт җирләрен – җиде икълимнең дүртесен – Һиндстанны яулап алдым. – Әмир Тимер дәһшәтле рәвештә көләргә тотынды. – Алышмагыз минем белән, дидем. Карышмагыз миңа, дидем. Юк бит! Алышалар, карышалар! Җиңәрләренә ышаналар! Аксак Тимерне, Чулак Тимерне җиңәр көч бармы бу дөньяда? Булса, әйтегез! Һич сүзем юк! Җиңсеннәр

мине! Җиңелгән кешегә шул кирәк! Җиңелсәң, ыңгырашма! Җиңгәнсең икән, җиңүең белән ләззәтлән! Аллаһ сиңа җиңү китерде!

Дәһли каласын алганда, кулда йөз мең әсир иде. Мин аларны Сәмәркандка алып кайтырмын дип уйлаган идем. Ләкин Дәһли каласына һөҗүм иткәндә, бу йөз мең әсир арттан төшеп, миңа комачау ясар иде. Шуңа күрә, Аллаһ кушуы буенча бер мизгел эчендә аларның башларын чаптырдым. Шулай итеп, арка ягым шөбһәсез калды. Шуннан Дәһлине байлыгы-ние белән кулга төшердем. Һиндстанның алтыны, көмеше, алмазлары, мәрҗәннәре, башка асылташлары казнама күчте.

Җиңелмәс солтан, Рум вилаятенең падишасы, Сивас, Урта диңгезнең боерыкчысы Баязид солтанны да мин аркасына салдым. Әгәр тәкъва мөселман булмасам, пәйгамбәребез Мостафа салаллаһу галәйһи вәссәлам үрнәгендә яшәмәсәм, миңа бу җиңүләр килер идеме? Юк! Һич килмәс иде. Димәк, әмир Тимер хак юлда!

Бүгенгә җитеп торыр!

Ул чыгып китте. Ханәгә Ибраһим бахшы хуҗа булып калды.

Ибраһим бахшы башка хаттатлар язганнарны укып, кайбер хаталар янына тамгалар куйды. Барлас углы Таргатайның углы Шаһ Тимер хәзрәтләре 1336 елда Киш каласында дөньяга килде. 1370 елда ул Мәвәрәәннәһернең хакиме булды. Башта ул Чыңгыз нәселле Тулык Тимернең углы Ильяс Хуҗаны үтерде, аннан соң әмир Хөсәенне кылычтан узгарды, Балх каласына хуҗа булды. Малик Гыясетдинне әсир алып, Хорасанны кулына төшерде, аннан соң Сизуар, Нишпур илләрен үз дәүләтенә кушты. Сарбедарларның түрәсе Хуҗалы Мохидне үзенә буйсындырды, 1383 елда Кандагарны тар-мар итте, аннан соң Мазендаранны, 1384 елда Җалаир солтанны куып, Азәрбайҗанга бәреп керде, Тәбризне, Карс, Тифлис калаларын буйсындырды, Мозафарныкылар кулыннан Ширазны тартып алды, шуннан соң ул Дәшти Кыпчак ягына китеп, Туктамышны җиңеп, Себер якларын иңләп алды, 1399 елда Һиндстанны аркылыга-буйга таптап чыкты, Дәһлине, 1400 елда Суайс, Халеб, Шам-Сүрия, Баһдадны тар-мар китерде. Аннан соң җиңелмәс төрек солтаны Елдырым Баязиднең ярты гаскәрен кырып, ике йөз мең кешесе белән солтанны әсир итте. Шаһ Тимер утыз алты ел җиңелмәс падишаһ булды. Ул Дәһли каласы янында йөз мең әсир индусны кылычтан узгарды. Үз ватаннарын саклап сугышкан, Тимергә буйсынырга теләмәгән, әсир төшкән ун меңнәрчә батырларны шәһәр диварларыннан аска аттырды. Үлми калганнарын әмир Тимер әрдәнә итеп өйдереп, ут төрттерә иде. Җитмеш мең мөселман башын кисеп алып, казаннарда пешекләп, ап-ак баш сөякләреннән тау өйдерде... Ибраһим саташа башлады, кебек. Әмир Тимер кая гына барса да, артыннан елга-елга кан агызды, илче итеп җибәрелгән хатыннарны, сабыйларны меңләгән ат белән таптатып, изеп бетерде...

Ул алга таба укый алмый иде инде, язмаларны хаттатларга тапшырып, үзалдына сөйләнә-сөйләнә чыгып китте.

Анкара янындагы кырылыштан соң, әмир Тимер бәйрәм итте, истирахәт кылды, тагын бер җиңүенә нокта куюы иде.

Аның яу тәхетханәсенә әсир төшкән Баязид Елдырым белән берничә әсирне зафәр иясе әмир Тимер янына китерделәр: Баязид солтан яу киемнәреннән, ләкин ул киемнәр теткәләнеп беткән иде.

Әмир Тимернең кәефе күтәренке иде, әсир солтанны күргәч елмаеп куйды:

– Хуш килдең, бөек солтан Баязид Елдырым хәзрәтләре! – диде тәхет хуҗасы.

Баязид солтан әйтте:

– Мөшкел хәлгә төшкән солтаннан мыскыллы көлү ир эше түгел.

– Кичер мине, солтан! – диде әмир. – Мин сине мыскылламыйм! Мин синнән алда җиңелгән ханнарны, әмирләрне, түрәләрне, падишаһларны, шаһиншаһларны, раджаларның язмышын күз алдына китереп елмайдым. Алар да әтәчләнде, Аксак Тимерне җиңәрбез, дип хыялландылар. Беркатлы да булсалар булырлар икән! Умырткалары сынгач кына, алар минем хаклы икәнем, минем гаделлек сакчысы икәнемне аңладылар. Сиңа әйттем ләса, хат юлладым. Күкләрнең вә җирләрнең хуҗасы Аллага шөкер, миңа ул җиде икълимнең күбесен һәдия итте. Җиде икълимнең күбесе алдымда баш орды, алар буйсынарлык камыты киде. Чөнки мин Аллаһ куйган чикләрдән хәттин ашмадым. Синең турыда да бөтен җиһан белә, нәселеңнең дә, затлы каннан икәнеңне дә беләбез. Син шундый белемле, итагатьле кеше тәртәгә тибәргә тиеш түгел идең. Илеңне, муллыгыңны саклыйсың килсә, Мәккә юлларын талап торучы хәрами Кара Йосыфны тотып миңа бир, дидем. Таланган кәрван ияләре, таланган калаларның башлыклары миңа илче күндерделәр: алар канэчкеч башкисәр Кара Йосыфтан коткаруымны үтенделәр. Мин халыкның үтенеченә каршы бара аламмыни? Юксыллар, ярдәмгә мохтаҗларга ярдәм итмәсәм, минем йокым кача. Син Кара Йосыфны тотмадың. Син аны якладыңмы? Халыкларның ялваруына бакмадың. Бәс, икебезнең гаскәр орышачак, дидем. Һәм синең кара тәкъдиреңә юл ачылачак, дидем. Тыңламадың акыллы кеше сүзен. Бу бичара хәлгә төшүеңә син бары тик үзең генә гаепле. Бу – үз кулларың белән утырткан энәле агачларның җимешләре. Мин синнән бик аз гына сорадым. Шул сүзләремә колак салмыйча, теләгемә каршы булган гамәл кылдырдың, мин сине җиңдем. Синең кире холкың үз башыңа булды. Кызганыч, шулай килеп чыкты!

Баязид солтан:

– Харап иттең син Ислам дөньясын, әмир Тимер, – диде.

– Ни сөйлисең син? – диде әмир Тимер.– Мин Ислам өчен җанымны, канымны кызганмыйча гамәл кылам. Килешми бөек солтанга нахак яла ягу, килешми. Мин сине кол шәкелендә тотмам. Абруйлы кунак буларак, хозурымда булырсың. Яуларымда катнашырсың, әгәр теләсәң, кылыч ал, атка мен, без Кытайны яуларбыз, аннан Ауропага, Юнан, Франк якларына сәфәр чыгарбыз да, диңгез кырыендагы илләргә хуҗа булырбыз.

– Мин кылыч кешесе түгел инде, Тимер, – диде солтан. – Мин кол, әсир. Нинди генә хөрмәт күрсәтсәң дә, нинди генә затлы кием кидерсәң дә, мин солтан түгел. Син мине аңламассың, чөнки син солтаннар нәселеннән түгел!

– Әйе, мин синең кебек затлы кан түгел, мангыттан азган чала татар, укымаган, язмаган, бары тик кылыч айкаган бәндә.

– Шулай! Шуңа күрә, син дөньяның кая барганын белмисең, аңламыйсың, аңларга да теләмисең. Син Исламны эчтән җимерергә алынган Иблис! Син Ислам исеменнән, Коръән исеменнән, Пәйгамбәр исеменнән Исламга,

Коръәнгә, пәйгамбәргә каршы гамәл кылучы монафикъ. Синең шушы наданлыгыңнан чит патшалыкларның илчеләре, җасуслары, шымчылары бик нык файдалана. Алар өч бөек шәхесне талаштырырга, сугыштырырга, бер-берсен тар-мар итәргә сине котыртты. Син Туктамышны бетердең, Баязид Елдырымны пыран-заран китердең. Ә христиан илләре, Аурупа шушы гамәлләреңне күзәтеп, «Тамерланга рәхмәт» дип кул чабып, алкышлап тора. Ауропадан, йолкыш кына илдән, йолкыш кына бер илче килсә, син аны пәйгамбәр күргәндәй, күтәреп аласың, мөселман илчеләрен түбән табынга утыртасың. Франк, Испания, Византия илләрендә мәшһүр буласың килә. Алар синең белән уйный, алар синнән көлә. Синдә акыл бар, син куәтле җитәкче, ләкин зиһеният юк, чөнки надан!

Тимер кычкырып көлде:

– Син мине чыгырымнан чыгармакчы буласың? Юк, мин җиңелүченең үте сытылганнан әйткән сүзләренә дикъкать итмим. Минем җиңүем алардан өстенрәк. Кытайны алганнан соң күрерсең, Византиягә, Римга, Англиясенә чаклы атымның тоякларын бастырачакмын.

– Мин аңынчы тормам, Тимер...

Баязидның хәле китте.

– Ярдәм итегез! – дип кычкырды әмир Тимер. – Алып чыгыгыз!

Баязидны алып чыгып киттеләр. Алар чыгып китүгә чапкын керде.

– Шаһ Тимер хәзрәтләре, Кастилия короленнән илчеләр кайтты! – диде чапкын.

Тимер айнып китте.

– Ә? Илчеләр! Араларында сәед Исрафил бармы? – дип сорады әмир.

– Сәет Исрафил бар, тәкъсирем!

Илчеләр Карадәрвиш Исрафил, Мостафа-Олонсо, Гайшә бикә керде.

Әмир кочагын җәйде:

– Хак! Мин саташам! Күземә күренәме якын кешеләрем? – Үзе шатлана, үзе елый. – Сәед Исрафил хәзрәтләре! Күрешер көннәрем дә булыр икән.

– Тәкъсир, мин синнән башка яши алмыйм икән, – диде Исрафил.

– Бу синең сөеклең – Болгар ханы Габдулланың кызы Гайшә бикә.

Әмир Тимер:

– Йа Аллам, син һаман миңа юл күрсәтәсең, Гайшәм бикәм, – диде.

Гайшә бикә әйтте:

– Әмирем! Мин дә синнән башка тора алмыйм икән? Нигә миңа Кастилия, Испания, нигә миңа корольләр, син булганда, алар чүп кенә.

– Җаным, Гайшәм, күпме хатын-кызлар күрдем, сине оныта алмый йөдәдем. Күпме кан койдым, сине оныта алмадым, күпме җан кыйдым, сине оныта алмадым.

– Кастилия короле чирләшкә, өйләнә алмый, синең бүләгеңне кабул итә алмый ул. Аңа чыгар өчен мин христиан динен кабул итәргә тиеш идем, Аллам сакласын, диненнән язган – дененнән язган.

– Күгелташ! – дип кычкырды әмир, ишектә Күгелташ күренде. – Бу бәйрәм ләса, оештырыгыз табын.

– Баш өсте! – дип, Күгелташ чыгып китте.

– Гайшәм бикәм кайткан! Мин Гайшәм бикәм хөрмәтенә Кытай илен басачакмын!

Бераздан әмирне, кунакларны дәстәрханга чакырдылар.

Күгелташ кереп, тантана аша әйтте:

– Рәхим итегез, буза, кымыз, шәраб, ачы бал, чишмә суы.

– Гайшәм бикә ни эчә? – диде әмир.

Гайшә бикә:

– Чишмә суы, – диде.

– Миңа шәраб салыгыз! – диде әмир Тимер.

Сарай әһелләре төпсәләргә куеп, касәләр ташый башлады.

Бәйрәм кызганнан-кыза бара иде.

Гайшә сиздермичә генә Тимер касәсенә агу салды. Тимер йотлыгып эчеп куйды.

Бәйрәм башлана. Буталыш, шау-шу, мылтык ату, карнай кычкырту.

Әмир Тимер исерә төште. Бәйрәм дәвам итте, Гайшә бикә һәм башкалар чыгып китте. Янычар кыяфәтендәге Салазар керде.

– Тәкъсирем! – диде Салазар.

– Янычар! – диде әмир. – Син төгәл башкардың вазифаңны, Янычар. Сивас халкы исеменнән хат язып, илчеләр әзерләп җибәрү дә, Кара Йосыфтан зарланып, башка илләр исеменнән хатлар язуың да Баязидка муенчак кигезергә ярдәм итте. Ал!.. Күгелташ!

– Әмерең, әмирем! – диде Күгелташ.

– Бу адәмгә һәдияң әзерме?

– Әзер, тәкъсир! – дип, Күгелташ кечкенә сандык алып килде.

– Һиндстан мәрҗәне, Дәһли алмазлары сиңа!

– Тәшәккүр, пирем! – диде Янычар-Салазар.

– Син үзең кайсы яклардан, Янычар? – дип кызыксынды әмир.

– Мин Кастилиядә туган, Баязид Елдырымның Изге Рим империясе гаскәрләре белән булган орышында әсир булдым. Менә, Баязидка хезмәт итәм.

– Һәм миңа да! – дип өстәде әмир.

– Сезгә дә, сир, – диде Янычар. – Хәзер инде мин сезгә генә хезмәт итәрмен. Уң кулыгыз булып, Кытайга барасым килә.

– Машалла! Барырбыз! Күгелташ! Янычарны казна хисабына куй!

– Баш өсте! – Күгелташ тиз генә чыгып китте дә ашыгып, кире керде. – Тәкъсир! Бөек солтан Баязид Елдырым фани дөньядан бакыйга күчте, – диде.

– Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун. Әсирлек хурлыгын кичерә алмады, – диде әмир.

Янычар кыяфәтендәге Салазар тантаналы рәвештә әйтте:

– Аның үлүе яхшырак, тәкъсир. Ул мәгърур кеше иде. Иреккә җибәрсәң дә, яшәмәгән булыр иде. Баязидның билен сындырып, син Ауропага хисаплап бетергесез игелек кылдың. Иисус Христос синең бу яхшылыгыңны онытмас! Ул сине җәннәткә кертәчәк, сир. Син аның Җирдәге хәлифе, аның кушканнарын үтәүче. Рәхмәт сиңа. Ауропа илләре синең бу батырлыгыңны онытмас. Кастилия, Португалия, Франция, Византия сине изге Георгий ордены белән бүләкли. Хачлы орден алып, Тимер янына килә. Аның күкрәгенә хачны кадый.

– Мин төш күрәм. Алда да мин шундый бер төш күргән идем, имеш,

пәйгамбәребез Мостафа салаллаһу галәйһи вәссәлам, минем күкрәгемә тәре-хач кадаклап куйды. Кычкырып уянып киттем. Мине уятыгыз, мин саташа-ам!

Кунаклар, яраннар йөгерешә.

Күгелташ:

– Тәкъсир! Ни булды? – дип кычкырды.

Салазар әйтте:

– Берни дә булмады, Күгелташ.

Гайшә бикә әйтте:

– Әмирем, күкрәгеңдә ни ул? Бу бит Кастилия короленең аеруча батырлыклар кылганнарга бирелә торган ордены.

– Әйе, кара алтыннан эшләнгән бу нәмәстәкәйне миңа төшемдә пәйгамбәребез Мостафа саллаһу галәйһи вәссәллам үз кулы белән такты.

– Әстәгъфирулла!

Тимерне барысы да җиңү белән, Гайшәнең кайтуы белән, Кытайга һөҗүме белән җиңүләр теләп котлый башладылар. Ләкин әмир Тимер авырая бара иде.

– Әмирем! – диде Күгелташ. – Ятып торыйк, Кытайга яуга чыгар алдыннан сиңа ял кирәк. Алда Кытай диварлары тора.

Тимер үзенә хас сабырлыгын югалтып кычкырды:

– Аксак Тимер каршысында алынмаган дивар юк!

Күгелташ Тимерне алып чыгып китте.

Карадәрвиш Гайшәгә әйтте.

– Булдымы? – диде.

– Булды! – диде Гайшә бикә.

– Алайса, озакламас!

Кинәт акырган аваз ишетелде. Аксак Тимер кулына кылыч тотып атылып чыкты.

– Кытайга-а! Җиде икълимнең бишенчесен яуларга-аа! Ачыгыз Коръән, анда минем бу яңа сәфәрем турында ни язылган икән? Ач, Исрафил хәзрәт!

Карадәрвиш кабаланып, Коръән ачты.

– Фетнә тулысы белән юк ителгәнгә чаклы, бары тик Аллаһ дине калганчыга кадәр сугышыгыз!

– Сугышыгыз, диме? Баязид әйтте: «Ля кум дине кум вә лияддин!» Сезнең динегез үзегезгә, безнең дин үзебезгә! – Гайрәт белән кизәнеп, ул кылычын келәмгә кадады да, үкереп елый башлады. – Димәк, мин гомерем буе хаксызга кан койган булып чыгаммы? Сәед Исрафил хәзрәт, сәедләр мине хата юлга өндәгәнмени? Нигә миңа моны элек аңлатмадыгыз? Сәед Исрафил син дә мине алдадыңмы, суям! Үтерәм! Баязид Елдырымның рухы пәйда булды. Баязид?

Баязидның рухы әйтте:

– Туктат син кан коюларыңны, шаһ Тимер, – диде.

– Син дә кан коясың бит, Баязид, – диде Тимер.

– Мин Ислам дәүләтләрен киңәйтү өчен сугышам.

– Мин дә Исламны көчәйтү өчен кан коям.

– Син Иблис юлында, Тимер. Йөрмә Кытайга. Шушында туктап кал.

– Кытай мәҗүсиләр, потпәрәстләр иле, Баязид солтан!

– Ля кум дине кум вәлиәддин. Һәркемнең дине үзенә. Сугымчы кәсапчылар да йөзәрләгән малның җанын кыйганнан соң туктап кала, сөннәтче бабалар да йөзләгән баланы сөннәткә утырткач, гамәлен туктата. Чөнки кан тотачак. Алар гаделлек кысаларында кан койса да, вакыты җиткәч, туктап кала. Син адым саен мөселман канын коясың. Аларның каны сине бер тотар бит, Тимер. Туктат кан коюыңны!

– Мин Коръән кушканча гамәл кылам, Баязид солтан!

– Синең нәселең асылда мангыт, син мангыттан азган чала татар. Синең ата-бабаң мәҗүсилек, ярымбуддачылыктан Исламга күчкән. Сез бары тик Үзбәк хан заманасында гына намаз укый башлаган чыгытайлар. Ислам сезнең телегезгә менгән, рухыгызга сеңмәгән. Сез намазны фәкать үзегез өчен генә укыйсыз, ә чын мөселман башкалар файдасы өчен Аллага гыйбадәт кыла. Вәхши бары тик үзе өчен генә ураза тота, намаз укый. Аның тупас-каткан бәгыре үз карыны турында гына кайгырта. Зиһенле адәм башкаларның иминлеге турында уйлый. Коръәнчә гамәл кылмыйсың син, Шаһ Тимер. Син хыянәт иткән яшь хатыныңның башын чабып өздең. Ул мөселман иде. Коръәндә тугры булмаган хатынны үтерергә димәгән, тиешле җәзасын гына бирергә дигән, ихлас тәүбә итсә, гафу итәргә, аңа кагылмаска кушкан. Коръәнчә булса, син мөселманның канын агызмас идең. Син Аллаһы Тәгалә вазифаларына үреләсең! Моннан да олы гөнаһның булуы мөмкинме? Син кяферләр белән бер басмада торасың. Мөселман булсаң, сиңа Аллаһы Әфгандагы Исфизар каласының ике мең мөселманын тереләй җиргә күмәргә рөхсәт иттемени? Исфагандагы җитмеш мең кешенең баш сөягеннән тау өяргә сиңа пәйгамбәрең куштымы? Минем карамактагы Сивас каласын алганнан соң тыныч тормышлы дүрт мең мөселманны тереләй күмәргә сиңа Коръән куштымыни? Йөз мең индусның башларын чаптыру да синең саваплы эшләреңә язылырмы? Бөек Болгарны җир белән тигезләвең өчен дә син Аллаһтан әҗер көтәсеңме? Сәбәпсезгә үтерелгән хайван өчен дә Аллаһу Тәгалә җавапка тартырмын дигән, сәбәпсезгә үтерелгән бихисап кешенең каны, җаны өчен дә җәннәт өмет итәсеңме? Син кяфер, синең урының җәһәннәмдә! Ул сиңа хас! Син гомерең буе акыл белән эш йөрттең, гомерең буе ике маңгай күзең белән генә дөньяга бактың. Акылың бар, зиһенең юк, шуңа күрә, синең күңел күзең сукыр. Күңел күзең сукыр килеш Коръән укыйсың, аның асылына төшенә алмыйсың. Күңел күзең сукыр булганга син миһербансыз!

Баязид эреп юк булды.

Тимер башын ике кулы белән тотып, иелеп төште:

– Беләм... Күңелем кошы күкрәк читлегемне ярып, иреккә чыгып очар... минем соңгы тәхетем Аллаһ янында... ул җан өрүче дә, ул җанны алучы да... Мин үлгәч, чәч-баш туздырып, акырып елаган булып кеше көлдермәгез... Кайсы хатыннарның елап, ирләрен үлемнән алып калганнары бар? Киемнәрегезне ерткалап әрәм иткәнче сез мәетем янында тыныч кына Фатиха сүрәсен укып утырыгыз. Аллаһтан минем гөнаһларымны ярлыкавын үтенегез...

Тәхетханәне тутырып, өрәкләр чыкканын күргәндәй булды ул, аларның барысы да башсыз. Гүя әкренәйтелгән хәрәкәтләр белән Тимерне урап алдылар. Әмир кинәт кычкырып, аягүрә басты.

Өрәкләр шомлы аваз белән кычкырды:

– Син алдың безнең җанны-ы! Син кистең башыбызны! Кая куйдың җаныбызны-ы! Кайтар җаныбызны-ы, Аксак Тиме-ер! Дәмәшкъта син чаптырган башлар бу, җиде йөз мең баш...

Тимернең карашында шашкынлык күренде, ул:

– Каравыл! Сакчылар! Кемнәр бола-ар! – дип кычкырды. Өрәкләр эреп юк булды. Әмир алмашына бара иде. – Мин вәхшиме, Баязид? Мин вәхши түгел, мин мөселман, мин һәрвакыт гадел булдым... Ю-ук, мин кяфер түгел, мин монафикъ түгел, мин Аллаһның юлында булдым... Пәйгамбәремез Мөхәммәд... Мостафа... салаллаһу... галәйһи вәссәлам... Җитмеш мең баштан тау өйдердем... йөз мең кешенең башын чаптырдым, ун мең кешене тереләй җиргә күмдердем... Су-у, тамагым яна-а, су-у. – Гайшә аңа су бирде. Әмир су эчеп карады да савытны кискен рәвештә Гайшә бикәгә сузды. – Бу агу-у, яндыра-а, мине агуладылар! А-а... Башларын китерегез... аларның җаннарын алып килегез...

Бичара әмир Тимернең сүзләре аңлашылмый, ава-түнә чаршау артына кереп китте дә егылды.

Күгелташ аңа ярдәм итәргә теләгән иде, ярдәм кирәк түгеллеген ул аңлады һәм чаршау артыннан чыгып әйтте:

– Җан тәслим кылды Бөек Тамерлан! – диде.

Гайшә бикә яшь аралаш:

– Этләргә этләрчә үлем! – дип пышылдады.

Дәрвиш тирән сулыш алып көрсенде.

– Акыллы, бөек адәм иде, ләкин зиһенсез иде, мәрхүм, – диде.

Күгелташ та пошаманда иде, ул сабыр гына:

– Гайшә бикә, син ирекле, син Болгарыңа кайтып китә аласың, – диде.

– Минем Болгарым юк, – диде Гайшә бикә. – Мин туганнарым янына Казанга кайтып китәм.

– Хәерле юл! – диде Күгелташ. – Синең монда калуың хәвефле булыр. Хәзер әмир вафатыннан соң тәхет өчен сугыш башланачак. Исрафил хәзрәт, Мостафа бәк, сез дә ирекле. Дүрт ягыгыз кыйбла.

– Күгелташ! – диде Исрафил хәзрәт. – Безнең күптәннән инде дүрт ягыбыз да кыйбла.

– Астарлы сүзеңне аңлатып бир, хәзрәт, – диде Күгелташ.

Карадәрвиш (Исрафил хәзрәт) чаршау артына кереп китте һәм тиз генә әйләнеп тә чыкты: аның өстендә Испания монахы киемнәре иде. Күкрәгендә алагаем олы хач асылынып тора иде.

Күгелташ аңлар-аңламастан:

– Әстәгъфирулла! – дип акырды. – Сәед хәзрәт! Сез Кастилиядә иман алыштыргансыз түгелме!

– Испаниядә түгел, без монда иман алыштырдык, Күгелташ. Без асылда католик монахлары!

– Әмирем! Тор, ярдәм ит, зинһар! – дип шашып кычкырды Күгелташ: – Йа Аллам, димәк, башка сәедләр дә чын сәед түгел, сәед чапаны бөркәнгән христиан монахлары булып чыга. Менә ни өчен алар Коръәннең сугышырга өндәгән урыннарын гына ачканнар икән.

Карадәрвиш әйтте.

– Хакыйкать шулдыр ки, Күгелташ, Коръән сугышырга өндәми, ул бары тик азатлык сугышын гына җиһад дип саный. Коръән йортыңа басып кергәннәргә каршы гына сугышырга куша. Җиһад басып алу сугышы түгел, җиһад – гадел сугыш. Тимер Коръәннең бер өлешен генә үз файдасына алган.

– Ул сәедләргә ихластан ышана иде.

– Исламны сәед булмаган ялган изгеләр боза килде, Күгелташ. Динне тамырыннан белмәгән мөселманны алдавы бик җиңел. Бу яһүдтән азган мөселман галиме Әбу Сәбәдән килә. Ул Исламның нигезенә еллар буена эчтән кимереп ята торан мәзһәб кертте, шигыйлар мәзһәбе. Артык аерма да юк кебек, ул бары тик Галине дә хәлиф итәргә кирәклеген язды. Әнә кара, шигыйлар белән сөнниләр хәтта бер-берсенә кыз бирмиләр, өйләнмиләр. Мөселман кешесе бик ышанучан, беркатлы ул. Мәрхүм Тимер акыллы иде, ләкин анда зиһен юк иде. Зиһенсезлек Исламны астан, эчтән кимерә. Һәрхәлдә мин, мин генә түгел, король, король генә түгел, бөтен католиклар, католиклар гына түгел, бөтен Аурупа Аксак Тимергә мәңге рәхмәтле. Хуш, Күгелташ, Тамерланның тугры яудашы, бәхил бул! Безне Испаниядә король Һенрих III көтә.

– Төштер бу, – диде Күгелташ.

Карадәрвиш әйтте:

– Төш кенә булса икән, өн. Күгелташ, Испания короленең кулы монда хәтле җитә. Яшәсен христианнар! Алла безгә үзе ярдәм итә!

Күгелташ шашар дәрәҗәгә килеп җитте:

– Йа кодрәтле Аллаһым, дөнья буталды... Нәрсә соң бу? Аллаһ юлында, дөньяда тәртип урнаштырабыз дип, без бөек әмир Тимер бәк белән кяферләргә хезмәт иткән булып калабызмыни? Никадәр куәт, никадәр гайрәт сарыф иттек, никадәр зиһен салдык! Никадәр кан койдык, никадәр җан кыйдык, барысы да Исламга зараргамы? Әмирем, тор, аягыңа бас! Терел дә тормышыңны яңадан башла! Хаталарыңны төзәт, гөнаһларыңны ю! Ятим калган миллионлаган сабыйлардан син гафу сора! Аллаһ сине ярлыкасын! Син инде Аллаһ каршында җавап тотасыңдыр! Ярлыкармы безне Аллаһ, әмир Тимер?

Корольнең соңгы көне

Тирә-якта дала, диңгез, тау-кыялар.

Атка атланган Карадәрвиш (Бонифаций) белән Мостафа (Олонсо) ыргып чаба.

Аттан төшеп, алар көймәгә утырды.

Көймәдән соң тагын ияргә менделәр; ыргып, томырылып чабалар да чабалар. Ниһаять, алар Толедога кайтып җитте.

Король сарае һаман үз урынында. Тәхетханәдә король Һенрих янында көмәнле королева Изида утыра иде.

Канцлер яңгыравыклы азаз салды:

– Король Һенрих Кастильский җәнапларының чакыруы буенча илчеләр килде. Арагон короле Хуан I илчеләре. – Тантаналы рәвештә, илчеләр керде, йола йөгенүләре биюгә әверелде. – Наварра короле Карл III илчеләре,

Византия императоры Мануил II илчеләре, Франция короле Карл IV илчеләре.... – дип санап китте канцлер.

Король Һенрих аягүрә басып, карышкы таягын тотты да сүз башлады:

– Хөрмәтле корольләрнең хөрмәтле илчеләре. Мин сезне бүген католик диненең зиһниятле шәхесләре аркасында ирешкән бөек җиңүләребезне бәйрәм итәр өчен чакырдым. Күрше мөселман маврларының куәтләре какшады, төрек солтаны Баязид тар-мар ителде, үзе шушы кайгыны кичерә алмыйча вафат булды. Бөек татар ханы Туктамыш, Идегәй гаскәрләре хәзер вак төркемнәргә аерылды, үзләре һәлак булды. Иң куркыныч Аксак Тимер дә, ниһаять, җиңелде, ул Кытайга сәяхәт вакытында вафат булды. Мин бүген үземнең исемемнән, сезнең исемнән шушы җиңүдә катнашкан каһарманнарыбызны күп илләрдән килгән иң олы бүләк, орденнар белән бүләкләргә тәкъдим ясадым, һәм ул бүләкләр әзер. Гранада хәлифен дәүләт эшләреннән аерып, аның хәрби куәтләрен зәгыйфьләндерүдә үзен кызганмаган зат ул донья Леонора. Ул Гранада хәлифе Мөхәммәднең башын әйләндереп, принцлар арасында низаглар чыгуга сәбәпче булды. Нәтиҗәдә Кастилия Гранададан аерылды. Хәзер Гранада үзе Кастилиягә салым түли башлады. Леонора өч илнең ордены белән һәм гомере буе түләнә торган алтын белән айга мең сум франк пенсия белән бүләкләнә. – Тантаналы чыгыш, донья Леонорага бүләк тапшырыла. – Икенче баһадирыбыз – ул минем җан дустым сеньор Салазар. Аның хезмәте бәһаләп бетергесез, ул Аксак Тимер белән Баязидны кара-каршы сугыш кырында очраштырган зат. Аңа бер замок, биш дәүләтнең каһарманы орденнары, ике мең алтын франк пенсия. Берләштерелгән Испаниянең онытылгысыз, мәңгелек каһарманы, утны-суны кичкән монахы Пилигрим Руи белән аның якын дусты сеньор Олонсо Паэс – икесе ике миллион гаскәрне җиңгән каһарман. Алар Аксак Тимер белән Туктамышны, Туктамыш белән Идегәйне, Аксак Тимер белән Болгар падишасы Габдулланы чәкәштергән затлар. Икесе дә биш илнең алтын орденнары белән бүләкләнә. Пилигрим Руига ике кальга, дон Олонсога бер кальга, өчәр мең алтын франк пенсия беркетелә. Яшәсен католик зиһнияте! Яшәсен Ауропаны коткарган каһарман испаннар! Бәйрәм итәбез!

Тантана, шау-шу башланды, төпсәләр белән шәраб чыгарылды, тәгам бирелде. Алгы планда Һенрих белән Руи (Бонифаций).

Бонифаций әйтте:

– Эшнең яртысы бетте, сир.

– Котлыйм! – диде король. – Рәхмәт сиңа, Бонифаций. Син булмасаң, мин бетә идем.

– Бетмәс өчен тагын көрәшәсе бар.

– Инквизитор Бонифацийның ялган икәнен фаш итү – синең белән минем бурыч.

– Кардинал Бардини мине таныды булса кирәк.

– Сак бул! – диде король.

– Син дә сак бул, королем! – диде Бонифаций.

Һенрих королеваны биергә чакырды.

Бонифаций янына кардинал Бардини килде.

Бардини әйтте:

– Котлыйм сине, Пилигрим Руи-Бонифаций. Сокланам мин сиңа Бонифаций дустым. Тсс! Синең серне бер мин генә беләм. Сакчың Олонсо белә булыр. Өч кеше белгән сер сер була алмый инде ул. Ихтимал, король дә бу турыда беләдер... Кайларга гына барып чыкмагансың син, дускай.

– Сездән качып йөри торгач, мин дөньяны ике кат әйләнеп чыктым, кардинал. Ә сез мин югында монда күпме гөнаһсыз җаннарны теге дөньяга аткардыгыз икән?

– Тиешлесенең барысын да. Әле аткарасылар күпме. Син Һенрих король белән генә Бөек Кардиналның көчен зәгыйфьләндереп була дип уйлыйсың. Бу тиле кеше хыялы. Инквизициягә каршы барган кеше чиркәүдән мәхрүм ителә, аның мәетен зиратка да җирләтмиләр.

– Минем бу янаулардан куркыр вакытым узган, кардинал.

– Йә, король белән бергәләп Бонифаций янына барып, син ялган, менә ул чын Бонифаций, дип әйтсәгез, ни буласын күз алдына да китерә алмыйсыз. Мин сиңа ярдәм итәргә әзер, мин сине тәхетеңә кайтарырга да телимдер, ләкин бу эш мөмкин түгел, кардиналларның күбесе бу Бонифацийны хуплый, ялган икәнен белсәләр дә, аларга шушындый Бонифаций кирәк, аларга таларга, көчләргә булсын, синең кебек пакь Бонифацийның бер генә кардиналга да кирәге юк, хәтта халыкның үзенә дә. Юкка чыккан идең бит инде, сине юлбасар Педро дип тотып алганнар да асканнар, дип тә ишеттек.

– Әйе, мине Педро юлбасар дип тотып, үлемгә хөкем иттеләр.

– Ә син: «Мин – Бөек Кардинал! Юлбасар Педро минем урындагы ялган түрә», – дип кычкырдыңмы? Ләкин Бөек Кардинал икәнлегеңә синең исбатың юк.

– Исбатым бар!

– Бу җиңүләрдән соң сез ни кылмак буламсыз инде? Әлбәттә, Педроның ялган түрә икәнен фаш итәргә алыначаксыз.

– Анысы инде безнең эш, кардинал де Бардини җәнаплары. Сабый чактан якын дустым, бер-беребезне коткарырга ант эчкән дустым, Бардино! – дип, Карадәрвиш чыгып китте.

– Багарбыз, Руи де Бонифаций, кем алдан өлгерер. – Ул ишарә ясады, Балтазар күренде. Бөкрерәк, нурсыз чырайлы, үте сытылган бер бәндә керде. – Пилигримнан күзеңне алма, сиздермичә күзәт. Ике мең алтын мараведи кесәңдә булыр, – диде тегесе.

Икесе ике якка китеп барды. Бәйрәм дәвам итә. Һенрих белән Леонора тагын очрашты.

– Һенри! – диде сеньора.

– Леонора! – диде король.

– Мин һаман сине оныта алмыйм. Өйләнә алмыйм, дип алдасаң да, син мине мавррга сатсаң да, мин сине барыбер өзелеп сөям.

– Алай әйтмә, Леонора! Күреп торасың, мин үзбаш кеше түгел. Корольләрдән дә ирексез кеше дөньяда юк. Без дәүләт турында уйларга тиеш, дин турында. Королева Изидага мин үзем өчен түгел, Испания булсын, дип өйләндем. Хәлифкә мин сине Испания булсын, дип бирдем. Бу гөнаһларымны Алла кичерер дим, чөнки мин үзем өчен түгел, ил өчен мәхәббәтемнән ваз кичтем, Изидага өйләндем, католикларны афәттән

котарыр өчен, мин якын кешеләремне ерак-еракларга Тартариягә, Азиягә юлладым. Кичер мине.

– Кичердем инде. Минем белән бер биесәң, тагын да ныграк кичерермен.

– Бим, Леонора, рәхәтләнеп бием, ләкин бу минем синең белән соңгы биюем булыр. (Бииләр.)

– Ни өчен? Сарай гайбәтләреннән куркасыңмы?

– Юк, мин гайбәттән курыкмыйм. Минем гомерем аз калып бара.

– Һенри!

– Шулай, җаным. Хуш! Бәхил кал. – Каты ютәлләгәч, барысы да король янына җыела башлады.

– Ни булды, Һенрих король җәнаплары? – диде Салазар.

Король тынына капланып, көчкә:

– Хәлем китте... – диде.

– Һенри! – диде Леонора, ул арада хаста янына королева Изида да килеп җитте.

– Король, сиңа ни булды? – дип сорады Изида.

Бонифаций йөгереп килеп, аның авызына дару салды, король тынычланган кебек булды, аны алып кереп киттеләр. Бәйрәмнең яме бетте. Бонифаций ялгыз калды. Арттан кара шәүлә булып, Балтазар керде.

Балтазар әйтте:

– Пилигрим җәнаплары, мин сезнең батырлыкка шаккатам... Минем исемем Балтазар.

– Балтазар? – дип гаҗәпләнде Бонифаций. – Кайдадыр ишеткәнем бар бу исемне, гаҗәеп матур яңгырашлы исем.

– Мине бозык хатын урамга ташлап киткән. Монахлар табып алып, чиркәүдә үстерделәр.

– Балтазар! Балтазар! Син...

– Тумыштан гарип мин, сеньор. Мине монахлар Бөкре Шайтан, дип йөртә. Мин аларга ачуланмыйм. Шайтан булгач, мин шайтан вазифаларын үтәргә тиеш.

Ул каяндыр хәнҗәр чыгарып, Бонифаций ягына кискен хәрәкәт ясады, Бонифаций эчен тотып бөгелеп төште. Бонифаций иелгән килеш ыңгырашып, сүз әйтергә тырыша иде:

– Койрыклы йолдыз... узып киткәндә... тагын бер бала туар, анысы дөньяга мәкер ташыр, диләр... Син башкисәр Педро юлбасарның уйнаштан туган углы Балтазар булып чыктың.

Балтазар ярсып, тагын пычагын яралыга батырды. Балтазар әйтте:

– Син уйнаштан тумаган, ләкин син миннән дә гарибрәк, Пилигрим.

Ул тиз генә ачык ишек тарафына китте. Чыгуга ишектә тоткавыл пәйда булды, егылып ятучы Пилигримны (Бонифацийны) күреп алды, аның янына атылып килде.

– Пилигрим! – дип ачынып кычкырды сакчы. – Йа Иисусе Христосе! Пилигримны үтергәннәр.

Король ягыннан атылып, Салазар йөгереп чыкты да әче итеп кычкырды:

– Король җәнаплары җан тәслим кылды.

– Пилигрим! – дип ачынып кычкырды тоткавыл.

– Ни булды? – дип сорады Салазар һәм үлеп ятучы Бонифацийны күрде. Салазар Пилигрим янына килеп иелде. – Атам, атакаем!

Бонифаций соңгы сулышы белән:

– Улым, Салазар... мине... – диде.

Салазар тыела алмыйча елый башлады:

– Атам, атакаем!

– Салазар... улым... – дип Бонифаций – Руи – Карадәрвиш бакый дөньяга күчте.

Уртага җыелдылар. Хатын-кызлар илаулап еларга тотынды.

Эчкәридән король Генрих III гәүдәсен алып чыгып, Бонифаций белән янәшә урнаштырдылар.

Салазар әйтте.

– Икесе дә вакытсыз вафат. Әмма бу ике каһарманны Испания онытмас, аларның җанын кыючы җинаятьчеләрне инквизиция һичшиксез эзләп табачак һәм тиешле җәзасын бирәчәк. Амин!

Тавышсыз гына ирләр хоры җыелды. Алар мәет өстендә укыла торган доганы хор белән җырлый башладылар.

Салазар янә әйтте:

– Ауропаны, христианнарны мөселманнар, татарлар мурыннан коткарып калучыларның рухы җәннәттә булсын! – диде.

Сарай эчендә хатын-кыз кычкырган аваз, аннан соң яңа туган бала тавышы ишетелде. Эчкәридән кулына биләүле бала тоткан Дая чыкты.

Дая әйтте:

– Испания короле Һенрих IIIнең углы, тәхет варисы дөньяга килде.

Хор «Аллилуйя... Аллилуйя...» – дип, мәрхүмнәргә, яңа туган балага мәдех җырлый башлады.

Чиксез киң, чиксез биек күктә канатларын җилпемичә генә мәгърур бөркет оча. Аста таулар, тарлавыклар, тау елгалары, иген кырлары җәйрәп ята.

Кайнарташ аланындагы таш яныннан йөгереп бара торган урман тычканын җылан кабып йотты. Аннан соң ризыкны ләззәтле йокы белән эшкәртер өчен таш өстенә шуыша башлады.

Үткер күзле бөркет канатларын җыйды да аска, туп-туры Кайнарташ аланына таба атылды. Бер мәлдән инде тук җылан ач бөркетнең тырнаклары арасында боргалана иде.

Бераздан җыланнан бушаган кайнар таш өстенә яшь егет белән яшь кыз килеп утырды.



Мөҗәһит

КАБАТЛАНСЫН ДОГАЛАР...

Тукай ул берәү генә

Тукай әллә ничәү түгел,
Тукай ул – берәү генә,
Ләкин кереп урнашкан ул
Күпләрнең күңеленә.

Тукай пәйгамбәр түгел, тик
Аны белмәсәң – гарьлек.
Чөнки язган һәр җөмләсе
Хәдисләргә тиңләрлек.

Тукайга баш иябез һәм
Чәчәкләр китерәбез.
Тукайны укып, үткәнне,
Киләчәкне күрәбез.

***

«И Аллам» дип әйтүләр дә
Җиңеллек бирә бугай.
Аллаһ үзе безнең хәлне
Сизә һәм күрә бугай...

«И Аллам», «И Аллакаем...»
Буш сүзләр түгел бит ул.
Төп ышаныч тик Ходайда –
Нишлисең, күңел бит ул...

Мөҗәһит (Мөҗәһит ӘХМӘТҖАНОВ) (1950) – *шагыйрь; А.Алиш, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Акыллыга сүз әйттем», «Җиләкле җәй», «Очты, очты...» һ.б. китаплар авторы. Мөслимдә яши.*

Китәсе килми

Китәселәр килми әле,
Чөнки яшәп туелмады.
Бу дөньяның рәхәтлеге
Минутлык та тоелмады.

Китәселәр ничек килсен? –
Оныкларны күрәсем бар.
Җаен чәчәкле болында
Такыялар үрәсем бар.

Китәргә иртәрәк әле,
Күпме җирләр йөрисем бар.
Башларымнан үткәннәрне
Яшь буынга сөйлисем бар.

Китәрләргә кая әле...
Тәмамлыйсы эшләрем бар.
Бергәләшеп гомер сөргән
Чордашлар, дус-ишләрем бар.

***

Кабатлаулар файдалы да,
Әле алар кызык та.
Урынсызга кулландыңмы,
Бетерәләр бозып та.

Үткәннәрне кабатлыйбыз
Яңасын үрә-үрә.
Онытылмый хатирәләр
Кабатлаганга күрә.

Бабамнарның тормыш юлы
Кабатланмасын иде.
Сугыш, ачлык, афәтләрнең
Эзе калмасын иде.

Яратып кабатласыннар
Теләкләрне, җырларны.
Кабат искә алыйк бергә
Үткән матур чорларны.

Фикерләр дә кабатлансын,
Кабатлансын догалар.
Дога кабатлаган җаннар
Тик бәхетле булалар.

Сине табу канат куйды

Сине табу миңа ачыш булды,
Сине табу мине үстерде.
Сине табуларым канат куйды,
Алып батыр кадәр көч бирде.

Сине тапкач, курку биләп алды,
Ә югалтсам, ничек яшәрмен?
Бар афәттән Ходай саклый күрсен,
Түгелмәсен генә яшьләрем...

Тәфтиләү

«Тәфтиләү»гә сыеп беткән сыман
Халкымның бар шатлык-кайгысы.
Искә төшә үткән төннәремнең
Болытлысы түгел, айлысы.

«Тәфтиләү»не уйныйм, үзем уйлыйм
Әле Тукай, әле халкымны.
Күңелемдә Тукай һәм «Тәфтиләү»...
Йөрәккәем тагын талпынды...

«Тәфтиләү»не Тукай тыңлагандыр,
Җырлагандыр күңеле тулганда.

Ә «Тәфтиләү» бүген дөнья гизә,
Бәлки Тукай сүзе булганга...

«Тәфтиләү»ләр, «Әллүки» ләр белән
Үтеп бара безнең гомерләр.
Аллаһ насыйп итсә, оныкларым
Бу җырларны көйләп йөрерләр.

Сагыну

Сагынмыйча яшәп булмый,
Сагындыра туган як.
Сагындыра уйнап үскән
Әти, әни торган як.

Сагындыра туганнарым,
Сагынмый ничек түзим?
Сагынусыз яшәп булмый,
Мин аннан ничек бизим?

Гомер буена сагынып
Яшәргә язсын иде.
Йөрәгемдәге утлар да
Сагынып янсын иде...

Бер үк Кояш

Югыйсә ул бер үк Кояш
Дөньяның бар кыйтгасында:
Чүлдәгеләр уттай яна,
Күренми дә кайсысында.

Югыйсә ул бер үк Кояш,
Кемгә якын, кемгә ерак.
Кешеләрне аермый һич:
Кем хәерче, кем баерак...

Югыйсә бит бер үк Кояш,
Ә төрлечә бәя ала.
Аны да бит шул халәткә
Куйган бары бер үк Алла...

Әлләә...

Татар теле белән бергә
Моңнар да китеп бара.
Әлфия, Илһам кебекләр,
Кызганыч, бетеп бара.

Хәзер бит сәнгать кирәкми,
Кәмит булса, шул җитә.
Кендектән түбән мәзәкләр
Күпләр күңлен җилкетә.

Халык җыеп, дан яулыйлар,
Сәхнәдә – кәмит, кызык.
Әллә чын җырчылар бетте,
Әллә үзебез бозык?..

Равилә
Шәйдуллина-Мурат

КАРТ ШОМЫРТ ХАТИРӘСЕ

РОМАН

* * *

Фәгыйлә карчык тәрәзәләргә таң алсулыгы сарыла башлауга, почмак яктагы мич кырыенда зәңгәр җирлеккә зур-зур кызыл чәчәкләр төшкән чаршау белән бүлеп куелган бүлмәсендә йокысыннан уянып китте иң элек иртәнге намазын укыды. Анда да әллә ничә тапкыр буталды, ах, монысын укымадым бугай, дип, кабаттан, яңабаштан укып чыкты. Аннан соң кичә кичтән төенчегенә төйнәп, баш астына тыгып куйган әйберләрен алып, иңенә чуклы челтәр ефәк шәлен салды да, өйдәгеләрне уятмаска тырышып, ишеккә таба юнәлде. Әнә, бишпочмаклы йортның юка гына такта белән бүлеп куйган икенче ягында, сәке өстендә тезелешеп яткан улы Шамил, килене Нурания һәм биш оныгы татлы таң алды йокысында. Әтиләре ягында – малайлар, әниләре ягында кызлар таралып йоклыйлар. Тик ул аларның кемнәр икәнен танымый. Карчык аягына кызыл эчле ялтырый тышлы гәлүшләрен киям дигәндә, туктап, кире керде дә, атлаган саен шыгыр-шыгыр килеп җырлап торган, чәчәкләп-чуклап чын күннән тегелгән читекләрен киясе итте.

Ухылдый-ухылдый аягына киеп, башыннан шуып төшкән шәле астыннан бүселеп чыккан чал чәчләрен рәтләп, яулыгы астына тыгып куйгач, төенчеген беләгенә элеп, ишекнең келәсен күтәреп ачты да ишегалдына җәелгән таш сукмактан урамга таба атлады. Күгәнен мул итеп кара дегет белән майлап куйган ишек, тавыш-тынсыз, шыгырдамый гына ябылды. Ишегалдындагы бәбкә үләннәренә мул итеп чык төшкән. Алар, Урыстау өстеннән ялкау гына күтәрелеп килүче кояшның кызгылт нурлары астында төрле төсләргә кереп, зәңгәрсу-кызгылт зөбәрҗәт ташлар сыман җемелдәшәләр. Урак койрыклы, зур кызыл кикрикле ак әтәч, читәнгә кунып, туып килүче ал таңны сәламләп, әллә ниткән куанычлы тавыш белән кычкырып җибәрде. Кетәклектә тавыклар уянып шыбырдаштылар, иренеп кенә кыткылдап алдылар. Әтәч шап-шоп итеп канатларын кагып алды да, җиргә төшеп берәр төрле җим табып алдымы, кыт-кыт килеп, тавыкларын чакырды.

Ахыры. Башы 2020 елның – 11,12 нче, 2021 елның 1 нче санында.

Әтәч тавышына күрше әтәчләр дә кушылып, инде таң атуын, торырга вакыт җиткәнен Алансу халкына хәбәр иттеләр. Абзарда иренеп кенә сыер мөгрәп куйды, сарык бәтиләре бәэлдәштеләр.

Урамнарны нурга төреп, үзенең мәшәкатьләре, шатлык-куанычлары белән Алансуда яңа көн туып килә иде.

Фәгыйлә карчык, урам якка чыккач, олы юлдан Кыйгасар елгасына таба атлады. Өстенә кигән аклы ситсы күлмәге юка, шуңа күрә карчык иртәнге салкынча һавадан калтыранып куйды, җилкәсенә салган ак ефәк шәле дә карт сөякләрен җылытмады. Камзулын кияргә оныткан иде шул. Хәтере юк иде Фәгыйлә карчыкның. Туңса да, кире керәсе килмәде. Ашыгыч эше бар кебек сиксәнне узган карчыкка хас бумаганча, тар сукмактан җәһәт-җәһәт атлавын дәвам итте. Күршеләренең сары эте Сарбай, карчыкны танып, сәлам биргән кебек, бер-ике мәртәбә һау-һаулап өреп алды да тынып калды. Фәгыйлә карчык атлады да атлады. Чәчәкләп-чуклап чын күннән тегелгән читекләре шыгыр-шыгыр килеп җырладылар. Юк, җырламадылар, еладылар бугай.

– Кая барасың, карчык? Шулай таң белән уянып, кай якларга юл тотуың? – дип, читек җырына кушылып, иртәнге җил аякларына килеп уралды. Карчыктан җавап ишетмәгәч, җил дә тынып калды. Каермаларга уралып үскән эт эчәгеләренә, каерма төбендәге сукыр кычытканнарга, мәче борчакларына да энҗеләрдәй чык сибелгән.

– Сөбханалла, – дип куйды Фәгыйлә. – Күз тимәсен, иртәсе бигрәк матур, сөбханалла! Юлларым да шулай уң булса иде инде. Исән-имин генә Хәбибуллам белән Шамилемне барлап алып кайтыйм. Кукан янына басуга дип кенә чыгып киткәннәр иде, әле дә күренмиләр. Кайларда гына каңгырып йөриләрдер? Югыйсә адаша торган көн дә түгел, ә болар юк та юк. Әллә, Ходаем, өтермәнгә үк ябып куйдылар инде, үзләрен Аллаһ сакласын.

– Теге Гарәфи мөртәт Куканны сабанга җикте, буразнага бастыра алмый. Чыбыркы белән яра гына, әти, үтерә Куканымны, әйдә басуга, – дип, әтисен алып чыгып киткән иде улы. Шуннан икесе дә гаип булдылар. Суларга гына төшкән кебек булдылар, валлаһи. Шулай инде, ир-атка күз-колак булырга кирәк. Хатын-кыз карап тормаса, йортта тормышның рәте буламыни? Менә Котдуслар йорты. Шомыртлары чәчәк аткан икән, агачның яфрагы да күренми, шау чәчәктә утыра карт шомырт агачы.

Урамның икенче ягыннан барса да, Фәгыйләнең хуш истән башы әйләнеп киткәндәй булды. Котдус карт белән Нәзифә карчык урам тирәсендә күренмиләрме дип, инде төсе уңган күзләрен Котдуслар йортына төбәп күпме генә эзләсә дә, йортта җанлану сизелмәде.

– Шушындый матур иртәдә ни җаннарың белән йоклап ятмак кирәк? Әле пәрдәләре дә тартылып ачылмаган. Нәзифә карчык уңган-булган лабаса, ник әле һаман уянмаганнар? – дип, нигәдер алга таба атлап китә алмыйча, озак кына вакыт туктап торды.

– Тукта әле, кая барырга чыккан идем соң әле, кемнедер эзләп баруым лабаса. Теге Габделхәй кызы Нурания эзләп тапканчы, тизрәк атларга кирәк. Кай тарафка баруымны оныттым бит әле. Хәбибуллам белән Шамилем Чакрак тау буйларына сабанга киткәннәр иде түгелме? Әллә Кыйгасар елгасы буенамы? Хәтер диген инде син, ә!

Фәгыйлә карчык Котдуслар йорты каршында кайсы якка атлыйсын белмичә озак басып торды да, урамның икенче ягына чыгып, Котдусларның җилкапкасын ачып кереп, карт шомырт агачы төбендәге иске эскәмия читенә утырды. Эскәмияне терәткечле итеп ясап, яшел чирәм төсенә буяп куйганнар. Утырып, ял итәр өчен галәмәт тә җайлы инде. Карчыкябык җыерчыклы куллары белән шомырт агачының кайрылары каралып, яргаланып торган кәүсәсен сыйпап куйды.

– Син дә картаясың, агач, кара бу кәүсәләрең ничек муртайган, минем кулларым кебек буын-буын. Шулай, гомер узган саен агачлар да кешеләр кебек картаялар, муртаялар. Аннан соң нишлиләр? Нишләсеннәр, алар да безнең кебек үк мәңгелеккә китәләр. Аларның да безнеке кебек хәтерләре бетәме икән? Менә, күр син, олы юлга чыктым, тик кая таба, кай тарафларга барасымны оныттым. Кемне генә эзләп баруым соң әле минем? Һай, каһәр суккыры, хәтерем бетте ләбаса, хәтерем бетте. Бу Котдус хатыны Нәзифә уянып чыкса, аннан сорар идем дә, ул да күренми шул. Шундый да матур иртәдә ничек җаннары түзеп йоклап яталардыр, билләһи! Җаннары юктыр боларның, – дип кабатлап, ап-ак пәрдәләр тартып куелган тәрәзәләргә тагын бер кат моңсуланып карап куйды. – Әй гомерләр диген син, ничә яшь тулды икән соң миңа? Күптер инде. Алай дисәң, әле теге Габделхәй кызы Нурания һаман биш-алты яшьлек кызчык. Ул нишләп бездә тора икән, үз йортлары юкмы? Ә Габделхәй белән Маһруйбикә кайда икән соң?

Кояш, җиз табактай, ялкауланып кына кызарып чыгып, карт шомыртның тәлгәш-тәлгәш хуш исле чукларын кан төсенә кертте. Йомшак кына таң җиле исеп куйды. Фәгыйлә карчыкның иңнәренә шомырт тәлгәшләренең ап-ак таҗлары коелды. Һәм шомырт исе! Башларны әйләндереп, Котдус картның бакчасында шомырт исе аңкый иде.

– Һай-һай, исе дә исе! Әйтерсең лә, Акборын чишмәсе буендагы аклык аланы, билләһи!

Тагын җил исеп куйды да, шомырт агачы иелеп, йомшак ботаклары белән карчыкның иңнәренә тагын кар бөртекләре кебек ак таҗларын койды:

– Барасы юлыңны оныттыңмы, Фәгыйлә түти, барма, кире борыл, өеңә кайт. Оныгың тагын эзләп чыгар бит.

Озак уйланып утырды карчык, тик очсыз-кырыйсыз уйларының очына чыга алмады. Тәмам башы буталган иде.

Шомырт агачы хуш исле чәчәкләренә кунган бал кортларының безелдәшкән тавышына куанып, карчыкның яратып, кәүсәсеннән сыйпавына сискәнеп киткәндәй, иртәнге җилдән тибрәлеп куйды да тагын тукталып, үзенә текәлеп карап торган ак әбигә карап:

– Кая таба юл тотуың, Фәгыйлә түти? Шулай таң белән ни эшкә киенеп-ясанып Кыйгасар якларына чыгып китеп барышың, өстеңә дә юка гына киенгәнсең, туңарсың, – дип, янә кабатлап сорады.

– Менә исемә төште тагын – Хәбибуллам белән улым Шамил кичә Кыйгасар буе басуына Кукан янына дип чыгып киткәннәр иде. Инде күпме вакыт авышты, кайтмыйлар да кайтмыйлар. Гарәфи мөртәтне кыйнагандыр бабаң. Шуңа күрә ябып куйганнардыр. Исәннәрме икән

җаннарым? Шамилем дә бигрәк яшь, әле унбере генә тулды. Шуларны барлап алып кайтырга юлга чыккан идем. Инде юлларым хәерле була күрсен! Карт кешегә мондый озын юлларда йөрүе авыр инде ул, бик авыр.

– Ни сөйлисең син, Фәгыйлә түти? Аларның чыгып китүенә чирек гасырдан артык вакыт үтте бит инде. Котдус карт белән Нәзифә карчык та күптәннән юк. Аннан соң улың Шамил сугышларда йөреп кайтты. Хәзер өеңдә киленең – теге заманда колын ашатырга килеп йөргән кызчык – Нурания белән биш бала үстерә. Бар, кайт, өйдәгеләр югалтырлар үзеңне. Аннан соң Кыйгасар елгасы борылып, Кәвәлгә таба ага торган җирендә тирән бит ул, күрәсеңме, нинди мул булып томан төшкән? Кире борыл, Фәгыйлә түти, кире борыл, томанда адашырсың.

– Кит, булмаганны сөйләмә, исәр агач! Нинди чирек гасыр? Үзем кичә иртән озатып калдым. Мәүлетгали атына утырып чыгып китте дә кайтмады Хәбибуллам. Гыйниятуллам да кайтмады. Зөһрәм дә, Нәфисәм дә, Камилем, Рәшитем, Әминәм... Барысы да басу капкасы артына чыгып китеп юк булдылар. Менә шуларны барлап алып кайтыйм дип. Үзәкләрем өзелеп, кичәдән бирле көтәм үзләрен. Алар чыгып киткән басу капкасы ягына карап көтә-көтә күз нурларым түгелеп бетте ләбаса! Ә син өеңә кайт, дисең! Юк, бу юлы тапмыйча кайтмыйм! Иремне, балаларымны эзләргә чыгып китәм, ә мине Габделхәй кызы Нурания, шундый да матур акыллы бала инде, җитәкләп кире алып кайта. «Әйдә, әби, өйгә кайтабыз, сине әти белән әни көтә», – дип, кире алып кайтып китә. Гел шулай инде менә. Кем көтә, нинди әти белән әни? Алар күптән үлде бит инде. Рәтләп аңлатып бирә алмый. Габделхәй кызы нишләп бездә тора икән соң ул? Бу Котдус белән Нәзифә ни җаннары белән йоклап яталар?

– Хәтерең юк, акылың юк, Фәгыйлә түти. Сине иреңне, балаларыңны эзләп йөргән җирдән тотып алып кайтучы Габделхәй кызы түгел, Шамилең белән Нурания кызы – оныгың. Ә Котдус картның бу дөньяны ташлап киткәненә инде чирек гасыр, аның артыннан карчыгы...

– Кит, булмаганны сөйләмә, Шамилемә нибары унбер яшь. Ничек инде унбер яшьлек баланың кызы булсын, ди? Котдус белән Нәзифә карчыкны да кичә генә күрдем. Әле менә безнең өйдә яшәүче кызымның ире сыер сатып алып кайтты да: «Әни», – ди, – нигә миңа әни дип әйтә торгандыр – «Сыерыбыз булгач, безгә ниемә ул кәҗә, әрәмгә ашап ята», – дип, Аксакалымны тотып суйды, әҗәткана! Утырыплар еладым инде, рәнҗепләр еладым. Ул кәҗәдә адәм акыллары бар иде, сөйләшергә теле генә югые җанымның! Үзенә дә әйттем, кәҗәмнең итен ашаганда, Аксакалым, авызыңнан башын чыгарып, мә-ә-ә, дип кычкырып торыр әле, дидем. Хәзер минем янга утырып ашамый да инде, миннән курка кәҗә башын кыючы җәллад!

– Туктале, туктале, Фәгыйлә түти, ялгышасың лабаса. Әле генә әйттең бит, Нурания – Габделхәй кызы, дип. Ә син аны үз кызың, дисең. Хәтерең юк шул, кортка, хәтерең бетте. Ә Шамил синең улың бит ул. Инде улыңның да биш баласы бар.

– Кит, булмаганны, исәр агач, Шамилем, исән булса, минем Аксакалымны суяр идеме? Ә Нурания Габделхәй кызымыни ул? Юк, минем кызым ул.

Аның белән торучы, минем Аксакалымны суючы җәллад кемдер, белмим. Хәбибуллам белән улым Шамилне табып алып кайтсам, кудырып чыгарам мин ул кансызны. Аксакалымны хараплар гына итте, пир суккыры! Адәм акыллары бар иде кәҗәмдә, билләһи! Аксакалымны сагынып елаплар уянам да төннәр буе йоклый алмый ятам. «Әй Аллакаем, Фәгыйлә карчык, мине саклый алмадың», – дип рәнҗепләр киткәндер инде, миңа рәнҗепләр киткәндер кәҗәкәем, рәхмәт төшкере!

Фәгыйлә сукрана-сукрана эскәмиядән күтәрелеп, капкага таба атлады.

– Кая барасым искә төште бит әле. Хәбибуллам белән Шамилемне эзләп алып кайтырга дип чыккан идем ләбаса. Минем Аксакалымны харап иткән җәлладны куып чыгарсыннар. Аннан Нәфисәм белән Гыйниятулламны да табып булмасмы? Зөһрәмне, Рәшитем белән Камилне, Габдрахман хәлфәне, оныгым Әминәне.

Кыйгасар буендагы зират сөттәй ак томанга төрелгән. Җир өстеннән ап-ак сөт елгасы агып баргандай томан агыла.

Хәтере утызынчы елларда адашып калган Фәгыйлә карчык, читекләрен шыгырдатып, зират ягына таба атлады. Тирә-юнен ямь-яшел чирәм каплаган сукмак буйлап зиратка таба атлаучы Фәгыйлә – каһәрләнгән елларда тормышы чәлпәрәмә килгән карчык – әйтерсең лә, томан эченнән мәңгелеккә таба Хәбибулласын, Шамилен, кызлары Зөһрә белән Нәфисәне, онықларын эзләп китеп бара иде.

Акылы киткән иде шул Фәгыйлә карчыкның. Ирен, балаларын, онықларын югалту хәсрәтеннән акылын җуйган иде.

Карт шомырт агачы, иртәнге җилдә ап-ак чәчәкләрен тибрәтеп, хуш исле таҗларын җиргә коеп, аның артыннан ялварды:

– Кайт, Фәгыйлә түти, Хәбибулланы таба алмассың, ул юк инде. Болай ялгызың гына ерак юлларга чыгып китеп адашырсың. Томаннар эчендә югалырсың. Әле Шамилең белән киленең синең чыгып китүеңне сизми калгандыр, таң алды йокысы бигрәк татлы бит ул. Уянгач, кайгырышып, тагын сине эзләргә чыгарлар. Нураниягә охшаган кечкенә кызчык – онычың – сине табып, яңадан җитәкләп, өйгә алып кайтыр. «Әби, әби, әйдә өйгә кайтыйк. Сөтләп, чәй эчәрбез, аннары качышлы уйнарбыз. Рәхәт булыр, әби. Шундый да рәхәт булыр инде менә». Син онычыңа каршы килә алмассың.

Нәфисәң турында да берни белмисең шул. Зөһрәң, Хәбибуллаң, Гыйниятуллаң, Рәшитең, Камилең, Әминәң турында да хәтерләмисең. Аларның күбесе әллә кайларга, кеше бер киткәч, кире әйләнеп кайтмый торган мәңгелеккә киттеләр. Ә кайберләре – Алансу авылы ят иткәннәре башка җирләргә нигез корды. Син аларны Кыйгасар елгасы буендагы, Алансуның сандугачлар сайрап торган, тын гына томан эчендә оеп утырган чәчәкле, җиләкле зиратында да таба алмассың. Балаларыңның төрлесе төрле якта, Себердә, Үзбәкстанда әҗәлләрен таптылар. Һәм мәңгелеккә китеп, гомер томаннары эчендә эределәр. Шамилең сугышлардан исән-имин әйләнеп кайтты да, теге аксыл-сары чәчле, зәңгәр күзле, Йолдызга шикәр ашатырга килеп йөргән кызчык белән тормыш кордылар.

Сугышлардан орден-медальләр тагып әйләнеп кайткан оныгың Рәшит кояш кебек якты Сәлимә белән тормыш корып, Казанда яши. Ә син әле һаман шул – гарәп аргамагы Куканны сукага җиккән вакытта, ак оекбашлы, болыннарда уйнаклап чабып йөрергә тиешле колынчак Йолдызны авыл куштаннары суеп ашаган чакта, менә-менә бәби табарга тиеш булган кызың Зөһрәне Себер җибәргән, балалыктан чыгып кына килүче оныгың гүзәл Нәфисәне Казан төрмәсендә өчәр башлы аждаһалар көчләгән заманда, үзеңне мыек чылгыйлары ике яктан салынып төшкән, җирән чәчләрен мул итеп фуражкасы астыннан чыгарып куйган гаскәринең үтергәнче кыйнаган елларда адашып йөрисең. Адәм баласы бу кадәр газапларга түзә алмый! Акылың бетте, Фәгыйлә карчык, акылың юк! Нихәлләр итмәк кирәк. Йа Раббым, ничекләр итеп кенә яшәп бетерерсең?! Ул елларны эзләмә инде син, Фәгыйлә түти, таба алмассың! Бәлки, үзең дә бу дөнья белән хушлашып мәңгелеккә киткәч, якыннарың белән кавышырсыз. Балаларың белән күрешерсез дә, хәтерең әйләнеп кайтыр һәм син алардан башка яшәлгән гомерең турында сөйләрсең...

Башка бер сүз дә дәшмәде карт шомырт агачы. Фәгыйлә карчыкны күздән югалганчы карап озатып калды да, күңеленә килгән авыр уйларыннан уелып, тынып калды. Күңеле сизде агачның, Фәгыйлә карчыкның ак томаннарга өртелгән зират ягына бил тиңентен сөттәй агып торган аклыкка күмелеп, мәңгелеккә чыгып китүе иде.

Кыйгасар буендагы арыш басуы. Иртәнге акрын җил – Фәгыйлә карчыкның җыерчыклы, ләкин Хәбибулласын табып, өенә алып кайту өмете белән өретелеп янып торган йөзен иркәләп искән җил – талгын гына яшел уҗымнарны дулкынландыра. Карчык тынлыкта оеп утырган зират буена җиткәч, тагын туктап калды.

– Тукта, кайсы басуга таба чыгып киткән иде соң төпчеге Шамил белән Хәбибулласы, Чакрактау буе басуынамы, әллә Кыйгасар буенамы?

Фәгыйлә инде шактый юлны узып өлгергән иде. Зират яныннан Чакрактауга таба борылып керә торган ат юлы бар. Әнә ул арыш басуының нәкъ уртасыннан, тәгәрмәч араларында ефәк яшел юл калдырып, офыкка таба сузылган тәгәрмәч эзләре.

«Ходавәндәләр, бу адәмнәрнең күзләре юк микәнни соң, арыш басуын таптап йөрмәсәләр? Зират яныннан Кыйгасар елгасы буйлап кына үтеп булмый микәнни? Иген басуын кем таптап йөри инде, менә фәрвайсызлар!» – дип уйлап, карчык Чакрактауга таба атлады. Чыклы үлән эчендә йөреп чигүле читеге юешләнде, коңгырт-кара төскә керде. Соңга таба нигәдер карчыкның хәле китебрәк тора. Йөрәге дә, чабыш аты сыман, туктый-туктый тибә. Аннан соң бөтен гәүдәсен әллә ниткән кымырҗык бер салкын урап ала да, көзге усак яфрагы кебек калтырата. Ябык гәүдәсе гел түшәк сорап тора, билләһи. Көндез ятып торырга күнекмәгән Фәгыйлә карчыкка Нурания килене:

– Әнкәй, аз гына ятып, хәл алып тор, – дип, ястык-түшәкләрне кабарта-кабарта урын җәеп бирсә дә:

– Кит, кызым, булмаганны, көн яктысында сузылып ятып торырга мине кем дип беләсең! Аннан соң яткач ятуга китә ул, аяклар йөргәндә йөреп

торырга кирәк, хәрәкәттә – бәрәкәт, – дип, килене әзерләп куйган урынга ятмыйча, үзенә бер шөгыль табып чыгып китә.

Килене күпме әйтеп карады:

– Әнкәй, мин синең кызың түгел, киленең. Шамил синең улың...

– Дөрес сөйләмисең син, ялгышасың. Әгәр улым булса, Аксакалымны суяр идеме? Кансыз җәллад!

– Әни, улыңа шундый авыр сүзләр әйтмә инде, аңа болай да җиңел түгел. Аннан соң курмы җыюы бик авыр. Каян җиткерәсең? Сыер булгач, кәҗә ниемә кирәк? Болай да балалар «уфалла» белән эт эчәгесе, алабута, билчән ташып интегәләр, аның бит чабып алырга печәне дә юк, барысы да колхозныкы.

– Үземә дигән ризыкны кәҗәмә ашаткан булыр идем. Хараплар гына итте Аксакалымны! Түбән оч мәхәлләсенең Гатаулла мулла акыллары бар иде Аксакалымда, сакалы да нәкъ шуныкына охшаган иде, валлаһи, указлы мулла зиһеннәре бар иде. Кич белән көтүдән азан тавышы ишетүгә чабып кайтыр иде дә «Фәгыйлә карчык, ахшам керде, намазыңа утыр» дигәндәй, күземә карап торыр иде. Теле генә югые бәгырькәемнең!

Фәгыйлә карчык бу сүзләрне көн дә кабатлый. Ул инде оныкларын да, улын да, киленен дә танымый. Каһәрләнгән утызынчы елларда каядыр чәчелеп, таралып беткән гаиләсе кайсыдыр басуга, әллә Чакрактау, әллә Кыйгасар буе басуына сукага җигелгән гарәп аргамагы Куканны коткарырга чыгып киткән унбер яшьлек улы һәм Хәбибулласы гына хәтерендә яңара. Алар таң тууга, Фәгыйлә карчыкны йокысыннан уяталар.

– Әни, кайда син? Әйдә басуга кил әле. Куканыбызны коткарырга кирәк, – дип, әнисен чакырып уята унбер яшьлек Шамил.

Кайсыдыр басуда, үзәкләрне өзеп, Кукан кешни: ми-ха-ха... Кукан белән Йолдызның буш аратасында, колынчакның муенсасын күкрәгенә кысып, төпчек улы Шамил үкси. Җаннары өзелердәй булып, илерә-илерә елый ул, эти-әнисеннән ярдәм көтеп елый. Әнә Хәбибулласы, кечкенә генә биштәрен асып, басу капкасына таба мәңгелеккә китеп бара.

– Кая барасың, сиңа әйтәм, булыш инде улыңа, булыш, – ди ана, тик Хәбибулла ишетми.

Әнә Йолдызның кояш нурларында елкылдап торган тиресе аркылы агачта эленеп калган. Һәм күгәргән кадакка элеп куйган муенсага тагылган кечкенә кыңгырау тавышы Фәгыйлә карчыкның хәтерендә көн саен яңгырап, улы белән картын эзләргә басуга чакыра.

Башка бернәрсәне дә хәтерләми Фәгыйлә карчык. Өй тулы балаларның да кем икәннәрен белми. Тик Габделхәй кызы Нуранияне генә таный. Әнә бер кеп-кечкенә кыз бала, әле иртәнге чык тамчылары да кибеп бетмәгән үләнле сукмак буйлап йөгерә-йөгерә, кемнедер эзли. Салам чәчләре колын яллары кебек сибелеп-сибелеп кала.

– Әб-и-и, син кайда-а-ау?

Аның өзгәләнә-өзгәләнә кычкыруы, Ялантау, Урыстау, Чакрактауларның текә маңгайларына бәрелеп, Фәгыйлә түтинең колагына килеп ирешә.

Һай, кемне генә эзли икән бу бала, дип уйлый барыр юлын Чакрактауга юнәлткән Фәгыйлә карчык. Әллә адашкан инде, бигрәкләр дә өзгәләнә.

– Монда кил, кызым, монда кил! Югалткан әбиеңне икәүләп эзләрбез. Мин Хәбибуллам белән Шамилемне эзләрмен, ә син – югалткан әбиеңне. Икәүләп эзләсәк, рәхәтрәк булыр, тизрәк табарбыз.

Тик аның акрын тавышы үзеннән ары китми. Әллә иртәнге җил үзе белән каядыр ияртеп алып китә инде тавышын, моны Фәгыйлә карчык аңлый алмый. Кыз баланы кызганып йөрәге телгәләнә.

– Монда кил, кызым, томаннар эчендә зират янында адаша күрмә. Кыйгасар буенда яр бигрәк текә, – дип, баланы чакыра.

Кинәт... һаваны томырылып чапкан атлар, тулпарлар тавышы, тояк тавышы яңгырата. Фәгыйлә карчыкның күз алдына, утлы ялкын кебек, ак-кара-кызгылт ялларын тузгытып, көнчыгышка таба чапкан атлар ташкыны күренә. Әнә бит иң алдан Кукан Йолдызы белән суырылып чабалар. Көнчыгышка таба, кояшка таба, карчыкның Хәбибулласы белән Шамиле чыгып киткән якка таба агыла атлар ташкыны. Нәрсәнедер исенә төшерергә теләгәндәй, карчык азрак туктап торды да киредән зиратка – Кыйгасар буе басуына таба томырылып, суырылып, җирән ялкын булып атлар ташкыны чапкан якка, әбисен эзләп, салам чәчләрен тузгытып яшь колыннар кебек чапкан кыз балага таба атлады Фәгыйлә.

Зират капкасы янына җиткәч, нигәдер хәле китеп, аркасын зират коймасына терәп, җиргә утырды. Атлар ташкынына ияреп, томырылып Кукан белән Йолдыз чапкан якка, көнчыгышка карап күзләрен йомды.

– Әби-и-и! Син кайда-а?! – дип чакыра кыз бала.

– Монда мин, кызым, монда, менә соңгы тукталышта, ял итәргә генә утырдым, – дип, соңгы тапкыр Фәгыйлә карчыкның йөрәге җавап бирде.

Ә Кукан белән Йолдыз, Хәбибулла белән Шамил чыгып киткән Кыйгасар елгасы буена, көнчыгышка таба томырылып чаба калдылар.

* * *

Тереклек елгасын чыкканнан соң, Урыстау итәгендәге Аклык аланында шомырт чәчәк аткан чак, башларны әйләндерерлек хуш ис! Акрын гына искән җилдә ак төстәге чәчәкләр тибрәлә. Әйтерсең, бер-берсен куып тотарга теләгән наян кызлар җитәкләшеп йөгерә...

Күз күреме җирдә Көлич белән Алансу арасында Ситдика һәм Төп чишмәләрен узгач, Аклык аланы башлана. Бу – дөньяның иң матур, иң гүзәл урыныдыр. Мондый сафлыкның, мондый гүзәллекнең башка җирдә булуы мөмкин түгел! Шомырт чәчәкләре кояшның көмеш сыман нурларында тагын да аграк булып, чуклары сафлыкның, аклыкның үзенә әверелеп, күңелләрне алгысытып, акрын гына тибрәләләр дә тибрәләләр. Гүя: «Күреп калыгыз безне, бик тиздән таҗларыбызны җиргә коярбыз, ә алар кап-кара җимешләргә урын калдырып, ак кар бөртекләре кебек җиргә түшәлер. Шуннан ул таҗларыбызны шаян җилләр үзләре белән бик еракларга алып китәрләр дә дөньяга чәчәрләр, дөньяга аклык таратырлар», – ди Аклык аланында үсеп утырган шомырт агачлары. Дөньяны нурга төреп шомырт агачлары чәчәк аткан чак.

Әнә шомырт агачлары арасыннан ефәк күлмәк кигән бер сылу килеп чыкты. Өстенә кигән өрфия күлмәге дә шомырт чәчәкләре кебек ак иде.

– Әтием, әтием! Күрегез әле бу аклыкны, күрегез әле! Монда нинди матур! – дип, алсу-ак чәчәкләргә үрелде. Башына такыя үреп кигән кыз бала үзе дә чәчәк кебек гүзәл иде. Дулкын-дулкын кара чәчләре тубыгына кадәр төшеп тора. Ап-ак йөзенә җәй алсулыгы кунган. Очарга әзерләнгән карлыгач канатлары кебек сызылып киткән кара кашлары, кашларына тиеп торган озын керфекләре, карлыгандай кара зур күзләре, битләрен чокырайтып елмаюы һәм битендәге тары ярмасыннан да кечерәк миңе!..

– Алиһә! – диде Солтангәрәй. – Син, кызым, алиһәләргә тиң.

– Ә нәрсә дигән сүз ул «алиһә», эти? Ни дигән сүз?

– Мин сиңа ул сүзнең төгәл генә тәрҗемәсен әйтеп бирә алмыйм. Тик шуны гына әйтә алам: син, кызым, чәчәкләр кебек матурсың, сафсың, гүзәлсең! Аллаһ бәхетеңне бирсен, кара җаннар тормышыңны җимермәсен! Менә инде студент булдың, укып бетергәч, доктор булырсың. Кешеләрнең тән яраларын гына түгел, җан җәрәхәтләрен дә дәваларсың, кызым. Әниең, Әсхәдулла бабаң, Римма апаң кебек изге күңелле зур доктор булырсың, Газизә. Тик Аллаһ бәхетеңнән аермасын! Әнә әниең Үзбәкстанда медицина өлкәсендә нинди зур уңышларга иреште! Син дә кызым, мәрхәмәтле, кешеләрнең җаннарын җылыта белүче доктор булырсың!

– Әнием, әнием! Синең бу аклыкны күргәнең бар идеме? Нигәдер сөйләгәнең булмады. Бала чагың, яшьлегең нинди матур җирләрдә узган икән бит, – дип, Газизә, кулларына ак чәчәкләр гөлләмәсе тотып, агачлар арасыннан кечкенә Маратны җитәкләп килеп чыккан әнисенә таба атлады.

– Юк, кызым, шомырт чәчәк атканда, аланлыкта алсу-ак чәчәкләр тибрәлеп хуш исләр тараткан вакытта, миңа бу аланга килергә туры килмәде. Бу аланлыктан без әтиең белән көзен, шомлы җилләр искәндә, күк йөзен кара болытлар каплаган төнне моннан күп еллар элек узган идек. Әле бүгенгедәй хәтеремдә, шундый да караңгы төн иде. Әтиең мине Көличкә, Яков агайларга кадәр озатып куйды. Ул вакытта мин унбиш яшьлек, синнән дә яшьрәк кыз бала идем. Әтиең миңа: «Нәфисә, кайчан да булса сине бу аланлыкка яз көне шомырт чәчәк атканда алып киләм», – дигән иде. Тик бүгенгә чаклы килергә насыйп булмады. Бу көннәрне күрермен дип уйламаган да идем. Нинди зур бәхет икән! Рәхмәт әтиеңә! Урау-урау юллар, каһәрләнгән газаплы еллар аша туган җирләрне, әти-әниемне, әбиемне күрү бәхетенә ирештем. Ә сиңа, кызым, мин күргәннәрне күрергә язмасын. Энең Марат белән дус-тату, сау-сәламәт булып яшәргә язсын!

Нәфисә белән Солтангәрәй, үз уйларына чумып, сөенешеп, балаларына карап тынып калдылар.

Газизә, энесе Маратны җитәкләп, Урыстау түбәсенә менеп китте.

– Әтисе, әйдә, Көличкә кадәр барыйк әле. Анна түти, Яков агай исәннәрме икән? Картайганнардыр инде. Нинди мәрхәмәтле кешеләр алар! Ходай саулыкларын бирсен, исән була күрсеннәр!

Солтангәрәй, Нәфисә янына килеп, хатынының иңнәренә үзенең көчле беләкләрен салды.

– Нәфисә! Ул вакытта янында үткәргән караңгы төннәр минем иң

бәхетле төннәрем бит. Көличтә яшәгән ун көн гомереңдә мин көнне үткәрә алмыйча интегеп бетә идем. Югыйсә көзге көннәр кыска гына, төннәре озын. Ә миңа исә синең белән үткәргән ул төннәр шундый кыска булып тоела. Җиз иләктән иләгән кебек сибәләп торган көзге вак салкын яңгыр да ул сихри төннәрнең серлелеген генә арттыра кебек. Синнән аерылып Алансуга кайтып җиткәнче үк, сине сагына башлый идем, җаным. Тик соңыннан нинди газаплы еллар башланды! Очы-кырые күренмәгән сагышлы, сагынулы еллар! Миндә ике Солтангәрәй яшәде. Берсе – шушы Аклык аланында караңгы төннәрдә көзге яңгыр астында адашып калган сөйгәнен бер күрергә тилмереп ашкынып торган яшь егет. Икенчесе – Габдрахман абзыйга, хәзер инде бабайга, «яклармын», «саклармын» дип вәгъдәләр биреп, антлар эчеп калсам да, сине зур газапларга дучар иткән Солтангәрәй. Күпме гомерем синең белән Үзбәк якларына чыгып китмәгәнгә үкенеп үтте. Үзем дә белмим, ул вакытта әллә ничек кенә булды, әллә кеше сүзеннән курыктым, әллә кыюлыгым җитмәде, яшьлекнең иң матур чаклары синсез узды. Газизә әтисез кимсенеп үсте. Мин бит, ялгыз яшәсәм дә, гомерем буе гел синең белән янәшә булдым, Нәфисә. Хәлимә түти дә үлгәнче гел синең турыда гына сөйләп торды. «Әй, Нәфисә безнең янда булса, бергәләшеп яшәр идек», – дип хыялланды. Тик ул көннәрне күрә алмады. Кылый Камалыйның борыны бите белән тигезләнеп, борын тишекләре ыржаеп, кеше күзенә күренә алмаслык булып калганнан соң да, миңа текәлеп карап торды. Минем эш икәнен сизенде инде, тик дәшмәде. Хәлимә түти дипломат иде. Ялгыз каз шикелле яшәвемә борчылып, үз ахирәтенең кызы белән кавыштырмакчы булып карады. Тик юкка! Йөрәгемнең түрендә бары син идең, җаным! Анда башка беркемгә дә урын юк иде, Нәфисә! Авырып, үлем хастасы булып түшәккә егылгач та, Хәлимә түти: «Солтангәрәй, болай интегеп яшәмә, кит син Нәфисәң янына, эзләп тап, барыбер оныта алмаячаксың. Ул да сине сагынып тилмереп яшидер. Икегез дә пар аккошлар кебек бит сез. Аккошлар, парларын югалтсалар, сагыштан үләләр. Сине дә күреп торам, Казанда шәүләң генә йөри, җаның Нәфисә янында, Үзбәк якларында бит инде. Әгәр өйләнешеп Казанга кайтып торсагыз, йорт-җирем сезгә калыр, Ташкенда калсагыз, анда үз тормышыгызны корырсыз. Яраткан, җан тарткан кешең белән кайда яшәсәң дә бәхетле булырсың. Мине озаткач, Нәфисәң янына кит. Мәскәүгә чыгып киткән улымны алыштырган өчен рәхмәт сиңа, Солтангәрәй! Алланың рәхмәте илә Нәфисәң белән кавышып яшәргә язсын!» – дип, теләкләр теләде. Үзем дә күптән шул турыда уйлап йөри идем. Хәлимә түти бу фани дөньяны ташлап киткәч, аны озатып, ашларын уздыргач та юлга кузгалдым. Әллә кайчан чыгарга тиешле юлга соңга калып тәвәккәлләдем, Нәфисә. Шуның өчен үземне гафу итә алмыйм!

– Син нәрсә, Солтангәрәй, нәрсәләр генә сөйлисең?! Нинди гаебең булсын ди? Язмышыма шулай язылган булгандыр. Кылый Камалыйга кул күтәреп тә дөрес эшләмәгәнсең, җаным. Ул үзенә тиешле җәзаны болай да алыр иде. Андый кабахәт җаннарны Аллаһ мәңге кичермәс! Юкка андый вак җан белән бәйләнгәнсең.

– Түзә алмадым, Нәфисә, күргән газапларың йөрәгемнән китмәде.

Җаным үрсәләнде. Соңыннан үзем дә үкендем инде, Камалыйның хатынына, балаларына никадәр хәсрәт китердем. Аларның ни гаебе бар иде соң?

– Әйдә, ярар, бер яктан уйлаганда, тиешлесен алган, үзенә күрә таман. Солтангәрәй, бәхетемә газаплар чигеп, хурлыклар, кыерсытулар аша, урау-урау юллар үтеп килергә туры килде. Әле дә ул көннәр төшләремә кереп, манма тиргә батып, сискәнеп уянам. Янымда булуың да төш кебек кенә. Уянып китәрмен дә, юкка чыгарсың, тагын ялгыз калырмын, дип куркам! Исән генә була күр, Солтангәрәй! Миңа яшәү көче биргәнең өчен рәхмәт! Газизләрдән газиз Газизәмә чын әти була алганың өчен! Җиде яшенә кадәр: «Ник әтием юк? Бар балаларның да әтиләре бар, ә минем әтием кайда?», – дип өзгәләнеп, кимсенеп үскән кызым, сине күргәч: «Әтием, әтием кайтты!» – дип, сиңа килеп сарылды. Ә син: «Кызым!» – дип, аны кочагыңа алдың. Улыбыз Марат өчен, безнең тигез бәхетебез өчен рәхмәт! Ташкентка безне эзләп килгән көнең әле дә хәтеремдә. Бүгенге кебек кояшлы яз иде. Әсхәдулла абзыйларның бакчасы шау чәчәктә. Алсу, ак, шәмәхә, зәңгәрсу төстәге чәчәкләргә төренгән агачлар талгын гына җылы язгы җилдә тибрәләләр, хуш ис таратып, күңелләрне җилкендереп торалар. Ә күңелдә шундый моңсулык, күңел ашкынып нидер көтә. Сөю көткән җан кемнедер көтеп сулкылдый. Миңа, Солтангәрәй, синең турыда уйлау да гөнаһ иде, чөнки мин Әкрамҗанга тугрылыклы хатын булырга, кызымның бәхете булсын дип, мине җаныннан да артыграк күреп яраткан егеткә кияүгә чыгарга ризалык биргән идем. Ә йөрәгемдә, Солтангәрәй, бары тик син генә идең бит, анда башка кешегә урын юк иде. Менә шулай, кызымның бәхете өчен үз бәхетемне корбан итәргә әзер идем. Газизәм белән мәктәптән кайтып килгәндә, Әсхәдулла абзыйларның капка төбендәге йөзем агачлары астындагы эскәмиядә утыручы сиңа охшаган егетне күреп, акылдан язам дип торам. Башта үз күзләремә үзем ышанмадым. Юктыр, аңа охшаган гынадыр, дим, күпме еллар узгач... Ә үзем, елмаеп каршы килгәнеңне күргәч, кочагыңа атылдым. Мине әдәпсезгә санагансыңдыр инде, Солтангәрәй.

– Нәфисә, ниләр сөйлисең?! Мин бит үзем дә сине башта танымадым. Элеккеге, билләре өзелеп торган зәңгәр күлмәк өстеннән күкрәк турыларына, итәкләренә канәфер чәчәкләре чигелгән алъяпкыч япкан, озын кара толымнарына чулпылар таккан япь-яшь унбиш яшьлек кыз урынына европача киенгән, аягына биек үкчәле туфлиләр кигән, күз явын алырдай чибәр, гүзәл ханым килә. Башта уңайсызланып калдым. Соңыннан, бит урталарыңны чокырайтып елмаеп, кочагыма атылгач кына аңыма килдем. Дөньяның асты өскә әйләнде. Аз гына соңарган булсам, сине мәңгелеккә югалткан булыр идем бит.

Солтангәрәй, хатынын куенына алып, Урыстау түбәсенә менеп җиткән Газизә белән Маратка карап кул болгады.

Газизәнең алсу-ак өрфиядәй ефәк күлмәге туган якның талгын гына искән назлы җилләрендә, Аклык аланындагы болындагы ак чәчәкләргә кушылып, җилферди иде.

– Әйдәгез, балалар, яшьлек эзләребез буйлап Көличкә, Яков агай белән Анна түти янына барып кайтыйк әле, – дип, сукмак буйлап атладылар...

* * *

Нурания йокысыннан уянды да, тәрәзә пәрдәләрен тартып куеп, урамга карады. Күк йөзендә тулган ай җиргә зәңгәрсу ак нурларын сибә, чекерәеп янып торган йолдызлар атыла. Алар шулкадәр күп һәм, берәм-берәм үзләре артыннан якты эз калдырып, җиргә коелалар сыман. «Аллага шөкер, көне матур булырга охшаган. Малларга ашатырга тезмәдә бер чеметем печән заты калмады. Инде сыер кайчаннан бирле түбәдән төшереп парландырган күгәргән салам ашый. Җитмәсә, кабыргалары тырпаеп таралырга торган ябык ач сыерны җилененнән кан саркылып чыкканчы савабыз. Мескен малкай, үзе буаз, ничекләр итеп кенә бозаулар?! Балаларны уятып, Чакрак болынына эскерт төбендә калган салам йолкырга җибәрергә кирәк. Председатель белән бригадир уянганчы кайтып җитә алсалар, сыерына салам парландырып бирерләр иде. Азрак пешкән бәрәңге кабыклары, чүт кенә көрпә болгатып бирсәң, малларның тамаклары туя инде ул», – дип урыныннан кузгалды да, кичтән ире Шамил кертеп куйган коры утынны мич төбенә тезеп, кучкардан чыра алып, ут тергезеп җибәрде. Миче күңелләрне күтәреп, чатор-чотыр итеп яна башлагач кына, таралып, тезелешеп йоклап яткан балаларын йокыдан уятасы итте.

Сәгать иртәнге өч. Стенага элеп куйган, кияүгә чыкканда этисе Габделхәй бүләк иткән затлы зур кара сәгать, акрын гына келт-келт итеп, минутларны саный. Балаларның таң алды йокысын йокларга тиешле минутларын. Колхозлашу елларында авыл активлары алып чыгып киткәндә кулларыннан төшеп китеп, бизәкләре төрле якка чәчелгән сәгатьне, ватык, моның беркемгә кирәге юк, дип, ташлап калдырганнар иде. Әле этисенең төн буе сәгатьнең ватылып-чәчелеп беткән бизәкләрен җилем белән ябыштырып утырганын бүгенгедәй хәтерли Нурания. Төзеп-җыеп бетергәч, стенаның ап-ак итеп юылган бүрәнәсенә кадак кагып, галәмәт зур, зиннәтле сәгатьне элеп куйды. Ачкыч белән, этисе әйтмешли, «заводын» борып җибәргәч, күпне күргән сәгать өйгә җанлылык кертеп йөреп китте дә, күп тә үтмәде, җиде тапкыр нindидер моңлы бер аваз белән сукты. Әле соңыннан да бу аһәң күпмедер вакыт зеңгелдәп торды. Шул моң, шул аваз Нураниянең күңеленә мәңгелеккә уелды. Әтисенең дә күз тирәләренә моңсу гына елмаю кунды. «Әй әтрәк-әләмнәр, шундый затлы әйберне бәреп калдырдылар. Иске казанны – әнисенең аш пешерә торган казанын – мичне җимерә-җимерә суырып алдылар. Юк шул инде, юк, зат танымыйлар. Күргән әйберләре түгел шул. Мал бәясен белүчеләр юк. Хәер, авылында сәгать төзәтүчесен дә каян тапсыннар?» – дип, этисе кемнәндер зарланган кебек сөйләнгән иде. Нурания кияүгә чыкканда, Котдус карттан калган бизәкле кара сәгатьне бүләк итте Габделхәй.

– Мә, кызым, бу сәгать синдә югалмас, кулың эш белә: тегүен дә тегәсең, ирләр эшен дә җимертеп эшлисең, итек астына олтан да саласың, самавырын да ямыйсың, сәгать тә төзәтә беләсең, – дип, күңелен булдырган иде.

Инде менә дистә елдан артык вакыт узды, комсомоллар төшереп ваткан сәгать һаман да Шамил белән Нурания гаиләсенең гомерен саный. Бер генә минутка да соңармый, Котдус картның пөхтәлеге, Габделхәйнең төгәллеге кебек.

Тик-так, тик-так, тик-так. Менә сәгать өч тапкыр доңгылдатып сугып куйды. «Вакыт, вакыт, балаларыңны уят, Нурания. Җәллисеңдер, тик нишләмәк кирәк... Дәресләрен хәзерләп бетереп соң гына йокларга яткан сабыйларыңны ничек кызганмыйсың. Таң алды йокысы бигрәк татлы бит ул, бигрәк тәмле була. Тик нишләмәк кирәк... Кирәк тирәкне ега, ди».

Нурания тагын бер кат тәрәзәләргә күз салды. Айның көмеш нурларында коенып, Галиәхмәт Ринаты белән сеңлесе Сания, чана сөйрәп, Чакрактау басуына таба китеп баралар. Галиәхмәтләр иренә кардәш тиешлеләр, галәмәт уңганнар, тырышлар.

Нурания тәрәзә яныннан кузгалып китте дә таралышып йоклап яткан балалары янына килде. Сабыйлар рәхәтләнеп йоклыйлар. Әле йокының иң татлы чагы. Балаларның әниләре куенында, матур төшләр күрә-күрә, рәхәтләнеп йоклар чагы. Ләкин...

– Балалар, торыгыз инде, уяныгыз. Тиз генә чәйләп алыгыз да эскерт төбендә калган саламны йолкырга барыгыз. Кеше-кара уянганчы кайтып җитә алсагыз, малларга башак болгатып ашатырыек.

– Әй әни, әз генә йоклыйк инде. Тагын әз генә, чүт кенә. Бигрәк иртә бит әле, әни. Әле әтәчләр дә уянмаган.

– Ниткән йоклау ди ул, әнә Галиәхмәт Ринаты сеңлесе Сания белән әллә кайчан чаналарын сөйрәп чыгып киттеләр инде, кайтыр вакытлары җитә. Ә сез һаман йоклап ятасыз. Төне буе укыйсыз да, иртән йокыгыз туймый. Әгәр колхоз председателе яисә бригадир каршыгызга очраса, саламыгызны колхоз фермасына алып барып бушаттырыр. Ул сыер белән сарыкларны, әкияттәге кебек, муеннарына капчык асып, хәер сорашырга чыгарып җибәриммени соң? Сыерсыз да калсак нишләрбез, ниләр генә эшләп бетерербез, Ходаем? Ичмаса, әтиегез дә саусызланды, – дип, күңеле тулып елап җибәрде Нурания. – Әнә Галиәхмәт Ринаты сеңлесе Сания белән...

Әниләренең елавы балаларның шунда ук йокысын ача. Сикерешеп торалар да, чиратлашып мич артындагы кулъюгычта бит-кулларын юып, киенеп, чәй дә эчеп тормыйча чаналарын сөйрәп, Чакрактау буе басуына таба атлыйлар.

Галиәхмәт абзый Ринаты аларның абыйларыннан бер генә яшькә өлкәнрәк. Нурания белән Шамил көн саен, таң тууга, әнә Галиәхмәт абзый Ринаты сеңлесе белән шуны эшләгән, моны эшләгән, дип тәкрарлый башлый.

– Әни, ник безне бер дә мактамыйсың соң син? Без дә эшлибез бит инде, бер минут тик торган юк бит!

– Сезне кеше мактасын. Нигә дип без үз балаларыбызны үзебез мактап утырыйк ди? Әнә Галиәхмәт абзый Ринаты...

Менә шулай Галиәхмәт абзый Ринатының бәллүрдәй юка боз челтәрен ватып узган чана эзе буйлап Чакрактауга таба чана сөйрәп чыгып китә балалар.

Нурания күңелендә чана табаны астында юка боз челтәрләренең чатнап, ватылган тавышы хәсрәтле бер аваз булып яңгырап тора.

– Нишләмәк кирәк, балалар! Маллар ач. Әнә сыерлары абзар түбәсеннән

төшергән парланган салам салынган тагарак янында шактый вакыт ашамыйча басып торды, тик нишләсен, тамак гүргә кертә, ди. Соңыннан, аптырап, керт-керт итеп ашарга тотынды. Аз гына арыш көрпәсе сибелгән, чери башлаган, күгәргән салам. Әнә саламы төшерелгән абзар түбәсенең такталары шәрәләнеп, йөрәккә шом салып, сураеп тора.

Әтиләре авырып китте шул. Әгәр икәүләшеп эшләсәләр, балалары-сабыйлары болай интекмәсләр иде. «Үпкәсендә чире бар, балалар укытырга ярамый» дигән белешмә язып бирделәр. Һәм унтугыз яшеннән сугышка кереп, сугышның башыннан ахырына кадәр ут эчендә, фронтның алгы сызыгында Ватанны саклаган Шамил Муратовны аена 20 тәңкә түләп пенсиягә чыгардылар. Нурания ул акчаны утыз көнгә бүлеп карый, көнгә 66 тиен чыга. Бу акчага ничек яшәмәк кирәк? Акылы утызынчы елларда адашып калган Фәгыйлә карчык һәм укырга атлыгып торган биш бала!

Үзенең хезмәт хакы да юк дәрәҗәсендә. Җитмәсә, мәктәп директоры рус теле дәресләрен, кисеп алып, башлангыч класс укытучыларына бирде.

Беркөнне, кабинетына чакыртып:

– Нурания Габделхәевна! Мин рус теле дәресләрен, сездән алып, башка укытучыларга бирергә булдым, чөнки сезнең белемегез җитәрлек түгел, дип саныем, – диде. Әйе, саныйм димәде, «саныем» диде.

Нурания, аптырап, яшьле күзләрен директорның ябык, каклаган каз кебек каракучкыл йөзенә төбәп:

– Белемемне хезмәттәшләремнекеннән түбән дип уйламыйм. Минем сыйныфтан югары сыйныфка күчкән балалар, тәртип ягыннан булсын, белем ягыннан булсын, яхшы якка аерылып тора. Сез бу турыда югары класс укытучыларыннан белешә аласыз. Сугыш елларында эвакуацияләнгән Ленинград хатын-кызлары белән гел рус телендә аралаштык. Үзегез дә белеп торасыз лабаса, ирем саусызланды, балаларым ишле, иң кечесенә нибары алты ай. Каенанам акылын югалтты.

– Карагын әле, сез нәрсә дип мине өйрәтеп торасыз? Ул балаларны минем өчен түгел, үзегез өчен тапкансыздыр бит. Тулмаган сәгатьләрегезне төнлә интернатта эшләп тутырырсыз. Ә ирегез, әнә, дуңгыз фермасын төзергә эшчеләр кирәк, ди, шунда барыр.

Әйе, шулай диде мәктәп директоры, карагыз әле димәде, «карагын әле» диде. Балаларның әтиләре, җиде ел буе сугышта, сугыш беткәч, җимереклекләрне төзәтеп йөреп саулыгын бетереп кайткан фронтовик турында.

Шамил болай да, үзен-үзе кая куярга белмичә, тәмам рухы сынып, җаны елап йөри иде. Нурания директорның бу сүзләрен иренә әйтеп торасы итмәде. Күз яшьләренә коенып, елый-елый өенә кайтты.

Ничек яшәргә, балаларны ничек аякка бастырырга? Укысыннар, югары белем алсыннар иде. Юк, белем алып кына түгел, кеше булып калсыннар иде балалары. Әтиләре Габделхәй үзләренә дә күпме әйтте: укырга кирәгез, читтән торып булса да югары белем алыгыз, диде. Нык беләкле берне еккан, белемле меңне еккан, диде.

Сугыш арты еллары, кая инде уку?! Тәмам җимерелгән илне аякка бастырырга кирәк. Бер-бер артлы тезелешеп, биш балалары туды. Гомернең

агып киткәне сизелми дә калды. Менә шушы татар сүзләрен вата-җимерә сөйләшә торган яшь директор килгәч, Нурания өчен акыл җитмәслек кара көннәр башланды да инде.

Ире туры сүзле иде шул. Яңа директор белән тыныша алмадылар. «Үпкәсендә чире бар, мәктәптә эшләргә ярамый» дигән белешмәнең дә ялгыш, ялган икәнлеге бик соң, пенсиягә чыгарга өч ел калгач кына беленде. Ә әлегә сугышларны күрмәгән яшь директор Нуриянең җелегенә төште. Һәрдаим дәресләренә кереп утыра, үзе булмаса, уку-укыту бүлеге мөдирен кертә. Һәм һәрбер педсовет укытучының йөрәк өянәге белән тәмамлана иде.

Йа Аллам! Нуранияме көн үткәнгә йөрүче? Улмы эшләми? Уку авыр бирелә торган балаларны өенә чакырып укытты, үзенең вакыты булмаса, өлкәнрәк балаларына кушты. Ләкин яңа директорга ярый алмады.

Менә шуларны уйлады Нурания, балаларын эскерт төбенә бозланып каткан салам калдыкларын йолкырга җибәргәндә. Әтиләре белән барырлар иде дә, тик ярамый – кеше-кара күрсә, караклыкта гаепләп, Шамилен партиядән чыгарырга мөмкиннәр.

Әнә алар – өч сабый – чана сөйрәп, Чакрактау басуына таба китеп баралар. Чана табаннары астында челтер-челтер килеп, кар катламын бәллүрдәй каплаган язгы боз челтәре ватыла. Балалар, таң йокыларын калдырып, әти-әниләренә булышыр өчен, колхоз председателе, бригадир, өлкәннәр уянганчы, кеше-кара күзенә чалынганчы, таң атканчы кайтып җитеп, мәктәпкә барырга тиешләр. Соңгарак калсалар, язгы кар эреп, чаналары батачак. Ат йөгедәй юеш салам төялгән чана батса, сөйрәп чыгарам димә! Чөнки бу, әниләре әйтмешли, ни арба, ни чана вакыты. Аякларына олтан салынган киез итек кисәләр – юеш, бутый кисәләр – аяклары бозга әйләнә, салкын. Әле шуның өстенә кар астына су төшкән, карның катысы юкка чыккан. Кар дип басасың, аяк төшеп китә дә, бутый эченә челтерәп, сабыйларның нәни аякларын өтеп кенә ала торган салкын язгы кар сулары кереп тула.

Алар килеп җиткәндә, Галиәхмәт Ринаты сеңлесе Сания белән шактый гына салам йолкып, чаналарын яртылаш тутырып куйганнар иде инде.

– Сез бүген соңга калгансыз, яктырганчы кайтып җитә алсагыз ярый, – дип каршы алды Ринат. – Әгәр персидәтелгә эләксәгез, бетерә инде. Саламыгызны фермага алып барып бушаттыра. Узган атнада бригадирга очрадык, өйгә буш чана сөйрәп кайтасы булды, маллар ач калды.

– Без бүген өчәүләп килдек, бәлки, тизрәк төяп булыр, – дип, тиз-тиз салам йолкый башлаганнар иде, кая ул! Көндез эрегән кар төнге салкында саламга берегеп каткан, һич сөйрәп алырлык түгел. Балаларның нәни куллары суелып бетә. Казан каласында яшәүче ерак туганнарының балаларыннан калган иске бишмәт җиңнәреннән күренеп торган беләкләре иртәнге язгы салкыннан яргаланып, «чебиләп» кызарып тора. Өчәүләшеп черәшә-черәшә, интегә-интегә, балалар салам йолкыйлар!

Ул эскерт төбендә калган саламны яз көне барыбер яндырачаклар, чөнки салам калдыклары язгы чәчүгә төшкән тракторларга комачаулый. Ә әлегә, кояш Урыстау өстеннән алсуланып, агарып күтәрелә башлаганчы, өйгә кайтып җитешергә кирәк. Нәни кулларын суя-суя, кар суларына бата-бата, алда көннәр матур булыр, адәм баласының тормышы гел газаплардан гына

торырга тиеш түгел ләбаса, дип, Котдус картның туруннары, Хәбибулла белән Габделхәйнең оныклары, дәһшәтле сугышларны узып, окоп казып, урман кисеп җиңү көнен якынайткан Шамил белән Нурания балалары, әниләренә, авыру әтиләренә булышыр өчен, кар белән берегеп каткан колхоз саламын йолкыйлар, салам урлыйлар.

– Кайтыйк булмаса, – ди абыйлары, югарак кына бастырык белән бастырып, чанадагы саламны бәйләп бетергәч.

Абыйлары тәртәгә җигелә, ике сеңел арттан этә.

Ябык, хәлсез сабыйлар, интегә-интегә, ат йөгедәй авыр чана сөйриләр, «нужа» чанасын. Юлсыз җирдән киләчәккә сукмак салалар. Ул сукмак аларны якты киләчәккә – коммунизмга алып барачак. Өметсез – шайтан, ди.

– Апа, апа, минем бер бутыем кар астында төшеп калды, – ди бер аягында басып торучы сеңелләре Рәмзия.

Абыйлары, кар астыннан бутыйны табып алып, шыбырдатып, аннан кар суын агыза.

– Син моны кия алмыйсың инде, сеңлем, чат су булган бу. Мә, аягыңа минем бияләйләрне ки, салкын тия күрмәсен, үпкәң кабарыр да, урын өстенә егылырсың, – дип, абыйлары сеңлесен чана өстенә менгереп утырта да салам белән төреп куя һәм яңадан чананы сөйри башлый. Ике бала – абый, сеңел – «нужа» чанасын, салам өстендә туңып, калтырап елап утырган сеңелләрен сөйриләр.

Инде кайтып җитәргә аз гына калган иде. Урыстау өсте агарып, кояш чыгар вакыт җитеп килә иде. Әллә кайдан гына, кинәт кенә, җир астыннан чыккан кебек, кара айгыр җигелгән чанада утыручы бригадир килеп чыкты. Сикереп төште дә, тәртәгә кереп, чана сөйрәүче абыйларының якасына ябышты. Салам өстендә калтыранып утыручы сеңелләре Рәмзия үксеп елап җибәрде.

– Тимә абыйга, тимә! – Икенче сеңелләре бригадирның телогрейкасыннан сөйрәде. – Әтигә әйтәм мин сине, нигә абыйга сугасың?!

Саламны фермага илтеп бушаттылар.

Нурания балаларын капка төбендә каршы алды. Сөмсерләре коелып кайткан кызлары әниләренә килеп сарылдылар. Кызларның күзләрендә мөлдер-мөлдер яшь тулып түгелергә тора иде. Үсмер малай – абыйларының күзләре әрнү-газаплардан утлы күмер кузлары кебек көйри.

– Әни, бер дә кайгырма, иртәгә, Алла боерса, Галиәхмәт Ринатыннан иртәрәк кузгалырбыз. Ул бригадир уянганчы кайтып җитәрбез, әни. Тик менә чананы алып калды, кабих. Әти алып кайтыр әле. Бер ярты аракы бирсә, алып кайта инде ул чананы, – дип, әнисен юатты абыйлары!

– Ярар, улым, нихәлләр итәсең, язмышыбызга шулай язылгандыр. Ул саламны берәр айдан барыбер яндыралар инде. Кешегә бирсәләр файдасы булыр дип куркалардыр...

Ни өчен шулай эшләгәннәрен балалар түгел, әниләре дә аңлый алмый.

– Менә бераздан тормыш җиңеләер бит, әни? Малларга курмыны да әти белән болыннан гына чабып алып кайтырбыз. Җәй буе кукуруз басуыннан билчән, эт эчәгесе, алабута җыеп җык булдык бит инде. Анысын да, нәчәлникләр кулына эләксәң, колхоз бозауларына илтеп

бушатасы. Ә коммунизм җиткәч, болай итеп кача-поса, таң йокыларын калдырып, салам урларга йөрмәбез. Маллар җиләкле болын печәнен генә ашап торырлар. Менә Американы куып җитәрбез дә җилләр кебек узып та китәрбез әле, әни?

– Абый, ул Америка дигән җирдә инде коммунизм җиткәнме? Андагы кешеләр шундый әйбәт йөгерешчеләрме? Сабантуйда беренче булып килгән Мәгъсүм җизнине Америкага җибәрсәң, беренче килә инде ул! Мәгъсүм җизнине безнең авылда уза алган кеше жук бит. Әгәр аны Америкага йөгерешкә җибәрсәләр, безгә дә коммунизм тизрәк килеп җитәр иде.

Абыйлары, көлеп, сеңлесенә:

– Мәгъсүм җизни генә узып китә алмас Американы. Аны күбрәк итеп мал үстереп, аннан соң сөтен, маен, күкәен, җонын җитештереп кенә узып китеп була. Аннан машиналар, тракторлар ясап... күп инде. Америкада бөтен кешенең дә үз машинасы бар икән. Капка төпләрендә генә тора икән аларның машиналары. Чыгып утырасың да ачкычын борып җибәрәсең. Ә машина асфальт юлдан и оча инде, и оча, ди. Менә бездә дә кайчан да булса шулай булачак. Көзге кебек тип-тигез асфальт юллар салыначак. Әле сезне үземнең машинама утыртып йөрермен.

– Абый, абый, ул Америка дигән җирдә кар суларына бата-бата балалар салам урлап йөрмиләрме? Чынлапмы, абый, анда юллар пыяла кебек тигезме?

– Әйе инде, ник әле мин сезгә егет башым белән ялган сөйләп торыйм ди.

– Абый, синең үзеңнеке генә булачакмы машина? Үзең йөртәчәксеңме? Алдалама. Безнең авылда беренче май бәйрәмендә бер чиләк күкәйне, аллы-гөлле төсләргә буяп, авыл балаларына өләшә торган җырчы Гөлсем апаның ире Инсаф абыйда гына машина бар. Аның нумерын да беләм: ТРР-66-22. – Рәмзия үзенең белдеклелеге белән мактанып, әтисенеке кебек зәңгәр күзләрен тутырып, ялт итеп абыйсына күтәрелеп карады. Тик ул Инсаф абыйның агач машинасы бөтен калхузныкы. Инсаф абый, балаларны төяп, Мишәгә алып барды. Мин дә бардым, син өйдә юк идең ул көнне. Әти белән урманга төп чыгарырга киткән идең. Аннан соң, – дип сузды Рәмзия, – син әле машина йөртә белмисең дә. Безнең авылда Инсаф абый гына машина йөртә белә. Ялганчы син, абый.

– Машинасы булса, йөртәм инде мин аны. Инсаф абый да шундый ук кеше, күктән төшмәгән бит. Әйдәгез, мәктәпкә соңга калабыз, – дип, абыйлары, сеңелләрен калдырып, өйгә кереп китте.

Ә мәктәптә...

Бригадир, иртүк килеп, Шамил Муратовның җинаятьче балалары турында җәвит иткән.

Язгы кояш нурларында ялт итеп балкып торган мәктәп ишегалдында укучыларны линейкага тезеп, мәктәпнең ике йөздән артык пионеры, октябряты алдына бастырып, «коммунизм төзүче Совет иленең сыйнфый дошманнарын», «карак», «угры» балаларны эт урынына сүкте мәктәп директоры.

– Сез ни йөзегез белән колхоз милкенә кул сузып йөрисез, ә?! «Намус» төшенчәсенең әсәре дә юк икән! Пионер галстугы, Ленин бабайның

балачагы рәсеме төшкән значок тагып йөрергә хакыгыз юк сезнең, оятсызлар!

Линейкада басып торучы балалар күзләрен аяк очларына төбәп басып торалар. Чөнки үзләренең дә төн карасы таралып, таң атканчы чаналарын сөйрәп чыгып китәселәре бар. Бу – авылда яшәүче, коммунизм төзүче совет халкының яшәү рәвеше.

Күзләреннән чишмәдәй яшь агызып басып торучы бу өчәүне җәмәгать суды алдына чыгарып сүгүче мәктәп директоры үзенә ләббәкәй дип тормаган фронтовик Шамил Муратовтан шулай итеп үч ала.

– Карагын әле бу балаларга! Павлик Морозов үзенең әтисен – сыйнфый дошманны – Совет властен төзүчеләр кулына тапшырган. Ә сез?! – Директорның болай да каракучкыл йөзе җир төсенә керде. – Оятсызлар, барыгын, урыныгызга барып басыгын, – дип, балаларны җәза мәйданыннан азат итте.

Аннан соң линейкада кемнедер мактадылар. Мәктәпнең эш планнары турында сөйләделәр. Һәм җырладылар:

Коммунизм җирдә чәчәк ата,
Тантанасын инде күрәбез.
Безнең яшьлек – иң бәхетле яшьлек,
Шатланабыз шуңа күрә без.

Шуннан соң мәктәп директоры Нуранияне кабинетына чакыртты:

– Нурания Габделхәевна! Ничек оят түгел?! Нигә әле сез – үзегез балалар тәрбияләргә тиешле укытучы – карак, угры балалар үстереп ятасыз? Сезгә, гомумән, мәктәптә урын булырга тиеш түгел! Ул балаларыгыздан барыбер рәтле кеше чыкмаячак. Белеген шуны: күрә торып җинаятьчеләр үстерәсез ләбаса.

Нурания көчкә кайтып җитте дә, аңсызланып, бүлмә яктагы урын-җир өстенә ауды. Балалар, язгы кар суына бата-чума, авылның бердәнбер докторы Нюра апаларына йөгерделәр. Инде бутый эченә кереп тулган кар сулары да аякларын туңдырмый. Тизрәк Нюра апалары килеп җитсә, әниләре исән калачак! Соңарсалар ни булыр! Гел шулай, балалар, һәр педсоветтан соң кешегә авыр сүз әйтә белми торган әниләрен коткарыр өчен, кар көртләрен ерып, бата-чума, Нюра апаларына чабалар.

Мәктәп директоры әтиләренә сүз әйтә алмас, ә әниләрен һәрдаим рәнҗетеп торыр. Әле шуның өстенә һәр яз саен, шәп атларга утырып, районнан инспектор Хәкимов дигән адәм килеп төшәр. Бу чисталык, пөхтәлекнең үзе булган зәңгәр күзле чибәр инспектор килгәч, балалар көн саен Нюра апалары янына чабарлар. Кыз балаларның башларына кадап куйган кәкре таракларын турайттыручы инспектор Хәкимов укытучылар һәм укучы балаларның күңелләрендә мәңгегә уелып калыр.

Кич буе кайнар суда яки учак каршында җылытып, искелек калдыгы саналган кәкре таракларны китап эченә тыгып, берәр авыр әйбер белән бастырып куярлар. Ә ул гөнаһ шомлыгы кәкре тараклар аз гына вакыт Хәкимовның расчёскасы кебек тураеп торырлар да, мәктәпкә барып җиткәнче, тагын элеккеге хәлләренә килерләр. Инспектор Хәкимов, кыз балаларны линейкага тезеп куеп, башта куе зәңгәр төстәге расчёскасын

чыгарып, болай да пөхтә чәчен тарап, куен кесәсенә тыгып куяр. Аннан соң гына кызларга күмер кузлары салып кыздырган кайнар үтүк белән бастырып куеп үтүкләп турайткан «капитализм калдыгы» таракларын күрсәтергә кушар. Кыз балалар «расчёска»га әйләнгән кәкре таракларын, калын китап эченнән чыгарып, Хәкимовка сузарлар.

Язгы кояш кар көртләрен ашап, авыл урамнарында челтер-челтер килеп гөрләвекләр аккан чакта, инде агач бөреләре яз килгәнгә куанып, шартлап ачылырга торганда, кыз балаларның, укытучыларның котларын алып, кәкре таракларын турайтырга килер ул галәмәт чибәр, күн итеген көзге кебек ялтыраткан гөнаһ шомлыгы инспектор Хәкимов.

Ул киткәннән соң, укучы кызлар, әниләре әче су белән кадерләп юып тәрбияләп үстергән, тубыкларына кадәр төшеп торган куе калын чәчләренә рәхәтләнеп искелек калдыгы кәкре таракларын тагып йөрерләр. Яңа язларда, яңадан, шәп айгырларга утырып, Хәкимов килеп җиткәнче.

Дәһшәтле сугышта унтугыз яшендә ут эченә кереп исән калган, югары белем алырга мөмкинлеге булмыйча, кемнеңдер булышлыгы аркасында «балалар укытырга ярамый, үпкәсендә чире бар» дигән ялган белешмә бирелгән Шамил Муратовның һәм Баһадир исемле үгезне җигеп җир сөргән, җиңүне якынайтыр өчен үзе теләп урман кисәргә киткән Нурания балалары алар. Пионер галстугы тагарга хаклары булмаган, иртә таңнан председатель уянганчы, бригадир йокыдан торганчы үрәчәле чанага җигелеп, берәр айдан ут төртеп яндырылачак саламны урларга баручы, үзләре кебек үк «бур» иптәшләре алдында оялып, йөзләре муеннарына тагылган кызыл галстук төсенә кереп кызарып, күзләреннән чишмәдәй яшь агызып, линейка алдында басып торган «карак» балалар.

Апрель ахырларында басуда әллә ничә җирдә эскерт төпләрендә калган саламга ут төртеп яндырырлар. Дөрли-дөрли янар ул салам.

Дөрли-дөрли янган салам яктысы Котдус картның туруннары, Хәбибулланың оныклары күз алдында Урыстау өстеннән күтәрелгән таң алсулыгына кушылыр. Аягыннан төшеп калган бутыена челтерәп кар сулары тулган сеңелләре, үпкәсе шешеп, әллә ни гомер үлем белән тартышып ятар. Яшәргә, яшәргә дип ашкынган җан үлемне җиңеп чыгар. Салам янган галәмәт зур учактан төшкән яктылык Урыстау өстеннән алсуланып күтәрелеп килүче коммунизм таңына кушылыр. Сабыйлар, күзләрен мөлдерәтеп, аптырап, басу тутырып очкыннар ата-ата янган салам эскертләренә карап торырлар. Ялкынга кушылып, җаннарында хыяллары янар.

Яшәр, үсәр, укыр, әти-әниләренә терәк булыр өчен; Котдус карт һәм авылга керергә ярамыйча, сугыш вакытында Шамский хастаханәсендә вафат булып, кемдер тарафыннан Яңа Бистә зиратына җирләнгән Хәбибулла картның нәселен дәвам итеп яшәргә кирәк.

Әти-әниләрен гел рәхәттә генә яшәтербез дип ант эчә сабыйлар.

Совет халкының хәзерге буыны коммунизмда яшәр. 1980 елда инде коммунизм булыр. Аз гына, тагын аз гына түзәсе калды.

Әлегә кызарып, ялкынланып янган саламнан төшкән яктылык Урыстау өстеннән күтәрелеп килүче коммунизм таңының алсуланып торган шәүләсенә барып тоташа.

* * *

Карт бүредәй улый-улый котыра буран. Әйтерсең, явыз каенана яшь киленгә дөньяга кем хуҗа икәнен аңлата. Өлкән яшьтәгеләр, авырулар, сызланып, йоклый алмый интегәләр.

Нурания карчык та, сызлап интектергән буыннарын угалап, ни өчен шәһәргә, балаларына кыш чыгарга китмәгәненә үкенеп, ыңгыраша-ыңгыраша урыныннан кузгалып, йоклата торган ак сәдәбен эчеп килде. Соңыннан, бетмәс-төкәнмәс авыр уйларыннан алҗып, тынгысыз йокыга талды.

Һәм өндәгечә, ап-ачык итеп төш күрде.

Җып-җылы, ямь-яшел бәбкә үләнле, кояшлы җәй, имеш. Ул – яңа гына кияүгә чыккан яшь килен – тәрәзәләрне ачып куеп, өй җыештырып йөри. Ире Шамил мәктәптә, каенанасы кызы Рәшидәгә кунакка киткән. Тыныч, тук, матур тормыш. Сугыш та юк, үгез җигеп сукага чыгасы да юк. Өстәлдә күпереп пешкән кара икмәк. Абзар тулы мал, кош-корт. Шау чәчәктә утырган алма бакчасы. Һәм йөрәк астында, беренче тапкыр дөньяга барлыгын белдереп, яңа җан талпынып куйды.

Рәхәт, бик рәхәт иде күңелгә!

Кинәт капка төбенә җигүле ат килеп туктады. Нурания ачык тәрәзәдән әтисе Габделхәй килгәнен күрде, аның куе йомшак тавышын әллә ничә мең тавыш арасыннан аерыр иде ул.

Танымыйча, ул бит төннәр буе әтисенең җырлый-җырлый тимер чүкегәнен тыңлап үсте. Әтисе гел моңлы озын җырлар җырлый торган иде. Әнисе Маһруйбикә корырак, кырысрак холыклы булды. Ә әтисе сигез бала арасыннан Нуранияне аерыбрак ярата иде, ахрысы. Әллә кызчыкның үзен шулай яраттырасы килдеме икән? Әтисенә булышчы иде шул ул. Ул эшләгәндә, чыра яндырып яктыртып тора иде.

– Әй кызым, үстең инде, – дип, әтисе мактый. Һәм төн буе тимер чүки. Тимер чыңына «Кара урман»нар, «Ямбикә»ләр, «Сәрвиназ»лар, «Гөлҗамал»лар кушыла.

Диң-диң, шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал,
Диң-диң, житкән кызлар киндер җеп эрлиләр,
Энҗе-мәрҗән кызларның кул бавы...

Кыз кара урманнарда күңеле белән адашып йөри. Энҗе-мәрҗән беләзекләр кигән калфаклы чибәр кызларның җеп эрләгәне күз алдына килә. Шул җепләргә хыяллары иярә, һәм күзенә, керфекләренә куе, татлы йокы эленә. Зәңгәр төтен, кургаш исе, күптән ак каурый болытларга әверелеп, әтисенең тыныч, тау халыкларыныкы кебек мәгърур йөзе белән ак томанда эреп, юкка чыга.

Әй балачакның рәхәт, хәсрәтсез татлы мизгелләре! Сез дә бик тиз, март аеның йомшак җилендә эреп, йөгерек гөрләвекләр булып аккан кар сулары кебек, мәңгелеккә агып киттегез дә җир куенына кереп юкка чыктыгыз! Тик җанда, күңелдә җәйге тымызык, җылы сахра җилләре куып керткән «Кара урман»нары, «Гөлҗамал»лары, «Ямбикә»ләре белән тимер чүкеп утыручы әтисе Габделхәйнең акыллы күз карашы, бәрхет

тавышы аны, йөрәкләрне авырттырырлык дәрәҗәдә газиз хатирә булып, гомере буе озата барды.

Менә бүген, шушы шыксыз салкын төнне җәйгә әйләндереп, әтисенең тавышы ишетелә түгелме соң? Ул тиз генә тәрәзәгә капланды. Ә анда чыннан да җәй, имеш. Капка төбендә, әле ул бала чакта кунакка барганда тарантаска гына җигелә торган Каратуры. Тик нигәдер аны бу юлы арбага җиккәннәр. Анда – ямь-яшел чапкан үлән өстендә – әнисе белән Зәкия түтәсе утыра. Әнисенең башында яратып яба торган, чит-читенә зәңгәр кыңгыраулар чигелгән ап-ак яулыгы. Бу яулыкны аңа Мәскәүдә яшәүче элеккеге күршеләре Хәкимә алып кайткан иде. Әнисе аны бик яратып рәешкә генә, үзе әйтмешли, теш сызлаганда гына яба иде шул. Зәкия түтәсе дә бик матур киенгән.

Тукта, аның әти-әнисе дә, Зәкия түтәсе дә күптән гүр ияләре бит инде. Каратурыны да колхоз оешкан елны әллә кемнәр килеп алып киттеләр бит. Ә алар килгәннәр...

Ул, йөгерә-йөгерә, әти-әнисе янына арбага чыгып утырды. Ә алар дәшмәделәр. Әтисе атка чөңгерде, ат кузгалып китте дә, чаптырып килеп, Нураниянең бала чагы, яшьлеге узган төп нигезгә, карт шомырт төбендә төшереп калдырды һәм авыл башына, зират ягына таба китеп барды. Ә ул, газизләре киткән зират ягына карап, нигә сөйләшмичә рәнҗеп киткәннәрен аңламыйча аптырап, шау чәчәкле шомырт төбендә басып калды.

Һәм манма тиргә төшеп уянып китте. Күзен ачса, шомлы караңгы төн. Тышта, әллә нинди куркыныч тавышлар чыгарып, җил улый. Шомырт чәчәкләре түгел, баганадан төшкән яктыда күшеккән ап-ак күбәләкләр кебек кар бөртекләре бөтерелә.

Җәй дә юк.

Бәрхет тавышлы горур әтисе дә юк.

Кыңгырау чәчәкле яулык япкан кырыс әнисе дә юк.

Зәкия түтәсе дә юк.

Каратуры да юк.

Чәчәкләрен коеп утыручы карт шомырт та юк.

Беренче баласының беренче талпынуын сизеп куанган яшь килен дә юк.

Кыш, караңгы кыш бар.

Картлык, беркая да качып котыла алмый торган картлык бар.

Балаларын югалткан хәсрәттән җанны өшетердәй шомлы тавыш белән улаучы карт бүредәй котырган буран бар.

Тукта әле, нигә керде соң бу җанны җылытырдай матур төш? Әти-әнисе нигә рәнҗегәннәр? Әтисе, үләр алдыннан: «Җиде баламның берсе дә намаз укымый, Коръәнне кулга алмый», – дип рәнҗегән иде. Ләкин моңа балалар гаепле түгел. Мәктәптә дин, Алла юк, дип укыттылар. Алласыз, динсез буын үсте ләбаса. Әтиләре үзе дә мәчетсез, мәхәлләсез калган авылда җыелышып, кача-поса, җәмәгать белән җомга намазы укыдылар. Ә аларны куштаннар кәнсәгә барып әләкләделәр. Чакыртып сүктеләр, ләкин туктата алмадылар. Әтиләре күргәндә, балалары намаз укымый иде шул. Тыныч күңел белән китеп барган булыр иде Габделхәй карт. Ярый әле балалары аның алдында динне хурламады. Бигрәк тә кияве Шамил килеп керер иде дә, ике кулын күтәреп, бабай, йә бер дога, дип, дога кылыр иде. Шул сүзләр

бабасының җанына сары майдай, йомшак песидәй җылы йомгак булып йомарланып кереп ятар иде һәм йөрәген җылытып торыр иде.

Димәк, авылда партком секретаре булып эшләүче кияве чын йөрәктән түгел, динем өчен түгел, көнем өчен дип кенә җыелышларда Алла юк дип сөйли икән. Димәк, өметсез үк түгел.

Инде балалары биш тапкыр намаз укыйлар, кулларыннан Коръән төшми. Әти-әниләре рухына көнгә бишәр тапкыр дога кылалар. Диннең күтәрелүенә, адәмнәрнең йөрәгенә миһербанлык кайтуына, авыл өстендә азан тавышы яңгыравына сөенәләр. Әти-әниләре бу хәлләрне белеп ятадыр, иншалла, шулайдыр. Шулай гына булсын!

Аптырап ята торгач, Нурания карчыкның башыннан ниндидер үкенечле уй үтте. Тукта, төп нигезгә барып дога кылмаганга да шактый вакыт узган! Дөнья хәлләре белән матавыкланып, төп йорт онытылып киткән. Инде үзенең йорты да балалары өчен төп нигезгә әйләнгән шул. Алар карты – алтмыш дүрт яше тулганчы ук гүр иясе булган Шамил Муратов белән биш бала тәрбияләп үстерделәр. Ул биш бала, башлы-күзле булып, унга әйләнделәр. Аларның балалары туып, утызлап булдылар. Нурания, гомере буе балалар укытып пенсиягә чыгып, оныклар үстерергә булышты. Алар да башлы-күзле булдылар, балалары туды. Шуннан соң Нурания карчык аларны санаганда бутала ук башлады. Бик зурайды бу нәсел. Җәй буе ишегалды тулы бала-чага, капка төбе әллә ниткән, моңарчы күз күрмәгән машиналардан бушамады. Мәшәкатьләр баштан ашты.

Нурания карчык, ыңгырашып, урыныннан кузгалды. Тәһарәт алып, иртәнге намазын укыды, озак итеп әрвахларга дога кылды. Кече як тәрәзәсеннән урамга күз салса, буран басылган, аксылланып, караңгылыкны ярып, саркылып кына таң беленеп килә иде. Яктыргач, энесе Җәүдәт, килене Халисәләргә барып – төп нигездә шулар калган иде – бөтен шартын туры китереп дога кылып, ясин укып кайтырга ниятләп, чәен куеп җибәрде. Тиздән, күңелләрне күтәреп, самавыры җырлый башлады. Төнге караңгы уйлары таралган кебек булды.

Ә төшке аш вакыты җиткәндә, Алансу авылының кибет урамыннан, буран күмеп киткән юлны ярып, сумкасына Җәүдәтнең оныклары Ришат белән Зөлфәткә күчтәнәчләрен салып, йомшак мамык шәл бөркәнгән, затлы чәшке тун кигән Нурания карчык төп йортка, әти-әнисе нигезенә таба атлады.

– Бисмилләһир рахмән ир-рахим, әгузе билләһи минәшшайтанир-раҗим. Хәерле сәфәр!

Килене Халисә шау-гөр килеп каршы алды, куанды, сөенде:

– И апай, ничекләр киләсе иттең? Менә килен эштән кайтышка пилмән пешергән идем. Бәхетле авыз икәнсең! – дип мәш килде. Халисә каенана гел килене яраткан ашларны гына пешерә иде.

Бигрәк уңды шул энесе Җәүдәт хатыныннан! Ул авылның иң уңган, иң акыллы килене булды. Авылда каенаналар:

– Их, Халисә кебек киленең булса иде, – дип кызыкты.

Кызлы әниләр кызларына:

– Аллаһ безгә Җәүдәт кебек ир-егет бирсә иде, – дип, теләк теләде.

Төп йорт, төп нигез кырмыска оясы кебек кайнап торды. Ерак

туганнарның балаларының балаларын чын күңелдән сөенеп каршы алды килен. Алар барысы да, Халисә киленне яратып, «туган апа» дип өзелеп тордылар. Кучтәнәчләрдән, бүләкләрдән өзмәделәр. Шулай итеп, Җәүдәт белән Халисә Котдус картның, Габделхәй бабайның тормыш кагыйдәләрен сакладылар. Сабантуй мәйданыннан туган-тумачаны барлап җыйдылар, табын кордылар. Ә кичен Сабантуй хөрмәтенә «бисмилла» әйтеп чалынган сарык ите пеште, тавык тутырылды. Өчпочмагы, бәлеше, тагын әллә ниләр... Бер-берсен моңарчы күрмәгән, белмәгән туган-тумачалар шунда танышты. Үзләренең Котдуслар нәселеннән булуларын белеп сөенеште. Соңыннан бер-берсе белән йөрешә башладылар һәм икенче Сабантуйга тагын да ишәеп, яшьләре кияүгә чыгып, өйләнешеп, яңа кода-кодагыйлар артып, балалары да үзләрен Котдусларныкы дип санап, Алансуга кайтып бәйрәм иттеләр. Бакча тутырып безелдәшкән бал кортлары кунакларга кучтәнәчкә бал җыйдылар. Габделхәй бабайның яшьтие карт шомырт, Сабантуй саен ап-ак ефәк шәлен ябынып, туганнарны каршылады.

Котдусныкылар булу – мәртәбә! Бу – затлы нәсел. Бу нәселдән кыз алу – горурлык. Шуңа күрә Җәүдәткә кыз сорап Күкчәгә менгән башкода Шамил Муратовка кызның әтисе Гаялетдин:

– Кызым май кайнаган сәгатьтә туган икән – Габделхәй малаеннан башкода килде, - дип сөенде.

Кызын Алансуга озатканда, әти кеше кызын кисәтте:

– Кодалар шәп, егет шәп, әгәр берәр начар хәбәрең килсә, матри, кыз!

Юк, кодалар кызны үз кызлары кебек күрделәр – килен инде Котдусныкы иде. Кыз аш булды да таш булды. Җәүдәт кебек ир авылында түгел, дөньясында да юк иде. Авылда ничә шофёр булса да, аның шикелле игелеклесе булмады. Төнлә берәрсенең хатыны балага авырса, берәрсен йөрәк өянәге тотса, кемгә печән алып кайтырга кирәк булса, төп нигезнең, Җәүдәтләрнең ишеген кактылар, ул каршы килмәде. Эше өчен хак алмады. Әчегән бал, аракы салып карадылар, эчмәде. Ул чын ир-егет иде. Ул Котдусныкы иде. Машинасының тавышын Балыклы авылын чыгып, зират янына җитә башлауга, Халисәсе әллә кайдан ишетеп танып ала иде.

– Әнә «хәзинәм» кайтып килә, – дип, йөгереп каршы чыкты, тиз арада чәен куйды. Гөрләшеп яшәделәр.

Габделхәй карт Җәүдәтенең кулында тынычлап җан бирде, чөнки төп нигездә төпле, ышанычлы улы Җәүдәт белән Халисә калдылар. Хәләле дөньядан киткәч, Маһруйбикә карчык тагын егерме ел яшәп, туксан ике яшендә дөнья куйды. Алар районда бер килен белән каенана булып яшәделәр. Каенана өчен киленнән дә уңган-булган кеше юк иде. Кызлары янына барса да, кунасы итмәде, килене Халисә янына, оныклары Шәүкәт белән Хәдичә янына ашыкты.

Гомер уза торды. Җәүдәтнең эшчәнлеге югары бәяләнде – икенче дәрәҗә Хезмәт даны ордены белән бүләкләнде, егерме җиденче съезд делегаты булып сайланды.

Төп йортка яшь килен төште, онык Хәдичә кияүгә китте. Котдусныкылар ишәйде. Төп йорт искереп, яңа йорт салырга вакыт җитте. Ләкин нигәдер яңа йортны ул нигезгә саласы итмәделәр, күршедәге ташландык нигезгә

салдылар. Яңа йорт ташпулат иде. Ташпулат алдында бәрәкәтле иске йорт мескенләнеп, кечерәеп, инде яшен яшәп бетергән йөз яшьлек карт кебек, җиргә сеңеп калгандай булды. Ләкин әле тәрәзәләрендә кичләрен ут яна. Җәүдәт белән Халисә төп нигезне ташлап бетермәделәр.

Шушы төп нигезгә ясин уку иде Нурания карчыкның нияте. Теләге изге. Төшендә Габделхәй карт кызын нигезенә ат җигеп китереп куйган иде.

– Кызым, төп нигезне онытма, – дип әйткән кебек иде төшендә.

Ләкин Халисә килен:

– Әй апай, килгән-килгән, әйдә, яңа нигезгә дә кереп, ясин укып кит инде, – дип каударланды. Йөгерә-йөгерә, күршедә яшәүче Габделхәй картның икенче кызы Фәүзияне алып чыктылар, туганнары Рәфикъ хатыны Мөршидәне җилтерәтеп алып килделәр. Пилмәннәрен, тәм-томнарын күтәреп, яңа нигезгә ясин укып дога кылырга кереп киттеләр.

Аягы тартмаган иде Нурания карчыкның, әтиләре риза булмас кебек иде.

Шәп иде яңа йорт. Сагыз исе аңкып торган, буялмаган идән. Ул байлык, ул чисталык!

Нурания карчык, итегеннән төшеп эрегән кардан ап-ак нарат идәнгә җыелган суны күреп уңайсызланып, итеген салу нияте белән кече якка чыгып китте һәм, кунаклар күпме генә көтсәләр дә, кире әйләнеп кермәде. Ярты сәгатьтән биш кабыргасы, аяк бармаклары сынган Нуранияне салган машина Теләче хастаханәсенә элдерә иде...

Бигрәк тирән – өч метр тирәнлектә цементлап катырылган иде шул җилләтергә дип ачып куелган яңа нигезнең идән асты.

* * *

Акрынлап Яңа ел якынлашты. Балалары белән бергә җыелышып, гөрләшеп, Яңа елны каршыладылар. Бәхетле иде ак әби. Аның әле, Җидегән йолдыз кебек, җиде туганы да исән иде. Иде...

Өченче гыйнвар көнне Җидегән йолдызның нәкъ уртасындагы йолдызлар – Җәүдәт белән Халисә – фаҗигале рәвештә вафат булдылар. Халисә киленнең:

– Йа Аллам, безне бер-беребездән аерма! – дип сораганнарын ишеттеме әллә Тәңрем?

Бу юлы төп нигезнең капкасын соңгы тапкыр каерып ачып куйдылар. Ыңгырашып ачылды күпне күргән капка. Авылдан бәхет эзләп читкә чыгып киткән, ә картаймыш көннәрендә газиз җаннарын туган туфракка тапшырырга дип кайткан, нәсел-нәсәбәләре киселгән күпме авылдашларын озатып калырга дип ачыла иде бит ул! Җаннары таш булып каткан авылдашларының күңелен Җәүдәт белән Халисә җиңгәнең кайнар шулпасы, җылы сүзе эретә иде.

– Йа Алла, бар бит җирдә игелекле җаннар, Ходай сезгә озын гомер бирсен, хәвеф-хәтәр күрсәтмәсен! – дип тели иде Алансу халкы.

Өченче гыйнвар көнне Алансу һәм Күкчә халкы аһ итте. Гомер буе иген иккән, хезмәт сөючән бу ике җан, беркем белән дә бәхилләшмичә, хушлашмыйча, бакый дөньяга күчтеләр. Имәндәй ирләр сыгылып елады. Нигезгә барлык нәсел-нәсәбәт җыелды. Ишегалды елап шешенеп беткән

халык ташкыны белән тулды. Оныклары нәни Зөлфәт, рәттән куелган ике җеназа тирәсендә тезләнеп, төн буе дәү әтисе белән дәү әнисенең нигәдер салкын, сары йөзләрен нәни куллары белән сыпырып, куеннарына кереп ятасы итте. Ләкин әллә нинди усал әбиләр җибәрмәделәр. Нигәдер барысы да еладылар. Зөлфәт шул көнне «олыгайды», ул үлемнең нәрсә икәнен аңлады. Үлем ул салкын шомлы тынлык икән, әбиләрнең Зөлфәт белмәгән телдә нәрсәдер укулары икән. Үлем ул дәү әнисенең, иртән торып:

– Улым, тор, әчегән сөткә болгатып, син яраткан төче коймак пешердем, – дип әйтмәве икән.

Үлем ул дәү әтисенең, зур машинасына утыртып, Шәкүр карак елгасына печән әйләндерергә алып бармавы икән.

Үлем ул дәү әтисез, дәү әнисез салкын өйгә кайтып керү икән.

Дәү әтисез, дәү әнисез тормыш үзе бер нәүмизлек икән. Тормыш аяусыз икән. Үлем бар икән.

Җеназа артыннан капка шыгырдап ябылды.

Халисә җиңгәнең өстенә ябылган кызыл чыбылдыкның бер почмагы, каерылган яралы каз канаты кебек салынып төшеп, җилдә кагына кебек иде.

– Мәңгегә хушыгыз, онытмагыз безне, туганнар, догагыздан калдырмагыз!

Инде алты туган, намазлык өстенә басып, әти-әнисе, әби-бабасы һәм араларыннан шулай фаҗигале төстә иртә китеп барган туганнары рухына багышлап дога кылалар.

– Урыныгыз җәннәттә, каберләрегез нурлы булсын! Иншалла, сез җәннәттә булырсыз, сезнең артыгызда дога кылучы игелекле дәвамчыларыгыз бар!

Сезнең артта картайган, карт игенченең буын-буын куллары кебек кара ботакларын селкеп, нәүмизләнеп, каршыдагы ике болдырлы йорт тәрәзәсендә ут кабынуын өмет итеп, ялгыз карт шомырт басып калды.

Картайган капка инде читтән туганнарын күмәргә кайткан авылдашларын каршы алырга ыңгырашып, шыгырдап башка ачылмады. Җәүдәт белән Халисә җиңгә артыннан ул бөтенләйгә ябылды.

* * *

Рамил, иртәнге әтәчләр белән бергә уянып, ишегалларын, капка төпләрен ялт иттереп себереп керде. Ишегалларында яшел хәтфәдәй җәелеп үскән яшел чирәм үзенең элеккеге җете яшел төсен югалта төшкән.

Әбиләр чуагы! Әле атна-ун көн элек кенә биш баласы, кияү-киленнәре кайтып бәрәңге сабагын чабып киттеләр. Әнә ул карасу-яшькелт бәрәңге сабаклары читән башларына эленеп куелган. Алардан башларны әйләндерерлек бәрәңге сабагы, көз исе килә.

Туган якларыннан аерылып, күкне канатлары белән кисә-кисә җылы якка торналар китеп барган һавадан да бәрәңге сабагы исе килә. Урала-урала, битләргә тоҗымнар чорнала. Тып-тын. Көлдә пешкән бәрәңге исе, бәрәңге сабагы исе белән кушылып, Рамилнең хәтерен сискәндереп уятты.

Симәнә бәрәңге орлыгын Наһарлар алып чыгып киткәч, әнисе

Фәхринурның кысыр калган бакчага чыгып үкси-үкси елаган чаклары, мәрхүм әтисе ясап калдырган күкени бавын кисеп алып сыерларының мөгезенә бәйләп алып чыкканда, ияләшкән абзарыннан китәсе килмичә тарткалашкан сыерның моңсу рәнҗешле караҗимештәй күзләре, әнисенең илереп-илереп елавы Рамилнең күз алдыннан узды.

Һәм ачлык. Тамак һәрдаим ашарга сорап тора. Әнисе, түбәнөйдән өч бәрәңге алып менеп, аны мич авызына гына пешерергә куя. Ләкин үсә торган малайларга нәрсә инде ул бер бәрәңге, тел очына гына тия?! Тамакларын алдарга гына ярый. Энесенең зәңгәрсуланып, тире белән сөяккә генә калган йөзе. Куе керфекләр белән уратып алынган, эчкә баткан зур күзләре. Әнә ул күзләр, тәрәзә бозын эретеп ясаган түгәрәкләрдән карап, абыйсы Рамилнең хәер сорашып, кайсы булса да авылдан кайтканын көтәләр һәм, абыйсы кайтып кергәч, комсызланып, әнисе тегеп Рамилнең муенына аскан капчыкка текәлеп, аннан берәр кисәк ипи катысы чыкмасмы дип тилмереп карыйлар.

Салам ягып кына җылытылган иске өйдә җылы тормый. Ачлык һәм үзәккә үтәрдәй салкын. Рамилнең бала чагы шулай үтте.

Әнисе Фәхринур сукыр лампа яктысында, иске киемнәрен ямый-ямый, төннәр буе елый. Сизрәп беткән иске киемнәр икенче көнне үк ямау кырыеннан янәдән тишелеп чыгалар.

– Әй әни, менә үсим генә әле, сиңа матур киемнәр генә кидерермен. Итле аш кына ашап торырсың, әни җаным. Сине гомерем буе гел яратып, кадерләп кенә торырмын, – дип, ант итә иде Рамил.

Инде ул газаплы еллар артта калганга да никадәр вакыт үтте! Рамил, өйләнеп, ташпулат сыман зур йорт салып керде. Биш баласы үсеп җитеп башлы-күзле булдылар да, кошлар кебек, туган нигезләреннән чыгып китеп, үз ояларын кордылар. Фәхринур, тук, җитешле тормышта калган гомерен яшәп бетереп, улы Рамиленә хәер-фатихасын биреп, бу дөньяны калдырып, ире Фәйзрахман янына күчте.

Рәхәттә, муллыкта яшәп тә үтә икән ул гомерләр. Рамилнең бала чагындагы кебек, интегеп, газапланып, бер телем икмәккә тилмереп тә уза икән.

Менә шундый уйлар уятты Рамилнең башында бакчадагы читәннәргә эленгән бәрәңге сабагы исе, көз исе, муллык исе.

Бүген шимбә. Тиздән капка төбен тутырып машиналар кайтыр. Беләкләрендә көч ташып торган яшь ир-егетләр ике-өч сәгатьтә бәрәңге бакчасын актарып атарлар. Көлешә-көлешә, барысы бергә җыелышып бәрәңге алырлар. Быел бәрәңге уңышы мул. Әнә күршеләрнең бакчасында казып аткан бәләк-бәләк бәрәңгеләр агарып яталар. Җир өсте ап-ак.

Эшләре беткәч, ак мунчага кереп, тирләп-пешеп, арасына мәтрүшкәләр кыстырып бәйләгән каен себеркесе белән чабынып алгач, тавык шулпасы ашап, әниләре пешереп куйган гөбәдия, чәкчәк белән чәй эчәрләр. Ашарга нәзберек ул-кызларын ашата алмыйча интегеп бетәрләр.

Рамилнең бик әйтәсе килә, нәрсәгә дип кыстый-кыстый ашатасыз ул балаларыгызны, болай да аклары – ак, кызыллары – кызыл, исән-сау, сәламәт балалар. Ашыйсылары килсә, үзләре үк сорап ашый алар. Тик дәшми. Үз уйларына батып, өй тулы балаларына, кияү-киленнәренә,

оныкларына карап уйланып утыра. Аллага мең шөкер, ачлык юк, сугыш юк. Әнә балаларының һәрберсе үз машинасына төялешеп кайталар, калада үз фатирларында рәхәтләнеп яшиләр. Барысы да Рамилнең үзе кебек тырыш, булдыклы булып үстеләр, җимертеп эшләделәр, малын таптылар. Әти-әниләрен хөрмәтләп, матур итеп яши беләләр.

Үзенең бала чагы, ачлык турында сөйли башласа, онындары:

– Дәү әти, нигә кибеткә барып ипи алып кайтмадың соң? Колбаса да алырга була иде бит, – диләр.

Рамил дәшми, оныкларының кәефен бозасы килми. Белмәсеннәр, ачлыкны да, кимсетүләрне дә күрмәсеннәр оныклары, туруннары. Әти-әниләре янында җитешле, тук тормышта яшәсеннәр, тик иманлы булсыннар, дип, балаларын озатып кала.

* * *

Григорий – Мәскәү үзәгендәге дүрт бүлмәле фатирда яшәп ятучы карт академик – кыңгырау тавышын ишетеп, акрын гына килеп, авыр имән ишекне ачты да, аптырап, килүченең йөзенә текәлде.

– Вы ко мне? Проходите.

Затлы киемнәр кигән, кулына чын күннән эшләнгән кара портфель тоткан, күзлекле, мәһабәт гәүдәле, кара күзле ир-егет:

– Да, скорее всего, я к вам, я из Казани, – диде.

– Пройдёмте в кабинет, – дип, академик ир-егетне үз бүлмәсенә чакырды. Җиңелчә гәүдәле, өстенә җылы халат, аягына йомшак башмаклар кигән ап-ак чәчле карт кабинетына иң башта килгән ир-атны үткәреп җибәрде, аннан соң гына үзе узды.

– Садитесь, – дип, азрак кыршыла төшкән кара күн кәнәфигә төртеп күрсәтте. Үзе имән агачыннан кырый-кырыйларын затлы итеп уеп эшләгән язу өстәле артына үтте. Җайлап кына урнашкач, алтын кысалы күзлеген салып, озак кына итеп ят ир-атка карап торды да: – Ну-с, я вас внимательно слушаю, – дип, картлыктан төсе уңган коңгырт күзләрен кыса төшеп, тынып калды.

Керүче дә, ничектер уңайсызланып, җавап бирмичә тын гына торганнан соң сүзен дәвам итте, сөйләшүләре рус телендә барды:

– Алдан әйтүемчә мин Казаннан, – дип кабатлап, картка текәлде.

Карт әллә ничек кенә, әллә ир-атка гына шулай тоелдымы, сискәнеп киткән сыман булды.

– Әйе, мин ул шәһәрне бик яхшы беләм. Анда бит татарлар күп яши. Сез дә татардыр әле. Казанга командировкаларга еш барам. Сезне күрүгә үк рус кешесе булмавыгызны аңладым. Мин үзем тарихчы. Төрле милләт кешеләренең бер-берсеннән аерылып торганын беләм.

– Сезнең исемегез Гәрәй Мифтахетдинович бит?

Картның йөзе агарып китте. Башын аска иеп, чигәләрен уып озак утырды. Әйтерсең каршысындагы кеше турында бөтенләй онытканиде. Әллә йоклап китте инде, дип уйлап куйды ир-ат.

– Әйе, Гәрәй, ә әтиемнең исемен белмим. Үзем Григорий исеме белән үстем. Үстергән әтием – Матвей Сергеевич – күптән мәрхүм. Чын әти-әниемнең татарлар икәнен белеп үстем. Шул каһәрләнгән еллардан еракка

китеп баручы поезд һәм тәгәрмәч тавышлары гына истә калган. Күз алдымда поезд тәрәзәсеннән карап калган кечкенә кызны да хәтерлим. Ул: «Гә-р-ә-й-й» – дип кычкыра иде. Шуннан соң әти мине Мәскәүгә алып килде. Әмма мин гомерем буе үземнең чын әти-әниемнең кем икәнен беләсем килеп яшәдем.

– Мин шул поездда елап китеп барган кызның оныгы. Аның исеме – Факиһә иде, ул сезнең апагыз. Быел ул бакыйлыкка күчте. Гомере буе сезне сөйләде. Сезне эзләде, төшләрендә күрә иде. Исәнлегегезгә ышанды. Бик озак эзләдек сезне.

Карт калтырана-калтырана урыныннан торды да ирнең янына ук килеп басты. Аннан соң кечкенә урындык алып килеп, каршысына утырды.

– Димәк, сез минем туганым буласызмыни? Ничек таптыгыз мине, барысын да сөйләгез әле? Әти-әниләрем кемнәр?

Шуннан соң торып, шкафтан ниндидер иске папка алды, аннан күн янчык эченнән кара тегәрҗепкә тагылган бармак башы кадәр генә искереп, саргаеп беткән чүпрәк медальон кебек әйберне кадерләп, зур саклык белән акрын гына тартып чыгарды.

– Теге каһәрләнгән вакыттан шушы гына калды, – дип, ир-атка сузды.

Ир-ат академик кулындагы бу биш тиенлек акча зурлыгындагы кара тегәрҗепкә асылган чүпрәк медальон кебек әйбергә текәлеп торганнан соң, Гәрәй-Григорийга әбисенең йөз чалымнарын күрәсе килгәндәй тутырып карады да, картның йөзеннән нидер эзләгәндәй:

– Бу бөти. Минем әбиемнең дә нәкъ шушындый бөтие бар иде. Аның эчендә дога. Әбием үзенең шундый ядкарен кыйммәтле хәзинә итеп саклады. Сезнең әти-әниегез Себердә үлеп калганнар, сез киткәннән соң алар нибары ярты ел гына яшәгән. Әби ятимә булып үскән. Язмышыгыз бик аяныч булган.

Картның җыерчыклы яңаклары буйлап күз яшьләре акты. Ул күзлеген салып, кесәсеннән ап-ак кульяулык чыгарып, яшьләрен сөртте:

– Рәхмәт! Үз тамырларымны таба алмам да инде дип уйлый идем. Илаһыга мең рәхмәт, минем догаларымны ишеткән һәм менә ярдәм итте. Без әти белән ике тапкыр Себердә булдык. Мин Сталин лагерьлары турында фәнни мәкалә дә яздым. Әти андагы тормышның нинди булуы турында бик күп сөйләде. Чын әти-әнием турында гына бер мәгълүмат та таба алмадык. Әниемнең ябык кына хатын икәнлеген хәтерлим. Себердә мин аларны күрмәгәнмен дә инде, алар һәрчак тайгада агач кискән. Әтиемнең үз улы түгеллегемне белеп үстем. Ул миңа шушы медальонны тапшырды да: «Сакла, бу синең мөселман әти-әниләреңнән калган дога», – диде.

Мин аларны бик озак эзләдем, ләкин таба алмадым, шуңа күңелемдә тынгылык булмады, – дип, гафу үтенгәндәй янә кабатлады Гәрәй-Григорий. – Шуннан язмышыма күндем, ә сез таба алгансыз, күпме еллар узган булса да, эзләүдән туктамагансыз!

– Без дә сезне эзләдек бит. Әбием генә сезне күреп өлгермәде, кызганыч. Һәр намазыннан соң ул Аллаһтан сезнең табылуны, исән-сау булуыгызны сорады.

Ир-ат торып басты да карт академикны кочып алды. Картның күкрәгендәге алтын чылбырга аскан тәре тәрәзәдән төшкән сүрән кояш

нурларында ялтырап китте. Гәрәй картның дерелдәп торган гәүдәсе, иратның кочагында эреп, сеңеп бетеп, әйтерсең Себер тайгаларында һәлак булган әти-әнисе Мифтахетдин белән Гөлҗамалның җылысын тоярга тырышкандай калтырана иде.

– Мә, улым, – диде Гәрәй-Григорий, – минем медальонны да ал һәм теге поездда елап китеп барган кызның бөтие янына куй. Алар бергә булсын. Минем апам, синең әбиең Факиһә табылганымны белеп сөенер. Без теге дөньяда табышырбыз, очрашырбыз, әти-әниләребез белән дә сөйләшеп утырырбыз әле, – диде Мифтахетдин белән Гөлҗамалның улы Гәрәй, әти-әнисенең туган якларына кайтып, Чакрактауда, Ялантауда җәй көннәрендә чебен-черкиләрдән куркып битлек кимичә, җиләк, чикләвек җыеп, Мишә суларында коенып, яшь колыннар кебек, хуш исле Кыйгасар болыннарында йөгереп уйнап үсеп һәм, ниһаять, авыз тутырып туйганчы арыш ипие ашар идем дип хыялланып каһәрләнгән Себердән кайтырга чыккан, ләкин язмыш кушуы белән исән калып, Мәскәүгә килеп җиткән Гәрәй-Григорий. Рәхмәт сиңа, Себер җилләрендә дә очып китәрлек өрәк кебек ябык профессор Матвей Сергеевич! Син татарның бер баласын саклап калдың, Гөлҗамал белән Мифтахетдиннең нәселен дәвам иттең. Ул малай мөселман иде, христиан булды, ләкин исән калды. Теге Енисей ярындагы чокырлардагы мәетләрне бүреләр ботарлады, ә Гәрәй-Григорий исән калды!

Гәрәй-Григорий, Мифтахетдин белән Гөлҗамалның нәселен дәвам итеп, Рәсәйнең данлыклы академигы булуга ирешкән. Үзе артыннан шундый дәрәҗәле галимнәр, уллары Константин белән Сергейны калдырып, җир йөзендә җыясы тәгаме беткәч, мәңгелеккә кайтыр, әти-әнисе, апасы Факиһә белән күкләрдә очрашыр. Гөлҗамал, улын күкрәгенә кысып, йөзен күз яшьләренә чылата-чылата сөяр, иркәләр. Гәрәй-Григорий апасына, Факиһәнең өзгәләнә-өзгәләнә ераклаша барган поездның тимерле вагон тәрәзәләреннән кулын сузып, «Гә-рә-ә-й!» дип ачыргаланып кычкырган тавышы йөрәгенә уелып калганнан соң ниләр булганын, ниләр күргәнен, ничек итеп Мәскәү каласында гомер иткәнен сөйләр. Ә алар үзәкләре өзелеп тыңлар... Мәңгелек бар. Адәм баласы җир йөзенә сыналыр өчен килә. Ә анда мәңгелектә кылган гамәлләрең өчен җавап тотасы бар. Ә җир йөзендә яшәүче кеше кыяфәтендәге газраилләргә анда мәңгелек ут булачак. Һәркем үзенә тиешле җәзаны анда алачак. Эшләгән гамәлләреңә күрә анда җавап бирәсе, дип, күңелендә нindидер җиңеллек тоеп, академик белән хушлашты Факиһәнең оныгы.

– Вы, молодой человек, приезжайте ещё. А я расскажу своим сыновьям про вас, общайтесь. Я буду очень рад, если вы будете общаться, – дип озатып калды карт академик.

* * *

– Әни, син йокыңнан тордың, ахрысы, иртәнге ашны әзерләдем, әйдә чәйләп алыйк, – диде кызы Нурания карчыкка, әнисенең икәүләп намаз укый торган өйалды бүлмәсендәге тәрәзәгә күз салып, яңадан урынына барып ятканын күреп. Кояш инде шактый гына күтәрелгән. Өй түрендәге агачта чутылдап сандугач сайраганы ишетелә.

– Көн матур булырга охшап тора, әни, урамда бер җил әсәре юк.

– Бәй, кызым, син ясин укыймыйсыңмыни, минем колагымда синең ясин укыган тавышың ишетелә. Хәзер, укып бетер инде, аннан соң чәйләрбез.

– Юк, әни, минем бүген Коръән укыганым юк әле. Кичкә укырга җыенам. Син авырмыйсыңдыр ич, бер торгач, яңадан барып яттың?

– Юк, кызым, Аллага шөкер, исән-сау йоклап тордым. Кем синең мәкам белән ясин укый икән соң, кызым? Шундый да матур, моңлы итеп укый инде җаным, йөрәкләргә сары майлар булып урала.

Кызы, аптырап, куркынып, әнисенә карап алды.

Шул көннән башлап Нурания карчыкның колагында иртәнең бер вакытында тулы ясин чыктылар. Көн саен, бер көн калмыйча! Кызы укый торган мәкам белән, кызы тавышы белән укыйлар иде. Балалары бу хәлгә аптырады.

– Әни, әйдә докторга барып карыйк. Бу бит дөньяда булмаган хәл. Кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас. Нурания карчыкның башы киткән, диярләр. Докторга күренергә, тикшеренергә кирәк.

– Шундый сүз сөйләгән кешенең үзенең башы дөрес түгел аның, балалар. Димәк, Аллаһы Тәгаләдән миңа хәбәр бу. Җыена башла, Нурания карчык, тиздән җирдә җыясы тәгамеңне җыеп бетерәсең, минем янга кайтыр вакытың җиткән, дип, миңа күкләрдән хәбәр бу, балалар. Инде яхшы гына, сезләргә борчу китермичә генә үз урыныма, әтиегез янына, кызым Рәмзиям янына барып урнашырга язсын! Урын хастасы булып, сезне газаплап ятарга язмасын! Белмисез генә, балалар, кызым белән ярты җаным китте бит минем, яртылаш үлдем бит мин. Кеше якынын югалткач, йөрәгенә кырык бер энә кадалыр икән. Кырык көн үткәндә, адәм шул энәләрнең кырыгыннан арыныр, ә бер энәсе гомерлеккә кадалып калыр да, сулкылдап, сызлап, җанын әрнетеп торыр, үлгәнче, гүргә кергәнче. Аны бары тик баласын югалткан кеше, бигрәк тә ана кеше генә белә ала. Алай дисәң, аталарның да йөрәге шулай ук әрнидер инде ул, тик ирләр йөрәкләрендә саклыйлардыр. Баласын югалткан ата-ана йөрәгендә ул энәләрнең кырык бере дә әрнетеп, сызлап торалар икән ул, кызым. Төннәр буе Рәмзиям белән сөйләшеп ятам. Күз яшемне күрсәтеп, сезне борчыйсым гына килми. Ни өчен, нинди гөнаһларым өчен үземнән алда баламны күмдем? Яшәү дәверендә кыерсытылганнарны яклап, кеше балаларын карап-тәрбияләп, ун ел буе акылыннан киткән каенанамны анамнан артык күреп тәрбияләдем ләбаса. Ә миңа Аллаһы Тәгалә кеше күтәрә алмаслык кайгы бирде. Баласын күмгән ата-ана теге дөньяда тәмуг күрмәс, диләр. Ә мин тәмуг утларында монда янам! Үзем белмичә кылган гөнаһларым өчендер инде. Менә мин, туксанга җиткән карчык, әле һаман яшәп ятам. Ә кызым, оныкларын да күрә алмыйча, кара җир асларына кереп ятты. Берәрсен рәнҗеткән булганмындыр, күрәсең.

– Әй әни җаным, нинди гөнаһлар турында сөйлисең соң син?! Әүлияларга тиң кеше ләбаса син, әни. Алансу халкы арасында бер генә кеше дә синең турыда начар сүз әйтмәс.

– Әгәр кеше артыннан, үлде, җүнле адәм түгел иде, дип әйтерлек булса, яшәп тә торасы юк, кызым. Җирдә яхшы исем, яхшы эз, адәм рәтле балалар калдырып китә алмагач, яшисе дә юк. Әтиегез үзе артыннан әллә ни мал-мөлкәт калдыра алмады. Әмма ләкин нинди балалар калдырып китте! Менә

бу – әтиегезнең җир йөзенә килеп калдырган яхшы исеме, якты эзе! Нәрсә ул дөнья малы? Дуңгыз каны бит ул. Ага да бетә, кызым, ага да бетә.

– Әни, Алансу авылы хатыннары балаларын беренче класска сиңа бирергә атлыгып торалар иде бит, әйеме? Аллага шөкер, улым, кызым Нурания сыйныфына бара, яхшы тәрбия, аң-белем биреп чыгара инде ул балама, дип сөенәләр иде. Хәтерлисеңме син шул көннәрне, хәтерлисеңме, әни?

– Хәтерләмәгән кая. Класска килгән нарасыйларымны нәни кулларыннан тотып язарга өйрәттем. Өлкән класс укытучылары, башлангычтан быел Нурания апа сыйныфы килә, тәртипле, белемле балалар килә, дип сөенеп торалар иде. Эшләгән бар эшемне җиренә җиткереп эшләдем. Тик мәктәп директоры гына бәйләнеп үзәгемә үтте. Укыту дәверендә үземә, сезгә бәйләнеп җанга тиде. Шамил абый балаларына билгене чамалап куегыз, дип, укытучыларга һәрдаим әйтеп килде. Нинди үче булгандыр бездә, белмим. Әтиегез туры сүзле иде бит, тыныша алмадылар. Шуның шаукымы тигәндер, күрәсең. Ярар, анысын Аллаһ кулына калдырыйк, мин кичердем. Тик шунысы җанымны тырмап, яралап тора, бер генә дә исемнән чыкмый. Әтиегез бу якты дөньяларны ташлап киткәч, укытучыларны җыеп: «Кем дә кем дәресне өзеп Шамил аганы озатырга бара, шуның җәйге ялыннан бер көнен кисеп алам. Әгәр барсагыз, миннән пощады көтмәгез», – дигән. Әтиегезне озатырга баҗасы Мәгъсүм Хисмәтов белән укучысы Наил Хәсәнов килделәр.

– Әйе, әни, мин бу көннәрне яхшы хәтерлим. Мәгъсүм җизни килеп бу хәбәрне әйткәч, чоланга чыгып үксеп-үксеп елаган идең. Ләкин каргамадың, рәнҗедең генә. Әти сугышта башыннан ахырына кадәр катнашып, сугыш беткәч тагын ике ел җимереклекләрне төзәтеп йөргән кеше ләбаса.

– Каһәр төшкән сугыш, әтиегез югары белем ала алмый калды шул. Яшь гомере сугыш кырында үтте. Әгәр югары белем алган булса, кем генә булмас иде. Зирәк кеше иде мәрхүм, юмарт кеше иде. Икәүләшеп читтән торып югары белем алырбыз дип хыялланган идек, булмады. Тупырдашып биш бала тудыгыз, Аллаһка рәхмәт. Исән-сау, тәрбияле, эш сөючән булып үстегез. Аннан соң Фәгыйлә әбиегез бөтенләй хәтерен югалтты. Кая анда уку кайгысы?! Аннан әтиегез авырып китте. Ә сез – бишәү! Бишегезгә дә белем бирергә, бишегезне дә олы юлга чыгарырга кирәк.

Шулай, кызым, әтиеңнең җәсәден зиратка күтәреп барганда, укытучылар, күз яшьләрен сөртә-сөртә, дәресләрен дә өзеп тормыйча, тәрәзәдән карап калдылар. Шул мәктәпне төзегән, гомере буе шунда укыткан, ут эчендә бар булган сәламәтлеген бетереп кайткан сугыш ветеранын шулай мыскыл итеп озатты мәктәп директоры. Әтиеңне озатканда, мәктәптә дәресләрне дә өзеп тормадылар. Алансу авылы укытучылары: «Шамил ага, синең рухыңа дога кылыр өчен биш балаң, тугыз оныгың кала. Син гомереңне юкка сарыф итмәдең. Матур итеп яшәп, безне ташлап китеп барышың. Бәхил бул, Шамил ага!» – дип, тәрәзәдән карап, күз яшьләренә коенып, үзләре белән бергә укыткан хезмәттәшен озатып калдылар. Укучылары утырткан каеннар да: «Шамил ага, яз җиткәч кенә, безнең бөреләребезгә яшәү суты тулып шартларга җыенгач кына,

әле алтмыш дүрт яшең дә тулмаган килеш кайларга гына китеп барасың соң син? Күр әле син, сине озатырга күпме укучыларың, туганнарың, балаларың, оныкларың җыелган! Кояшы да бүген шундый да җете булып, синең үзеңнең күңелең шикелле якты булып чыкты. Урының җәннәттә булсын, Шамил ага, бер килгән, бер китәсе», – дип озатты әтиеңне. – Тагын бер үзәгемне өзгән вакыйга җаныма уелып калды, кызым, монысын мәңге оныта алмам, мәңге! Кызым Рәмзиямне, балага авыргач, бүлнискә мәктәпнең йөк машинасына утыртып озатып җибәрдем. Ул чакта хәзерге кебек өй саен җиңел машина юк иде. Балакаемны көчкә машина әрҗәсенә күтәреп салдылар, көчкә! Авыртуга түзә алмыйча, иреннәрен канатканчы тешләп ухылдый балам. Әле шактый гына мәктәп директорының өеннән чыкканын көтеп тилмердек. Озакка киткәч, ишекләрен шакыдым. «Сез тизрәк җыенып чыга алмассызмы, кызым балага авырый», – дидем. «Вакыты җиткәч чыгармын. Барлык хатыннар да баланы бертөсле таба, синеке генә башкача тапмас», – дип, тагын да озак вакыт чыкмыйча торды. Әй кызым, йөрәгемнән каннар тамды инде шул чакта! – Нурания карчык, кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып, күзләрен сөртеп алды. – Аннан соң чыкты да кабинага кереп утырды. Аңа ул вакытта нибары кырык биш яшь иде. Үзе укыткан укучысы йөк машинасы әрҗәсендә, балага авырып, дөньяга кеше тудырырга азапланып барганда, бу кабинага кереп утырды! Аның барасы юлы да хәзерге кебек асфальт юл түгел бит әле. Балаларга үзе тәрбия бирергә тиешле кеше шундый буламы? Укытучы бар кешегә дә үрнәк булырга тиеш. Үзең тәртипле, әдәпле булмыйча, ничек итеп кеше тәрбияләп булсын ди?

– Әни, әни, син бүген әллә нинди әле, үткәннәрне искә төшереп, йөрәгеңне бозып утырмасана. Үткән эшкә салават, диләр.

– Анысы шулай инде, кызым. Мин үзем бик бәхетле! Рәхмәт сезгә, барыгызга да рәхмәтемнең чиге юк! Матур тормыш кордыгыз, аерылышып, бозылышып, минем йөрәгемне бозмадыгыз. Үзегезне дә балаларыгыз мине тәрбияләгән кебек тәрбияләсеннәр!

– Әни, ниләр генә сөйлисең соң син бүген? Хушлашкан кебек сөйләшәсең. Әйдә, рәхәтләнеп серләшә-серләшә чәйләп алыйк әле. Матур җәй айларында рәхәтләнеп сеңлең Сания апа, Фәүзия сеңлең белән Алансуда туган нигезеңдә яшәргә насыйп булсын! Син бит кыш буе, кайчан язлар җитәр дә, тупырдашып балаларым үскән туган нигезгә кайтырмын, дип тилмереп көтәсең. Тик безне борчымас өчен генә бер сүз дә дәшмисең.

Алар шул ук көнне Казанга барырга булдылар.

...Төнге сәгать икеләр тирәсендә Нурания карчык кызы Раушанияне йокысыннан уятты. Төнге йокы күлмәгеннән генә тәрәзә каршына килеп басты да күзләрен кулы белән каплады.

– Кызым, уян әле, шундый матурлыкны күрми каласың лабаса. Әнә күр, теге ерак тәрәзәдән минем йөземә җиде төрле нур килә, шундый да якты нурлар инде. Гомеремдә андый яктылыкны күргәнем юк иде. Шул нурлар йөземне җылыта, шундый рәхәт, кызым! Әйдә, син дә күреп кал.

– Әни, ни сөйлисең? Ул тәрәзәдә тычкан уты кадәр генә ут яна. Берәрсенең авыруы, йә кечкенә баласы бардыр. Бернинди нур юк, синең күзеңә генә күренә. Әйдә, ятыйк инде, иртән иртүк торасы бар, ятыйк.

Нурания карчык ул күргән нурны кызының күрмәвенә аптырап урынына барып ятты да «Аятел Көрси» догасын укыды:

– Аллаһу лә иллә һү...

Иртән иртүк торып чәйләр эчкәч, кызына:

– Кызым, абыеңа шалтырат, бүген минем аларга мунчага барасым килә, мунча ягып җибәрсен дә мине килеп алсын. Дүртегездә дә торып чыктым, инде абыеңа барасым килә. Безгә килмәде дип хәтере калмасын.

– Ярар, әни, хәзер шалтыратам. Әгәр өйдә булсалар, мунча ягар, барасың килгәч килеп алыр.

– Апаңа да шалтырат, ул нигә миңа әйтмичә Чехиягә китәргә җыена икән? Бу нинди тузга язмаган эш? Хәзер үк җыеп бир әле апаңны! Ничек инде капылт кына чыгып китәсе иткән? Гел юлда йөреп торасыз инде. Сез кайтканчы йөрәк тыныч түгел, хәвеф-хәтәрдән Аллаһ сакласын!

Раушания тиз генә апасының телефонын җыеп әнисенә сузды.

– Әлү, кызым, нихәлләрдә сез? Ирең, балаларың, оныкларың авырмыйлармы? Кызым, син чит илгә чыгып китәргә җыенасың икән, никтер миңа әйтеп торасы итмәгәнсең. Ничекләр генә көтеп җиткерим сине, ничекләр генә көтеп алыйм?

– Әни, әгәр, китмә, дисәң, китмим. Алдан әйтеп куйсам, кан басымың күтәрелер дип курыктым, шуңа гына әйтмәдем. Барыбыз өчен дә кайгырып, төн йокыларыңны калдырасың бит.

– Юк, кызым, минем өчен генә барасы юлларыңа бармый калма, Алла теләсә, күрешербез әле. Исән-имин барып кайтырга язсын!

Олы улы Дамирга барып җитеп, өйлә намазын укыганнан соң, озаклап сөйләшеп утырды Нурания карчык. Инде шактый еллар элек катыланган колагы чебен очкан тавышны да ишетә иде. Узган гомерен, әби-бабаларын, ире Шамилне яратып искә алдылар.

Аннан балачакта үзе карап үстергән сиксән биш яшьлек Сания сеңлесе белән озак итеп телефоннан сөйләште:

– Сания, ничек яшәп ятасың, кызың, оныкларың исәннәрме? Мин менә улыма, Дамирыма килдем әле. Балаларымның барысын да йөреп чыктым, инде менә Дамирыма мунчага килдем. Әй бәхетле дә яшәдем соң, Сания! Балаларыма зур рәхмәтем! Әүвәлге авырлыклар үттеләр дә киттеләр. Бүгенге көнем, әлхәмдулиллаһи, Аллаһыма рәхмәт.

– Апа, апа, – ди Сания, – кара ничек ачык ишетәсең. Быел Алансуда рәхәтләнеп яшәрбез әле. Тагын бергә Алансуда җәйләрбез, Алла кушса. Дөньясы бик матур, бик рәхәт бит, апа! Бергәләп матур итеп яшик әле. Без синең белән ачлыгын да күрдек, ялангачлыгын да. Хәзерге көнебез бик рәхәт.

– Ярар, Сания, икенде җитте, намазга соңга калмыйк.

Нурания карчык икенде намазын укырга кереп китте дә, балалары күпме генә көтмәсен, әйләнеп кире чыкмады. Улы, акрын гына ишек шакып, әнисе янына хәл белергә керсә, әнисе, намазлыгы өстенә ятып, сәҗдәгә киткән дә шунда мәңгелеккә күзләрен йомган иде.

Март аеның егерме тугызы. Нурания карчык хәләле Шамил, кызы Рәмзия кебек, март аенда – табигать уянганда, агач бөреләренә яшәү суты тулып шартлап ачылырга торганда – балаларының барысы белән дә

хушлашкан кебек сөйләшеп, бер кешене дә мәшәкатьләмичә, мунчалар кереп, тәһарәтләнеп, сафланып, бу дөньядагы соңгы намазын укып, фани дөньяны ташлап китте. Гомере буе Аллаһыдан: «Йа Раббым, тыелганнардан тыелып яшәргә насыйп итсәң иде, кеше кулларына калдырмасаң иде!» – дип теләгәннәре кабул булды ак әбинең. Туксан яшь туларга бары өч ай калган иде. Бер атна элек кенә Шамилнең вафатына утыз ел үткәненә зурлап Коръән ашы үткәргәннәр иде.

Улы чакырып китергән «ашыгыч ярдәм» машинасы докторы мөселман кешесе булып чыкты. Әбинең елый-елый шешенеп беткән балаларын, оныкларын күреп:

– Ник елашасыз, еламагыз, әле минем туксанга җитеп намазлыкка ятып сәҗдәгә китеп үлгән мөселманны күргәнем юк иде. Миңа андыйларның туры килгәне булмады, – дип кабатлады. – Нинди бәхетле әби! Күрәсезме, елмаеп үлгән бит әниегез. Җәннәт кошы инде бу, бер ялгансыз әйтәм. Әбинең соңгы урыны җәннәттә булачак!

Алансуда яңа кабер. Нурания карчыкны кызы Рәмзиясе янына җирләделәр. Март ахыры булса да, көн җилле, салкын, яңгырлы иде. Әллә балаларының хәсрәтенә кушылып, җиһан елый?! Җанга авыр. Әниләрне озату, алардан мәңгелеккә аерылу үзәкләрне өзә. Әни җаным, яшәү дәверендә үзем дә белмичә берәр авыр сүз әйтеп рәнҗетмәдемме икән? Безнең эштән кайтуны тәрәзәдән карап тилмерепләр көткәнсеңдер. Ә без, эш, эш дип, дөнья кудык.

Алай дисәң, үзегез бит безне:

– Тырыш булыгыз, балалар! Тырышкан тапкан, ташка кадак каккан, – дип өйрәтеп үстердең. – Сез Алансуның ике уңган, иң булган, бер-берсе белән ярыша-ярыша, бер-берсеннән ак көнләшү белән көнләшеп яшәүче нәсел дәвамчылары. Инде тузгытылган, тар-мар ителгән ике нәсел – Котдуслар һәм Хәбибуллаларның – якты исемнәренә хыянәт итәргә, тап төшерергә хакыгыз юк, – дип тәрбияләдегез.

Инде менә киттең. Рәнҗеп кенә китә күрмә, әни! Без сезне догабыздан ташламабыз. Биш вакыт намазыбыз артыннан әти-әниебезгә, вакытсыз дөньядан киткән сеңлебез Рәмзиягә, әби-бабаларыбызга җәннәтләребезне насыйп әйлә, дип, һәрдаим догада торырбыз.

Җыелышып әти-әнисез буш нигезгә кайттык. Кыш буе ягылмаган салкын өйдә бушлык. Беркемнең берни турында да сөйләшәсе килми. Әйтерсең, әни белән бергә нигезнең дә җаны чыгып киткән! Инде унбиш еллап кышларын ялгыз гына ямансуланып кала торган, ләкин әле җәй җиткәч кайтырлар, яшәү дәвам итәр, дип, көзләрен сагышланып, кызгылт-сары яфракларын җиргә коя торган, әтиләре Шамилнең урманнан күчереп алып кайтып утырткан имән агачы да моңаеп калган.

– Кая киттең соң син, Нурания карчык? Шундый игелекле балалар үстереп, рәхәткә чыккач кына, безне ташлап кайларга китеп барышың? – дип, имән агачының бөреләре шартлап ачылыр. Келәт почмагында Нурания карчыкның сиксән яшенә кадәр умарта кортларын караганда кия торган, ире Шамилдән калган битлеге нәүмизләнеп эленеп тора.

– Өйдәгез әле, газ мичен ягып җибәрик, өйгә җылы төшсен, – ди абыйлары. – Җаннарыбыз да җылынып китмәсме? Нигезне ташларга

ярамый, югыйсә эти-әниебез, әби-бабаларыбыз рәнҗер! Бер-беребез белән тату, дус булып, һәрдаим ярдәмләшеп яшик, туганнар! Бу безгә эти-әниләрдән, ерак бабаларыбыздан васыять! Безнең мал бүлешеп, ямьсезләнеп яшәргә хакыбыз юк! Ишетәсезме, хакыбыз юк! Әгәр дә без шундый түбәнлеккә төшсәк, алар безне кичермәсләр! Оныкларны да шулай итеп тәрбиялик! Безгә гасырлар аша ерак бабаларыбыз шулай дип дәшә: «Тату яшәгез, балалар, оныклар, туруннар! Татулыкка ни җитә?!» Кыз туганнар, – дип дәвам итә абыйлары, – нигезгә ешрак кайтып йөрергә тырышыгыз, әни сездә яшәде, әнине сез тәрбияләдегез. Рәхмәт сезгә! Шулай килешик, нигез мәңгелек, эти-әниләрне рәнҗетмик!

Әйе, әби-бабаларыбызның, эти-әниләребезнең кан хәтере безгә әллә ничә буыннар аша дәшә:

– Нәселне саклагыз! Нәселне бетермәгез! Бу – безнең сезгә васыятебез.

* * *

2019 елның көзе. Татарстан Республикасы Президенты Миңнеханов Рөстәм Нургали улы безне – төбәк тарихын өйрәнүче илле җиде кешене – Себергә татарлар белән очрашуга юллады.

Көннәр кояшлы, җылы – әбиләр чуагы. Без – бер вагон галимнәр, язучылар, журналистлар, тарихчылар, сәнгать әһелләре. Шулар арасында Котдус улы Габделхәй оныгы – мин дә бар. Бу – мәңге онытылмаслык җылы, барысын да бер уй, бер фикер, бер гамь берләштергән зыялыларның сәяхәте. Ике тәүлек буе бер вагонда гәпләшеп, фикер алышып барабыз. Күбебез – Себергә сөрелгәннәрнең оныклары, туруннары. Сөрелгәннәрнең үзәк өзгеч газаплы тормышлары турында бер-беребезгә сөйлибез. Әңгәмәбез үзебезнең әби-бабаларыбызның күз яшьләренә төрелгән, каһәрләнгән язмышы хакында. Адәм баласының башына да сыймаслык, мәңге онытылмаслык вәхшилекләр турында.

Куылганнардан кемнәрдер, гарипләнеп, өметсезлеккә, төшенкелеккә бирелеп, газизләрен югалтып, илгә кайта алганнар. Ә күбесе – «коммунизм» дигән якты киләчәк төзеп, ач-ялангач килеш интегә-интегә Себердә урман кисүчеләр – шул яктылыкны күрә алмыйча корбан булганнар. Кайда ул «коммунизм» дигән җәннәт кебек якты киләчәк?! Шул «җәннәт»не төзегәндә Себердә корбан булган, газапланып үлгән әби-бабаларыбыз, әни-этиләребез, сез дә юк!

Ул елларны үзәкләрне өзеп искә төшереп, кан саркылып әрнеп торган хәтер бар, йөрәкләрдә сулкылдап торган яра бар! Ярый әле хәтер яши. Әгәр хәтер дә югалса, бу вагонда баручыларның күбесе әби-бабаларының кем икәнен онытса, ни булыр иде?! Үзенең тамырларын белмәгән, оныткан милләт яши алырмы? Юк, әлбәттә. Без яшәргә тиеш! Әби-бабаларыбызның, яши алмыйча сабый вакытларында ук якты дөньяны ташлап киткән туганнарыбызның яшәп бетермәгән гомерләрен дәвам итеп яшәргә тиешбез! Киләчәк буынга алар каһәрләнгән язмышлары турында балаларына, оныкларына сөйләп калдырсын өчен яшәргә тиешбез!

Бер вагонга утырып, Татарстаннан Себергә сәяхәткә мөселман кардәшләр белән очрашуга дип кузгалган фикердәшләрне бер уй, бер гамь берләштергән. Онытмабыз, безнең онытырга хакыбыз юк!

Әгәр милләтебезгә хыянәт итсәк, битараф булсак, гомер тузаннары астында хәтер күмелеп калыр да, без үзебезнең тамырларыбызны, нинди асыл затларның оныклары икәнлегебезне онытырбыз. Әби-бабаларыбызның газиз җаннары безгә рәнҗеп ятар.

Ике тәүлеккә якын Себер ягына таба тукылдап баручы поезддагы оныкларның, туруннарның йөрәкләрендә бер уй:

– Юк, без сезне онытмадык, үзебез исән чакта һичкайчан онытмабыз! Бу турыда балаларыбызга, оныкларыбызга, киләчәк буыннарга тапшырыр өчен, фәнни хезмәтләребездә, әдәби әсәрләребездә язып калдырырбыз.

Без – үзебез хәтер. Без югалмадык. Без – күпме генә юк итәргә тырышсалар да, тамырларыбыз нык булу сәбәпле, шытып чыгып, бәрәкәтле туфракта, кояшның якты нурларында коенып, туган якның назлы җилләрендә иркәләнеп үсеп, киләчәк буынга әби-бабаларыбыз турында сөйләп калдырыр өчен, нәселебезне саклап калыр өчен, калкынып, зур дәрәҗәләр алып, инде үзебез дә өлкән яшькә җиткән оныклар, туруннар! Без исән булганда, хәтер исән булыр! Хәтер булганда, халкыбыз исән булыр!

Поезд тайга эченә килеп керде. Вагонның ачык тәрәзәсеннән ылыс, нарат күркәләре, сафлык исе бәреп кереп, тәрәзәләргә эленгән ак ефәк пәрдәләрне җилфердәтте дә, сискәндереп, хәтерне уятты.

Йа Аллам! Тынчу тыгыз караңгы мал вагонында бер тамчы суга тилмереп, ач Зөһрә апам минем туганым Әминәне, җир йөзендә бары биш ел яшәп калган, үсеп җиткән булса, миңа апа булырга тиешле нәни кызчыкны дөньяга китергән. Тәрәзәләренә такталар кадакланган, тоткыннар белән шыгрым тулы мал вагоны. Күзләремне йомсам, тарихларда калган куркыныч хәлләр җанлана башлый.

Тук-тук, онытмагыз, онытмагыз, дип, чуен юл буйлап тукылдый тәгәрмәчләр.

Юк-юк, онытмадык, онытмадык, дип, чигәгә бәрә хәтер.

Чөнки без – сезнең оныкларыгыз, сезнең өметегез. Без беркайчан да югалып калмабыз, сезнең, нәни кызчык Әминәнең, Себер салкыннарында, адәм түзә алмаслык газаплы тормышта әрәм булган илнең иң алдынгы кешеләренең гомерләрен, нәселләрен дәвам итеп, балалар үстерербез, нәсел калдырырбыз. Һәм аларга ерак әби-бабалары турында сөйләрбез. Сезнең турыда сөйләрбез. Шундый адәм түзә алмаслык шартларда да, Габдрахман хәлфә кебек, Йөзембикә абыстай, Зөһрә, Мифтахетдин, Гөлҗамал кебек миллионнарның, намусларын югалтмыйча, мөселманнарның, христианнарның бер-берсенә булышып, кешелекләрен саклап калуы турында язып, сөйләп калдырырбыз.

Мин НКВД төрмәсе музеенда. Инде менә ничә көн музейда, куылганнарның, гаепсезгә төрмәгә утыртылып, газаплап үтерелгәннәрнең язмышын өйрәнәм. Күзләремә җыелган яшь тамчылары, яңакларымны пешереп агалар да агалар. Кемгәдер – белмим кемгә – җаннарым айкалып кычкырасым килә.

Бүгенге тормышта байлык дип күзләре тонган адәмнәргә, әгәр тормышыгыздан канәгать булмасагыз, менә бу музейга килегез, гыйбрәт алып китәрсез, дип кычкырасым килә.

Тикшерүче бүлмәсе. Аның җиңүче кыяфәтендәге карачкысын ясап куйганнар. Кәнәфи – тикшерүченеке, ә каршысында – тоткыннар утыргычы. Шул артсыз урындыкка утырам... Һәм тәннәрем чымырдап китә...

Раббым, Аллам! Бу көннәрне балаларыма, оныкларыма күрсәтмә! Дошманыма да күрсәтмә! Дошманнарым да бәхетле булсыннар! Әнә елга тутырып агып барган суга гарык булып өскә калкып чыккан мәетләр фотосы! Әнә нәни кызчыкны Енисей елгасы, җир куенына тапшырыгыз сабый бала Зөлхиҗәне, аның – яши алмый калган баланың – Җир-ана куенына кереп ятарга хакы бар, дип, әнисе белән соңгы кат хушлашу өчен ярга бәреп чыгарган.

Музей директоры белән танышам. Аның әби-бабаларының бөтен гаиләсен җыеп атып үтергәннәр. Ни өчен Татарстаннан чаклы килгәнемне әйткәч, ул төрмә-музей буйлап миңа үзе экскурсия ясый.

– Рәхмәт сезгә! – ди. – Ул көннәр турында китап язып калдырырга җыенганыгыз өчен рәхмәт! Әйдәгез, мин сезне төрмә камералары белән таныштырам. Бу вәхшилекне кешелек онытмаска тиеш!

Чыелдап төрмә камерасы ачылды. Күз алларым караңгыланып китте. Ике кешелек тәрәзәсез-нисез камера. Борынга параша исе килеп бәрелгәндәй булды. Ике якта чылбырлар белән стенага беркетелгән ике ятак. Бер почмакта параша чиләге. Һәм номерлар сугылган, юкарып беткән иске телогрейкалар, мескен бүрекләр.

Күз алдыма Алансу гүзәле, өч башлы дию көн саен камерадан алып чыгып китеп көчләгән, уналты яшендә газаплардан чәче агарган ике туган апам Нәфисә килеп басты. Ничекләр түздең икән син әле балалыктан, сабыйлыктан да чыгып бетмәгән кыз бала?! Ябык ишекләр артында дөньясына ләгънәт укып, төн уртасында чыелдап камера ишекләре ачылуны котларың алынып, калтыранып көткәнсеңдер. Һәм... Йа Раббым, үзең кичер бәндәләреңне!

– Бу ике кешелек камераларга егермешәр кешене япканнар, – ди музей директоры.

Кинәт, суларга һава җитмәгән кебек булып:

– Ишекне ачыгыз, зинһар, – дип ялынам. Камера ишеген, туристлар кергәч, нигәдер ябып куялар.

Минем агарып, куркып катып калган йөземне күреп, ишекләрне ачалар.

– Монда кергәч күпләрне курку хисе били.

– Миңа документларны әзерләгез, зинһар, – дим.

Башым әйләнеп, урамга йөгереп чыгам. Һәм күкрәк тутырып саф һава сулыйм.

– Рәхмәт сиңа, Раббым, мин бу камера ишеген ачып урамга чыга алдым! Ә уналты яшьлек Нәфисә, Маша түти, газапланып үлгән еврей кызы Женя?! Ничекләр итеп түздегез икән сез, бәгырькәйләрем?!

...Документлар белән танышам.

Әнә берсе Сталинга хат язган:

«Мин халык дошманнарын юк итү буенча планны үтәдем. Минем әле тагын биш йөз кешене юк итәрлек мөмкинлегем бар. Өстән приказ төшерүегезне үтенәм...»

– Бәдбәхет! – дим. – Ничек үлдең икән син, җәллад?!

Исән калган, инде картайган мәхбүсләр экраннан бертуктаусыз тоткыннарның үзәк өзгеч төрмә тормышы турында сөйли. Чәчләр үрә торырлык язмышлар. Һәрберсе турында романнар язарлык.

– Ирем һәм биш яшьлек кызым белән бергә кудылар. Кызымны, кочагымнан тартып алып, икенче кешегә биреп җибәрделәр. Мин шуннан соң баламны күрә алмадым, – дип сөйли инде тәмам бетерешкән, керфекләре коелып беткән, күзләреннән туктаусыз яшь агып торган чал чәчле әби.

Җаным елап, калтырана-калтырана саубуллашам да урамга чыгам. Бу каһәрләнгән йорттан исән-имин чыга алу үзе бер бәхет. Әнә стеналарга эленгән фотосурәтләрдә камераларда газапланып үлгәннәрнең фотолары. Нинди гали затлар! Алар бу ишекләрне ачып чыга алмаганнар. Ә мин саф һавага чыга алам! Рәхмәт сиңа, Раббым!

Төрмә-музей алдындагы аллеяда шиңгән чәчәкләр. Чәчәк таҗлары, гомерләре белән хушлашкандай, башларын түбән игәннәр. Акрын гына искән җилдә тибрәлә-тибрәлә, яфраклар җиргә коела. Битләремә ефәк җепләр, тоҗымнар урала. Алтын сыман яфраклар, матур итеп җиргә салынган урам ташлары өстенә төшеп, сары келәм булып түшәләләр. Үзләреннән соң яшь бөреләргә урын калдырып, сары сагыш төсендәге яфраклар җиргә коела!

Тимер челтәрләр белән бизәлгән эскәмиягә хәл алырга утырдым. Уйларымнан уелып, вакыт төшенчәсен дә оныттым бугай. Күпме вакыт узгандыр, хәтерләмим. Иренеп кенә, талгын җилдә әйләнә-тулгана, алдыма кызгылт-сары яфрак килеп төште.

– Хәлегез авырмы әллә? – Яныма затлы гына итеп киенгән, башына кара фетр эшләпә, шундый ук төстәге пәлтә кигән ханымның килеп утырганын сизми дә калганмын. Кинәт дәшкән тавышка сискәнеп киттем.

– Рәхмәт, түзәрлек, – дим.

– НКВД төрмә-музеенда булдыгызмы?

– Әйе, мин Казаннан ук килдем.

– Сезгә нәрсә белән булыша алам?

– Беләсезме, минем монда ике туган сеңлем яши Менә адрес: «...Латыпова Венера Насхатовна».

– Венера Насхатовна? Ул бит медицина университетында укыта. Аларның кызлары Алина да шунда ук укыта. Венера олы йөрәкле табиб. Ә аның ире онколог, ул бит илдәге иң танылган табибларның берсе. Ун ел элек Латыпов минем этигә операция ясаган иде. Әтием бүген дә исән-сау гына яши. Минем этием исеменнән дә аларга рәхмәт әйтегез. Рәхмәтләребез чиксез.

– Үзегезгә рәхмәт матур сүзләрегез өчен!

Күңелемә мөлдер-мөлдер итеп горурлык хисе тулып, музейда күргәннәрем азрак арткарак чигенә төшеп, сеңлем Венераларга юл тотам.

Венера Нәсхәт кызы – Габделхәй Котдус улының күпсанлы оныкларының берсе. Мәскәүдә врачлар конференциясендә, шулай ук бабалары репрессияләнгән Латыйпов Виктор Равил улы белән танышып, тормышларын корып җибәрделәр.

...Тайгага сыенып утырган затлы йортларында ипле генә, салмак кына гәп корып утырабыз. Сөңге кебек очларын күккә терәп киселүдән котылып кала алган чыршылар, эрбет агачлары, карагачлар, моңсуланып, Себернең талгын җилендә ылыс исләре таратып тибрәләләр.

Үземнең музейда күргән-ишеткән, җаннарны тетрәндерерлек, искитәрлек вакыйгалар турында туганнарым белән уртаклашам.

– Беләсезме, – ди профессор, – ул музей урнашкан йорт морзалар нәселеннән чыккан бабамныкы булган. Бабам алтын юучылар бригадасында эшләгән. Атлы обозда алтын төялгән ящикларны озатып йөргән. Көннәрдән бер көнне юылган алтын төялгән арба юкка чыккан. Мылтыклы конвойчылар үзләре үк урлап бүлешкәннәрдер дә бабама сылтап калдырганнардыр. Ул бер олау алтынның кайда юкка чыкканын әле дә белгән кеше юк. Ә минем бабамны өч көн эчендә атып үтергәннәр, мал-мөлкәтен тартып алганнар, ә ике катлы йортыннан НКВД төрмәсе ясаганнар. Аны шулай тиз юк итү, күрәсең, күргән-белгәннәрен сөйләп өлгермәсен өчен кирәк булгандыр. Ә соңыннан моның шаукымы минем әти-әниемә дә тигән, беркая да кереп укый алмаганнар. Шундый гаҗәп, адәм аңламаслык, шаккаткыч дөнья булган бит ул заманнар. Мин хәзерге буынның, хәзерге яшьләрнең яшәү рәвешенә шаккатам. Алар алдында нинди зур мөмкинлекләр! Теләсәң, илдә укы, теләсәң, чит илгә чык. Без хатыным белән икебез дә генетиканы яхшы беләбез. Бар нәрсә дә нәселдән килә, нәселе нык булса, адәм баласы югалып калмый, ташны тишеп булса да калкып чыга.

Котдус улы Габделхәйнең ике оныгы тайга эчендәге затлы йортта, чыршылар шавын тыңлый-тыңлый, әби-бабаларыбыз, туганнарыбыз турында таң атканчы сөйләштек.

– Рәхмәт сезгә! – дип шаулашалар йөзьяшәр агачлар. Себер халкының саулыгы сагында торганыгыз өчен рәхмәт! Бәхетле булыгыз!

– Кызларыгыз кайда соң, нигә күренмиләр? – дип сорыйм.

– Олы кызыбыз Алина медицина университетыннан кайтып керми, фәнни хезмәт белән шөгыльләнә. Ә кече кызым ветеринария институтын бетергән иде бит, анысына ат җене кагылган. Барлык алган акчасына чабышкы атлар сатып ала, нәселле атлар. Инде ике чабышкысы бар. Әле гарәп аргамагы белән Мәскәүгә ярышка китте. Яшь мал, күптән түгел генә бик зур акчалар түләп сатып алды. Сөлек шикелле зифа гәүдәле, нәзек аяклы чабышкы! Ничек курыкмыйдыр, өйрәтелмәгән ат бит. Бер тапкыр өстеннән очыртып та төшерде инде. «Ташла, кызым, бу эшеңне, синең өчен куркып, үзәкләрем өзелеп, котым очып торам», – дим. Аның үз туксаны туксан. Ат өстеннән төшми.

– Аргамакның исеме ничек соң? Нинди исем кушты чабышкысына?

– Йолдыз дип исем бирде.

Йөрәгем дерт итеп сискәнеп киттем.

– Венера сеңлем, ул аргамакның бәкәлләре ак түгелме? Аякларына ак носки кимәгәнме? Төсе җирән карамы? Яллары нинди, карамы?

Минем капылт кына сәер сораулар бирүемә аптырап, сеңлем күзләрен миңа төбәде.

– Игътибар да иткәнем юк инде, апа. Әйе, төсе җирән кара, ә аякларына

күзем төшкәне юк. Кызым: «Әни, моннан да сылурак аргамакның булуы мөмкин түгел», – ди. Үзенеке булганга шулай дип әйтә инде ул аны. Һәр кешегә үзенең малы затлырак булып күренәдер. Чабышка керер алдыннан урынында басып тора алмый үрсәләнә, ди. Бигрәк шәп аргамак, дип сөенә. Исән-имин йөреп кайтсын инде.

Минем хәтер сукмаклары утызынчы елларга йөгерә.

Кукан, Йолдыз! Берсе, интегә-интегә, текә горур муенына камыт киеп, нәзек аяклары белән тездән туфракка батып, черәшә-черәшә сука сөйри. Икенчесенең – әллә нинди бәйгеләрдә катнашып, авылыбыз данын, бәлки, илебез данын якларга тиешле, Үзбәк якларын урап Алансуга кайтып, туган туфрагым монда булыр, дип дөньяга килгән Йолдызның – тиресе мал йорты каршындагы аркылы агачта кояш нурларында елкылдап янып тора. Сабантуйлар җиткәнен көтеп үрсәләнеп торган ярсу йөрәген зат танымаган надан авыл куштаннары пешереп ашаганнар. Капка кырыена каккан күгәргән кадакка элеп куйган нәни кыңгырау күңелемдә чыңлый. «Онытмагыз безне, онытмагыз!»

Себер якларында гарәп аргамагы турында ишетү, исеме Йолдыз булу күңелемне айкады. Аргамакның нәсел җебе өзелмәгән ләбаса! Алансуда Куканыбызның колыннары эш атына әйләнгәннәр. Ә Себердә яшәүче Габделхәй бабамның туруны гарәп аргамагы белән Мәскәүгә бәйгегә киткән. Гаҗәбенә ни диярсең?! Җиңеп кайт, сеңлем, җилләр юлдаш булсын үзеңә!

Җаным җылынып китте.

Татарстаннан килгән илле җиде делегат, авылларда Себер татарлары тарихы белән танышып, бер авылдан икенче авылга сәяхәт кылабыз.

Менә зур тарихлы татар авылы Йорт-Оры. Үз музейлары бар, сугышта һәлак булганнарга һәйкәл куелган. Мәчеткә кереп, намаз укыйбыз. Навил хәзрәт безгә авыл тарихы турында сөйли. Һәм көтелмәгән хәл, хәзрәт минем янга килде дә Себер татарлары сөйләме белән:

– Ханым, ә мин сезнең белән таныш, – ди.

– Юк-юк, сез мине белмисез, мин Себердә беренче мәртәбә, кемгә булса да охшатасыздыр, мин Татарстаннан, – дим.

– Әйе, әйе, сез мәркәзебез Казаннан. Мин, Бөтендөнья татар конгрессына килгәч, Казанда «Кукан» дип аталган ресторанга кердем, бик эчәсем килгән иде. Сездән чәй сорадым, ә сез миңа чәкчәк белән чәй чыгардыгыз, хакын да алмадыгыз. «Сез бит мосафир, хәзрәт, дога кылырсыз», – дип китеп бардыгыз. Исемегезне дә әйткән идегез, хәтер диген инде син, исемнән чыккан.

– Рәхмәт, хәзрәт, бик зур рәхмәт сезгә! – дип, күзләремә яшь җыелып китеп бардым.

Әй Кукан, Кукан! Күрәсеңме, сине Себердә дә беләләр. Туксан елдан соң мин синең турыда Себердә ишетәм! Казан үзәгендә оныкларың төзегән, синең исемеңне йөрткән җәмәгать туклануы йортында Себердән килгән имам, синең – затлы гарәп аргамагының – исемен, минем кушаматымны Себергә чаклы алып кайткан. Рәхмәт сиңа, Навил хәзрәт! Себер авылларында безнең гореф-гадәтләребезне, динебезне саклаганың өчен рәхмәт!

Тыныч кына, талгын гына аккан елга өстендә акчарлаклар оча. Тын елганы уятырга теләгәндәй, әле анда, әле монда уйнаклап, көмеш сыман балыклар сикерешә.

Акчарлаклар тавышында бала елаган, үксегән тавышлар ишетәм. Юк, мин колагым белән түгел, йөрәгем белән ишетәм. Миңа калса, Себердә траншеяда күмелеп калган сабыйларның җаннары акчарлакларга күчкән дә алар әти-әниләрен, илләрен сагынып һаман да бәргәләнәләр.

Улы Сабирҗанны эзләп күкрәк тиңентен ташып, ургылып аккан язгы суга кергән, елга үз куенына алган Балтач хатыны Әсмабикә су төбендә улын эзләп тапкандыр да куенына алып җылыткандыр. Алар әле дә Енисей елгасында көмеш балыклар булып йөзеп йөриләрдер. Сабый бала Әминә, нәни акчарлак булып, әти-әниләренең, абыйларының Себердәге тормышын өйрәнергә килгән сеңлесен елга өстендә өзгәләнә-өзгәләнә сәламлидер. Габдрахман хәлфә һәм Зөһрә кызлары белән күптән инде җәннәт түрендәдер. Амин, шулай булсын, дип, елга ярыннан кузгалып китеп бардым.

Себердә яшәүче мөселман кардәшләребез тормышы белән танышып, җаннарыбыз сафланып, илгә кайтып барабыз. Арылган: күзләргә йокы эленгән. Инде төн уртасы авышкан. Сәяхәтебезнең шулай уңышлы үтүенә куанып, шул ук вагонда поездның акрын гына тукылдап, тибрәлеп кайтып килүенә оеп, йоклар-йокламас ятам.

Кинәт колагыма, тальянга кушылып, егетләр, кызлар җырлавы ишетелә:

Сагынам, дуслар, сагынам, дуслар,
Сагынам, дуслар, илкәйне.
Илкәй белән бергә сагынам
Яшьләй сөйгән иркәмне.

Шулкадәр матур итеп җырлыйлар... Төш күрәм бугай. Шул атна-ун көн эчендә Алансуымны, Казанымны, гаиләмне, оныкларымны сагынып өлгердем. Җыр туктамыйча дәвам итә, поездның барганы да ишетелми. Колагымда егет-кызларның дөнья бетереп җырлавы, тальян тавышы:

Бездә биек таулар бар ла,
Тау астында таллар бар.
Талда – яфрак, бездә – сагыну,
Сездә нинди хәлләр бар?

Күзләремне ачам. Поезд туктаган, вагонда җан әсәре юк. Ә перронда ду килеп бииләр. Себер татарлары төн уртасында җыйнаулашып Казан татарлары белән очрашырга килгәннәр, кулларында – бүләкләр. Бу шәһәрдә туктыйсыбызны каян белгәннәр диген?!

Рәхмәт сезгә, мөселман кардәшләр! Сезнең күбегез куылганнарның, илгә кайта алмыйча калганнарның оныклары, туруннарыдыр. Әби-бабаларыгыз сезгә туган ил турында сөйләп калдырганнардыр. Ә сез безгә аларның сагыну хисләрен җиткерер өчен, төн йокыгызны калдырып, безнең белән

очрашыр өчен килгәнсез. Ә без, җаннарыбызда салкын Себернең җылы сагыну хисләрен тоеп, туган илгә кайтып китәбез.

Сау булыгыз, хушыгыз, Себер татарлары, мөселман кардәшләр! Яңадан очрашканга кадәр!

* * *

Дөрли-дөрли тайга яна. Һай-һай, әллә дөнья бетә инде, көнчыгыштан көнбатышка, җәһәннәм уты кебек, үз артыннан кара җир калдырып, аждаһа авызыннан бөркелгән утлы ялкын җирне ялмап кына бара. Бәрәкәтле Җирана куенына төшеп, борынлап чыгып, сайрар кошлар тавышына, кояшның җылы нурларында коенып үсәсе яшь үрентеләр дәһшәтле утлы ялкында куырылып кына киләләр. Гөлчәчәкләр, хәтфә үләннәр, күбәләкләргә, бал кортларына кунып ял итәр өчен генә дип чәчәк аткан чәчкә таҗларын ухылдап, уфылдап килгән утлы ташкын йота бара. Тайга эченнән атылып чыккан җәнлекләр котылу әмәлен эзләп бәргәләнәләр. Көнчыгыштан көнбатышка чапсалар – тәмуг, көнбатыштан көнчыгышка таба – җәһәннәм! Куе кара зәһәр төтен тыннарын буа.

Әнә нәни генә, сылу гына болан баласына ут капкан, мескенкәй, әнисе янына килеп, ярдәм сорап бөтерелә, бәргәләнә:

– Булышсана, әни, коткарсана! – дигәндәй, ялварулы күзләре белән әнисенә карый, газапларыннан котыласы килеп чабып китә, тик аның саен ялкын көчәя генә барып, сабыйның үзәгенә үтеп, нәни боланны ут йомгагына әйләндергән. Әнкә болан, сабый тирәсендә бөтерелеп, булышмакчы булып, баласын җиргә төртеп екты да, үзәкләрне өзәрдәй җан әрнеше белән иңгелдәп, әллә нинди тамак төбе авазы белән сулкылдап кычкырып җибәрде:

– Балам! – диде бугай әнкә болан. – Сабыем, ниләр генә эшли алам соң мин?! Ничек кенә булышыйм сиңа?! Ничек кенә бу газаплардан коткарыйм?

Утны сүндермәкче булып, баласын кара җир өстендә аунатты. Болан баласы соңгы тапкыр керфекләре көйгән күзләрен тутырып әнисенә карады да, тере ялкын төргәге булып, куырылып килеп, җиргә егылды. Ыңгырашып, үзенә булыша алмаган әнисенә рәнҗеп, мәңгелеккә күзләрен йомды.

Әнкә болан баласы янында озак басып торды.

Аннан соң башын югарыга, күккә күтәреп, җаны иңрәп, әллә ниткән авазлар чыгарып мөгрәде. Юк, мөгрәмәде, җан авазлары белән кычкырып, соңгы тапкыр сабые белән хушлашты.

Һәм көнбатышка таба чапты. Тик көнбатыштан да тайганы иңләп-буйлап тере ялкын килә иде. Җәнлекләр, кая качарга белмичә, котылу әмәлен эзләп, әле бер якка, әле икенче якка ыргылалар, әткә-әнкәләре, балалары – барысы да. Тик качып котылыр әмәл юк... Тәмуггтан әле беркемнең дә качып котыла алганы юк! Ул барысын да тигезли.

Әнә Мифтахетдин, Гөлҗамал, Йөзембикә абыстай, нәни кызчык Әминә исемнәре уеп язылган эрбет агачына да ут капкан.

Вәхшилекнең тере шаһиты булган йөзьяшәр агач инде дөрләп янып бетте дигәндә, өстән, самолёттан, су койдылар. Чыжылдап сүнде ут, һәм... Эрбет агачы караеп, инде әллә кайчаннан күпме генә яңгыр көтсәләр дә бер

генә болыт әсәре дә күренмәгән күк йөзенә омтылып, Себер урманнарында харап булганнарга кара һәйкәл булып, сураеп басып калды.

Балаларын илгә озаткан Мифтахетдин белән Гөлҗамал, Йөзембикә абыстай, нәни болан баласы кебек тереләй пешеп газапланып үлгән сабый – тууга Йөзембикә абыстайның кәфенлегенә биләнгән Әминә – исемнәре, эрбет агачының кәүсәсен канатып, үткен пычак очы белән уеп язганда агачның сагызы агып төшеп, күз яшенә әйләнеп катып калган гәрәбә эреп төшеп, инде әллә кайчан җир белән тигезләнеп, мүк белән капланган каберләр өстенә тамды. Дөрли-дөрли, ахылдый-ухылдый килгән дәһшәтле ялкын барысын да ялмады, аждаһа булып йотты.

Бу – Аллаһның вәхшилеккә булган каһәре. Газапланып үлгән миллионнарча адәмнәрнең, тумыйча калган сабыйларның, яшәргә, нәсел калдырырга дип дөньяга килеп тә, ачлы-туклы яшәп, салкыннарда өшеп, Себернең бетмәс-төкәнмәс канечкеч черкиләреннән таланып, төрле авырулардан интегеп үлгән сөрелгәннәрнең, әти-әниләренең үзәкләрен өзеп харап булган сабыйларның рәнҗеше иде.

Әнисеннән ярдәм көтеп, яшь болан баласы тере ут йомгагы булып әрнеп кычкыра. Янында баласын коткара алмаудан гаҗиз булып, әнкә болан: «Коткарыгыз!» – дип, җиһанга оран сала. Габдрахман хәлфәнең күбәләктәй нәни кызы Әминә янына – тереләй пешеп газапланып үлгән сабые янына – тезләнеп иңгелдәгән тавыш, каһәрле еллар аша әйләнеп кайтып, бу авазга кушыла.

Ә күктә, зәп-зәңгәр күктә, бәргәләнә-бәргәләнә, Гөлҗамалның җаны – ялгыз аккош сулкылдый:

– Гә-рә-ә-й, кайда син, улым?! Тавыш бир, балам Гәрәй!

Һәм канатлары белән күк йөзен кисә-кисә акчарлаклар – Енисей яры буендагы траншеяларда күмелгәннәрнең җаннары бәргәләнә:

– Аң булыгыз, кешеләр! Бу вәхшилекләр башка кабатланмасын!

Иртәме-соңмы, бу дөньядамы, мәңгелектәме, моңа гаепле адәмнәр җавап тотарлар. Беркемнең дә кеше гомерен өзәргә хакы юк!

Җирләр тетри, таулар җир белән тигезләнә, елгалар ярларыннан ташып чыгалар да, дөньяны су баса.

Ни өчен дөньяны чир басты? Моңарчы кеше белмәгән, ишетмәгән авыру акылына килә алмаган кавемне өйләренә куып кертте, әби-бабалары, балалары, оныклары белән очраша алмыйча аптырыйлар.

Байлык, акча артыннан куып, бер-берегез белән очрашырга вакыт тапмый идегезме? Инде хәзер менә вакытыгыз күп, тик очраша алмыйсыз, дип, хәтер күңел ишеген шакый. Бәлки, җаныгызда бер-берегезгә карата ярату, мәрхәмәт, ихтирам хисе уяныр.

Әти-әнисенең хәлен белергә вакыт тапмаган балалар: уллар-кызлар!

Үз туганы белән ата малын бүлешеп пычакка пычак килгән абый-сеңелләр!

Көнчелектән кара көеп, юктан гына тавыш чыгарып яшәгән күрше-күлән!

Бәлки, акылыгызга килерсез?!

Юк шул, адәмнәр чукракланганнар, ишетмиләр. Күрмиләр, күзләре тонган. Маңгай күзләре генә түгел, күңел күзләре дә сукырайган адәмнәрнең.

Туган – туганы белән, күрше – күрше белән, илләр илләр белән сугыша.

Юк шул, әле дә аңына килә алмый кешелек!

– Аң булыгыз, сак булыгыз, кешеләр! – дип, дөрли-дөрли яна тайга. Агачларның да орлыклары, коелып, Җир-ана куенына төшеп, яңа үсентеләр борынлап чыкмаслар. Җәнлекләр, кошлар бу урыннарга кире әйләнеп кайтмаслар. Озак еллар буена тайга кап-кара җир булып калыр, Җир-ана җәрәхәтләреннән арынганчы, бу вәхшилекләрне онытканчы.

Әйе, Җирнең дә хәтере бар!

* * *

Шомырт агачын яшен сукканнан соң, Котдусларның алма бакчасы ничектер моңсуланып, ямансулап, ятим калды. Яңа язлар җиткәч, Аклык аланын хуш искә төреп, шомырт агачлары чәчәк атканда, бакчада тик умарта кортларының шомырт чәчәкләренең хуш исләрен эзләп безелдәшкән тавышы гына ишетелә иде.

Сиртмәле кое, коты чыгып:

– Инде минем кемгә кирәгем бар соң? Әнә һәрбер кешенең өенә су кергән, кранны гына борасы. Шунда ук савытларына шаулап су тула. Рәхәт заманнар җитте. Суымны алучы юк. Тиздән мине күмәрләр, – дип, соңгы көннәрен көтә иде. Шомырт агачын яшен сукканнан соң шулай күңеле киселеп, җаны әрнеп калган иде коеның.

Коеларны күмәргә ярамый. Коены күмгән адәмгә су рәнҗеше төшәргә мөмкин!

– Сез минем юлларымны чистартсагыз, мин янә челтер-челтер итеп агып, көмештәй су белән тулармын. Бер йотым суга тилмереп мал вагоннарында барган тоткыннарны исегезгә төшерегез. Күммәгез мине, зинһар, тимәгез миңа! – дип кычкырасы килде Котдус карт үзе казыган сиртмәле коеның.

Яңа язлар килгән иде. Алмагачлар шау чәчәктә. Язгы җилләр Аклык аланыннан авылга шомырт чәчәге исен аңкытып исәләр. Тик бакчада аклык, сафлык таратып үсеп утырган карт шомырт агачы гына юк. Шомырт агачының яшен утыннан янып-караеп калган төбе, йөрәкләргә шом салып, сураеп тора. Моңсу, ямансу...

Иртә таңнан бакчага көч-куәтләре ташып торган ир-атлар баулар, көрәкләр, баскычлар күтәреп килеп керделәр дә сиртмәле кое кырыена килеп бастылар.

Коеның йөрәге дерт итеп китте: димәк, күмәләр!

Коеның, сулышына буылып:

– Тимәгез, күммәгез мине, коеларны күмәргә ярамый, су рәнҗешен алырсыз. Коены казып калдырган, балаларыма, оныкларыма эчәргә көмештәй саф суым калсын дип тырышкан Котдус картның җанын рәнҗетерсез! – дип кычкырасы килде. Тик тавышы чыкмады, тыны буылган иде. Кое чишмәсе каян да булса бәреп чыгарга юл эзли иде. Инде кое төбендәге су да чыпчык тезеннән генә калган иде. – Ишетмәделәр, минем ялваруымны ишетмәделәр, – дип, сулкылдап, әрнеп типте сиртмәле коеның йөрәге. Бу – җирнең йөрәк тибеше иде.

Өстә көч-куәтләре ташып торган яшь ирләр озак итеп ни турындадыр сөйләштеләр, киңәштеләр.

– Менә тиздән, тиздән өстемә туфрак атарлар! – дип ыңгырашты кое

чишмәсе. – Болай да инде энә күзеннән генә сулап торам лабаса. Инде бетәрмен, бөтенләй кибәрмен!

Ләкин кое төбенә балчык түгел, Котдус картның туруны төште дә өстән төшерелгән чиләкләргә ләм тутыра башлады. Чишмәнең тыны ачылганнан-ачыла барып, ниһаять, кое төбеннән көмеш су бәреп чыкты.

– Ишеттеләр! Иңгелдәп әйткән сүзләремне ишеттеләр, – дип куанды сиртмәле кое чишмәсе. – Рәхмәт сезгә, сулышымны ачтыгыз, үзегезнең дә барыр юлларыгыз якты булсын, гомерегез рәхәт үтсен! Мин сезгә хәер-догада булырмын, – дип, челтер-челтер итеп акты кое чишмәсе. Һәм сиртмәле кое кынысыннан көмештәй су белән тулды.

– Рәхмәт сезгә, күршеләр, булышканыгыз өчен рәхмәт! Коеларны чистарту – саваплы эш. Кое мәңге суы бетмәслек, гел тулып тора торган бәрәкәтле кисмәк бит ул.

– Күптәннән чистартасым килеп йөри идем, нигәдер кул җитми торды. Аллага шөкер, инде бабайлар тыныч ятсыннар!

– Бу коеның суы бик тәмле! Минем әби чәй суына гел сезгә керә торган иде. Котдуслар коесының суы йомшак, такта чәй шундый әйбәт каралып чыгадырые, ди иде. Хатынга әйтермен әле, берәр чиләк су алып чыксын, – диде күршеләре.

Барысы да саубуллашып чыгып киттеләр.

– Тукта, коены чистарткан-чистарткан, шомырт агачының төбен дә казып алыйм әле. Әрәмәдән яшь шомырт агачы алып кайтып утыртырмын, – дип, каралып, сураеп утырган шомырт төбенә таба китте Габделхәйнең оныгы һәм үткен көрәген җиргә батырды. Ә агач төбеннән яшь үрентеләр чыгып килә иде! Бер генә урыннан да түгел, әллә ничә җирдән!

– Үлмәдем, яшим, җирнең бәрәкәтле дымын эчеп, күккә үрләрмен, бакчаны хуш искә күмеп, янә чәчәк атармын, Хәбибулла карт белән Котдус картның оныклары, туруннары кебек. Габдрахман хәлфәнең, Мифтахетдиннәрнең, Нәфисәләрнең нәселләрен дәвам итүчеләр кебек, мин, яшәреп, тамырларымнан яңадан борынлап чыктым, һәм күккә таба күтәреләм.

– Тамырың нык булса, дәһшәтле җилләр, яшенле яңгырлар гына кешеләрне дә, агачларны да үтерә алмый! – дип, язгы җилдә җилфердәп куйдылар карт шомырт төбеннән борынлап чыккан яшь үсентеләр.

* * *

Гомерләр уза. Йа Аллам, инде күпләр, бу дөньяны ташлап, мәңгелеккә китеп барды. Дөньяга яшьләр килеп, үсеп-калкынып, әти-әниләрен алыштырды. Моңарчы шулай булган, шулай тиеш. Агачлар да көзләр җиткәч картайган, саргайган яфракларын җиргә коялар да язын сабыр гына, ипле генә итеп бөреләренең шартлап ярылуын көтәләр. Яшәү кануннары шундый. Бер килгән, бер китәсе. Әле генә дөньяның кендеге булып яшәгән, яхшы атларда дилбегә тотып, мәңгелеккә килгән кебек кыланган адәмнәр, инде картаеп, мескенләнеп, капка төпләрендә җигелеп үзләрен көтеп торган арыган атларны күзәтәләр. Аларның итек табаннарын күреп үскәннәр калкынып, зур белемнәр алып, биек үрләр яулады.

Шулай икән, дөнья гел үзгәрештә. Әнә Алансу авылында «уфалла»

арбасы, колхоз саламын «урлап» төягән чана тартып үскән, Янсуарга Җәүдәт абыйсының иске велосипедында көн саен укырга йөргән Дамир Шамил улы Муратовны – «Тасма» заводының генераль директорын – зур кара машина йөртә. Әти-әнисе сөенеп бетә алмый. Уллларының орден-медальләренә, инде Рәсәйнең атказанган химия сәнәгате хезмәткәре булган олы улларының уңышларына авыл халкы шакката. Кайсы сөенеп, кайсы көнләшеп аптырый. Ничек инде Рәсәйдә ике генә булган шундый зур заводның директоры була алган Шамил аганың улы, Хәбибулла белән Котдус Габделхәенең оныгы, гади авыл малае? Әнә авылда беренчеләрдән шәхси машина сатып алган! Хәзер әти-әнисенең кая да барасы булса, улларына гына хәбәр итәләр. Шунда ук кайтып ала яки машина җибәртеп алдыра уллары, рәхмәт яугыры бала! Нурания белән Шамилнең калага чыгып киткәнен аптырап карап кала мәктәп директоры.

Химия фәненнән аны СССРның мәгариф отличнигы Люция Даутова укыткан иде.

– Дамир химияне яхшы белә, зур кеше булыр, – дигән иде. Хак сүз булган, күрәсең.

– Икенче кызлары әдәбияттан, тарихтан бик көчле, – дип сөйли иде Ләлә Галимулловна. – Әйбәт шигырьләр, хикәяләр яза.

Тик анысы бөтенләй икенче юлны сайлады!

Гаҗәбенә ни диярсең, Шамил Муратовның биш баласы турында да гел яхшы хәбәрләр ишетелеп тора!

Зурайды нәселнең бу буыны. Нурания карчык инде кияү-киленнәрен, онықларын, туруннарын санаганда бутала ук башлады. Күбесе бер үк төрле исемнәр туры килеп буталып бетә.

Сугыш вакытында Казанның Шамский хастаханәсендә үлеп, кемдер тарафыннан Яңа Бистә зиратында күмелгән Хәбибулла картның каберен табып, чардуган, таш куйдылар. Барып дога кылыр оныклары, туруннары күп, Аллага шөкер.

Без бетмәдек, без бар, без яшибез! Иң зур белем йортларында укыган онык-туруннар дөньяның төрле почмакларына таралдылар...

Шомырт агачының ап-ак таҗларын җилләр үзләре белән иярте алып китәләр дә җиһанга сибәләр...

Җилләр җиргә аклык тарата!

Нурлан
Ганиев

ЗУР СУЛАРДА ДУЛКЫН БИЕК БУЛА

Канатларсыз...

Канатларны салдым... Какмас булгач,
Нигә кирәк инде канатлар?
Язмыш җилләренә каршы очып,
Мин аларны азмы канаткан?

Җиңеләеп калдым канатларсыз,
Күктән җиргә төштем яңадан.
Асылыма кайттым, үз кыйблама —
Күрәсезме, мин дә яңарам.

Канатларым – чүйдә. Элеп куйдым,
Сыйпап китәм үткән-сүткәндә.
Мин киләчәк белән яшим хәзер,
Вәгъдә бирәм – кайтмам үткәнгә!

Акланмыйча калган өметләрнең
Ярчыкларын җыеп кул каный.
Мин кичергән инде моны гына –
Нишлисең бит инде, булгалый.

Яхшы аңладым мин – очар булсаң,
Түбән очма, бул гел биектә!
Канатларны салып ялгышканмын –
Канатлылар гына иректә!
Канатлылар гелән биектә...

Нурлан ГАНИЕВ (1985) *– шагыйрь; Ф.Кәрим исемендәге әдәби премия лауреаты. «Бер мизгел нибары» исемле китап авторы. Уфада яши.*

Ни кызганыч

Зур суларда дулкын биек була,
Киң канатлар оча югары.
Ай-кояшка тузан күтәрелми –
Купкан җирдә кала ул бары.

Киң күңелгә дөнья тар түгел ул –
Сыя ала анда бар галәм.
Гомер буе әрнеп яшәр өчен
Җитә икән ялгыш бер гамәл.

Кара уйлар төнлә генә тумый —
Уйларыңнан курык, онытма:
Кояш җылытмаса әгәр җирне,
Булмас иде кара болыт та...

Диңгезләрдә дулкын биек куба —
Кулләрнең ул керми төшенә.
Ни кызганыч, яшәү мәгънәсенә
Кеше соңлап кына төшенә...

Күзләр

Аһ бу күзләр! Өмет тулы күзләр!
Җавап көткән, үгет көткән күзләр!
Никадәрле халәт, мең төс сездә?!
Сез бакканда артык хәтта сүз дә.

Аһ бу күзләр! Шомлы, зәһәр күзләр!
Галәм сыйган соры, зәңгәр күзләр.
Минем кебек беркатлырак затлар
Карамыйча сезгә ничек түзәр?

Аһ бу күзләр! Хәйлә, ялган күзләр! –
Югалсаң да, әллә каян күзләр.
Җанны сытып, үзәгеңне өзәр,
Йөрәккә ук булып баккан күзләр!

Аһ бу күзләр! Сөю тулы күзләр,
Сөю тулы күзләр шундый гүзәл!
Мең җаваплы, мең сораулы күзләр,
Алар берәү-икәү түгел, йөзәр!

Аһ бу күзләр! Эчкә баткан күзләр,
Хәсрәт белән күккә баккан күзләр...
Тоныкланган, нуры сүнгән күзләр,
Онытмаган, күпне күргән күзләр.

Аһ бу күзләр! Уйнак, шаян күзләр —
Алар әле әллә кемне бизәр.
Аһ бу күзләр...
Күңел белән тоя белүчеләр
Хәлләремне сезгә карап сизәр...

Ат өйрәтә берәү

Ат өйрәтә берәү. «Йолдыз»ы да
Ак күбеккә батып ярсыган.
Таң томаны күтәреләме соң –
Бөтерелеп аннан пар чыга.

Чыгымчылый, тимер авызлыгын
Шатыр-шотыр чәйнәп ашкына.

Җир йөзендә беркем юк шикелле –
Хуҗа белән шушы ат кына.

Тояк асларыннан ак кар түгел,
Ак чаткылар оча, диярсең.
И тулпаркай, син дә инде тиздән
Камыт-ыңгырчагың киярсең.

Яңгыратып кешни, кушаяклап
Азатлыкка һаман омтыла.
Хуҗасы да нәкъ шул тае төсле
Бер котырып ала, бер тына.

Аның сүзе дилбегәдәй кыска,
Камчысы да каеш-каюлы:
«Ну ничауа, ерак киталмассың,
Биетәләр хәтта аюны».

...Бу ат – үзем. Камчылысы – язмыш,
Өйрәтергә теләп кизәнә.
Баш очымда чаж-чож килеп куя –
Юртып киләм гомер-үзәннән...

Мизгел һәм мәңгелек

Бер гомергә торыр мизгелләр бар,
Мизгелләргә торыр гомерләр.
Бер-бер артлы үрләр яулый кеше,
Бер-бер артлы биек ул үрләр.

Үрләр биек. Менүләре авыр,
Төшүләре авыр аннан да.
Кадерләрен белә, аңлый микән,
Санлый микән үрдә калганнар?

Дан-дәрәҗә һич мәңгелек түгел –
Кешелегең калсын кешегә.
Һич мактанма, тик мин булдырдым, дип,
Халкың бәя бирсен эшеңә.

Бер һаваны сулап яшәсәк тә,
Әнә бит без шундый төрлеләр:
Каты бәгырьлеләр, битарафлар,
Йомшак күңеллеләр, серлеләр...

Кояш сыеп беткән йөрәкләр бар,
Кара урман кебек күңелләр.
Еллар түгел, изге эшләр белән
Үлчәнә лә безнең гомерләр.

Дөнья йөген тартып гарык булган
Ач-ялангач үксез сабыйлар,
Дөнья малын кесәсендә йөрткән,
Җир кендеге булган абыйлар.

Барыбыз да Ходай баласы ла —
Мәңгелеккә бер көн китәсе.
Акыл сатмыйм – тормыш фәлсәфәсе –
Бу гомерне матур үтәсе.

...Бер гомергә торыр мизгелләр бар,
Мизгелләргә торыр гомерләр.
Үрләр арты үрләр яулый кеше,
Бер-бер артлы биек ул үрләр...

Җырларымны сезгә калдырам

Үземнән соңниләр калдырырмын —
Патша сарайлары салдырмам.
Алтын сарай түгел, ирек сөйгән
Җырларымны сезгә калдырам!

Үткәннәргә кире кайтмас өчен
Күперләрне махсус яндырам.
Күңелегезгә күпер булып яткан
Җырларымны сезгә калдырам!

Шөкер, җитә, булмас бәхет көтеп
Күзләремне башка талдырмам.
Миңа иң зур бәхет бүләк иткән
Җырларымны сезгә калдырам!

Аз булмады инде тормышымда
Ялгышларым юлдан яздырган.
Юлыгызга якты маяк булсын –
Җырларымны сезгә калдырам!

***

Шатлыкларның төсе һәрчак чагу,
Кайгыныкы гына гел кара.
Шатлыклардан елмаюлар туа,
Кайгылардан кала гел яра.

Ак төстәме, яшел, зәңгәрме ул —
Шатлык шатлык инде кайда да.
Алтын-көмешләргә төрелсә дә,
Кара булып кала кайгылар.

Сагыш төсе һәрчак сары инде,
Зәңгәр төстә гелән хыяллар.
Иртәгәсе – алсу, ә үткәннәр
Чуар төскә гелән буялган.

Һәр кешенең шатлык төсе үзгә,
Һәрчак чагу, якты – шул бары.
Тик кайгылар гына бердәй ачы,
Һәркем өчен кайгы гел кара...

Шәмсия
Җиһангирова

КИЛЕН КАПКАСЫ

хикәя

Кайда ничектер, ә менә безнең якта чит авылдан кияүгә килгән хатын-кызга исеме белән дәшмичә, Килен дип йөртәләр иде. Минем әнкәем дә шул исемлектә. Чөнки ул безнең авылга күрше авылдан килен булып төшкән. Бу хәлләргә чирек гасырдан артык вакыт үтсә дә, аны әби-бабайлар һаман да Килен дип йөртә. Кечкенә чагымда мин чыннан да әнкәемнең исеме шулайдыр дип уйлый идем. Ут күршебез Мәдхиямал әби бигрәк тә яратып, үз итеп, Киленкәем дип дәшә иде аңа. Хәер, аны күршедә яши иде дип әйтү бик үк дөрес тә булмастыр. Утыз яшенә җитеп тә, әле һаман өйләнмәгән улы Әшрәфҗан янында гомер итүче әбекәй көне-төне бездә диярлек. Йомышы төшсә-төшмәсә дә: «Киленкәем, син өйдәме соң? Ишегалдында гәүдәңне күрмәдем...» – дип, иртә таңнан кереп җитә иде. Шунысы да бар, ул беркайчан да урам капкадан йөрми, ике араны бүлеп торган койманы кыеп ясалган капка аша гына, әнием әйтмешли, «ыһ» дигәнче керә дә җитә. Капканың исеме дә кызык – Килен капкасы! Капканы кем кайчан уйган, ник шулай атагандыр, анысын сорап торган кеше юк, тик ул беркайчан да ябылып, бикләнеп куелмый иде. Без моңа шулкадәр күнегеп беткәнбез ки, керми торса, әнкәем хәвефләнә-тынычсызлана башлап, барыгыз әле, берәрегез кереп, хәлен белегез, авырып китмәсен әбиегез дип, апамны йә мине йөгертә иде. Озын сүзнең кыскасы, бала чагымдагы бер генә көнне дә Килен капкасының эшсез торганын, Мәдхиямал әбидән башка аш ашап, чәй эчкәнебезне хәтерләмим.

Әнкәем көне-төне колхоз эшендә. Мин ул эшкә киткәндә, татлы йокыда калам. Чит кеше-мазар кереп, ялгыш куркытмасын диптер инде, әнкәем ишеккә йозак элеп калдыра. Ялган йозак! Әйе! Нәкъ шулай диләр иде ачкыч белән бикләнмәгән йозакны. Менә мин, йокым тәмам туепмы, күземә төшкән кояш нурларыннан сискәнепме, берзаман уянып китәм. Өйдә әни юклыгын күргәч, кычкырып еларга тотынам. Минем ачы тавышымны ишетеп, Мәдхиямал әби ишекне ачарга тиеш. Кайчак әбием ишетсен өчен, тагын да катырак һәм шактый озак еларга туры килә иде...

Чит кеше-мазар куркыту дигәннән, кайда ничектер, безне «тыңламасаң, хәзер, әнә, урыс алып китәр» дип, бик тиз акылга утырталар иде. Елганың теге ягында авылыбызга терәлеп үк торган диярлек рус авылы бар. Рус авылы булса да, исеме татарча – Яңавыл. Хәер, ул гына түгел, турыдан барсаң, өч кенә чакрым ераклыкта, авылның икенче башында Кәчти дигәне дә бар. Шул авылларның кайсыннан булгандыр, ике көннең берендә, җәй дими, кыш дими, гел бер киемдә, чана яки арба тарткан зур сакаллы урыс карты (бәлкем, миңа гына бик карт кебек тоелгандыр) урам буйлап, татарча белгән бердәнбер җөмләсен – «Самавыр төзәтергә бармы?!»ны кычкырып, сөрән салып йөрер иде. Берчак җиз самавырның борыны ага башлагач, әнкәем яулыгы белән битен каплап, ым кагып кына, аны ишегалдына чакырып керткән иде. Гәүдәсе капкабыздан күренүгә, алып китмәсен дип куркып, Килен капкасыннан ялт кына чыгып качканымны хәтерлим... Менә шундый «алып китүчеләрдән» дә саклый иде безне Мәдхиямал әбиебез. Үзебезнең әби-бабаебыз булмаганлыктан, ул безгә икеләтә якын иде.

Хәзергесен белмим, без беренче апрель – алдау көнен олы бәйрәм кебек, зарыгып көтеп тора идек. Чөнки ул көнне рәхәтләнеп алдашырга була, синә беркем дә үпкәләми. Ә башка көннәрне... Аллам сакласын! Әнкәем һич кенә дә алдашканны яратмый, кеше алдау – кичермәслек зур гөнаһ дип, гел колагыбызга киртләп тора иде. Менә шул – безнең өчен бәйрәм көнендә Мәдхиямал әбине рәхәтләнеп алдый идек инде! Ышана иде бичарам. Бездә мунча бар. Аларда юк. Шуңа да әнкәем мунча яккан саен Мәдхиямал әбигә дә дәштерә. Рәхәтләнеп, мунча кергәннән соң, кич буена чөкердәшеп, чәй эчеп, дөнья хәлләрен сөйләшеп утырырлар иде. Беренче апрель көннәренең берсендә мин Килен капкасыннан гына турылатып, Мәдхиямал әбиләр өенә килеп кердем дә ашыга-кабалана: «Әбекәй, әнкәй сине тиз генә мунчага килсен, юынырга үзенең мунчаласын онытмасын, коенырга комган белән җылы су да алсын диде...» – дип такылдадым да аны-моны сизенмәгәе дип, кире чыгып та чаптым. Кая ул! Мунча бөтенләй ягылмаган иде ул көнне... Алдавы рәхәт тә бит, утырам калтыранып, ни белән бетәрен көтеп. Менә берзаман өй ишеге ачылып китте дә тастымал, мунчала, комганын күтәреп, Мәдхиямал әби килеп керде. Керә-керешли үк: «Рәхмәт, килен, мунчаң өчен, бик кызу, шәп булды...» – димәсенме?! Әнкәем ык-мык итеп, югалып калды. Мин, болар куркуымны сизенеп өлгергәнче, карават астына шудым. Ятам көтеп... Ничә минут үткәндер (миңа бик озак тоелды!), кинәт икәүләшеп шаркылдап көләргә тотындылар.

«Юләр карчык, димә инде син мине, комган-мунчаласы бер хәл... – дип кеткелди Мәдхиямал әби: – Барып җиткәч, мунча ишеген ачып кара идең, тити баш! Юу-ук бит! Мунча өйалдында чишенеп, анадан тума барып керергә кирәк караңгы, салкын мунчага... Чукынчык кызый... Ничәмә-ничә алданмам дип сүз бирдем, тагын алдады бит мине, кара инде син, әй?!»

«Әйтмә дә инде син аны, Мәдхиямалтәй, ничә әйттем юкса, олы кешене алдарга ярамый дип...»

Шулай сөйләнә-сөйләнә, чынаяк-тәлинкә чылтыратып, чәй эчәргә тотындылар. Мин аларның «быдыр-быдырларын» тыңлап ята торгач, оеп йоклап киткәнмен...

Хәер, Мәдхиямал әби үзе дә шаяртуның кимен куймый иде. Элек

авылларда зурлап, өй тутырып, ашка җыю бар иде. Сугым суйсалар да, кемгәдер кунак «төшсә», кызыл туй, сайлау-мазар булса, армиягә китсәләр-кайтсалар да... Андый чакта, үзләрендәге тәлинкә-кашык җитмәү сәбәпле, күршеләрдән алып тору гадәте бар. Буталмасын өчен һәркемнең кашыгына тамга уелган була. Соңыннан аш үткәч тә әле, бу кашык безнеке түгел дип, тамгасын тикшереп, алыш-биреш ясап йөрерләр иде.

Сабый балалар гадәттә «р» авазын әйтә алмый. Ә минеке кешечә түгел, «с», «ш» урынына да – «т», «ч» урынына да – «т». Әллә чынлап, әллә юри әнкәем мине Мәдхиямал әбигә йомышка кертеп җибәрә:

«Бар, кызым, әбиеңнән кашыкларын сорап тор, ашка җыябыз диген... »

Килен капкасыннан турыга гына элдерәм. Керә-керешкә: «Әбекәй, әнкәй катык торады», – дип, аваз салам.

Чыгып китә әбием өйалдына чәркә тотып. Алып керә дә тулы бер чәркә катык, миңа суза. Ә мин чәбәләнәм, катык түгел, катык торады, дим. Соң, Алла бәндәсе, бирдем бит инде дигәндә, мин һаман, катык түгел, катык, дип тәкрарлыйм. Аптырагач, мич буена килеп, стенадагы агач җайланмага тезеп кыстырып куелган кашыкларга төртеп күрсәтәм.

«Ә-ә-ә, шулай диген аны, кашык диген, син бит катык дисең», – ди әбием, кет-кет көлеп...

Еллар үтеп, бераз исәеп, мәктәпкә сабак алырга йөри башлагач, әбекәем атна саен диярлек хат яздырырга керә. Икенче-өченче сыйныфларда гына укыган чагым. Укырга-язарга алдан ук өйрәнеп баргач, шактый «шомарган» булганмындыр, күрәмсең, миннән олырак апама түгел, хат язуны нигәдер миңа ышандыралар иде. Килеп утырам өстәл артына шакмаклы дәфтәр бите тотып, каләмемне карага манарга әзер.

«Әбекәй, ни языйм?» – дип сорыйм.

«Рәхмәтулла бәбекәем...» дигән җавап алам.

Мин башымны өстәлгә кырын салып, тырышып-тырышып, хәрефләп кабатлый-кабатлый «Рәхмәтулла бәбекәем»не язып бетерәм.

«Булды, әбекәй, тагын ни языйм?»

«Рәхмәтулла бәбекәем» диген, кызым...

Мин, өлкәннәр кушкан һәрбер эшне җиренә җиткереп үтәргә өйрәтелгән сабый, тагын шул ук «Рәхмәтулла бәбекәем»не матур итеп сырлап язып куям. Җавап та шул ук була. Бер хатка ничә мәртәбә язганмындыр «Рәхмәтулла бәбекәем»не?! Бик күптер, мөгаен. Юкса Мәдхиямал әби әйтеп торып яздырган хатлардан шул ике сүз мәңгелеккә күңелемә уелып калмас иде...

Авыл мәктәбендә укыганда да, соңрак укуымны «җәһәннәм чите – Казанда» (авыл кешесе үзе барып күрмәгән җирләрне шулай атый иде) дәвам иткәндә дә, Рәхмәтулла бәбекәемнең авылга кайтканын хәтерләмим. Әнә шул – сүз башыбызда телгә алган утыз яшенә җитеп тә һаман өйләнмәгән улы Әшрәфҗан белән гомер итте Мәдхиямал әби. «Ник һаман өйләнмисең?» – дип сораучыларга җавабы гел бер, имеш: «Инәй үлмичә өйләнмим, дүртпочмаклы кечкенә генә өйдә ике хатын-кызны талаштырып, сугыштырып ятасым юк...» Хәер, аның Сафура исемле кызы да булган, имеш. Тавык фермасында эшләгән. Шунда башына зыян килеп, зиһене чуалып, юләрләр йортына алып киткәннәр, имеш. Мин белә башлаганда,

тавык фермасы да, Сафура да юк, имеш-мимешләр генә бар иде. Имеш-мимешләрнең тагын берсе: «Мәдхиямалның сугыштан исән-имин кайткан ире Вәлиулла бәхет эзләп, ерак җирләргә киткән җиреннән маржага өйләнеп, шунда төпләнеп калган...» дигәне дә сүз уңаеннан дигәндәй, сирәк-мирәк булса да, ишетелгәләп куя иде. Әшрәфҗанның исә ялтырап торган башын мин яхшы хәтерлим.

Адәм баласының хәтере бик серле, сәер бит ул. Гомер барышында күргәннәреннән үзенә кирәклеләрен генә сайлап саклый. Әшрәфҗан башын хәтерләмәс тә идем, бәлкем, бик хикмәтле баш иде шул ул – сугыша торган. Икәү иде әле алар. Ю-ук! Икесе дә Әшрәфҗанныкы түгел. Хикәяләү барышында икенче баш иясенең исемен дә телгә алырбыз. Яңавыл дигән рус авылы турында сүз әйткән идем бит. Безнең авыл тирәли сай гына елга ага. Елганың бер яры безнеке булса, икенчесе – әнә шул Яңавылныкы. Елгабызның киң, тирән чаклары да булган. Су тегермәне эшләп торганда. Әнкәемә ияреп, он тарттырырга баргач күргән идем ул тегермәнне, зур бер агач тәгәрмәчнең елга суын күтәреп әйләндергәнен гаҗәпләнеп карап торганымны әз генә хәтерлим. Без су коеныр яшькә җиткәндә, тегермәннән җилләр искән, елга инде шактый саеккан, тездән су ярып, руслар ягына рәхәтләнеп чыгып була иде. Безнең авыл маллары, каз-үрдәкләре дә моны бик яхшы чамалый, күпме «ярамый-ярамый» дип чыбыклап торсаң да, тамак тәмугка кертер дигәндәй, гел шул ярамаган якка чыгу җаен карыйлар. Яңавылныкылар шуны гына көтеп тора, диярсең, атка атланган каравылчы килеп тә җитә, безнең авыл малларын куып алып та китә. Ә көн кичкә авышкач, безнең авыл ир-атлары җыелышып, малларын алырга бара. Анда ничек аңлаша торган булганнардыр, белмим, күп очракта Яңавыл халкы «аңлашырга» безнең авылга килә иде. Авылга дигәч тә, авыл эченә түгел, елганың аръягына, юан күсәк, сынык сәнәк, тырма сабы ишеләрне күтәреп. Безнекеләр дә су буена төшә. Һәм китә аңлашу... Колхоз эшеннән кайткач җыелыша торган булганнардыр. Мин караңгылыктан ишетелгән тавышларны гына хәтерлим. Ни өчен дисәң, без – бала-чагалар, әни-әбиләргә ияреп, тау башыннан карап, тыңлап тора идек. Кичке эңгердә «шак-шок», «дөп-док» иткән, кычкырган, ыңгырашкан, «бәр, давай», «яннан», «арттан» кебек тавышлар тын һаваны ярып, еракларга яңгырый. Җыелышкан хатын-кызлар «аһ-уһ» итә дә «Әнә, Әшрәфҗан баш белән бәрде...». «Монысы Мәсрур башы!» дип кычкырып җибәрә. Күп тә үтми, караңгылыкны ярып, атлар кешнәтеп, яңавылларның таралышканы ишетелә. Кайсының башы, кемнеңдер кулы бәйләнгән безнекеләр дә тауга күтәрелә башлый. Кемнәрнедер ике яктан култыклаганнар, кемдер үзе титаклый... Алар тау башына менеп җиткәнче, әниләр безне җитәкләп өйләребезгә таба алып китә. Шул рәвешле айлар-еллар буе аңлаша торгач, Яңавыл авылы юкка чыкты, кешеләре башка авылларга күченеп бетте...

Еллар үтә, без үсәбез, әти-әниләр, әби-бабайлар картая, берәм-берәм якты дөньяны ташлап, бакыйлыкка күчә тордылар. Андый хәбәрләрне мин йә үзем сирәк-мирәк авылга кайтканда, йә әнкәем хатлары аша белә идем. Авылга чираттагы кайтуымның берсендә әнкәем мине кайгылы хәбәр белән каршы алды. Бер ай элек Мәдхиямал әбиебез дөнья куйган. Миңа авыр булмасын дип, хатка язмыйча, кайтуымны көткәннәр.Чыннан да, авыр

булды аны югалту. Тәбәнәк кенә җыйнак гәүдәсе, бала итәкле күлмәге, күлмәге өстеннән бәйләп куелган – мәңге салынмый торган алъяпкычы, иңнәрен каплап торган чәчәкле яулыгы, һәрчак елмаюлы ачык йөзе, һәр көн диярлек Килен капкасыннан гына ялт итеп килеп керүләре...

Мәдхиямал әби китеп, бер-ике ай да үтми, «инәй үлмичә, өйләнмим» дигән Әшрәфҗан авылның түбән очыннан туйсыз-нисез генә, сазаган кызны алып кайтып та утырта, бер-ике атнадан аерып та җибәрә.

Әнкәем аның белән ныклап аралаша-белешә дә алмый калган, килен кеше урам ягыннан да, Килен капкасыннан да безгә кереп йөрмәгән. Әшрәфҗаннан курыккандыр, ахрысы, бичара. «Берәр нәрсәгә ачуы чыкса, баш белән генә әйләндереп җибәрә...» дип зарланган, имеш, теге сазаган.

Әнкәем дә, Әшрәфҗан абыйдан куркыптырмы, Мәдхиямал әбинең үлеменнән соң, Килен капкасын аркылы-торкылы такталар белән кадаклап, келәсен биклэп куйган.

Шул беренче уңышсыз тәҗрибәдән соң аллы-артлы тагын өч килен килеп китә әле бу йортка. Белмим, кемгә кайсы ягы килешмәгәндер, дөресен генә әйткәндә, мин үзем дә нишләптер аннан уттан курыккан кебек курка идем. Әле теге – кашык урынына катык сорап йөргән заманнарда ук йомыш белән Мәдхиямал әби янына кергән саен Әшрәфҗан абыйны гел бер – өй түрендә агач караватта кырын яткан хәлдә күрә идем. Ачык чырай күрсәтмәс, биргән сәламеңне алмас... Өй эченең бушлыгы, тупас кына итеп кулдан ясалган ике агач карават, иске сандык, ашъяулыксыз өстәл, пәрдәсез тәрәзәләр дә хәтеремдә. Әнисенә берәр эштә булышты микән, әмма ул колхоз эшенә йөрмәде шикелле. Эшкә әйтергә дип килгән бригадирга: «Мин колхоз эшенә йөрмим, әнә, урыс эшләсен...» дип кенә җавап биргән, диләр иде.

Дүрт хатынның тәмен татып караганнан, тирә-юньгә «хатын белән тора алмый» дигән даны таралганнан соң, елдан артык ялгызы яшәгән Әшрәфҗан, көннәрдән бер көнне, Башкортстан ягыннан бишенче кәләш алып кайта.

...Ашкынып, туган ягыма кайтып киләм. Үзебезнең Югары Оч урамына борылуга, йөрәгем җилкенебрәк тибә башлый. Мине урам як тәрәзәдән күреп алган әнкәем атылып урамга чыгар да каршыма килер... Менә өйләрне саный-саный, йөгерә-атлый кайта торгач, Мәдхиямал әбиләр турына җиттем. Бу нинди могҗиза?! Тәрәзәләргә чиккән ап-ак пәрдәләр эленгән түгелме?! Әнә, капкабыздан әнкәем килеп чыкты. «Бакчада чүп утый идем, кызым, күрми калганмын», – дип тәкрарлый-тәкрарлый, кочагыма ташланды. Елашып күрешүләр, сагынылган сөйләшүләр. Минем күңелне гел теге чигелгән ак пәрдәләр кытыклап тора. Җаен туры китереп, сүз арасына үземне кызыксындырган сорауны кыстырам: «Мәдхиямал әбинең тәрәзәсендә нинди чиккән пәрдәләр ул?» Күземә генә күрендеме янәсе...

«Юк, күзеңә ялгыш күренмәгән, – ди әнкәем. – Килен төште бит Мәдхиямал әбиеңә. Үзе генә күрми китте килен рәхәтен, мәрхүмәкәем... Әле син өй эчләренә керсәң?! Бөтен нәрсә чигүле. Мендәрләр, ишек, матча кашагалары, карават япмалары... Ул өендәге чисталык! Идәннәре сары май кебек! Пешергән ашлары җелекмени, телеңне йотарлык! Ул камырлары! Бик уңган булып чыкты Гөлсәрвәр килен...»

Икенче көнне иртән, чыш-пыш килеп, әкрен генә сөйләшкән тавышка уянып китсәм, әнкәем миңа таныш түгел яшь кенә бер ханым белән чәй эчеп утыра. Аны «ханым» димичә мөмкин дә түгелдер, эчкерсез ачык йөзеннән, үзенә килешле чиста-пөхтә киеменнән үк тәртипле, зыялы нәсел баласы икәнлеге сизелеп тора иде. Миңа таба борылып, бик тә йомшак, ягымлы тыныч тавыш белән, «Шушымыни инде Казан каласында гыйлем эстәүче, әнисен сагындыручы кыз...» дигәнен ишеткән мизгелдән, әллә кайчаннан белгән кебек, шунда ук ярата башладым мин аны. Юынып, өстәл янына килеп утыргач, күзләрендә нindидер әйтелмәгән сагыш, моң барын тоемладым.

«Сыйланып утырабыз, кызым, Гөлсәрвәр апаң өчпочмак пешергән... Кап-кайнар, телеңне йотарлык тәмле... Әйдә, син дә авыз ит...»

Сүз арасында әнием моңарчы әйтергә оныткан шатлыгы белән дә уртаклашты:

«Килен капкасын ачтык бит без, кызым, Гөлсәрвәр апаң белән... Мәдхиямал әбиең барындагы кебек...»

Күңелемнән бала чактагы хатирәләрне барлап, әнкәемнең әлеге хәбәреннән чиксез куанып куйдым.

Гөлсәрвәр апа саубуллашып чыгып киткәч, әнкәем кабат Килен капкасы турында сүз кузгатты.

«Бервакыт төнлә ачыргаланып елаган тавышка сискәнеп уянып киттем. Ишегалдына чыксам, Гөлсәрвәр килен, бичаракаем, ачмакчы булып, шул капка янында елап тора икән. Туңып беткән. Кышка кереп барган мәлләр иде. Менә шул төнне ачтык Килен капкасын... Көн яктысында капка янына якын барма, кызым, яме... Әшрәфҗан күрүе бар. Белмәсен. Үтерер...»

Мин куркып, шомланып киттем:

«Кемне?!»

«Йә Гөлсәрвәр апаңны, йә мине...». «Әшрәфҗанның җене котырганда, өеннән чыгып качып, Гөлсәрвәр апаң шул капкадан гына миңа кереп, төн үткәрә. Ел дәверенең кышы бар, җәе бар дигәндәй, гел күлмәкчән килеп керә бичара... Салкын тидереп, авырып та ятты. Җитмәсә, үтмәс хастасы да бар икән. Күкрәк бакасы. Астма, диләрме әле? Чирле икәнен белгәч, үз ягында кияүгә дә алмаганнар. Бала китерергә дә ярамый икән ул хаста белән. Кул күтәрә торган гадәте беленгәч, әллә эти-әниең янына кайтып китәсеңме, дигән идем, үлсәм дә кайтмыйм, авылдашлар алдында оятын кая куйыйм, ди бичаракаем... Миннән гел күркә ите ала. Шуның файдасы бар икән ди хастасына...»

Берничә көн авылда кунак булып, Казаныма кайткач та, уемнан чыкмады Гөлсәрвәр апа. Искә алган саен, күземнән яшь саркый. Күңелемне нindидер әйтеп аңлатып булмый торган сагыш катыш шом биләп ала. Кодрәтемнән килсә, үзем җилтерәтеп җитәкләп алыр идем дә туган ягына озатып, кадерләп үстергән газиз кызларын эти-әнисе кулына исән-имин килеш тапшырып кайтыр идем. Хат саен әнкәемнән Гөлсәрвәр апаның хәлен сорашам. Аның исә җавабы гел бертөрлерәк була: «Әлегә исән әле, кызым, элеккечә торып ята.Төннәрен капканың ябылганы юк...»

Ә чираттагы бер кайтуымда Килен капкасы тагын аркылы такта белән кадакланган, Гөлсәрвәр апа, Әшрәфҗаннан качып, туган якларына

кайтып киткән иде. Әти-әнисе башкорт ягына базарга барган безнең авыл кешеләрен очратып, танышып, хәл-әхвәлен белешкәннәр дә икенче көнне үк ат җигеп килеп, алып кайтып киткәннәр...

«И-и, кызым, аның иң хикмәтлесе шунда, буйга узган иде бит Гөлсәрвәр апаң, көмәне бар иде... Матур гына түгәрәкләнеп килә иде инде гәүдәсе... Врачлар тапмаска киңәш иткәннәр. Үләсең, дигәннәр... Киңәш-табыш сорап, миңа да сүз каткан иде дә бичаракаем. Мин ни актан, ни карадан өздереп, төпле киңәш бирә алмадым. Хәер, нинди генә киңәш бирсәң дә, тыңламас иде... Табам булгач, табам! Үлсәм үләм, карынымдагы баламның җанын кыймаячакмын, ди!.. Ана йөрәге, ана җаны... Бернишләр хәлләр юк... Ниләр эшләп беткәндер инде? Исәндерме-юктырмы? Ул якларга баручы-кайтучылар да күренми, ахрысы... Актан-карадан бер хәбәр дә килепирешми ичмасам... Бер-ике атнадан Әшрәфҗан барып караган, имеш, Гөлсәрвәр киленне кире алып китмәкче булып, авыл ир-атлары, җыелышып чыгып, әҗәлеңне монда табасың килмәсә, безнең авылга бүтән эз басма, дип, куып җибәргәннәр...»

Айлар узды, еллар узып бара... Мин кияүгә чыгып, башлы- күзле булып, үз мәшәкатьләремә чумгач, авылга кайтулар тагын да сирәгәйде. Әнкәем дә олыгайды. Хәзер яулыгын яшь киленнәрчә колак артына чөеп бәйләмичә, Мәдхиямал әби кебек иңнәрен ябып, ияк астына төенләп бәйләп йөри. Авыл да картая. Утсыз өйләр, кыйшайган капкалар, җимерек коймалар ишәя бара. Мәдхиямал әбинең өе дә шул исемлектә. Ишегалларын кычыткан, әрем, шайтан таягы басып киткән. Кадакланган Килен капкасы шул биек үләннәр арасына поскан. Бөтен ихаталарын, койма-капкаларын җанны тырный торган шыксыз сорылык чорнаган, кайчандыр гөрләп торган нигезнең коты киткән. Теге хәлләрдән соң, Рәхмәтулла бәбекәем яшәгән якларга бәхет эзләп чыгып киткән Әшрәфҗан абый авылга бүтән бер генә дә кайтып күренмәгән иде.

Безнең нигездә исә туганнарымның уртак тырышлыгы белән яңа өй калкып чыкты. Яңа өйгә яңа койма-капкалар да кирәк иде. Коймалар коелды, урам капка яңартылды. Әмма әнкәем Килен капкасына кагылырга рөхсәтен бирмәде, тимәгез, торсын, дип кырт кисте. Алланыкын кем белә, бәлкем, Гөлсәрвәр килен кайтып төшәр, ди. Мин исә, бәхәсләргә артык катнашмыйча, эчемнән генә әнкәем яклы булып утырдым...

...Менә тагын кайттым туган авылыма! Кендек каным тамган изге нигеземә. Газизләрдән дә газиз әнкәем янына. Бер күрешер өчен. Әй гомер, гомер! Көнләп санаганда, шактый озын кебек тоелса да, бигрәк кыска шул адәм баласының фанилыктагы гомере. Әнкәем әйтмешли, бер саплам җеп кебек кенә... Ул да олыгайды, биреште, бетеренште... Заманында таза имән кебек «шыгырдап» торган төз гәүдәсе җиргә таба иелә төшкән. Әнә ул, элеккечә гаярь ат шикелле капкадан атылып чыкмады, каяндыр табып алган кәкре таякка таянып, әкрен-салмак адымнар белән миңа таба атлый... «Әнкәемнең дә бәхилләшер вакытлары җитеп килә... » дигән саксыз уемнан йөрәгем «жу» итеп китте. Ни хәлләр итәсең, Гамәл китабына язылып куелган вакытың җиткәч, барыбыз да шунда барасы... Кемдер иртәрәк, кемдер соңрак.

Әнкәем белән чөкердәшә-чөкердәшә чәй эчкәндә, әллә кайчан гүр иясе

булган апамны да искә алдык. Әшрәфҗан абый да, элеккечә, шул китүеннән, әнкәем әйтмешли, «аҗаган алгандай» юкка чыккан, кайтып күренмәгән. Алар турындагы сүзебез Килен капкасына ялганып китте.

Килен капкасы да картая, кызым, эшсез торып... Син дә... елдан-ел бәлигъләна барасың, диимме, буй-сыныңа уйчанлык йөгергән...»

Аһ! Әнкәем! Ничек саклык белән генә искәртә минем дә олыгаеп баруымны! «Бәлигъләна барасың», «буй-сыныңа уйчанлык йөгергән»... Берәү булса, йөзгә бәреп, «картаясың» дип кенә әйтер иде югыйсә! Хәер, йөзгә бәрмичә дөрес эшли әнкәем. Мин үзем дә тоемлыйм кая таба барганымны. Инде икенче балам мәктәпкә җыена лабаса!

Чәйләп алганнан соң, бераз чүп утыйм дип, өй янындагы яшелчә бакчасына чыктым. Миңа әнкәем иярде. Койма ярыгына башларын тыгып, үзара без аңламаган телдә «ко-ко-ко» дип гәпләшеп, безнең сөйләшүгә күркәләр дә кушылды. Әтиле-әниле ике сыерчык, берсен-берсе узышып, ояда чыр-чу килешкән һәм мәңге туя белмәгән сары томшыклы балаларына җим ташый. Сарымсаклар баш калкыткан, суганнар тишелеп килә...

Үткәннәргә бүгенгеләрне кушып сөйләшә-сөйләшә онытылып эшләп яткан җирдән шыгырт иткән тавышка кинәт сискәнеп, икебез берьюлы диярлек тураеп, тавыш килгән якка ялт борылып карадык. Койма буенда озын булып үскән куе ботаклы чия агачлары арасыннан капка да, шыгырт тавышының иясе дә күренми, әмма Мәдхиямал әбиләр ягыннан кемдер Килен капкасын ачарга азаплана иде. Командага буйсынгандай, йөгерешеп барып, үзебезнең яктан капкага барып ябыштык...

Бергәләп тырыша торгач, Килен капкасы ыңгырашкан тавыш чыгарып, кинәт ачылып китте. Күз алдыбызда пәйда булган нәфис буй-сынлы чибәр солдат егетне күреп, телсез-өнсез калдык. Бер-беребезгә карашып торган, шактый озак кебек тоелган сүзсез мизгелдән соң, өчебез беравыздан диярлек «Исәнмесез...» дидек тә тагын тынып калдык. Бу юлы тынлыкны нәфис буй-сын иясе бүлде: «Рөхсәттер бит... – диде ул, үзе кебек үк тыйнак тавыш белән. – Менә мәрхүмә әнием васыяте буенча Килен капкасын күреп китим дип килдем. Рүзәл мин... Гөлсәрвәрнең улы... Әби-бабай янына отпускага кайткан идем. Капка турында алар сөйләгәнне бик кечкенә чактан ишетеп үстем. Моңарчы ничектер җай чыкмады. Әнием мине тапканда, бакыйлыкка күчкән... «Улым үскәч, мине караңгылыктан яктылыкка чыгарган, яшәү көче биргән Килен капкасын барып күрсен, изге капка хуҗасына Аллаһымның чиксез рәхмәтләрен ирештереп, баш исен» дип әйтеп калдырган».

Ул сүзләрен әйтеп бетерер-бетермәс, менә-менә яшь бөртекләре тәгәрәп төшәм дип торган сөрмәле моңсу күзләре белән түбәнгә карады һәм әнкәем алдына тезләнде...

«Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә язучылар, галимнәр, музыка белгечләре һәм журналистлар катнашында уткәрелгән «түгәрәк өстәл» сөйләшүендә катнашучылар (утырганнар, уңнан сулга): баш редактор Шәмси Хамматов, Юрий Белостоцкий, Сибгат Хәким, Хәсән Хәйри, Зәйнәп Хәйруллина, Гомәр Бәширов, Хатип Госман, Мөхәммәт Садри, Риза Ишморат, Нәби Дәүли; басканнар – Зиннур Мансуров, Шамил Маннапов, Рафаэль Мостафин, Флүн Мусин, Нил Юзиев, Ил Саттар, Илдар Юзеев, Әмин Раков. 1980 ел, декабрь.

Композитор, педагог, Социалистик Хезмәт Герое, СССРның халык артисты, СССРның һәм Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премияләре лауреаты, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Нәҗип Җиһанов. Аның тууына 110 ел.

Роза Кожевникова (1950-2007). Шагыйрә, тәрҗемәче, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, М.Горький исемендәге әдәби премия лауреаты.

Казан дәүләт педагогия институтының татар әдәбияты кафедрасында (уңнан сулга, беренче рәттә): Эльмира Галиева, Фәрит Хатипов, Мәдинә Җәләлиева, Гөлнур Билалова; икенче рәттә – Әмир Мәхмүдов, Равил Рахмани, Фоат Галимуллин, Рифат Сверигин. Үткән гасырның 90нчы еллары.



Ринат Мәннан – шагыйрь һәм табиб. Бу айда аңа 75 яшь тулды.

Редакциябезгә шагыйрьләр җыелган. Утырып торалар (сулдан уңга): Рәдиф Гаташ, Равил Фәйзуллин; басып торалар: Мөдәррис Әгъләмов, Марат Кәбиров, Наис Гамбәр, Зөлфәт. 2004 ел.

Сәхифәне **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

Җәлил әнисе Рәхимә һәм сеңлесе Хәдичә белән. 1926 ел.

Дуслар җыелган җирдә. Утырганнар: Ф.Ильская, Ә.Ерикәй; басканнар: Ф.Бурнаш, М.Җәлил.

БАР ҖЫРЫМНЫ ИЛГӘ БАГЫШЛАДЫМ...

Татар халкының каһарман улы Муса Җәлилнең тууына 115 ел тулу уңаеннан Татарстан радиосы үзенең эфирында «Җәлил атналыгы» игълан итте. Дөрес, аның әсәрләре һәм шагыйрьгә багышланган тапшырулар болай да әледән-әле тыңлаучыларыбыз хозурына чыга. Шулай булырга тиеш тә. Беренчедән, Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең тиңсез батырлыгын хәтердә яңарту яшьләребез күңелендә милли горурлык хисләрен куәтләндерү өчен кирәк булса, икенчедән, халкыбызның гаярь бер кавем булуын башка халыкларга да белдерергә тиешбез.

Эфирда Җәлил атналыгын игълан итү безгә шушы эшне тагын да җанландырырга мөмкинлек бирде. Шагыйрьгә багышланган яңа тапшырулар белән беррәттән, 70 ел вакыт эчендә тупланган фонд язмалары хәрәкәткә килде. Бездә Җәлилгә бәйле аудиомирас шактый ук саллы урын алып тора. Болар – нәфис сүз осталары башкаруындагы шигырьләр, аларга иң затлы композиторлар иҗат иткән җырлар, «Алтынчәч» операсының сәхнәдән язып алынган концерт варианты; шагыйрьнең юбилей кичәләреннән, аңа багышланган төрле чаралардан, җәлилчеләрне искә алу митингларыннан репортажлар; Җәлил һәм аның көрәштәшләре образларын гәүдәләндергән әсәрләр; күренекле шәхесләребез турында язып калдырган истәлекләр һ.б.

«Казан утлары» журналы белән бергәлектә әзерләнә торган сәхифәбезнең бу чыгарылышында «Җәлил атналыгы» вакытында яңгыраган берничә язманы урнаштырырга булдык. Аларның беренчесендә сез мәшһүр җырчыбыз Усман Әлмиевның тавышын ишетерсез. Ул 1935 елда Мәскәү консерваториясе каршында ачылган татар опера студиясендә укый һәм менә шул вакытларда Муса Җәлил белән аралаша. Казанга кайткач, Нәҗип Җиһановның Муса Җәлил либреттосына язган «Алтынчәч» операсын куярга әзерлек башланып китә. Шагыйрь җырчыга Урмай партиясен башкаруга кагылышлы киңәшләрен бирә. Язмада менә шушы хәлләр бәян ителә.

Аннары Муса Җәлилнең исемен аклауга биниһая зур өлеш керткән язучы Гази Кашшаф истәлекләрен тыңларсыз. Ул биредә шагыйрьнең төрмәдәге камерадашы, «Моабит дәфтәрләре»нең бер өлешен саклап калган һәм Совет илчелегенә тапшырган игелекле Бельгия кешесе Андре Тиммерманс белән Мәскәүдә очрашуы турында сөйли.

Язманың өченче өлешендә исә Муса Җәлил шигырьләрен Габдулла Шамуков, Ринат Таҗетдинов, Фатих Колбарисов, Айрат Арсланов, Рәшидә Җиһаншина, Гәүһәр Камалова һәм Шәхсәнәм Әсфәндиярова язмасында ишетерсез.

Рәшит Ягъфәровның тууына – 75 ел

ХАЛКЫМ ДИП ЯНЫП ЯШӘДЕ

Күренекле фольклорчы галим, шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Рәшит Ягъфәров фәнни эшчәнлеге, әдәби иҗаты һәм Татар иҗтимагый үзәгендә алып барган бетмәс-төкәнмәс эшләре белән беррәттән, Татарстан радиосында да даими тапшырулар эшләргә вакыт таба иде. Кайвакыт ул биредә штатта кебек тоела башлый: әзерләп алып килгән язмаларын үзе үк эшкәртә, монтажлауда катнаша иде.

Фольклорчы буларак, Рәшит Фәйзрахман улы Советлар Союзының татарлар тупланып яшәгән төрле төбәкләренә экспедицияләр оештырды. Гыйльми сәфәрләреннән ул магнитофон язмалары төяп кайта. Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез тормышын яктырта торган «Кардәшлек» дигән тапшырулар циклы әнә шулай туды.

Татарстан радиосы фондында аның сәясәтче буларак ясаган публицистик чыгышлары, нәфис сүз осталары укуындагы шигырьләре саклана. Тыңлаучыларыбыз һәрвакыт көтеп ала торган тагын бер иш язмалары – балалар фольклорына багышланган тапшырулар шәлкеме.

Рәшит Ягъфәров мирасы турында сүз чыкканда без, әлбәттә, иң әүвәл аның милли бәйрәмнәребез турындагы радиокомпозицияләрен искә төшерәбез. Алар ел саен кабатланып, әле дә халыкка хезмәт итә. Бу композицияләрне Рәшит Ягъфәров туксанынчы елларда фольклор экспедицияләрендә табылган материалларга нигезләнеп әзерләгән. Бу сәнгать әсәрләрендә милли бәйрәмнәребезнең асылы, аларны үткәрү тәртибе дә аңлатып бирелә. Ул елларда тормышыбызга әле кайта гына башлаган Нардуган, Нәүруз, Карга боткасы бәйрәмнәрен оештыручылар өчен бу тапшырулар ярдәмлек булды.

Галим һәм язучы Рәшит Ягъфәровның якты рухын искә алып, әйдәгез, шушы композицияләрнең берсен тыңлыйк. Көн белән төн тигезләшкән вакыт – төрки халыкларның Яңа елы якынлашуын искә алып, «Нәүруз»гә тукталырбыз. Композициядә Рәшит Ягъфәров үзе һәм радио режиссёры Әлфия Гыйләҗи катнаша, диктор Тәлгать Хаматшин алып бара, мөхәррире – Рөстәм Акъегет.

Сәхифәне Татарстан радиосының шеф-мөхәррире **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

БЕР БИТЕ – ШӘРЫК, БЕР БИТЕ – ГАРЕП...

Язучы Фәүзия Бәйрәмованың бөек кыргыз әдибе Чыңгыз Айтматовның әнисе Нәгыймә турында китап язуын ишетсәк тә, читтә яшәгәч, кулга алып уку насыйп булмаган иде. Рәхмәт төшсен, «Казан утлары» (2020 ел, 12 нче сан) журналы мондый мөмкинлекне бирде. Документаль проза кысаларында автор «халыкка Нәгыймә Айтматова һәм аның нәселе турында мөмкин кадәр тулы мәгълүмат җиткерергә тырыштым» дигән тыйнак максат куйса да, әсәр югары эстетик дәрәҗәдә һәм трагизм элементлары белән язылган, дулкынландыра...

Фәүзия Бәйрәмова халкыбыз, милләт язмышына багышланган иң матур әсәрләрендә ил өстендәге мәкерле социаль чирләргә, кыерсытуга, таркаулыкка, сатлык-хыянәткә түзмичә җан ачысы белән кычкыра, оран сала. Ул – университет буенча шәриктәшем мәрхүм язучы Рафаэль Сибат бик яратып кулланган сүз белән әйтсәк, катлаулы симбиоз иясе.

Нәфис затның бер бите әхлак нурларын чәчкән шәрык булса, икенче бите хөрлек, иркенлек идеяләре белән рухланган гарепне искә төшерә. Ул – югары эстетик тойгылар, якты идеал белән эш иткән каләм иясе. Тик аны һәркем шулай дип беләме, бәялиме – читтә яшәгән кешеләргә караңгы, әмма язылган, басылганнарыннан чыгып, мин үзем Фәүзия ханымны татар әдәбиятының иң көчле вәкиле дип саныйм.

«Ана» әсәреннән укучы күңеленә сеңдерелгән иң беренче һәм олы тойгы – халкың белән горурлану. Аны автор тирәннән, тарих төпкеленнән үстереп килә, шәҗәрәләр, нәсел тарихлары аша нигезләп, күркәм затлар мисалындараслый.

Иң алга Ишмән нәселендәге Хәмзә Габделвәлиев килеп чыга. Ул 1860 елда Татарстанның Кукмара районы Мәчкәрә авылында туган, 1880 елда Ыссык-күл буендагы Каракол каласында төпләнеп, Газизәбану исемле кызга өйләнгән һәм Кыргызстан җирендә тамыр җибәргән. Бу шәхес үзен булдыклы эшмәкәр итеп таныткан, каладагы мәгариф, мәдәният үсешенә ныклы өлеш керткән, хәтта бу як халкын алма үстерергә өйрәткән иҗтиһатлы кеше.

Хәмзә белән Газизәнең 8 бала арасындагы Нәгыймә 1904 елның 7 декабрендә туа. Әнисенә охшап, яшькелт күзле, ак йөзле бик чибәр булган кыз җитеш, хәтта бай гаилә шартларында үсә. Мәчет каршындагы мәдрәсәдә белем ала, рус телендәге кызлар гимназиясендә дә укый, махсус курс тәмамлап, стенографист һөнәрен үзләштерә.

Авторның Нәгыймәне кәләш итеп тасвирлауга зур урын бирүе акланган. Тик кыз әти-әнисе теләгәнчә, үз тиңе татар егетенә кияүгә чыга алмый. Нәзакәтле Сөембикәләр заманы күптән узган инде. 1925 елда кыргыз егете, үсеп килүче партия-совет хезмәткәре Түрәкол Айтматовка никахлы хатын булып китә. Ул «республикада һәм җәмгыятьтә билгеле кеше була. Тышкы кыяфәте белән дә сөйкемле, озын буйлы, яхшы холыклы егет».

Язучының бай кызы Нәгыймәне аның янәшәсенә китереп бастыруы һәм «кызыл яулыклы» кәләш итеп күрүе шул замана рухына туры килә. Ренат Харис әйткәнчә, «замана юа да мана, юа да мана» бит...

Дөньякүләм танылган язучы, зур-зур дәүләт бүләкләре лауреаты Чыңгыз Айтматов әнә шул парның мәхәббәт җимеше булып тора да бит инде. Нәгыймә – татар милләте үстергән кыз, бөек әдипне тудырган, тәрбияләп үстергән АНА. Бу безнең өчен чиксез горурлык, сөенеч уята торган факт. Аны күп төрле дәлилләр, чыганаклар, тормыш

күренешләре аша ышандырып күрсәтүе, каләм фидакарьлеге өчен укучының авторга рәхмәте үтә дә зур.

Ә соң Ф.Бәйрәмованың каләм мөһере – оран, әрнешле тавыш монда бармы?

Чит мәмләкәткә барып, сөрән салу килешмәс, диюче дә булыр. Әмма мәдхиягә генә корылса, ул Бәйрәмова әсәре дә булмас иде шул. Укучы монда да аның әрнүле җан ачысын, нәфрәтләнү авазларын яхшы сизә. Атап әйткәндә, беренче чиратта ул илдәге геноцид сәясәтенә кагыла. Татар башына бигрәк афәтле кырау булып төшкән шул ул. Нәгыймәнең атасы да, туганнары да, ире дә, хәтта балалары да аның зәһәр котырынуыннан үлем-китем кичергәннәр, яисә әрнү-югалту, кимлек-хурлыклар күргәннәр. Шомлы егерме ел ирен көтеп тилмергән Нәгыймәнең йөрәген талый. «Әнисенең бу хәле Чыңгызны соң дәрәҗәдә тетрәндерә... якты образын күңелендә генә түгел, әдәбиятта да мәңгеләштерү өчен үзенең данлыклы «Анам кыры» әсәрен яза», дип искәртә Бәйрәмова. Язучының бу вакытны онытырга ярамый, геноцид яңадан баш күтәрмәсен өчен уяу булырга, аңа каршы көрәшергә кирәк, дигән чакыруын ачык тоя укучы.

«Ана» романы авторының милләттәше, җенестәше язмышына карап уйлануларында да аерым ризасызлыклар, дәгъвалар барлыгын сизә укучы. «Кыргыз халкында ата культы, ир-ат культы өстенлек итүе нык сизелә, хатын-кызның, ананың роле бәяләп бетерелми кебек», дип әйтеп үтә автор. Чынлап та, Нәгыймә Айтматованың биографиясе язылмаган, байтак документлар эзсез югалган. Нәгыймә апаның «Туган тел» оешмасы тарафыннан үткәрелгән 100 еллык юбилеенда да хөкүмәт вәкилләре, зыялылар, дин әһелләре катнашмаганнар. Хәер, Чыңгыз Айтматов үзе дә әнисенең бай, мәшһүр татар нәселеннән булуын озак вакыт ачыктан-ачык белдермәгән. Аның улы да, кызы да истәлекләрне атага, бабакайга атап язганнар, ә ана һаман читтә калган. Аеруча эч пошырганы шул: Чыңгыз Айтматовны тудырган АНАның музее төзелмәгән...

Кыргызстанда китапны әзерләү чорында Ф.Бәйрәмова боларның барысы хакында да сүз кузгата, үзенчә чаң кага. Кыскасы, безнең Фәүзия, Нәгыймә хакын хаклап, Чыңгыз Айтматов әсәрендәге нәфрәтләнеп тамгаланган маңкортлык белән кыргызның үз маңкортлыгын кыйратып сала. Шунысы сөенечле: оран салу бушка китми. Нәгыймә Айтматованың 110 еллык юбилеен зурлап, бик матурлап уздыралар. Нәгыймә апа туып үскән Каракол шәһәрендә Айтматовлар гаиләсенең шәхси музее ачыла. 2000 елда бөек кыргыз язучысы кунак булып, Казанга килә, бик матур очрашулар үткәрә... Менә бит чын язучы тормышны күзәтеп, тасвирлап кына калмый, ә аны гаделлек, матурлык таләпләренә туры китереп үзгәртүдә дә катнаша! Романтик шагыйрь Харрас Әюп юкка гына «Фәүзия яулыгы»н әләм кебек күреп, безнең кайбер ирләр башына бәйләтергә ымсынмаган икән шул! Шөкер, яулыкны җилләр алмаган, давыл очырмаган әле...

Шулай да әсәргә дәгъвам бар. Авторга документаль проза поэтикасы хакында житди уйлану кирәк. Романның һәр битендә диярлек төрле чыганаклардан алынган зур-зур өзекләр урын ала. Җитмәсә, алар рус телендә бирелә. Бу кыяфәтендә укучы әсәрне ничек кабул итәр соң? Суынуы да бик ихтимал. Туган тел сафлыгы өчен көрәш барган бер вакытта язучының корама, катнаш телгә юл куюын мин кабул итә алмыйм. Шуның белән бергә нәфис әдәбият әсәре фәнни хезмәт тә түгел, аны цитаталар, астөшермәләр белән бизәү әдәби иҗат канунына туры килми. Мәгълүмат артыннан кумыйча, романдагы сурәтлелекне көчәйтү дә зыян итмәс иде, шәт. Онытмыйк, сюжет, композиция кору маһирлыгы – документаль проза иҗатчысын да бизи торган сыйфат, ничек кенә аерма, сүз сәнгате булып кала бит ул.

Язучының яшьлек елларында иҗат ителгән «Болын» китабы сәнгатьчә эшләнеш ягыннан килешлерәк иде. Уйлан, каләмдәш, уйлан... Тел кадерен сакла!

Сәгыйдулла ХАФИЗОВ.
Башкортстан.

БАКЫРГА УЕЛГАН УЙЛАР...



Бакырга чүкеп ясалган декоратив фантазияләр – йөз егермедән артык катлаулы һәм зур картиналар авторы Александр Ивановның Казан үзәгендәге Яңа татар бистәсендә урнашкан Шиһабетдин Мәрҗани йортындагы остаханәсендә вакыт агышы тукталып калгандай тоела, аның каравы аң-акыл тизрәк хәрәкәт итә башлый. Монда бакыр җанлана, гүя дөньяга аваз сала. Үткән белән бүгенге, чынбарлык белән хыял арасында күпер хасил була.

Рәссамга аның иҗат юлы, ничек итеп Казанга күченеп килүе, темалар төрлелеге турында сорауларымны җиткергән арада да остаханә ишеге ябылып тормый. Кешеләр килә... Татар тарихы, ау, дин, сугыш, галәм, Тукай әсәрләре бакыр аша безгә дәшә. Диварларда гына урын җитмәгәнгә идәнгә дә тезелгән сәнгать әсәрләрен кемдер шаккатып, кемдер уйга чумып күзәтә. Шунысы хак: берәү дә битараф калмый. Тик остаханәгә ялганып киткән күргәзмә бүлмәсендәге кысанлык картиналарны карау мөмкинлеген чикли. Иркен зал кирәклеге күренеп тора...

Татарга тимер якын, дигәннәре хактыр, күрәсең. Борынгыдан килгән зәркәнчелегебез дә, тәрәзә йөзлекләре, ишек-капкалар, диварларны тимер бизәкләр белән матурлап эшләү дә милли архитектура һәм һөнәрчелегебезнең шактый үзенчәлекле катламы. Буыннан буынга тапшырылган эшнең югалмавы үзе үк игътибарга лаек фал. Тимер ныклыгын да буйсындырган осталарның үткен карашы сәнгать могҗизасын тудыра.

– Зур һөнәри осталык таләп иткән сәнгать төре: бакырга чүкеп, кабатланмас җәүһәрләр тудыру эше тамырлары белән Болгар дәүләте чорларына ук барып тоташа. Александр әфәнде, әлеге тарихи сәнгать төрендә кайчан иҗат итә башладыгыз? Тукай районы Мартыш авылында туып-үскән егетнең иҗат юлына беренче адым атлаган вакытларын искә алыйк әле?

– Һәр кеше үз сәләте белән туа һәм һәр бала кечкенәдән тормышның кайсы да булса өлкәсенә омтыла. Мин башкалардан рәсем ясарга яратуым белән аерылып тора идем. Кечкенә чакта бер төш күрдем. Авылда иптәш малай белән аклык бөркелеп торган өй эченә кердек. Ә анда озын буйлы ак киемле бер бабай түрдән үк кулын сузып, мине үз янына чакырды. Киштәдә тезелгән китапларга карап, ым какты. Алар арасында иң соңгысы – «Мөхәммәд Пәйгамбәр» исемле китап... Шуны укырга кушты. Ул бабайны берничә тапкыр кабаттан төштә күрдем әле. Армиядә хезмәт иткән вакытта, йокыдан уяткандай булды. Караватым янында басып тора. Күзләремә туп-туры карады да: «Әтиең үлде бит», – ди. Бу төшләр аша кергән Ак бабай миңа ниндидер фәрештә сыман тоелды. Гадәти төшләр түгел иде алар... Шул чакта, әйтерсең галәм белән тоташам.

Бөек көчкә, безне барлыкка китерүчегә ышанам. Кеше бу дөньяга юкка гына килмәгән. Һәркем үзенә юл сала-сала сынала. Һәм һәр кешедә илаһи бер оеткы бар дип саныйм.

– Күңелләрендә илаһилыкны үстерә белгәннәр үз омтылышларын тормышка ашыруда уңышка ирешәдер. Тик сәләт кенә җитми бит, юл күрсәтүче остаз да кирәк...

– Армия сафларында хезмәт итеп кайткач, Түбән Кама шәһәренә чыгып киттем,

янгын сүндерү хезмәтенә эшкә урнаштым. Шул вакытта Түбән Камада рәссамнар остаханәсе барлыгын ишеттем, кызыксынып танышырга бардым. Остаханә җитәкчесе грузин милләтеннән Арчуашвили Георгий Владимирович – танылган һөнәрче, рәсем остасы, Казаннан Түбән Камага күченеп, шушында иҗат итеп яши иде. Эшләрен күреп таң калдым һәм аның остаханәсендә укуым белән горурланам. Юлымда очрап, сәнгать буенча дөрес юнәлеш бирүе бик вакытлы булган. Махсус белем йортларына укырга кереп, сәләтемне үстерү өстендә эшләмәдем. Иҗат эшенә артык бирелгән идем. Үземне һәвәскәр дип атый алам.

– Үзегезнең шушы осталыгыгызны кемнәргәдер тапшырдыгызмы әле?

– Бакыр, тимергә чүкеп рәсем ясаучы осталар сирәк. Татарстанда мин берүзем. Киләчәккә максатларымның берсе – бакырга чүкеп, рәсем ясау буенча дәресләр оештыру. Бәлки, Казан сынлы сәнгать училищесында мондый мөмкинлек табылыр дип тә, шушы юнәлештә эш башладым. Һөнәрне дәвам итәрлек укучылар бик кирәк. Иҗатның бу төре татар сәнгатенең визит карточкасы булып китә алыр иде.

– Гамәли-сәнгать төре җәүһәрләренең дөньякүләм күргәзмәсе оештырыла һәм анда бары тик бер генә картинагызны алып бару мөмкин, дисәләр, кайсы эшегез сезнең белән юлга чыгачак?

– Аларның һәркайсы рухымнан өзелеп төшкән, һәркайсы миңа якын, кадерле. Әмма бер генә картина хакында сүз барса, һичшиксез милли темага багышланганын алып барып, дөнья халкына күрсәтер идем. Халыкның кем булуы турында иң беренче чиратта аның сәнгате, мәдәнияте, әдәбияты һәм тарихы сөйли.

– Кырык биш еллык иҗади гомерегездә күргәзмәләрдә дә шактый күп катнашкансыз. Шәхси күргәзмәләрегез Казан, Түбән Кама, Түбән Новгород, Чабаксар, Уфа, Саранск, Ижевскида узган. Аларда халыкның да, сәнгать белгечләренең дә фикерләрен ишеткәннән соң, үзегез өчен нинди нәтиҗәләр ясыйсыз?

– Күргәзмәләрне аеруча яратам. Иҗат кешеләренә саф җил агышы, кояш яктысы кебек кирәк бит ул мәгънәле фикерләр ишетү. Иҗатның аерым бер этабына нәтиҗә ясау өчен күргәзмәләр оештыру бик мөһим. Кешеләрнең соклануын күрү, киләчәктә илһамланып, яңа темаларга тотыныр өчен бер этәргеч була. Мактауны, тәнкыйтьне – һәр фикергә колак салам.

– Бер түгәрәк өстәл утырышында сәнгать белгече Розалина Шаһиева: «Александр Иванов – татар халкының бөек традицияләренә нигезләнгән зур эшне дәвам иттерүче оста. Бу бик катлаулы һәм күп көч таләп итә торган хезмәт. Александр Иванов картиналары аша без татар эпосы геройлары, легендар шәхесләр, фантастик образлар белән дә очрашабыз. Бу әсәрләрнең әһәмияте мөһим. Аларны күбрәк кеше күрсен өчен Алтын йорт булдыру кирәк дип уйлыйм. Билгеле булганча, сәнгать, мәдәният саклауга мохтаҗ», – дип ассызыклап узган иде.

– Эшләремне чит илләрдәге шәхси күргәзмәләргә сатып алырга теләүчеләр дә бар. Әмма картиналарымның Татарстанда калуын һәм нәкъ менә татар халкы хәзинәсен баетуын телим. Бәлки, Изге Болгар җирендә булыр ул галерея, бәлки, нәкъ менә шушында, Казанның йөрәк тибеше ишетелеп торган Кабан күле янында... Вакыт күрсәтер...

Әңгәмәдәш – **Айсылу ИМАМИЕВА**

Бу QR-код аша сайтыбызга кереп,
Александр Ивановның картиналарын карый аласыз.

РОССИЯДӘ ХАЛЫК САНЫН АЛУ ТАРИХЫ

ТАТАР ХАЛКЫ ҺӘМ АНЫҢ ТӨРКЕМНӘРЕ (XVI – XVII ГАСЫРЛАР)

Бүгенге Россия җирләрендә беренче җанисәпне Алтын Урда хакимияте оештырган. Урта гасырларда ул салым җыю, шул рәвешле дәүләтнең көчен һәм куәтен арттыруга хезмәт иткән. Алтын Урдада, шул исәптән Болгар һәм Урыс олысында, гомум халык санын алулар 1246-1259, 1273 һәм 1287 елларда уздырылган. Бу хакта мәгълүмат рус елъязмаларында сакланып калган.

Алтын Урда таркалгач, Мәскәү дәүләте XVI – XVII гасырларда бу традицияне дәвам иткән, ләкин җанисәп илкүләм түгел, аерым төбәкләрдә генә уздырылып, махсус кенәгәләргә («писцовая книга») теркәлгән. Алар төрле: җирне исәпкә алу, җир биләмәләрен бүлеп бирү һәм аларны рәсмиләштерү, халык санын теркәүгә бәйле кадастр хезмәтен үтәгәннәре дә, нотариаль-юридик хокуклы теркәү документлары, мәгълүмати белешмәлекләр рәвешендәгеләре дә бар.

1552 елны Казан каласы егылгач, төбәк белән идарә итү өчен Мәскәүдә «Казан ызбасы», аннары Казан сарае приказы төзелә. Аның карамагына элекке Казан һәм Хаҗитархан, ә 1590 еллардан соң Себер ханлыклары җирләре тапшырыла. 1637 елны Себер сарае приказы төзелгәч һәм элекке Әстерхан (Хаҗитархан) ханлыгы җирләрен Илчелек приказына тапшыргач, Казан сарае приказы карамагында Урта Идел, Мещера, Урал (Уфа өязе) һәм Түбән Новгород төбәкләре кала. Шушы идарә системасы 1708 елны Россиядә губерналар оешканчы саклана.

Кызганычка каршы, шушы төбәкләрнең тарихы һәм көнкүрешенә караган барлык документларны үзенә туплаган Казан сарае приказында берничә тапкыр янгын чыга, 1737 елны ул тулысынча янып бетә. Җанисәп кәгазьләренең дә бер өлеше генә сакланып кала.

Бу текстлардан киңкырлы тарихи мәгълүмат җыярга мөмкин. Төбәкнең икътисади үсеше, колонизацияләү барышы, эчке миграция, дәүләтнең төрле катлам вәкилләренә, җирле халыкларга карата сәясәте, җирләрнең хуҗалык ягыннан үзләштерелү барышы, авылларның урнашуы, аларда яшәгән кешеләр саны, гомумән, җирле җәмгыятьнең социаль структурасын ачыклау һ.б. шундыйлардан.

Казан егылгач яңа хакимият, идарә эшен җайга салу өчен, ханлык җирләрен ике өлешкә аера: Иделнең сул як ярындагы җирләр Казан өязе дип, ә сул яры биләмәләре (Тау ягы) Зөя өязе дип атала башлый, соңрак аларга өченче – Чабаксар өязе өстәлә.

XVI гасырның икенче яртысы – XVII йөздә җир бүлү һәм җанисәп кебек чаралар дәүләт тарафыннан егермеләп тапкыр уздырыла. Биредә хакимият гел тикшереп, халык санын алып торган икән дип уйларга нигез юк. Эш шунда ки, 1646 елга кадәр Мәскәү дәүләтендә хөкүмәт салымны кешегә беркетелгән җир мәйданыннан чыгып билгеләгән. Идел-Чулман төбәген колонизацияләү актив, еш кына дулкын-дулкын барган. Баш күтәрүләр вакытында үзәк өязләрдән йомышлылар (гаскәриләр) күпләп күчерелгән, аларны җир биләмәләре белән тәэмин итәргә, чиркәү-монастырьларга патша биргән яңа җирләрнең чикләрен билгеләргә, күченгән крестьяннар урнашкан урыннарны ясак салу өчен теркәргә кирәк булган. Димәк, биләмәләр бирү һәм теркәү материаллары бер үк вакытта кешенең җиргә хокукынраслаучы, шулай ук салым түләү күләмен һәм халык санын билгеләү кәгазе хезмәтен үтәгән. Әйтик, Урта Идел

төбәгендә шундый масштаблы җир бүлү 1591-1592 елларда башкарылган, әмма документлары сакланмаган.

Сакланганнарының иң борынгылары – Н.В.Борисов-Бороздин, Д.А.Кикин һәм аларның хезмәттәшләре тарафыннан 1565-1568 елларда Казан һәм Зөя өязләрендә, кирмәннәрдә, шәһәрләрдә, монастырьларда уздырылган халык санын теркәү документлары. Бүгенге көнгә Казан өязе буенча төзелгән документларның өч күчермәсе билгеле, алар өлешчә төрле елларда дөнья күрде. Бу кыйммәтле чыганакның өч күчермәсен дә берләштергән иң тулы текст 2006 елны Д.Г.Мостафина тарафыннан әзерләп бастырылды *(Писцовое описание Казани и Казанского уезда 1565–1568 годов: публикация текста. Казань, 2006. 660 с.)*.

Зөя өязе буенча кульъязма 1909 елны *(История Татарии в документах и материалах. М., 1937. Сс. 97–98, 189, 221)*, ә Зөя һәм Лаеш шәһәрләре буенча иң тулы текстлар 2002 елны *(Города России XVI века: материалы писцовых описаний / изд. подг. Е.Б. Французовой. М., 2002. С. 337–394)* дөнья күрде.

1597–1600 елларда элек төзелгән җирбиләү тасвирламаларына тикшерү уздырган (дозор кенәгәләре) статистик чара уздырыла, ул баш күтәрүләргә бәйле халык саны кимү яки башка төбәккә күченү нәтиҗәсендә буш калган авылларны ачыклау максатын куя. Билгеле булганча, Идел-Чулман төбәге җирләренең төп өлеше дәүләт карамагында булып, бер өлеше патшаның шәхси җирләре буларак теркәлә (дворцовые земли). Шушы «дозор» статистик ревизиясе документларыннан 1599/1600 елны Казан өязендәге патша җирләрен, авылларын, крестьяннар кишәрлекләрен тасвирлаган күчермә бастырылды *(Писцовые материалы дворцовых владений второй половины XVI века / сост. Е.И. Колычева, Н.П. Воскобойникова. М., 1997. С. 209–246)*.

1602-1603 елларда Иван Болтин җитәкчелегендә төркем Казан өязендә, Фёдор Аристов исә Зөя өязендә элекке теркәү кәгазьләрен тикшерү, йомышлыларга җир бүлеп бирү, аларның биләмәләре белән күршеләре арасында чикләрне сызу һәм аны рәсмиләштерү эшен башкаралар. Казан өязе буенча бу материаллар да бүген мәгълүм *(Писцовая книга Казанского уезда 1602–1603 годов / Сост. Р.Н. Степанов. Казань, 1978. 239 с.)*.

XX гасырда дөнья күргән статистика кенәгәләреннән, 1646 елны Казанда, шулай ук Казан воеводасына буйсынган кечкенә кирмән-шәһәрләр һәм Казан өязендә уздырылган шәһәр халкын һәм крестьяннарның җир кишәрлекләрен исәпкә алу документларын атау мәслихәт *(Покровский И.М. Казанский архиерейский дом, его средства и штаты преимущественно до 1764 года. Казань, 1906. С. 51–98; Казанский пригород Малмыж, по списку с переписных книг Тим. Бутурлина и подьячего А. Грибоедова 7154 (1646) года / сообщ. А. В-н [А. Вештомов] // Труды Вятской ученой архивной комиссии. 1908. Вып.2. С.16–20; Материалы по истории Татарской АССР. Писцовые книги города Казани 1565–68 гг. и 1646. Л., 1932. С. 71–130)*.

Соңгы егерме елда күренекле археограф Д.Г.Мостафина тырышлыгы белән 1647-1657 елларда Семен Волынский һәм аның иптәшләре тарафыннан Казан өязенең биш даругасы буенча уздырылган теркәү документлары, шулай ук махсус төзелгән йомышлы татарлар һәм новокрещённарның җир биләмәләре *(Писцовая книга Казанского уезда 1647–1656 годов. Текст и комментарии / сост. И.П. Ермолаев, Д.А. Мустафина М., 2001. 540 с.; Мустафина Д.А. Описание земель служилых татар в Казанском уезде в середине XVII века // Средневековые тюрко-татарские государства. 2018. №8. С.116-302)*, 1646–1652 елларда Зөя өязендә уздырылган һәм шулардан күчерелеп язылган кыскартылган текстлар буенча йомышлы татарлар һәм новокрещённарның җир биләмәләре һәр аларның бәйле кешеләре хакында чыганак *(Перечневая книга Свияжского уезда: По материалам писцового описания 1646–1652 годов / подгот. Д. А. Мустафиной. Казань, 2004. 167 с.)* дөнья күрде.

XVII гасырның икенче яртысында Россиядә статистик мәгълүмат туплауда ике

зур яңалык күзәтелә. Беренчесе, бу чаралар аерым төбәкләр белән чикләнмичә, гомум характерда уздырыла башлый; икенчесе – 1646 елдан салым билгеләү берәмлеге итеп җир биләмәләре урынына хуҗалык саны кертелә (хуҗалыклар санын язып баручы документлар «переписная книга» дип атала). Шул сәбәпле 1677–1679 елларда илкүләм салым түләүче халыкның саны яңабаштан исәпкә алына. Шушы җанисәпнең Казан өязенең Җөри даругаларында урнашкан торак пунктлары буенча материаллары шулай ук укучы кулына барып ирешә *(Писцовые книги Казанского уезда 1685–1687 годов: Публикация описаний Зюрейской дороги / подгот. Д.А.Мустафиной. Казань, 2009. 428 с.)*.

XVI – XVII гасырның икенче яртысына караган документларда Казан һәм Зөя өязләрендә (элеккеге Казан ханлыгы җирләрендә) яшәгән татарларны халык санын алучы руслар «ясак түләүче чюваш» яки «чюваш» категориясенә кертә, ул чорда бу сүз социаль төркем исеме буларак авыл халкына карата кулланыла (монда этник чувашлар да яши). 1565-1568 елларда Зөя өязендә 22 «чюваш», 11 «татар һәм чюваш», 6 «татар» авылы Писцовый кенәгәгә теркәлә. И.Болтинның чувашлар яшәмәгән Казан өязендә 1602-1603 елларда тутырылган Писцовый кенәгәсендә 117 «ясак түләүче чуваш», 91 «татар» һәм «ясак түләүче чуваш» авылы күрсәтелә *(Исхаков Д.М. Этнотерриториальные и этнокультурные группы татар и их взаимодействие // История татар с древнейших времен. В 7 т. Т.5. Казань 2014. С.220-221)*.

Шулай итеп, Казан ханлыгы җирләрендә «чуаш» яки «чюваш» термины белән төрки чыгышлы ясак түләүче, җир эшкәртеп көн күрүче халык атала. Соңрак казан татарларында «чуаш»/«юаш»/«җуаш» сүзе аерым төркемнәрне сыйфатлаучы билгегә әйләнә. Бу категория халык Ислам динен тота һәм татар телендә сөйләшә. Терминның социаль мәгънәсе XVII йөзнең соңгы чиреге – XVIII йөз башында, Петр I реформалары вакытында юкка чыга: хәзер инде «чюваш» авыллары кешеләрен документларда «ясак түләүче татарлар» дип теркиләр. Шушы заманнан «ясак түләүче чуашлар» атамасы чуваш этник төркемен белдерә *(Галлям Р.Г. Выступление // Исторические судьбы народов Поволжья и Приуралья. Сб. статей. Вып. 4. Казань, 2014. С.207)*.

Йомышлы татарлар

Нугай Урдасы, Хаҗитархан, Кырым һәм башка ханлыклардагы Мәскәү бөек кенәзенә һәм Мәскәү патшасына хезмәткә күчкән югары катлам вәкилләре элекке социаль дәрәҗәсен саклый: «хан улы», «кенәз», «морза» һәм «улан» булып йөри. Әмма XVI гасырда хезмәткә кергәннәр барысы да «йомышлы татарлар» («служилые татары») дип атала башлый.

Казан ханлыгы чорында йомышлы татарлар, нигездә, Россиянең үзәк районнарында, Нократ җирендә һәм Мещерада яши. Мещераның көнбатыш өлешендә Касыйм ханлыгы (1445 –1681) урнашкан була. Казан алынгач, татарларның югары катлавы йомышлы татар дәрәҗәсенә төшерелә. Мещераның көнчыгыш өлеше (Цнен-Мукшы районы) башта Алтын Урдага, аннары, 1481 елга кадәр, Олы Урдага буйсына. XVI гасырда бу төбәкнең төп халкы булып «мукшы» кенәзләре, морзалар, гади татарлар санала. Алар, яшәгән урыннарына карап, берничә вак төркемгә бүленә: кадом, темников, цнен, арзамас һәм алатырь йомышлы татарлары, мишәрләре.

1552-1557 елгы Казан ханлыгы өчен барган көрәштән соң, халык саны нык кими. Урта Идел төбәгендә яңа хакимиятнең социаль таянычы булырга тиешле йомышлы татарларга ихтыяҗ арта. XVI гасырның соңгы чирегендә воеводалар, йомышлы татар итеп, ясаклы кешеләрне күчереп, аларны хәрби максатларда файдаланалар. 1568 елны Казан өязендә 700 рус һәм 200 дән артык татар алпавыты булса, 1603 елга йомышлы татарларның саны (новокрещённарны кертеп) 2,5 тапкырга артып, ярты меңгә җитә *(Галлямов Р.Ф. После падения Казани…: Этносоциальная история Предкамья (вторая половина XVI – начало XVIII вв.). Казань, 2001. С.19–20)*.

Төбәктәге йомышлы татарлар ясак түләүдән азат ителә, хәрби хезмәтләре өчен җир биләмәсе (поместье) ала, аларга вакыт-вакыт акчалата да түлиләр. Гадәттә, биләмә итеп ясаклының элекке җире беркетелә торган була. Рус алпавытларыннан аермалы буларак, татарларның хуҗалык алып баручы (крепостной) крестьяннары булмый. Әйтик, 1646 елны Казан өязендә теркәлгән 619 йомышлы татар хуҗалыгының 449ында (72%) бер крестьян да юк. Булганнарының да күпчелегендә эшче көчләр бер яки ике крестьян хуҗалыгы яисә 2-3 хуҗалык хезмәтчеләреннән (сугышлардан алып кайткан әсирләр) артмый. Йомышлыларның еш кына ясаклы кешеләр белән бер авылда яшәүләре аларга, эшче көчләр җәлеп итеп, хуҗалыкларын алып барырга мөмкинлек биргән.

Казан өязе белән чагыштырганда, Мещерада көн күргән йомышлы татарларның хәл-әхвәле һәм матди хәле күпкә яхшырак булганлыгын әйтеп китү мәслихәт. Темников, Кадом һәм күрше өязләрдә яшәгән йомышлы татар һәм морзаларның җир биләмәләре зуррак булып, аларның мукшы, рус крестьяннары һәм үзләре катнашкан сугышлардан алып кайткан әсирләре – хуҗалыкта эшләүче яки үз йортлары белән яшәүче кешеләре булган.

1670-1680 еллардагы чукындыру сәясәте Мәскәү дәүләтенең үзәк районнарында яшәгән йомышлы татарлар (нугайлар) арасында мөселманнарны калдырмый. Чукынырга теләмәгән бер төркем нугайларны (романов татарларын) 1681 елны патша хөкүмәте Костромага күчерә *(Черновская В.В. Очерки по истории татар в Центральной России в XV–XVII вв.: монография. Казань, 2020. С.193)*.

Ислам динен тотучы морзалар һәм йомышлы татарларның, чукынмаган очракта, Христиан динендәге крестьяннарын тартып алу турындагы 1681 елның 16 май указы Башкорт восстаниесе басымы астында 1682 елның 8 июлендә юкка чыгарыла.

1710 елгы дәүләт статистикасы Казан, Зөя, Сембер, Пенза һәм Саранск өязләрендә 88 морзаның һәм 23 йомышлы татарның әле 35 авылда православие динендәге 260 хуҗалыкта яшәүче крепостной крестьяны калганын ачыклый. XVIII гасыр башында касыйм йомышлы татарларының 8765 крестьяны, темников морзаларының 1765 рус крестьяны була.

XVI гасырның икенче яртысы – XVII гасыр дәвамында Темниковта яшәгән йомышлы татар, мишәрләрнең башка төбәкләргә актив күченүләре күзәтелә.

Чик буйларын саклау өчен 1578 елны Тәтеш-Алатырь, аннан Темниковка кадәр, 1648-1654 елларда Корсуннан Саранскига, 1652-1656 елларда Сембердән Минзәләгә кадәр (Кама аръягы), 1676-1680 елларда Пенза-Сызрань саклану сызыклары корылу йомышлы татарларның күченә баруына һәм, Идел буе татарлары белән якынаеп, аралашып, Урал төбәген колонизацияләүгә катнашуына китерә.

Урта Иделдә «новокрещённар»

Бу чордагы писцовый һәм переписной кенәгәләрдә җирле халык арасындагы чукынганнар («новокрещённар») һәм мөселманнар белән мәҗүсиләр («чукынмаганнар / некрещёные») төркемнәре аерып күрсәтелә.

1555 елны Казан епархиясе оештырыла һәм яңа хакимиятнең миссионерлык эшчәнлеге 1565–1568 елларда Казан өязендә узган җанисәп кәгазьләрендә ачык күренә. Өяздә ясаклы новокрещённар рус йомышлыларына (3), патша ведомствосына (1) һәм чиркәүгә (3) караган авылларда теркәлә. Ул чорда Казанда 24 йомышлы новокрещён яши, 1557 елны Казан воеводасы Лаешта элек әсирлектә булган новокрещённарны урнаштыра.

Казан төбәгендә новокрещённарның элекке диннәренә кайтуы мәгълүм булгач, патшаның 1593 ел 18 июль указы нигезендә Казан митрополиты Гермоген җитәкчелегендә (1589–1606) новокрещён авылларына нигез салына, новокрещённарны аерып урнаштыру башлана.

Иван Болтинның писцовый кенәгәсе (1602–1603) буенча Казан өязендә йомышлы татарларның өчтән бере (200-дән артык гаилә) чукынган булып күренә. Новокрещён авыллары XVII гасыр башына Җөри һәм Арча даругалары буйлап, 1552–1557 елларда бушап калган җирләргә урнаша. 38,9 % (14 авылда) йомышлы новокрещённар үзләре генә, 47,2 % (17) йомышлы һәм ясаклы новокрещённар бергә, 5,6% (2) – ясаклы новокрещённар аерым, 8,3% (3) йомышлы һәм (яки) ясаклы новокрещённар һәм чукынмаган йомышлылар һәм (яки) ясаклы татарлар бергә яши.

XVI–XVII гасырларда чукынганнар бары тик керәшен татарлары арасында гына сакланып кала. Димәк, чукынган мәҗүсиләр (мари, чуваш, удмурт, мордвалар), дин белән бергә, этник үзбилгеләнүләрен дә үзгәртә: яшәү урынына карап, йә руслар, яки новокрещён татарлар тарафыннан ассимиляцияләнә. Белгечләр фикеренчә *(Мухаметшин Ю.Г. Татары-кряшены. Историко-этнографическое исследование материальной культуры. Середина XIX – начало XX в. М., 1977. С.26)*, керәшен татарларында «христиан дине битлеге астында мәҗүси йола-гадәтләр озак вакытларга кадәр сакланып кала, Ислам дине белән бәйле ышанулар исә чагыштырмача азрак була, болар татар-керәшеннәрнең гаять катлаулы һәм кайчак каршылыклы составлы булуы турында сөйли».

Урал төбәгендә (Уфа өязендә) татарлар

Тәүге тапкыр Уфа өязенә йомышлы татарлар 1574 елны, Уфа кирмәне төзелгәндә килеп урнаша һәм кирмәнне, чик буйларын саклаучыларга әйләнә. Турыдан-туры Уфа воеводасына буйсынганга, Казан воеводасы йомышлыларыннан аермалы буларак, аларга дәүләт җир биләмәсе бирми. Шул сәбәпле хуҗалыклары башкорт волостьлары җирләрендә булып, ә үзләре припущенник (кертелгән кеше) санала.

Хөкүмәт 1659, 1689, 1695 елларда йомышлы татарларга халык аз яшәгән төбәккә, Уфа өязенә күчәргә чакырып мөрәҗәгать итә. Бу социаль төркем «Уфа татары» дип йөртелә һәм, башкортлар кебек, 1762 елга кадәр Россиядә үткәрелеп килгән халык санын алуларда исәпкә керми. Казан воеводасына буйсынган йомышлы татарлардан аермалы буларак, җирле хакимият шундый 748 йомышлы татар һәм мещеряктан, хәрби хезмәткә җәлеп ителмәүләре сәбәпле, 1699 елны һәм 1718 елны берәр сумнан акча җыеп ала. Бу вакыйга, Уфа галиме У.Х. Рәхмәтуллин фикеренчә, үзе үк бу төркемнең Казан воеводасына буйсынган йомышлы татарлардан статуслары ягыннан да аермалы икәнен раслап тора *(Рахматуллин У.Х. Население Башкирии в XVII – XVIII вв. М., 1988. С.145)*.

Уфа өязендә башкортлар түли торган ясак Урта Идел буенда яшәгән халыклардан җыела торган ясактан күпкә кимрәк. Күченүләрнең, әлбәттә, башка сәбәпләре дә булган. Әйтик, биредә җирләрнең уңдырышлы һәм хакимиятнең күзәтүе йомшак булу шундыйлардан. 1552-1557 еллардагы баш күтәрүләрне гаскәрләр тарафыннан бастыру һәм рус колонизациясе дә, һичшиксез, йогынты ясаган. Д.Кикинның 1565-1568 елларда туплаган статистик мәгълүматлары буенча, Казан өязендә рус алпавытлары кулына элек татарлар хуҗалык алып барган 206 авыл һәм 60 буш калган урын күчкән. Бу күченүчеләрнең төп чыгышын дәлилләп тора.

Уфа галиме С.Васильев фикеренчә, Урта Идел төбәгеннән Уфа өязенә күченүнең 1550-1590, 1660-1675 һәм 1700-1735 елларда өч төп дулкыны күзәтелә.

1674 елны Уфа воеводасы башкорт җирләрендә уздырган тикшерү бирегә күченгән бобыльләрнең (бобыль – салым түли торган, әмма үз хуҗалыгы булмаган һәм ялланып эшләүче ярлы крестьян төркеме) җанисәбен алып, салым түләүче 649 һәм бернинди салым түләмәүче 623 кешене терки, 1272 ир-атның барысын да дәүләт алдында бурыч үтәргә мәҗбүр итә.

Болардан тыш, башкорт җирләренә ясак түләүче төрле этник төркемнәрдән оешкан һәм башкорт волостьлары җирләренә телдән яки язма килешү төзеп килгән ясаклы

крестьяннар – типтәрләр урнаша («типтәр» ясакны теркәп баручы «дәфтәр» сүзеннән барлыкка килгән). Моны Урта Идел төбәгендә 1678 һәм 1710 елларда халык санын алу материаллары да раслый. Шушы вакыт аралыгында төбәктәге хуҗалыклар саны 186 меңгә кими! Аннан соң да кимү дәвам итә.

Типтәрләр башкорт волостьларына килешү төзеп урнаша, шуңардан чыгып, ике арадагы мөнәсәбәтләр буенча өч төркемгә бүленә: 1. Башкорт җәмгыятенә тулы хокуклы әгъза буларак кабул ителгән типтәрләр (башкорт ясагы түли, башкорт сословиесе була). 2. Башкортлар җирләренең бер өлешеннән файдаланучылар. 3. Файдаланган җир өчен башкортларга акчалата рента түләүчеләр *(Рахматуллин У.Х. Население Башкирии в XVII – XVIII вв. М., 1988. С.151, 190).*

Җанисәп материаллары XVII гасырда бер төркем типтәрләр башкорт сословиесенә язылган дип әйтергә нигез бирә. 1631-1632 елларда Уфа өязендә ясак түләүче башкортлар саны 6188 хуҗалык, ә припущенниклар (типтәрләр һәм бобыльләр) 8355 хуҗалык исәпләнә *(Исхаков Д.М. Этнотерриториальные и этнокультурные группы татар и их взаимодействие // История татар с древнейших времён. В 7 т. Т.5. Казань 2014. С.226)*, 1722-1723 елларда исә типтәрләрнең саны ике тапкырдан артыкка кими. XVIII йөз башында җирле хакимият башкортларның саны ике тапкыр диярлек артуын күченеп килүчеләрнең башкорт сословиесенә язылулары белән аңлата *(Рамазанова Д.Б. Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. 2-е изд. Казань, 2020. С.22)*.

Казан воеводасына буйсынган һәм Уфа өязенә күченгән йомышлы татарлар, мещеряклар һәм ясаклы татарлар турында шактый тулы статистик мәгълүмат Петр I тарафыннан 1722–1723 елларда уздырылган I ревизия материалларында теркәлгән.

Бу вакытка башкорт җирләрендәге Оса (43,9% кеше, яки 100 авыл), Казан (27,9%, яки 87 авыл), Себер (18,4%, 64 авыл), Нугай (9,8%, 31 авыл) даругаларында җәмгысе 282 авылда 10 мең ир-ат яшәгәнлеге мәгълүм. Шуларның яртысы диярлек хөкүмәт кушуы яки рөхсәте белән төбәккә күченгән йомышлылар була (18,5% йомышлы татарлар һәм 30,4% мещеряклар/мишәрләр), аларның бер өлеше күченгән ясаклы крестьяннар белән бергә көн итә. Ясаклы татарларның күпчелеге үзләренең торак пунктларын Казан (37,9%) (хәзерге Татарстанның Әгерҗе, Актаныш, Менделеевск, Минзәлә, Мөслим, Тукай, Башкортстанның Бакалы, Бәләбәй, Бөре, Благовар, Дүртөйле, Караидел, Кушнаренко, Илеш, Уфа районнары, Удмуртия Республикасының Каракүл районы) һәм Оса (32,8%) (Башкортстанның Балтач, Бөре, Борай, Тәтешле, Караидел, Кызыл Кама, Култасы, Мишкә, Кырмыскалы, Яңавыл районнары) даругаларында нигезли. Йомышлы мещерякларның күпчелеге (55,6%) Оса даругасы, йомышлы татарларның 65, 3 % Себер (Башкортстанның Аскын, Бөрҗан, Кыйгы, Караидел, Салават, Өчөйле районнары, Свердлау өлкәсенең Урта Сергә районы) даругасы авылларында яши *(Татары Уфимского уезда в свете государственной статистики (материалы переписей населения 1722–1782 гг.): справочное издание / отв. ред. Р.Р. Исхаков. Казань, 2020. Табл. 1. С.17, 18, 19)*.

Күченеп килгән татарлар тиз арада мәхәлләләр оештырып, дини үзидарә төзиләр. 1736 елгы рәсми хәбәрләрдә Уфа өязенең дүрт даругасында мәхәллә руханилары белән идарә итү сайланып куелган, Казан ягыннан килгән ун ахун кулында булуы әйтелә. Алар, хакимият күзәтүе йомшак булудан файдаланып, мәчетләр төзүгә, мәктәп-мәдрәсәләр ачуга рөхсәт бирәләр, руханилар билгелиләр, авыллардагы дини-мәдәни тормышны тәртипкә салып, халык арасында Ислам дине көчәюгә хезмәт итәләр.

Йомгак ясап, шуны әйтәсе килә. XVI гасырның икенче яртысы – XVII йөздә хөкүмәт әмере белән Мещерада яшәгән йомышлы татарлар һәм мещеряклар, бер-бер артлы төзелгән чик буе ныгытмаларын саклау өчен, акрынлап көньякка, көньяк-көнчыгышка таба күчереләләр. Яңа яшәү урыннарында алар Урта Идел буе ясаклы һәм йомышлы татарлары белән мәдәни багланышлар кора, аралаша һәм кан алмаша.

Шул рәвешле, киләчәктә татар милләтенең үзәген тәшкил иткән Идел-Урал татарлары этносы XVII гасырның икенче яртысында формалаша. Себер татарлары бу мәдәни йогынтыга Көнчыгыш Себергә Идел һәм Урал төбәгеннән татарлар күченгәч тартыла. Бер үк вакытта чукындыру сәясәте татарлар арасында ике конфессиональ төркем – мөселманнар һәм новокрещённар – барлыкка китерә.

Татар халкының яшәү ареалы киңәю, төбәкләрдә этносоциаль һәм дини-мәдәни барыш, күргәнебезчә, ул заман җанисәп кәгазьләрендә шактый тулы чагылыш тапкан.

РОССИЯДӘ ХАЛЫК САНЫН АЛУ ТАРИХЫ (XVIII – XIX ГАСЫР УРТАСЫ): ТАТАР ХАЛКЫ ҺӘМ АНЫҢ ТӨРКЕМНӘРЕ РЕВИЗИЯ КЕНӘГӘЛӘРЕНДӘ

Яңа җанисәп документлары

XVIII гасыр башында Россиядә илкүләм зур реформалар уздыру, регуляр гаскәр булдырып, аны өр-яңадан коралландыру, хәрби-диңгез флоты төзү һәм башка яңалыклар белән бәйле нык арткан дәүләт чыгымнарын күтәрү крестьяннар җилкәсенә төшә. Хөкүмәтнең изүеннән котылу юлы эзләп, 1710 елны җанисәп уздырганда, гаиләләр берләшеп – бер хуҗалык, ягъни бер салым түләү берәмлеге булып языла. Нәтиҗәдә салым түләүчеләрнең саны нык кими, дәүләткә зур зыян килә.

Моңа җавап итеп, Петр I яңа берәмлек – ир балалар, ир-атлар санынннан чыгып, салым җыю тәртибен кертә. Качып калмасыннар дип, император әмере белән яңача җанисәп уздыру 1719-1724 елларда гаскәриләргә тапшырыла. Җан башыннан салым җыю өчен хөкүмәтнең ревизия исеме алган статистик чаралары тагын тугыз тапкыр уздырыла: II (1744-1747 еллар), III (1762-1767), IV (1782-1787), V (1794-1808), VI (1811-1812), VII (1815-1825) , VIII (1833-1835), IX (1850), X (1857-1859). Һәр ревизиядән соң салым түләүчеләрнең исемлеге элеккесе белән чагыштырып яңартыла, яңа исемлек төзелә.

Беренче ике ревизия вакытында ир-атлар гына исәпкә алына. Өченчесеннән башлап, җанисәп кәгазьләре типографиядә бастырыла һәм аларда (VI ревизиядән кала) гаиләдәге хатын-кызлар һәм аларның яшьләре дә күрсәтелә. Соңгыларында губерна, өяз, торак пункты исеме, халык санын алуның вакытын язудан тыш, алты графага түбәндәге мәгълүматлар теркәлә: 1) гаиләнең узган ревизиядәге номеры; 2) гаиләнең бу җанисәптәге номеры; 4) узган ревизиядә теркәлгән гаиләдәге кешеләрнең яше; 5) узган җанисәпне алганда теркәлгәннәрнең китү вакыты (рекрутка алыну, үлем һ.б.); 6) бу ревизиядә язылган кешеләрнең яше.

Салым күләме арта бару сәбәпле, гади халыкта (крестьяннар һәм мещаннар) җанисәп алу салым салу чарасы дигән караш урнаша: җай чыкса, аңа теркәлми калырга тырышу шуннан килә.

Җанисәп уздыру, илнең территориясе бик зур булу сәбәпле, берничә елга сузыла, кайчак гаиләләрне ике тапкыр язуга китерә, анда чынбарлыктагы түгел, ә билгеле бер торак пунктына беркетелгән, җире-йорты булган кешеләр санала. Җан башыннан түләнүче салымнан азат булган башка катлам һәм профессия вәкилләре ревизияләр вакытында игътибарга алынмый. Әйтик, VIII ревизиядә шундый 12 категория, ә X ревизиядә (1858 ел) 18 төркем исәпләнми. Шулай ук Кавказ арты, Польша, Финляндия кебек төбәкләрдә мондый җанисәп гомумән уздырылмый *(Гозулов А.И. Очерки истории отечественной статистики. М., 1972. С. 44-45, 47).*

Ревизиянең максаты җан башыннан салым түләүчеләрне санау булганлыктан, илнең чик буе төбәкләрендә яшәгән татарлар I ревизия материалларында теркәлми кала. Әйтик, II ревизия (1744), беренчесе кебек үк, «яулап алынган шәһәрләрдә, Әстерхан һәм Уфа татарлары, башкортлар һәм себер ясаклы татарлары арасында уздырылмый»

(Кабузан В.М. Народы России в XVIII веке. Численность и этнический состав. М., 1990. С.23).

Анда Чиркәү тәкъдиме белән «чукынмаганнар»ның этник билгеләрен теркәү яңалыгы кертелә. Ләкин «ясаклы» һәм «чит диннән чукынган кеше» дигән бүлекләрдә теркәлүченең кайсы халыктан икәнлеге күрсәтелми башлый.

Нәтиҗәдә Урта Идел төбәге халыклары түбәндәге графаларга теркәлә: 1) новокрещён яки чит диннән чукынган кеше; 2) чукынмаган башка дин кешесе; 3) ясаклы; 4) кораб төзү өчен урман кисәргә билгеләнгән татарлар, чувашлар һәм чирмешләр *(Кабузан В.М. Народы России в XVIII веке. Численность и этнический состав. М., 1990. С.26).*

Шул рәвешле, тәүге тапкыр II ревизия теркәлүченең этник билгесен, тулысынча булмаса да, исәпкә ала башлый.

III ревизиядә (1762) рус булмаган халыклар өч графага языла: 1) чукынган башка дин вәкилләре (новокрещённар); 2) чукынмаган чит диндәгеләр (иноверец); 3) Адмиралтействога беркетелгән чит диндәгеләр. Мәсәлән, Казан өязендә төрле сословиеләр вәкилләренең этник билгесе болай беркетелгән: йомышлы новокрещён татарлар, йомышлы новокрещён чуашлар, йомышлы новокрещён мукшылар. Ясаклылар русларга һәм чит диндәгеләргә бүленә: татарлар (чукынганнар һәм чукынмаганнар), чирмешләр (чукынганнар һәм чукынмаганнар) һ.б. *(Кабузан В.М. Народы России в XVIII веке. Численность и этнический состав. М., 1990. С.30-31).*

20 елдан соң уздырылган IV ревизия (1782) тәүге тапкыр башкортларны, Себердәге «ясаклы чит диндәгеләрне» һәм башка чик буйларында көн күргән, моңарчы җирле, төбәк җанисәбендә генә теркәлгән төркемнәре исәпкә ала. Анда шулай ук беренче тапкыр этник билге буенча чукынмаганнар гына түгел, ә новокрещённар – 1730-1750 елларда чукындырылган төркемнәр дә языла *(Кабузан В.М. Народы России в XVIII веке. Численность и этнический состав. М., 1990. С.36).*

1762 һәм 1782 елгы башкортларга кагылышлы беренчел ревизия материаллары әлегәчә табылмау сәбәпле, Көньяк Урал төбәгендәге этник төркемнәрнең үзара икътисади һәм мәдәни багланышларын өйрәнүдә зур кыенлыклар саклана *(Томашевская Н.Н. От социального пространства к социальному времени: Опыт этнической истории башкирского этноса в новое время. Уфа, 2002. С.87 – 88).*

Идел-Урал төбәге татарлары ревизия кәгазьләрендә

XVIII гасырның соңгы чирегендә Россиянең чикләре тагын да киңәя. Империя 1783 елны Кырым ханлыгын басып ала, Польшаны бүлү нәтиҗәсендә Литва татарлары аның составына керә. Алтын Урда заманында ватандашлар булган төркемнәр тагын бер дәүләттә яши башлый.

Бу вакытта Литва татарлары Ислам динен саклаган хәлдә туган телләрен онытып, белорус телендә сөйләшәләр. Яшәгән төбәкләренең ераклыгы һәм, иң мөһиме, – уртак аралашу теле булмау Идел-Урал һәм Литва татарлары арасында мәдәни багланышлар урнаштырырга һәм аларны ныгытырга мөмкинлек бирми.

Әби патша кырым татарларына 1783 ел 8 апрель манифесты белән дин иреге, руханиларга һәм морзаларга, югары катлам вәкилләре буларак, хокуклары саклануны вәгъдә итә. Ләкин Госманлы дәүләтенә дулкын-дулкын барган мөһаҗирлек хәрәкәте кырым татарларының санын нык киметә. Идел-Урал татарларының алар белән мәдәни багланышлары 1883 елны Бакчасарайда Исмәгыйль Гаспралы «Тәрҗеман» газетасы бастыруга керешкәч һәм, яңарыш идеологы буларак, Россия төрки халыкларына европалашу концепциясен тәкъдим иткәч нигезләнә.

Кырым һәм Литва татарларының шәһәрләрдә яшәгән өлеше үзенең шактый югары санда булуы белән игътибарны җәлеп итә һәм бу планда алар Идел-Урал төбәгендә

яшәгән кардәшләреннән аерылып тора. XIX йөз уртасында кырым татарлары арасында урбанизация шулай ук югары – 14 % тәшкил итә.

Икенче яктан, алар белән чагыштырганда, Идел-Урал төбәге татарларының саны тотрыклы арта. Бер гасыр эчендә – 1795-1897 еллар аралыгында бу күрсәткеч 617,3 меңнән 2 млн 249,5 мең кешегә җитә, ягъни 3,6 тапкыр үсә. Түбән Иделдә – 3,8 тапкырга, Көнбатыш Себердә 2 тапкырга арту күзәтелә. Соңгысында татарлар саны XIX гасырның икенче яртысында Идел-Урал төбәгеннән күченүчеләр хисабына күбәя, аларның шактые шәһәрләргә урнашып һәм мөселман җәмгыятьләрендә күпчелекне тәшкил итеп, Көнбатыш Себердәге татарларның мәдәни һәм мәгариф үсешенә уңай йогынты ясый башлый.

XVIII йөздә Әстерханда мөселманнар җәмгыяте йорт (юрт) татарлары һәм алар ассимиляцияләгән Иран, Һиндстан (Әфганстан) һәм Бохара сәүдәгәр колонияләре вәкилләреннән җыела. Рязань өязеннән һәм Урта Иделдән күченүчеләр XIX гасыр уртасында шәһәрдәге татарларның яртысын, гасыр азагында инде күпчелеген тәшкил итә.

Нәтиҗәдә 1897 елга Идел-Урал төбәгендә татарларның саны 2 млн. 249,5 меңгә, Көнбатыш Себердә – 45,2 меңгә, Әстерхан төбәгендә – 25,7 мең кешегә җитә.

Аграр Идел-Урал төбәгендә татарларның күпчелеге авыл җирлегендә көн күрә һәм йөз ел дәвамында бу хәл үзгәрми диярлек: 1795 елны – 98,2%, 1857 елны – 98,0%, 1897 елны – 95,1% тәшкил итә. Көнбатыш Себердә бу саннар тагын да югарырак булып, Әстерхан төбәгендә, киресенчә, авыл халкының саны якынча 80нән 60 % ка кадәр кими.

XIX йөздә Россия империясе оешу төгәлләнә. 1897 елны мөселманнар империядә элеккечә православие динендәгеләрдән (69,4%) соң икенче урында (11,1%) була *(Россия в начале XX века / под ред. акад. А.Н. Яковлева. М., 2002. С. 88–89)*. Яңа җирләр кушуның бер мөһим нәтиҗәсе булып русларның ил халкының яртысыннан азрагын гына тәшкил итүләрен (44,31%) әйтү мәслихәт. Империядә күпчелек этник азчылык дип аталып йөртелгән төркемнәр кулына күчә: украиннардан (17,8%) соң өченче урында төрки халыклар (13,6 млн. кеше яки 10,8%) исәпләнә.

XVIII гасырда татар халкының төп яшәү төбәкләре ачыкланып бетә. I ревизия уздырылган елларда (1719-1724) 91,3% татарлар Урта Идел төбәгендә (нигездә Казан һәм Зөя өязләрендә) көн күрә, татар-мишәрләрнең төп өлеше Түбән Новгород, Воронеж (Касыйм өязеннән кала – анда татарлар яши) һәм Казан (аның көньяк-көнбатыш өлеше) губерналарында туплана.

XVIII гасыр башында Казан губернасыннан Көньяк Урал һәм Түбән Идел ягындагы буш яткан уңдырышлы җирләргә халык Петр I керткән өстәмә салымнардан, җирле хакимиятнең башбаштаклыгыннан һәм чукындыру сәясәтеннән качып, күпләп күченә. Крестьяннарның социаль хәлен бәяләгәндә, бу адымны икътисади һәм милли изүгә каршы пассив көрәш чарасы һәм яхшырак тормыш эзләү дип атап булыр иде.

Әлбәттә, барлык күченүләр дә качып китү булмыйча, кайбер очракларда миграция башлангычы үзәктә формалаша.

1743 елны Оренбург кирмәненә нигез салынгач, яңа кирмән белән Казан арасында ышанычлы коммуникация һәм Яңа Мәскәү дип исемләнгән төзеләчәк тракт тирәсендә инфраструктура булдыру бурычы куела. Хакимият, льготалар биреп, бу төбәккә халыкны җәлеп итә башлый, Көньяк Уралга күченгән бер төркем типтәрләрне тракт буена авыллап-авыллап утыртып куя, аларга ямщик (почта ташу) вазифасын беркетә, шул рәвешле «чемоданлы татарлар» дигән төркем барлыкка килә. Әле 30 ел элек кенә бер игенче авылы булмаган төбәктә 1762 елны ясаклы татарларның 50 авылы теркәлә *(Рахматуллин У.Х. Население Башкирии в XVII–XVIII вв.: Вопросы формирования небашкирского населения. М., 1988. С.103-106)*.

Тагын бер мисал итеп, Оренбург янына татарларны күчерү турында 1744 ел 8 март

указы белән Каргалы елгасы буенча Сәет бистәсен нигезләү күрсәтелә ала. Ләкин мондый хөкүмәт чаралары бик сирәк күренеш булып, гадәттә, миграция «ирекле» яки качып китү төсен алган, ә хакимият аерым елларда, күченү хәрәкәтен туктатырга теләп, чаралар да кулланып карый.

XVIII гасырның 40 – 60 еллары башында бирегә тагын 82000 гаилә, ә 60-70-елларда якынча 6 мең ир-ат күченүе билгеле. Алар, нигездә, Казан губернасы белән чиктәш булган Минзәлә, Бөгелмә, Оренбург өязләренә урнаша *(Кабузан В.М. Народы России в XVIII веке. Численность и этнический состав. М., 1990. С.238).*

IV ревизия (1782) Уфа наместничествосында һәммәсе 44357 ир-ат татарларны терки, аларның өчтән ике өлеше диярлек типтәрләр һәм бобыльләр була (28068 ир-ат, яки 63,3%) бу социаль төркемгә, шулай ук, 12166 ясаклы татарны (27,4%), 268 новокрещённы (0,6%), 39 ясаклы «торговый татар»ны (0,09%), 26 ясаклы мещерякны (0,06%) өстәргә кирәк. Хәрби хезмәт башкаручы 3790 йомышлы татар һәм морзалар икенче зур төркемне тәшкил итә *(Татары Уфимского уезда в свете государственной статистики (материалы переписей населения 1722–1782 гг.): справочное издание / отв. ред. Р.Р. Исхаков. Казань, 2020. С.20).*

XVIII йөзнең соңгы өч дистә елында да (III-V ревизияләр вакыты, ягъни 1762-1795 еллар) татарларның Көньяк Урал төбәгенә күченүләре туктамый. Бу вакыт аралыгында Минзәлә өязендә аларның саны 27,9 дан – 30,6 % кадәр, Уфа өязендә 0,7 дән – 22,1 % кадәр, Бөгелмә өязендә 20,6дан – 26,0 % кадәр, Бәләбәй өязендә 9,2дән – 13,0 % кадәр, Стәрлетамак өязендә 5,0 дән – 12,7 % кадәр, Бөре өязендә 0,5 тән – 17,6 % кадәр арта. Чиләбе һәм Троицк өязләрендә алар бик аз санда теркәлә. Ревизияләр эчке миграция барганын да күрсәтә. Әйтик, Оренбург өязендә татарларның саны 24,6 дан –7,1 % кадәр (6833 ир-аттан 4335 кадәр), Богырыслан өязендә 22,6дан – 16,0 % кадәр кими, гәрчә гомуми саннар 5139 дан 12228 кешегә җитә *(Кабузан В.М. Народы России в XVIII веке. Численность и этнический состав. М., 1990. С.238).* Димәк, алар, яхшырак тормыш шартлары эзләп, башка өязләргә күченгән.

Мәгълүм булганча, типтәрләр төрле этник төркем вәкилләреннән торган. 1855 елгы тулы ук булмаган мәгълүматлар буенча алар арасында 802 ир-ат христиан (0,6%), 29256 традицион диннәр тарафдары (21,9%) һәм 103744 ир-ат мөселман (77,5%) булганлыгы билгеле *(Асфандияров А.З. Семья и брак у башкир в XVIII – XIX в. Уфа, 1989. С.35).*

Гомумән алганда, Урта Иделдәге һәм Көньяк Уралдагы татарларның саны үзгәрү үзара тоташкан пыяла савытларда су агышын хәтерләтә: 1762-1782 елларда Түбән Урал төбәгендә аларның саны – 49,9 процентка, ә Урта Идел буенда 20,1 процентка арта, 1782-1795 еллар арасында беренчесендә үрчем – 31 %, икенчесендә 16,4 % кына була. Шул рәвешле, Көньяк Урал татарлар күпләп яшәгән төбәккә әверелә, гасыр азагында биредә Идел-Урал татарларының өчтән бере көн күрә *(Исхаков Д.М. Историческая демография татар. Казань, 2014. С.127-130).*

1719-1747 еллар арасында Казан төбәгенә үзәк өлкәләрдән күпләп рус крестьяннары күченүгә карамастан, халык саны 54258 ир-атка кими *(Кабузан В.М. Народы России в XVIII веке. Численность и этнический состав. М., 1990. С.108).*

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,
тарих фәннәре докторы

(Дәвамы киләсе санда.)

БЕЗНЕҢ РУХТА ТАУ-КЫЯЛАР БИЕКЛЕГЕ...

Дала

Сулар ага, җилләр исә, комнар күчә,
Бар тереклек килә-китә гомер кичә.

Язын, җәен япан дала чәчәк аткан,
Ата-баба киң далада ат уйнаткан.

Төрки телле скиф-һуннар, болгар-кыпчак,
Иртеш-Дунай арасында яккан учак.

Кавемнәрнең алышынган исемнәре,
Мирас булып калган шанлы җисемнәре.

Татар яши вәкаләтле вәкил булып,
Кавемнәрнең асыл сыйфатларын алып.

Затлы булу безнең канда, җан-тәннәрдә,
Әдәп-әхлак, гореф-гадәт, тел-сүзләрдә.

Безнең рухта тау-кыялар биеклеге,
Җир-суларның, далаларның буй-киңлеге.

Даладагы һәр үсемлек – җаныбызда,
Дала рухы безнең милли каныбызда.

Тамырларыбыз да уртак – бер туфрактан,
Дала-татар игезәкләр, бер холыктан.

Дала шаулап-гөрләп яши татар барда,
Бәрәкәтле иген үсә басу-кырда.

Дала – изге ана, юньле бала да ул,
Татар яши дала белән бирешеп кул.

Дала безнең рухи дөнья, милли мөлкәт,
Буыннарны берләштергән ул – әманәт.

Без яшисе бер җан булып, бер тән булып,
Аллаһ безне берләштергән канун язып.

Бу бердәмлек мең-мең еллар дәвам иткән,
Ләүхелмәхфүз китабында теркәү үткән.

Дала – безгә, без – далага хаклы хәким,
Дала – безсез, без – даласыз үксез, ятим.

Иреккә сусау

Заставада ярсу бер кырыкмыш
Озак торган ябык аранда.
Табылмаган аны иярләргә
Тәвәккәл ир-солдат арада.

Кыбырсынып, биеп торган уйнак,
Үз җайдагын көткән зарыгып.
Мине дә ул, ярын көткән заттай,
Көтеп ала иде сагынып.

Ияренә менеп утыруга,
Тотына ул ярсып чабарга.
Туктатуның берәр чик-әмәлен
Кирәк иде миңа табарга.

Авызлыклыйм. Тезгенемне тартам,
Өзәңгегә терәп аякны.
Кырыкмышым томырылып чаба,
Чак тотынып калам шулчакны.

Чик буйларын урап чаба торгач,
Чара таптым мин дә чаяга:
Кушаяклап чапкан айгырымның
Терәп куям башын кыяга.

Тик айгырым минем бу тозакның
Тиз арада тапты ачкычын.
Сыртыннан ул мине ыргытты да
Очып үтте кыя баскычын.

Ул юк булды. Тауларга качты.
Әллә инде күкләргә ашты?..

Бердәнберем

Газиз халкым, синең хакта
Юк уйланмаган көнем.
Җанымны ярып бирердәй
Бердәнберем син минем.

Кендек каным тамган җирем,
Синең өчен җан атам.
Ватанымны, туган җирне
Җаным кебек яратам.

Туган җирем, газиз халкым –
Милләтем пар канаты.
Ата-бабам мирас иткән
Илемнең Идел-Йорты.

Рәис САФИН.
Казан.

ТУКАЙ ШӘХЕСЕНӘ ШӘРЕХЛӘР

ЭССЕ

Тукай – суперйолдыз

Үткән буыннар безгә Габдулла Тукайны халкыбызның олы бер даһие рәвешендә тапшырдылар. Без аның даһилыгына һичбер шикләнмәдек, аны милләт хадиме, демиург буларак кабул итеп алдык. Безнең күзәтүләр буенча татар әдәбияты тарихында иң күп тираж белән чыккан китаплар – аныкы (1917 елга кадәр генә дә Тукайның 72 китабы 221900 данә гомуми тираж белән нәшер ителгән), иң күп фәнни хезмәтләр Тукайга багышлап язылган, ахыр килеп, аның истәлеген мәңгеләштерү буенча иң күп чаралар да Шагыйрь исеме белән бәйле. Тукай һәйкәлләрен генә санасак та, алар – 10: Казанда – икәү, Яңа Кырлайда, Чаллыда, Түбән Камада, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Уфада, Әстерханда һәм Анкарада (Төркия). Музейлар, аның исеме бирелгән урамнарны санасаң, очына чыгарлык түгел. Безнең заман парадигмасына куеп караганда, Тукай – чын мәгънәсендәге суперйолдыз. Исән чагында ук үзен йолдыз дип игълан иткән (*«Шигъре Лермонтов вә Пушкин — олугь саф диңгез ул, / Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай — өч йолдыз ул»*[1]) Тукай үзе турындагы мифка үзе нигез салган дип уйларга да була. Гәрчә, безгә мәгълүм булган кадәренчә, үз заманында да, аннан соң да аның даһилыгын шик астына алучылар (мәсәлән, Г.Ибраһимов) булып торган. «Әхмәт Фәйзи «Тукай» романын яза башлаганда, – ди Бакый ага Урманче (бу аудиоязма Зөфәр Рәмиев архивында саклана), – Тукайга мөнәсәбәт төрле иде әле».

Бүгенге поп-культура контекстында исә Тукайның үз-үзен тотышы, бу дөнья белән аралашу ысулы мөгез чыгару, эпатаж булып бәяләнер иде. Әйтик, Габдулла Кариев белән Галиәсгар Камалның хатирәләрендәге шундый бер мисал моны куәтләп тә куя ала: 1908 елның августында Галиәсгар Камал Тукайны үгетләп, үзе белән ул вакытта Россиянең кесәсе булган Мәкәрҗәгә алып бара. Казан кунаклары анда «Двухсветная» дигән мосафирханәгә төшә, биредә алар ике атналап торалар. Мосафирханәнең управляющие Тимерша Соловьев «Сәйяр» труппасыннан кич белән ресторанда җырлар-такмаклар әйттереп, шигырьләр укуын сорый. Бу тәкъдимгә Тукай да дәртләнеп китә, программа төзеп бирә, анда үзе дә катнаша. «Габдулла әфәнде Тукай, җырлаган вакытта, безнең алда халыкка арты, безгә алды берлә, капельмейстер шикелле, куллары берлә болгап торадыр иде», дип яза бу турыда Габдулла Кариев. Читтән караганда, Тукайның халыкка арты белән чыгып җырлавы дуслары алдында аңлы рәвештә эшләнгән эпатажны хәтерләтә (шагыйрьнең капельмейстер түгеллеген труппа бик яхшы белә югыйсә). «Эпатаж» сүзе кулланылышка 1830 елларда Франциядә сәнгать әһелләренең «буржуйларны шаккатыру» *(epater les bourgeois)* теләге белән килеп керә. Буржуйларны «аристократ-сорыкортлар» дип бәяләгән Тукайның бу гамәлен

[1] Г.Тукай үзенең «Җавап» сүзен 1908 елда Зариф Бәширинең «Мөтәрҗим шагыйрьгә» («Чүкеч», 1908, 21 июнь) дигән шигыренә карата язган дип санала. Ләкин ул аны үз вакытында бастырып чыгармаган.

ресторанда ашап-эчеп утыручы байбәтчәләрне шаккатырасы килгән, аларга карата мөнәсәбәтен шул рәвешле белдергән дип шәрехләргә була, чөнки аның бу кыланмышында эпатажны хасил итә торган үзенчәлекләрнең күбесен, аерым алганда, халык алдындагы чыгыш булып, аның үзенә күрә уен рәвешен алуын билгеләргә була. Әмма Г.Камал истәлегендә түбәндәге сүзләрне укып, моның алай ук түгеллегенә, киресенчә, Тукайның үзенең «шаккатуына» ышанабыз: «Тукай халыкка арты белән торып, дирижёрлык итә, ләкин һәйһат муаффәкыятьнең (уңыш казану) исе дә юк, хорны тыңлаучылар булган шикелле, шаулап утыручылар да, кайнар су китерергә кушып, чәйнек шалтыратучылар да бар! Сәүдәгәрләрнең бу илтифатсызлыкларына Тукайның бик хәтере кала. Эшнең шулай булачагын алдан әйтеп төшендермәгән өчен миңа бик нык үпкәли. <...>Казанга кайтканнан соң да озак вакытларга кадәр миңа үпкәсе язылмый, урыны чыккан саен белдерә бара». Тукай үзе шакката, дидек һәм эпатаж аша – аңлы рәвештәме ул, интуитив рәвештәме – дөньяга үзенең сүзен әйтә. Аның бу эпатажы эпатаж өчен, ягъни үзенә игътибар иттерү, гавам белән эгоистик манипуляция ясау өчен түгел. Ул бу гамәле белән халыкның акчалы катлавына милли контентны (анда «Бәхилләшү» шигыреннән *«Караңгы икән көнемез, / Күрмәс икән күземез»* кебек «күңелне уйгата» торган юллар да була) мондый шартларда җиткерүнең дөрес түгеллеген; күңел ачып, ашап утырган урында халык җырлары һәм милли шигырьләр яңгыратуның китчка әйләнү ихтималын кисәтә. Шагыйрь ирексездән мондый вазгыятьтә калуын авыр кичерә, рухы белән кабул итә алмый. Җаекта чыга торган «Фикер» газетасында 1906 елда ук «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дип, мәкаләләр бастырып, Казанга килгән Тукайның максаты бер генә – милләтне мәгърифәтле итү, шуның аша тәрәккыяткә алып бару юлларын эзләү була. Ә халыкны мәгърифәтле итү өчен аның үзенең дә күпмедер дәрәҗәдә моңа әзер булуы кирәк, югыйсә ул мәгърифәт нуры таратучыларны беркайчан да аңламаячак. Тукайның артык укымышлы Муса Бигиевне, артык бай һәм зыялы Рәмиевләрне чеметеп алуы да ул катламнар белән халык арасындагы дистанцияне кыскарта. Шуның өчен дә Тукайның эпатажлыкка хирыслыгы һәркемнең, һәртөрле катлауның игътибарын һәрдаим әнә шул максатка туплап тору омтылышы белән аңлатыла.

Өйсез Тукай...

Бүгенге көн ноктасыннан торып караганда, Тукай Казанга гүя югарыда телгә алган мәкаләсендәгечә «һуштан язган милләтен» гасырлык йокысыннан уяту өчен килгәндер кебек.

Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!
Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.
Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

– дип, Казанны бөтен татар милләтенең мәркәзе, дип, танып килә ул. Аңа кадәр Казанның татар халкының милли-тарихи үзәге икәнен фәнни нигездә раслап, 1877 елда археологларның IV съездында Ш.Мәрҗани доклад әзерләгән була.

Шулай да югары максатлардан элек, Тукай Казанга провинциядәге Җаектан мәгърифәт һәм тәрәккыят үзәге булган Казанга киләм дип килә. Үзе белән танышу хатирәсен Фатих Әмирхан болайрак сурәтли:

«Борһан Шәрәф, аның кыяфәте миндә тугъдырырга тиеш булган тәэсирне икенче якка сәвекъ итәргә (юнәлтергә) теләгән сымак бер ашыгычлык белән:

– Бу – Габдулла Тукаев була, – дип, яңа кунакны миңа танытты.

Бу фамилия миңа «Әл-гасрел-җәдит» журналында чыккан кайбер шигырьләр аркылы таныш иде. Яңа кунак, мин күрсәткән урынга утыргач, бераз вакыт миңа карап торды. Минем сөальләремә каршы берәр генә җөмләле өзек-өзек җаваплар бирде. Аның берсе бераз зәгыйфьрәк күзләренең карашындагы үткенлек һәм караган нәрсәсеннән рәнҗелгән сымаклык аз гына дикъкать иткән кешегә дә сизелерлек дәрәҗәдә куәтле иде. Минем:

– Казан яшьләрене ничек таптыңыз? – дигән сөалемә каршы ул кыска гына итеп:

– Казанга Уральски булырга ярамый инде, – мәфһүмендә (мәгънә) җавап бирде».

1907 елда солдатка каралырга дип, туган ягына кайткан Тукай Казанда яшәп калырга карар итә. Чөнки монда Сәгыйть Рәмиев, Зариф Бәшири, Галиәсгар Камал кебек шәхесләр бар, ул аларның һәркайсы янына кереп, бик үзенчәлекле итеп танышып, дөресрәге, үзен танытып чыга. 1905 елгы буржуаз инкыйлаблар белән рухланып килгән яшь шагыйрь өчен Казан яшьләре дигән алдынгы яшьләр субкультурасы буй җитмәслек биеклек булып тоела. Әмма Гыйльметдин Шәрәф истәлекләреннән күренгәнчә, озак та үтми безнең «авылдан килгән» провинциаль шагыйребез бу биеклекнең буш куык кына булуына инана:

«Казанга килеп төшү белән миңа бик тиз Казан яшьләре белән танышырга, аларның мәҗлесләрендә булырга туры килде.

Очраганда, мәҗлесләрендә сөйләнгән сүзләре: русларның яңа һәм иске мөхәррирләренең әсәрләре, алар хакында язылган тәнкыйтьләр, рус әдәбиятының тарихлары хакында була иде.

Мин боларның берсеннән дә хәбәрдар түгел. Минем бик зур нәрсә итеп, Уральскидан кадәр сөйрәп килгән Пушкинымны «күп сөйләнгән нәрсә!» дип кенә уздыралар; аның үзе тугрысында түгел, аның хакында Белинский, Писаревларның тәнкыйтьләрен генә чагыштыралар, берсе Белинскийның сүзен мәгъкулли, икенчесе Писаревны куәтли иде.

Мин, болар арасына кереп, башта тәмам югалып калдым. Эч поша, үземнең әлегә кадәр Уральскида капланып ятуыма ачына башладым. Минем бик аз нәрсәдән хәбәрдар булуым, теге бай баласының минем яңа ишетә торган рус әдәбияты тарихын су кеби эчүе; мин гади мөтәрҗим дип йөри торган фәләннең Пушкинны, тәнкыйтькә көче җиткән Белинскийларны, тәнкыйтькә куәте җитәрлек рус әдәбиятыннан хәбәрдар булуы пишкадәмнәр янында мине сахра малае итеп калдырды. Мин ул чакта үземнең кимчелегемне белеп, эчтән тынам, мондый мәсьәләләр хакында сүзне озынга җибәрмичә, башка бапларга күчә торган идем.

Айлар, еллар үтте. Әлеге яшьләрне мин бөтенләй таныдым. Алар минем алда учительдән алып кайткан шул көндәге сабакларын сөйләшеп йөргәннәр икән… Алар «аттестатчылар», берничәсе шул ук «аттестатчылар»ның мәҗлесендә йөреп, «аграрный вопрос», «эффектный» дип, урынлы-урынсыз модный сүзләр кыстырып сөйләүче ябалаклар булып чыктылар.

Казан яшьләре хакындагы минем баштагы фикерем дә бөтенләй үзгәрде. Минем баштагы алдануым алданырга кирәк урында да мине алданмаслык итеп тәрбия итеп калдырды…»

Тукай Фатих дустына да үзенең Казандагы хәленнән зарланып алырга җай таба: «Казанга килгәннән бирле соң дәрәҗәдә эшлексезләндем. Минем бүлмәмдә көне-төне буе вакытларыны кая куярга белмәгән кешеләр җыелып яталар…» – дип искә төшерә

Әмирхан. Ягъни милли мохиткә сусап, өемә кайтам дип дәртләнеп килгән шагыйрь озак та үтми Казан мохитенең ул көткәнчә дәрәҗәдә үк аның рухи ихтыяҗларына җавап бирмәвен аңлап ала.

Казанда ул туган авылы Кушлавычка багышлап – «Туган авылым» дигән, Казан артына багышлап, «Туган илемә» шигырьләрен яза.

Казандагы гомерен ул мосафир булып, күпчелек гомерен «Болгар» номерларында, җәйге дачада, «Амур»да уздыра. Мосафирханәләрдәге номерларында аның ишеге бер дә ябылмый торган була. Ул аларны беркайчан да бикләп йөрми. Казанда ул үзенә өй тапмый.

Әмма «Китмибез!» дип, үзенең Россия империясендә урыны барлыгын аяк терәп раслаган шагыйрь өчен Казан барыбер мәркәз булып кала. Әйтик, «Печән базары яхуд Яңа кисекбаш» дигән поэмасының үткен сатирага, ирониягә корылуы да шуның белән аңлатыла: ярата ул бу мохитне, аңлый, шуңа күрә сатира аша тәнкыйтьли дә. Чөнки юмор-сатира жанрының табигате шундый: ул билгеле бер коллективка, мохиткә генә аңлаешлылыгы, башкалар өчен ябык текст булуы белән аерылып тора. Казанны дөньяның теләсә кайсы пайтәхетеннән өстен куюы Мәхмүт Галәү истәлегендәге бер эпизод аша да күренә:

«Бишәр тиен түләп, «панорама» карарга кердек.

Бүлмә эче караңгы. Стена буйлап түгәрәк пыялалы якты тишекләр тезелгән. Тишектән элек биткә эссе бәреләә. Аннан зур керосин лампасы күрәсең, каршыда – зурайтылган рәсем. Бүгенгедәй хәтеремдә: рәсемнәр Неаполь һәм Венеция күренешләре иде. Йортлар, күлләр, таулар, көймәдә йөрүче кешеләр панорамада җанлы булып күренәләр. Без бүлмәне әллә ничә тапкыр әйләнеп, панораманы авыл малайларыча кабат-кабат тамаша иттек. Тышка чыккач, матур күренешләргә сокланганымны әйттем:

– Нинди бәхетле кешеләр яши икән шундый җирләрдә?

Тукай елмайды да беравыкка иреннәрен генә кыймылдатып тын барды. Аннан кинәт сорап куйды:

– Печән базары мәчетенең рәсемен күргәнең бармы?

– Бар.

– Әнә шул рәсемне Неапольгә илтеп, панорамада күрсәтсәң, синең төсле үк: «Печән базары мәчете тирәсендә нинди бәхетле кешеләр яши икән?» – дип сораучылар табылыр иде.

– Әгәр мәчет астында «күкәй салып» утыручы, узган-барганга өреп калучы Мөхәммәтҗан хафизны анда илтсәң, читлеккә ябып «зверинецта» да күрсәтерләр иде бит? — дидем.

– Һәр җирнең үз «Печән базары», һәр Печән базарының үз «Мөхәммәтҗаннары» була…»

Шулай да Габдулла Тукай вафатына бер ел кала – 1912 елдан башлап, сәяхәтләргә чыгып китә. Бу вакытта инде ул бик хәлсез, авыру була. Авыруы аны көннән-көн ныграк җиңә бара, ул үзен көч-хәл белән генә йөртә, әмма Тукай соңгы бер елында Өчиледә, ике тапкыр Уфада, Самарада, Петербургта, Троицкида булырга өлгерә. «Үлемне соңгы станца дип белгәнгә», станцияләр санын арттырып, дәрвишлектә йөрүеме, әллә җанына өй булырдай урын эзләвеме Тукайның?

Ландыш ӘБҮДӘРОВА, Луиза ЯНСУАР

УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

Уңышлы аклану

Заманында күренекле җырчы Зиннур Нурмөхәммәтов «Йолдызлар сәламе» дигән бик зур фестиваль оештырган иде. Исән булган барлык татар җырчылары катнашты әлеге тамашада. Атаклы нәфис сүз остасы Фәйзи Йосыпов та чыгыш ясап, эчүчелек турында бер шигырь сөйли. Ләкин, яше шактый булу сәбәпле, зиһене буталып, икенче чыгышында да шул ук шигырьне кабатлый. Тамашачыларның чыш-пыш килүеннән, серле итеп елмаюларыннан «эшне» аңлап алса да, тукталмый, бүленми – азаккача укып бетерә. Алкышлар тынгач, болай ди:

– Җәмәгать! Ике тапкыр укыганыма исегез китмәсен. Миңа Илһам Шакир: «Хәзер халык күп эчә бит, Фәйзи ага, янә бер сеңдереп сөйлә әле, бераз файдасы тимәсме», – дип әйткәнгә генә шулай эшләдем, ди.

Халык гөрләтеп, Фәйзи абыйга тагын бер кул чаба – бу юлы судан коры чыкканы өчен.

Хәйләсез дөнья файдасыз

Г.Камал театры артистлары Сергач ягында йөри. Бер мәлне билет сатучы Роберт Әбелмәмбәтовны бәреп очыралар – кешеләрнең акча түләп, тамаша карыйсы килми. Спектакльдә Наил Дунаев милиционер ролен башкарасы икән. Әлеге хәлне күргәч, ул костюмын кигән килеш фойега чыгып баса. (Сергачта аны ул вакытта бик танымыйлар да әле). Районнан милиция килгән, ахры, дип, халык шым була, ипләп кенә, билетлар алып, залга кереп тулалар. Милиционер образында актер сәхнәгә чыккач кына, эшне абайлап алалар... Оста уенга, тамаша тәменә керешеп киткән халык спектакльне азагына кадәр карап, шаулатып кул чаба.

«Түбә»

Бер төркем артистлар төнлә «Юмор фестивале» концертыннан Казанга кайтып бара. Мамадыш юлындагы бер кафега ашарга тукталгач, боегып киткән коллегаларын дәртләндерергә теләпме, шаярыпмы, Равил Шәрәфиев спектакль «куеп ала»: тыныч кына «салып», ашап утырган халыкны сискәндереп, күзен акайтып, кафега бәреп керә дә әшәке тавыш белән:

– Крыша приехала, готовьте бабки! – дип кычкыра.

Залдагы халыкның кайберсе шыпырт-шыпырт кына чыгып сыза башлый. Читтәрәк ашап утыручы бер татар егете генә данлыклы актёрны танып ала.

– Сезмени бу, Равил абый? – дип, бик озак көлешәләр.

«Булган бит инде»

Данлыклы Илһам Шакиров Чирмешән районының Бәркәтә авылында чыгыш ясагач, тамашачылар аңардан үз авылдашлары – Г.Тукай исемендәге филармония солисты Минхамәт Гыйләҗев турында сораганнар:

– Безнең Минхамәт ничек җырлый соң, Илһам?

Олуг артист сорауга сорау беләнрәк җаваплый:

– Кайтадыр бит?

– Кайта.

– Җырлагандыр бит?

– Әйе.

– Тыңладыгызмы соң?

– Тыңладык.

– Алайса, булган бит инде!

Кем яна?

Яшел Үзән районы авылларының берсенә салкын клубка артистлар килеп төшә. Аннан-моннан гына табылган калорифер китереп куялар. Концерт башлана. Габдулла абый Рәхимкулов, гадәтенчә, алдан ук сәхнә киемнәрен киеп, калориферга терәлеп җылына башлый. Юлда арыган, өшегәнлек белән оеп китә. Бераздан төтен һәм көек исе чыга башлый:

– Әй, алё? Кем яна? – ди җырчы.

Ипләбрәк караса, үзенең кримплен чалбар балагына ут капкан икән. Шулчак аны конферансье Илдус Сафин игълан итеп куя. Габдулла абыйга янган балагын каккалый-суккалый сәхнәгә чыгып китүдән башка чара калмый... Кайдадыр утырган хәлдә, кайдадыр ян беләнрәк басып, янган балакны каплап-томалап дигәндәй җырлап керә.

Юк өчен борчылу

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең лекторы, музыка белгече Фатыйма Вәлиева гастроль вакытында Сара Садыйкова һәм Нәфисә Василовалар белән бер фатирга керә. Тик, гөнаһ шомлыгы, Фатыйма ханым йоклаганда ару гына гырлый икән. Кыскасы, тегеләр төн буе йокы күрми.

Иртән Фатыйма ханым киерелеп-иркәләнеп уянганда, композитор белән җырчы ханымнар утырып тора икән.

– Хәерле иртә, кызлар!

– Ух... – дип, тегеләр төксе генә икенче якка борылып утыра.

– Йоклый алдыгызмы соң?

– Йокларсың монда... – ди Нәфисә кәефсез генә.

– Нишләп?

– Төне буе трактор йөрде...

– И кызлар, урамдагы трактор тавышын тыңлап, йокламый яталар, димени?!

Җырлавыңны болай да беләләр

Күренекле җырчы Флёра Сөләйманова филармониянең лекториенда эшләгән дәвердә була бу хәл. Наҗия Теркулова кебек җырчыларга музыканттан тыш, сүз остасы Әзәл Яһүдинны да беркеткәннәр икән. Ә Флёра апага яңа гына консерватория тәмамлаган баянчы Азат Хәлимовны биргәннәр дә – вәссәлам. Шуңа күрә районнар буйлап йөргәндә, Флёра апага концертны үзенә үк алып барырга да туры килә. Ул ара-тирә сөйләп тә алгалый.

– Бик озак сөйли бу дип, миңа үпкәләмә инде, Азат энем, яме? – ди ул берсендә сәхнәдәшенә.

– И Флёра апа, сез сөйләгез, сөйлә! Җырлаганыгызны болай да беләләр. Сез күбрәк сөйләгез! – дип куйган ди музыкант егет.

Үз балчыгың үзеңә

Усман Әлмиев иҗаты гөрләгән чакны Түбән Новгород өлкәсенең Сергач районындагы бер авылда җырлый икән. Авыл кешеләре бит инде классик юнәлештәге, опера фасонындагы әсәрләрне, йомшак итеп әйткәндә, өнәп бетерми. Ул як тамашачысы тәкәллеф саклау ягыннан да бик егылып төшә торганнардан түгел. Берсе алкышлар вакытында хәтта артистның аяк астына балчык та тондыра! Халык тына, нәрсә булыр икән хәзер дип сагаеп кала. Усман ага да югалып калмый. Балчыкны иелеп ала да очып килгән якка чүреп җибәрә:

– Мә, үз балчыгың үзеңә!!! – дип тә өсти.

Шуннан тамашачы җиңел сулап куя. Авыр хәлдән җиңел котылган җырчы да яңа дәрт белән концертны дәвам иттерә. Шул көннән алып, бу як халкы өчен Усман Әлмиев үз кешегә әйләнә.

Һәркайда – Әхмәтовлар

2006 елның 8 декабрендә Рәшит Ваһапов фестиваленең йомгаклау концертына Казакъстаннан дөньякүләм танылган опера җырчысы Бибигөл Түләгәнованы чакыралар. Фестивальне оештыру комитеты рәисе Рифат Фәттахов олуг ханымның кызы Мәрьямгөл Түләгәнова белән сөйләшү алып бара, Казанга килергә кыстый. Ниһаять, озак сөйләшүләрдән соң, Мәрьямгөл ханым ризалаша:

– Бибигөл Әхмәтовна риза. Үзегез дә Әхмәтович икән бит. Ярар. Карагыз әле, Рифат әфәнде, ә концертмейстер кем булыр икән соң?

Рифат Фәттахов, тантаналы-вәкарьле тавыш белән трубкага болай ди:

– Концертмейстер – Татарстанның атказанаган сәнгать эшлеклесе Тәлгат Әхмәтов!

– И-и-и! Тагын Әхмәтов! Болай булгач, барабыз да барабыз инде!

Таяк кем кулында?

2005 нче елның 10 апрелендә Рәшит Ваһапов фестиваленең чираттагы концерты Мәскәүдә узды. Бик күп сәнгатькәрләр, шул исәптән «Казан» мили-мәдәни үзәге артистлары, Мәскәүнең татар җәмәгатьчелеге катнашты, галәмәт яхшы үтте. Мәскәүләр дә җавапсыз калмады – Әсәдуллаев йортына алып барып, банкет – хәләл мәҗлес үткәреп, безне сыйларга булдылар.

Бардык, кунак булдык... Инде кайтыр юлга кузгалырга урамда автобусларга төялешәбез. Бер чатта Россия Мөфтиләр шурасында эшләүче Ягъфәр хәзрәт Фәйзрахманов «Казан нуры» оркестры җитәкчесе-дирижёр Рәсим Ильясовны «вәгазьли». Сөйләшүдән аңлаганымча, оркестрдагы музыкантларга урын җитмәгәнме, тиешле урынга утырмаганнармы, хәзрәт шул уңайдан дирижёрга дәгъва белдерә булса кирәк:

– Артистларың сине тыңларга тиеш!

Рәсим, зыялы кеше буларак, җаваплылыкны өстеннән төшермәкче:

– Мин башлык түгел бит, миннән башка да монда өч-дүрт администратор бар! Мин бу концертта музыкант кына...

– Юк-юк. Алай димә! Синең кулда – таяк бар бит!

Мең елга бер

Мәскәү 2005 елның Сабан туена әзерләнә. Берничә көннән Россия башкаласы милли бәйрәмне гөрләтергә җыена, режиссёр Әлфия Кәримова соңгы штрихларны куя: барлау, тикшерү, кабатлаулар, мәйданны сынау эшләре бара.

Татарстанның атказанган артисты, җырчы Роза Хәбибуллина Мәскәүдә яши. Ул гадәттәгечә, режиссёрны үз борчулары белән өтәли:

– Мәскәү Сабан туенда мәскәүләргә ничу делать, концерт өчен дә әз вакыт калдырасыз...

Илдар Кыямов парламентёр сыман аны юатырга тели:

– И Роза ханым, Казанның 1000 еллыгында безнең җырчыларны да кайсын – дачасына, кайсын авылына кысрыкладылар. Казан бәйрәме казанлылар өчен түгел дип үпкәләделәр дә әле...

– Казанда ичмаса мең елга бер генә бит ул. Ә Мәскәүдә ел саен шул хәл!

Театрның файдасы

Г.Камал театры Гаяз Исхакыйның «Курчак туе» драмасын сәхнәләштерде. 2009 елның 3 ноябре көнне спектакльне журналистлар һәм тәнкыйтьчеләр өчен күрсәттеләр. Урта рәттә утыручы Римзил Вәлиевнең ерак сәфәрдән кайткан көне булгандыр, күрәсең, (ул чакта «Азатлык» радиосының Казан бүлекчәсе рәисе) беренче бүлекнең уртасында җиңелчә генә оеп китә.

Тәнәфестә тамашачыларга чәй эчү каралган. Шунда ук беренче тәэсирләр турында фикер алышулар да башлана.

– Римзил абый йоклап китте, аңа ошамады, ахры, – ди бер журналист. Фикер алышуга драматург Туфан Миңнуллин кушыла:

– Сез журналистлар һаман театрны сүгәсез, гел тәнкыйтьләп язасыз. Менә бер файдалы ягы бар икән: эштән арып, хәлең беткәндә, хет утырган килеш йоклап чыгарга булса да ярый икән бит театр дигәнең...

Остаз фатихасы

Салават Фәтхетдиновның шәкертләре күп. Шулардан берсе – Рифат Зарипов үсеп, концертант сыйфатында сәхнәгә мөстәкыйль рәвештә чыгарга уйлый.

– Салават Зәкиевич, сез миңа хәер-фатиха бирегез инде! – ди ул.

Шук телле артист шәкертенә карап-карап тора да болай ди:

– Фатихамны бирәм, энекәш, хәерен халыктан алырсың инде...

Ышык тапкан

Җәйнең эссе көнендә Чаллы шәһәрендә Фән Вәлиәхмәтов артыннан һич калмыйча бер малай ияреп йөри икән. Җырчы аптырашка кала: «Минем бала дисәм, гөнаһ кылганым да юк инде. Минеке булырга тиеш түгел, – дип уйлап куя ул. – Әллә җырларымны ярата микән?» – дигән икенче уй да йөгереп үтә. Шактый гына баргач, ул артына борылып:

– Энекәш, нигә арттан тагылып йөрисең? Әллә минем җырлавымны яратасыңмы? – дип сорый.

– Абый, көн бик кызу бит, ышыкта йөрисе килә, ә синең күләгәң зу-ур! – дип җавап бирә малай.

Илдар КЫЯМОВ *әзерләде.*

Редакциядән: *Бу айда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, «Татарстан–Яңа гасыр» телеканалының дикторы, нәфис сүз остасы, җырчы, шагыйрь, журналист, редакциянең дусты Илдар Кыямов үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез!*

Ictimaği-mədəni tormışıbızdan

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ КОЛЛЕГИЯСЕ УТЫРЫШЫ

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы үзенең ел йомгакларына багышланган коллегия утырышын Чаллыда Аяз Гыйләҗев исемендәге Татар дәүләт драма театры бинасында уздырды. Зур җыенны монда уздыруның хикмәте шунда: Чаллы театры бинасының ачылышы – 2020 елның иң зур мәдәни казанышларының берсе. ТР мәдәният министры Ирада Әюпованың чыгышында әйтелгәнчә, былтыр Бөек Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан 3000ләп мәдәни чара үткәрелгән, Гази Заһитов образында совет солдатына һәйкәл куелган. 2020 елда шулай ук егермеләп мәдәният йорты салынган. ТР Милли китапханәсе яңа бинага күченгән. «Җиде көндә кино» проекты, «Алтын Казан» мюзиклы, «Үзгәреш җиле» фестиваленең Нью-Йоркта узуы, «Шүрәле» балетының (Фәрит Яруллин) Mezzo телеканалыннан күрсәтелүе, «Угол» иҗат лабораториясенең һәм Әлмәт театрының «Алтын битлек» номинанты булуы – узган елның мәдәни вакыйгалары. Утырышта ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты һәм чыгыш ясады. Ул Мәдәният министрлыгының эшенә уңай бәя бирде, быел РФ Дәүләт Думасына сайлаулар уңаеннан активлыкны арттырырга, иҗат берлекләре белән эшне тагын да җанландырырга чакырды. Спикер шулай ук бер төркем мәдәният вәкилләренә Дәүләт бүләкләрен тапшырды. Бүләкләнүчеләр арасында язучы Рәдиф Сәгъди дә бар. Ул ТР Президенты Указы белән күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге һәм татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде. Каләмдәшебезне котлыйбыз! Әлеге чарада әдәбият темасы башкача кузгатылмады, Татарстан Язучылар берлеге эшчәнлеге турында сүз булмады диярлек. ТР Мәдәният министрлыгының ел йомгакларына багышланган чарасында РФ Дәүләт Думасы депутатлары Илдар Гыйльметдинов, Әлфия Когогина, Чаллы шәһәре мэры Наил Мәһдиев катнашты.

ТАНТАНА

Арчаның Мәдәният йортында ТР Президенты тарафыннан игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын ачу тантанасы булды. Бу чара шулай ук татар әдәбияты классигы Гомәр Бәшировның тууына 120 ел уңаеннан искә алу кичәсе дә иде. Ике чараны бергә үткәрү символик мәгънәгә ия. Арчалыларның якташ әдибе гомер буена туган телебез сагында булды, аның чисталыгын, сафлыгын кайгыртып яшәде. Тантанага килүчеләр Мәдәният йортының фойесында Арча әдәбият һәм сәнгать музее (җитәкчесе Шәфигулла Гарипов) хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән, Гомәр Бәшировның тормышы һәм иҗаты турындагы күргәзмәне карадылар. Икенче катта районның балалар бакчаларындагы милли почмаклар белән таныштылар.

Бәйрәмдә Арча муниципаль районы башлыгы Илшат Нуриев, ТР Дәүләт Советының икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе Лотфулла Шәфигуллин чыгыш ясады. Тантанага якташ язучылар да чакырылган иде. Шагыйрь, галим Рифат Җамал, прозаик, галимә Гүзәл Әдһәм, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, аның урынбасары Вакыйф Нуриев, шушы районда яшәп иҗат итүче каләм иясе Зиннур Тимергалиев арчалыларны бәйрәм белән котлады, Гомәр Бәширов турында истәлекләре, әсәрләре турында уй-фикерләре белән уртаклаштылар. Чыгышлар Арчаның үзешчән сәнгать осталары, җырчылары, биючеләре, күршеләре Кукмарадан – мари, Балтач районы Көшкетбаш авылыннан удмурт җыр һәм бию ансамбльләре чыгышлары белән үрелеп барды.

ШӘЙХИ МАННУР ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Мамадышта шагыйрь, прозаик Шәйхи Маннурның тууына 116 ел тулу уңаеннан искә алу чаралары үткәрелде. Бәйрәмдә катнашучылар әдипнең шәһәр үзәгендәге һәйкәленә чәчәкләр салды, шушында ук митинг булды. Анда Шәйхи Маннур исемендәге премия лауреатлары игълан ителде. Быел бу олы бүләккә язучы-прозаик Камил Кәримов ия булды. Күптән түгел генә 70 яшен, иҗатына 40 ел тулуны билгеләп үткән әдип бу премиягә 35 ел элек тәкъдим ителгән иде. Әмма оештыру мәсьәләсендәге кайбер сәбәпләр аркасында бу бүләкне алмый калды. Тагын бер премия Мамадышта туган, Әл-Фәрит ибн Габделбарый тәхәллүсе белән туган авылы тарихын язган Фәрит Хисмәтовка бирелде.

Искә алу чаралары Ш.Маннурның туган авылы Тулбайда дәвам итте. Монда кайткан кунаклар әдипнең каберенә чәчәкләр салды, аның рухына дога багышладылар. Язучы үзе салдырган китапханәдә (хәзер музей-китапханә) булдылар. Монда мәктәп укучылары Шәйхи Маннурның шигырьләрен укыды. Искә алу чараларында язучылар Зиннур Мансуров, Камил Кәримов, Рафаил Газизов, Марат Закир, Вәрис Гали, Амур Фәлахов, Мансур Сафин, Рәкит Аллабирде, җырчы Миңгол Галиев һ.б. катнашты.

ЮБИЛЕЙЛАР

Азнакай төбәгендә Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, шагыйрь, Һади Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты Илдус Гыйләҗевнең тууына 75 ел тулуга багышланган искә алу чаралары булып узды. Әдипнең туган авылы Туйкәдәге мемориаль тактасына чәчәкләр салынды, кабере янында аның рухына дога багышланды. Искә алу чаралары Илдус Гыйләҗевнең яңа чыккан «Яшәү – сөю» китабын тәкъдим итүгә багышланган тантаналы кичә белән тәмамланды. Аны Азнакай муниципаль районы башлыгы Марсель Шәйдуллин ачты. Кичәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, язучылар Марсель Галиев, Фоат Садриев, Факил Сафин, Рифкать Шаһиев, Нур Әхмәдиев һ.б. катнашты.

***

Арчадагы «Казан арты» тарих-этнография музеенда Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь, галим, мөгаллим, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты Хәнәфи Бәдигыйнең тууына 80 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе булды. Анда әле күптән түгел генә гүр иясе булган Габделбәр улы Канәфи рухына дога багышланды. «Казан арты» тарих-этнография музее җитәкчесе урынбасары Шәфигулла Гарипов язучының күпкырлы иҗат эшчәнлеге турында сөйләде. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә Йолдыз (Йолдыз Шәрәпова), Казан төзелеш-архитектура университеты укытучысы, электрон-хисаплау җиһазлары лабораториясе мөдире, әйдәп баручы инженер, Бәдигыйнең якташы Фәрит Хуҗин, мөгаллимнәр, китапханәчеләр, Хәнәфи аганың авылдашлары, туганнары үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар. Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте студентлары шагыйрьнең шигырьләрен укыды, җырларын җырлады. Хәнәфи Бәдигыйнең пләмәше Альмира Зәйнуллина «Казан арты» тарих-этнография музее җитәкчесе Гөлназ Камаловага туганының китапларын, шәхси әйберләрен тапшырды. Кичәне Арчадагы «Әлифба» музее җитәкчесе Дамир Таҗиев алып барды.

ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе утырышы булды. Аны берлек рәисе Данил Салихов алып барды. Утырышта Ләбиб Лерон, Факил Сафин 2021 елда Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителде. Идарә әгъзалары шулай ук әдәби премияләргә дә кандидатларны расладылар. Соңгы елларда басылып чыккан китаплары өчен Равил Рахмани – Гаяз Исхакый, Вакыйф Нуриев – Фатих Хөсни, Халисә Мөдәррисова – Һади Такташ, Әнвәр Шәрипов – Җамал Вәлиди, Булат Сәлахов – Туфан Миңнуллин, Азалия Бадюгина Максим Горький исемендәге әдәби премияләргә тәкъдим ителде.

Утырышта Натан Солодухо, Олеся Феоктистова, Гөлчирә Нәҗметдинова Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде.

2020 елның 27 декабрендә 72 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, тәрҗемәче **Наилә Фәрид кызы Краева** вафат булды.

Мәрхүмәнең җәсәде Казандагы Яңа Бистә зиратына җирләнде.

2021 елның 1 гыйнварында 73 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, прозаик, шагыйрь, драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Фатих Хөсни исемендәге әдәби премия лауреаты, Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале иясе **Габделәхәт Габдрахман улы Гаффаров (Әхәт Гаффар)** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Казандагы «Курган» зиратына җирләнде.

Сәхифәне **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: повесть М. КАБИРОВА «Исцеление», кинороман Р.БАТУЛЛЫ «Великий мор», роман Р. ШАЙДУЛЛИНОЙ-МУРАТ «Воспоминания старой черёмухи»; стихи М. ДЖАЛИЛЯ, Л.ЛЕРОНА, М.АХМЕТЗЯНОВА, Н.ГАНИЕВА.
Литературный конкурс «Ах, милей родной народ!»:
рассказ Ш.ЗИГАНГИРОВОЙ «Калитка невесты».
«Бесценные голоса»: посвящается 115-летию М.Джалиля и 75-летию Р.Ягъфарова. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.
«Литературная критика»: статья С.ХАФИЗОВА.
«Искусство»: интервью А.ИМАМИЕВОЙ с художником А.ИВАНОВЫМ.
«Перепись населения- 2021»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.
«Творчество читателей»: стихи Р.САФИНА
«К 135-летию Габдуллы Тукая»: Л.АБУДАРОВА, Л.ЯНСУАР. Штрихи к портрету Тукая.
«Страницы юмора» подготовил И.КИЯМОВ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Театр Камала (г. Казань), фото И.Мухамедиярова; писатель, журналист Рахман Шафигуллин.

IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: story by M.Kabirov «Healing», cinematic novel by R.Batulla «The Great Pestilence», novel by R.Shaidullina-Murat «Memories of the old bird cherry»; poems by M.Jalil, L.Leron, M.Akhmetzyanov, N.Ganiev.
Literary contest «Ah, dearest native people!»: story by Sh.Zigangirova «Bride's gate».
«Priceless voices»: dedicated to the 115th anniversary of M.Jalil and the 75th anniversary of R.Yagfarov.
The column is led by N.Akmal.
«Literary criticism»: article by S.Hafizov.
«Art»: interview by A.Imamieva with the artist A.Ivanov.
«Population Census-2021»: article by I.Zagidullin.
«Readers' creativity»: poetry of R.Safin.
«To the 135th anniversary of Gabdulla Tukay»: L.Abudarova, L.Yansuar. A few strokes to the portrait of Tukay.
«Pages of humor» prepared by I.Kiyamov.
From the photo archive of the magazine.
Diary of social and cultural life.
On our covers: Kamal Theater (Kazan), poet Rahman Shafigullin

---

Тышлыктагы сурәтләр

Тышлыкның беренче битендә: Камал театры. Казан.
И.Мөхәмәдияров фотосы.

Тышлыкның дүртенче битендә: язучы, журналист Рахман Шәфигуллин (Казан).